ISSN 0206–4189
Индекс 73210

12+

# КАЗАН УТЛАРЫ

1.2014



# 2014 — ТАТАРСТАНДА МӘДӘНИЯТ ЕЛЫ



# Казан утлары
# Qazan utlari

2014

1

(1095)

*ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:*
*«ТАТМЕДИА»*
*ачык акционерлык җәмгыяте*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Илфак Мирза улы**
**Ибраһимов**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Нурия Беломоина**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фаттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Марат Закир, Әлфәт Закирҗанов, Камил Кәримов, Вакыйф Нуриев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир — 562-10-62.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге — 222-09-83 өст. 1612.*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80.*

**Факс** — (843) *222-09-83 өст. 1612.*

**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Яңа үрләр яулыйк! ....5

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Рәниф ШӘРИПОВ. Биш алма. *Поэма.* ....6
Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА. *Хикәяләр.* ....11
Сания ӘХМӘТҖАНОВА. Арча поезды. *Шигъри цикл.* ....29
Хәким ГАЛИДӘН. Патша солдаты Әхмәтнәсир. *Роман.* ....37
Фарис ФӘСХИ. Җанны пакьли торган яктылык. *Шигырьләр.* ....76
Рафаил ГАЗИЗ. Тәрәзәләр. *Бәян.* ....80

**МИЛЛИ ИДЕЯ**

Тукайча татар кодексы. (*Зиннур Мансуров әзерләде*). ....127

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Айдар ХӘЛИМ. «Йөрәк каным ага гүя тәнем буйлап...» *(Салисә Гәрәеваның иҗатына бер караш)*. ....142
Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. Хак сүз өчен кабат кайткандыр *(Факил Сафин иҗатына бер караш)*. ....148

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ....156
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ....159

Клара БУЛАТОВА. Таш тәтиләр турында баллада. *(Рафаил Төхфәтуллинның тууына 90 ел)*....163

**ПЕЧӘН БАЗАРЫ**

АМАНУЛЛА. Бухгалтер гыйшкы. *Шигырь.* ....165

**АК ҖИЛКӘН**

Хисаметдин ИСМӘГЫЙЛЕВ. Ачкыч. ....167
Алсу СӘЛАХОВА. Сөйкемле кыш. ....168
Факил САФИН. Тулган ай. *Бәян.* ....169
Балачак – үсмерчак вакытында язылган хатлар. *Мәхмүт Хәсәен белән Рафаил Төхфәтуллин хатлары.* ....175

*Камилханә*

Гүзәл ФАРСЫЕВА. «Өченче класслы» кияү. *Хикәя.* ....179
Камил КӘРИМОВ. Гүзәллекнең чиге юк. ....180
Альберт ХӘСӘНОВ. Табигать турында парчалар. ....182

**ФИКЕР**

Рәфикъ ЮНЫС. Җыр өмәсе үткәрик әле! ....185

«Казан утлары» архивыннан. ....154
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

Р.ФАЙЗУЛЛИН. «Завоевать новые высоты!»
«Проза и поэзия»: роман Х.ГАЛИДАНА «Царский солдат Ахметнасир», повесть Р.ГАЗИЗОВА «Окна», рассказы А.АХМЕТГАЛИЕВОЙ; поэма Р.ШАРИПОВА; стихи С.АХМЕТЗЯНОВОЙ, Ф.ФАСХИ; баллада К.БУЛАТОВОЙ.
«Национальная идея»: Татарский кодекс по Тукаю. Подготовил З.МАНСУРОВ.
«Литературная критика»: статья А.ХАЛИМА, посвященная творчеству С.Гараевой; статья Р.ШАРАФИЕВА о творчестве Ф.Сафина.
«Наука»: Ф.ГАРИПОВА. «История наших деревень».
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Сенной базар»: АМАНУЛЛА. «Любовь бухгалтера».
«Белый парус»: повесть Ф.САФИНА; рассказики Х.ИСМАГИЛОВА, А.ХАСАНОВА; рассказ Г.ФАРСИЕВОЙ с предисловием К.КАРИМОВА; переписка писателей М.Хусаинова с Р.Тухватуллиным в школьные годы; стихотворение А.САЛАХОВОЙ.
«Мнение»: Р.ЮНУС. «Проведем-ка субботник песни».
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Зима»; портрет поэта Р.ФАЙЗУЛЛИНА. Работа Э.Зарипова.

# IN THIS ISSUE:

R.FAYZULLIN. «Gaining new heights!»
«Prose and poetry»: novel by H.GALIDAN «Royal soldier Ahmetnasir», story by R.GAZIZOV «Windows», stories by A.AHMETGALIEVA, poems by R.SHARIPOV, S.AHMETZYANOVA , F.FASKHI; ballad by K.BULATOVA.
Tatar code after Tukay. Prepared by Z.MANSUROV.
«Literary criticism»: article by A.HALIM devoted to creativity of S.Garaeva; article by R.SHARAFIEV about creativity of F.Safin.
«Science»: F.GARIPOVA. «History of our villages».
Pages from «Tatar Encyclopedia».
«Hay market»: AMANULLA. «Love of an accountant».
«White Sail» novella by F.SAFIN; tales by H.ISMAGILOV, A.HASANOV; story by G.FARSIEVA with foreword by K.KARIMOV;
correspondence of writers M.Hasanov with R.Tuhvatullin in school years;
poem by A.SALAHOVA.
«Opinion»: R.YUNUS. «Let's carry out a song feast».
Diary of social-cultural life.
On our covers: «Winter»; portrait of the poet R.FAYZULLIN. Work by E.Zaripov.

*The magazine edits monthly*

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция жавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә жыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 30.12.2013, график буенча 30.12.2013.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-2839. Тираж 3107.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААЖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2014 ел.

# ЯҢА ҮРЛӘР ЯУЛЫЙК!

«Ни генә дә җиккесез! Чаба Заман — житкесез!..» Әйе, Вакыт томырылып чаба... Әле күптән түгел генә яңа гасырны каршылаган идек, инде уңдүртенче елы да килеп житте! Кеше акылы казанышларына күбебез ияреп тә житә алмый бугай. Вакыт «кызуырак әйләнгән» саен, Җир-галәм үзе дә Кешенең «учына сыя», дәресрәге, ихтыярына буйсынып калды шикелле. Кешелек үз-үзен харап итәрлек дәрәҗәдә «көчле!» хәзер.

Нинди генә өлкәдә эшләмәсең, гаме булган һәр кешене Замана бик нык уйландыра бүген. Иҗат кешеләрен бигрәк тә. **Заман таләпләренә лаек дәрәҗәгә ничек ирешергә?** Язучы икәнсең, **нәрсә турында, ничек язарга?** «Кеше җаны өчен көрәш барган» чорда **фикердәш укучыларыңны ничек табарга, җыярга? Җәмгыятьнең рухи үсешенә үзеңнән ничек өлеш кертергә?** «Ничек?»ләр күп. Җавап табу гына җиңел түгел. Чишелеш өчен, әлбәттә, иң әүвәл максатны төгәл ачыклау зарур. Минемчә, безнең өчен бүген иң мөһиме — **халкыбызны зыялы милләтләр рәтендә саклап калу**, ягъни, **телне, милли мәгарифне, әхлакны**, дәүләтчелегебезнең нигезе булган **Республикабызны саклау, гавәм халкының үзаңын үстерү**. Моңа ирешү өчен **тарихны белү, хезмәтне сөю, талантларны кадерләү**, киләчәкне анык күзаллап, **максатчан булу** шарт.

Язучы халкына бүгенге көндә бер дә җиңел түгел. Хәер, намуслы иҗатчыга беркайчан да җиңел булмаган. Халыкка төрле яктан мәгълүмат-информация ташкыны ишелеп төшкәндә, бигрәк тә. Өстәвенә, табигатьтәге аномалия күренешләре ешайган шикелле, иҗтимагый тормышта да сәяси катаклизм хәлләре житәрлек. Шуна күрә, үзеңдә тулы җаваплылыкны тоймыйча иҗат итәргә тырышу — мәгънәсезлек. Тотынгансың икән, максатыңны ачыклаудан тыш, иман-ышанычыңны ныгыт, көч-дәрманыңны чамала!

Язучының коралы — Сүз. Чын Сүз девальвацияләнми. Алтын Сүзнең кадере беткәне юк. Заманы-чорына карап Сүзне ташка чокыганнар, тирегә төшергәннәр, кәгазьгә басканнар. Сүз — ничә гасырлар буена, Китап рәвешендә, Кешелекнең иң бөек казанышы саналган. Нинди форматта булмасын, дөньяда барыбер Сүз калачак, Ул — мәңгелек. Ә син, язучы буларак, Аны иярли аласыңмы? Сүз хуҗасы икәнсең, әйдә, акылыңны күрсәт, матурлыкны данла, изгелек иңдер! Техник казанышлар Сүз кодрәтен күрсәтү чаралары гына. Шунысын да онытмыйк, безнең артта — меңьеллыкларга сузылган Сүз тарихы, Әдәбият тарихы. Сирәк халыкларда гына булган тарихи мирас, тарихи байлык.

Без, бүгенге журнал хезмәткәрләре, озак еллар буе үзебез белгән, аңлаган шушы хакыйкатьләргә таянып эшләргә тырыштык. «Казан утлары» — бүгенге көндә Россия күләмендә иң абруйлы журналларның берсе. Язмыш рәхмәте белән, мина бу журналда егерме биш елга якын баш мөхәррирлек вазифасын башкарырга туры килде. Бу елларда журнал минем өчен ата-анам да, балам да, иҗат йортым да булды. Журналның бөтен яшәү дәверендә чыккан мең дә туксан биш санның өч йөзгә якыны минем баш мөхәррирлек култамгам белән дөнья күрде. Бу дәвердә эш өчен зур көч салган хезмәттәшләремә чиксез рәхмәтлемен, ирешкән уңышларыбыз — уртак хезмәт нәтиҗәсе. Бу сан — хезмәт коллективының минем житәкчелектә әзерләнгән соңгы саны. Журналдагы житәкчелек дилбегәсен яңа кулларга тапшырырга вакыт житте. Алар сөекле басмабызны яңа үрләргә, яңа биеклекләргә күтәрер дип ышанасы килә. Әмма бу күчеш минем журналдан аерылуым түгел, киресенчә, алга таба да көч-сәләт житкән кадәр уртак журналыбыз үсешенә өлеш кертергә тырышачакмын.

Сүзебез башында «Вакыт томырылып чаба!» дидек. Әйе, чаба гына түгел, оча! Бүтәнчә була да алмый. Шулай да еллар, гомерләр уза дип артык офтанмыйк! Үткән елларның мәгънәсе кешеләргә күпме дәрәҗәдә игелек кылу белән бәяләнә бит! Бер-беребезне бәрәкәтле гамәлләр белән сөендерик. Хәерле Яңа Еллар булсын!

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН,**
*Татарстанның халык шагыйре.*



Рәниф
Шәрипов

# БИШ АЛМА

ПОЭМА

1

**Без китәсе идек. Машинабыз
Менә–менә инде кузгала.
Күкрәгенә кысып биш алманы,
Йөгереп килә сабый кыз бала.
Тын калдылар бу баланы күреп,
Озатырга диеп килгәннәр.
Ә сабыйның күзләрендә курку,
Өлгерәмме, юкмы дигәндәй.
Көзге шыксыз болытлы көн иде,
Җилдә үксеп яңгыр сибәли.
Без китәбез. Җил–яңгырга каршы,
Кил син, сабый, йөгер, кил әле.
Кил, курыкма, йөгер, без китәбез,
Ашыгырлык юллар калмады.
Югалтырбыз бәлки биш минут без,
Югалтмабыз, тик, биш алманы.
Күкрәгенә түгел, йөрәгенә
Кысып килгән ихлас җимеш бит.
Бу йөгереш урам буйлап түгел,
Еллар буйлап куркып килеш бит!
Рәхмәт, сабый, алмаларың өчен,
Ходай сиңа алда җай бирсен!
Алмадамы соң эш, бу дөньяда
Сәлам бирә белми кайберсе.
Без китәсе идек. Сабый кызны
Күрдек әле, ярый, иншалла!
Нигә шулай сискәндерде мине
Сабый кулындагы биш алма?..**

---

Рәниф ШӘРИПОВ (1950) – *шагыйрь, публицист; «Ян, учагым», «Мәңгелек сер», «Азатлык көне» һ.б. китаплар авторы. «Татнефть» һәм Татарстан Язучылар берлегенең С.Сөләйманова исемендәге әдәби премиясе лауреаты. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

2

Яман шәүлә йөри авыл буйлап,
Чор билгесе, заман сулышы.
«Киләчәксез авыл» коткысының
Тере авыл белән сугышы.
Мин хәтерлим әле бу мәктәпне,
Дистә-дистә анда без йөрдек.
Мәктәп тора. Ләкин, нинди файда?
Укучылар бары өч бөртек...
Нигә китә кеше туган җирдән?
Нигә бетә авыл дисезме?
Авылларның яман аты бармы?
Заманасы әллә көйсезме?
Дәвер саен яңа юлбашчылар,
Юлбашчыда яман коткы бар.
Күпме еллар күндәм авылларны
Коллар исәбендә тоттылар.
Биш алма да, биш минут та түгел
Җуйганыбыз туган авылдыр.
Кайтып-китеп йөргән безгә түгел,
Авылыма күбрәк авырдыр.
Күкрәгенә биш алмасын кысып,
Йөгереп килә сабый кыз бала.
Җилдә үксеп күзге яңгыр ява,
Ә күңелдә яра-эз кала...
Яман шәүлә йөри авыл буйлап,
Чор билгесе, кара күләгә.
Авылымның соңгы җан сулышы
Соңгы сабыйларга эләгә.

3

Бер алманы бишкә бүлә идек.
Биш алманы ничек бүләсе?
Алмаларны җиргә тәгәрәтеп,
Әкрен генә әллә үләсе...
Җимерелеп яткан каралтылар,
Үлән баскан таныш, буш юллар.
Күпме алар, сукыр тәрәзәле,
Җансыз, ямьсез, үле авыллар!
Урамнары, зиратлары белән,
Тормыш кала, күпме эш кала.
Соңгы сулышымы авылымның
Мәктәптәге шушы өч бала?
Чокыр-чакыр ватык юллар буйлап,
Яман шәүлә, бушлык кузгала.
Әле үзе белми,
Шул бушлыктан куркып,
Йөгереп килә сабый кыз бала.
Алары да китәр. Калса калыр
Ялгыз ирләр белән карт-коры.
Киленнәр дә килми авылларга,
Заманаңны шөпшә чаккыры!
Шул бер җайга керде инде авыл,
Барысына хуҗа бер түрә.
Түрәләре никтер, гел имансыз,
Дәшми генә коллар тир түгә.

Бер алманы бишкә бүлә идек.
Тук замана җитте, иншалла!
Бер генәсе татлы булгандыр бик,
Ачы хәзер никтер биш алма.

4

Кайтып җиттек без дә. Ә башкала
Ыгы-зыгы белән мәш килә.
Күз алдымнан китми бер кыз бала,
Күзләремә никтер яшь килә.
Нәрсә җитми?
Телевизор карыйм,
Тәмле ашап, җылы урында...
Экраннарда бушлык, яман шәүлә,
Ә уйларым сабый турында.
Экраннарда бушлык, хәтәр шәүлә,
Колакларда моңсыз, көйсез җыр.
Көе була торып, көйсез калган —
Өе була торып, өйсездер.
Азат тормыш инде якын кебек,
Мөмкин хәзер иркен суларга.
Тик, соң инде.
Күпме вакыт үткән,
Күпме егәр бушка югалган.
Олы юлдан читтә, үз ямендә
Гөрли иде авыл күптәнме?
Безне әле куып җитеп була,
Куып җитеп булмый үткәнне.
Күпме бала урам буйлап чаба.
Кем өлгерми, кемдер өлгерә.
Ул сабый бит, китмәгез дип,
Безне
Ташламагыз диеп йөгерә!
Калдырмагыз безне, ташламагыз!
Күзләрендә шуны күрәм мин.
Кемдер әйтер, юкны сөйләмә дип,
Ләкин, авыл җанын беләм мин!

5

Күкрәгенә биш алмасын кыскан,
Көзге җилдә ябык гәүдәсе.
Ул йөгерә, тик, артыннан куа
Замананың кара шәүләсе.
Ул шәүләдән качып булмый инде.
Бу абыйлар китә, барыбер.
Килер бер көн, озын, озак бу юл
Ике якка кинәт ярылыр.
Бер ягында аның хәтер калыр,
Бер ягында мәңге буш өйләр.
Читтә үскән баласына безне
Соңгы сабый, үскәч, бер сөйләр.
Алмаларны җиргә тәгәрәтеп,
Әкрен генә шулай үләсе.
Ләкин, ничек тере авыл җанын
Ике якка ярып бүләсе?..
Без китәбез инде. Сез каласыз.
Шулай килеп чыкты язмышлар.

Хак юлга бу бер дә охшамаган,
Нәрсәдәдер монда ялгыш бар.
Без китәсе. Шулай килеп чыкты.
Тик, күңелдә кала ярасы.
Бар дөньясы дөрес түгел кебек,
Үзгәртергә юк бит чарасы.
Шыксыз, күзгә болытлы көн иде,
Яңгыр сибә-сибә җил улый.
Көйсез-өйсез киләчәкне күреп,
Авыр гына шулай Җир сулый...

6

Без китәбез. Без яшибез ерак,
Тәмле ашап җылы урында.
Гамьсез генә яшәп булмый никтер,
Уйлыйм һаман авыл турында.
Авылдагы соңгы дусларымның
Күзләрен бер кайтып күрәм дә,
Юк булса да, гаебем бар кебек,
Үзем аңламаган күләмдә.
Сәер инде. Мин әллә кем түгел,
Көч-куәтем чикле-чамалы.
Гомер юлым чуар, ачы, кырыс,
Язмышым йөз төрле ямаулы.
Азмы читтә гомер итүчеләр,
Тәмле ашап, җылы урында.
Моңсыз-көйсез җырлар тыңлый-тыңлый,
Уйламыйча авыл турында,
Кыйбла чишмәсендә[1] Җир сулышын
Ишетми дә, күрми, белми дә.
Гаепсезләр гаеп сизгән чакта,
Гаеплеләр сизми берни дә.
Күпме авыл тын тәүфыйгы белән
Денсез чорга килеп бәрелгән.
Тик, бар иде, бар иде бит куәт,
Аралардык үлем хәленнән!
Бар иде бит, бар иде бит форсат
Сүз әйтергә авыл турында!
Никтер, кайчак, тәмле-җылы түгел
Тәмле аш та, җылы урын да...

7

Йорт аралаш түрә чыккан бездән,
Алтын куллы, тырыш, белемле,
Сүз үтәрлек куәт ияләре,
Эш кырырлык маллы, керемле.
Гаеплисем килми беркемне дә,
Барыбызның көче чамалы.
Авыл көне бер дә җиңел түгел,
Язмышы да ертык, ямаулы.
Сез кайларда хәзер, авылдашлар?
Мәктәпкә бит бергә без йөрдек!
Барлык эшегезне егып салыр
Авыл сабыйлары өч бөртек...
Читкә китеп таулар күчерәсез...
Җиңел булмагандыр язмышлар.

[1] Авылымдагы шул исемдәге чишмә

Шул ук көндә авыл үлеп бара...
Нәрсәдәдер монда ялгыш бар.
Күкрәгенә биш алмасын кыскан
Ябык кына сабый гәүдәсе.
Ул йөгерә, тик, артыннан куа
Ялгыш юлның кара шәүләсе.
Безнең авыл күпме түрә биргән –
Таза, матур, тырыш, белемле.
Ләкин читтә, читкә түгәбез бит,
Авыл биреп калган керемне!
Үлсә үлә, ләкин, биреп кала
Барыбызга зиһен, тазалык.
Үлсә үлә... Соң инде, соң...
Нишләдек без? Нәрсә карадык?

8

Килер бер көн — озын, озак бу юл
Ике якка кинәт ярылыр.
Бу ялгыш юл. Чарасы юк аның.
Килеп җитә ул көн барыбер.
Бар дөньясы дөрес түгел кебек.
Төзәтерлек юк бит чарасы.
Ерагая авыл, якынайган саен
Минем белән сабый арасы.
Ни эшләдек? Нәрсә карадык без?
Нинди олы байлык югала...
Ничек кенә җимермәделәр бит,
Тыгып алып утка, суга да.
Кайткан саен, дусларымны күреп,
Онытылып, иркен суласам,
Киткән саен, никтер, бөтенләйгә,
Бөтенләйгә инде хушлашам.
Җимерелгән нигез, әнкәм монда кала,
Күршеләрем кала, йөрәгем.
Каберем дә шунда калсын иде...
Бу васыять — соңгы теләгем.
Бәлки, файда бирер авылыма
Каберемдә торган исемем.
Бәлки, мин дә бик тиз онытылмам,
Гасырларның кагып ишеген.
Киткәндә дә, якты мизгел булып,
Күз алдымда торыр иң элек –
Урам аша, биш алмасын кысып,
Бер сабый кыз килә йөгереп.



Айгөл
Әхмәтгалиева

# ХИКӘЯЛӘР

## Кайтаваз

Каяндыр ишетелер-ишетелмәс кенә моң агыла иде. Урал тавының ташлы итәгендәге мәгърур кыяфәтле сылу каеннар шавында идеме ул, әллә инде тау күкрәген ярып, кылтык кызлар тавышы белән челтерәгән инеш агышында идеме – ничек кенә булмасын, колакны иркәләгән әлеге моң таң калырлык иде.

– И Ходай Тәгаләнең кодрәте! Җирдәге ожмахтыр бу, балалар. – Ана, машинадан төшкән шәйгә, аякларының авыртуын да онытып, тирә-яктагы илаһи матурлыкка текәлде. Үзе гомер бакый кыр-дала ягында яшәп, күккә ашкан тауларны, таш өстендә бии-бии аккан инешләрне тәүге тапкыр күргәч, сокланудан телсез калды. Яфракларын җәйге җилдә җилпәзә урынына лепердәтеп, иркәләнеп серләшә-серләшә болытларга үрләгән агачлардан карашын аермый гына, берара билен уып торды. Чал чәчләрем күренмәсен әле дигәндәй, ак яулыгын маңгаена ук төшереп, кысып бәйләде, камзулын төймәләде.

Кияве белән кызы исә җыелма өстәл белән урындыкларны җиргә куеп, табын әзерләү хәстәренә керештеләр. Аларга ни, бу якларга беренче тапкыр гына килүләре түгел шул, тау түбәсенә карап, авыз ачып тормаслар.

– Әнкәй, әйдә, тау елгасына төшеп, юынып меник тә чәйләп алырбыз. Әлләни озакламабыз, ят җирдә кем килеп чыкмас...

Ана, кызының сүзен җөпләп:

– Шулай, балам, юл кешесенең юлда булуы хәерле, – дип өстәп куйды.

– Ашыкма, иркенләп ял ит, әби, – диде кияү кеше, кечкенә өстәлгә кыяр-помидор, кыздырылган тавык, пәрәмәч ише ризык тезә-тезә. – Әле күлгә барып җиткәнче, күз күгәрер. Рәхәтләнеп аякларыңны язып ал, кузгалырга җитешербез.

Соңгы елларда ананың аяклары сызлап интектерә иде, шуңа да кияве белән кызы үзләре йөрергә яраткан тозлы күлгә алып барырга күндерде аны. Карчыкны юл ераклыгы, ару-талу куркытмады, мәчесен, тавык-чебешләрен сылтау итеп киреләнде. Янәсе, күрше-күләннең генә күз-колагы җитешмәс. Дөресен әйткәндә, балаларына артык мәшәкать тудырасы килмәгән иде, олы кешенең олыларча, яшьләрнеке яшьләрчә дигәндәй... Шулай да, ай-вайга карамыйча, тәки үзләренекен иттеләр: кияве машинаның арткы утыргычына йомшак мендәрләр түшәп, анага патшабикәләр урыны әзерләде, кызы

---

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА – *язучы; «Болытта җиләк үсә», «Синең өчен яшим» исемле китаплар авторы. ТР Язучылар берлеге әгъзасы. Чаллыда яши.*

җәһәт-җәһәт юл төенчеге хәстәрләде, йорт-кураны күршеләргә тапшырды. Төн пәрдәсен ертып, таң нурлары шәйләнә башлаган сәгатьтә юлга да кузгалдылар. «Мине кадерләгән кебек, үз балаларыгыз сезне кадерләсен» — ананың юл догасына изге теләк-фатихасы кушылды.

Ана һәм кыз гөлҗимеш куаклары белән каймаланган сукмактан җитәкләшеп су буена төштеләр. Дуамалланып, ярсып аккан елганың боздай салкын суында бит-кулларын югач, арыган тәннәренә мизгел эчендә көч, сихәт өстәлгәндәй булды, ананың ирен читендәге буразналарына якты елмаю эленде.

— И Ходайның хикмәте! — Аның соклануы, сөенүе, рәхмәте шушы сүзләргә сыйган иде.

Кызы эндәшмәде. Кайнап торган елгага карагач, авылның язгы ташуда кодрәтле дәрьяга әверелгән, җәйләрен чыпчык тезеннән генә булган нәни инеше, әнкәсенең яшь, үзенең сабый чагы күзалдына килеп, кинәт кенә күңеле нечкәрде. Кул сузымы арада гына иде ул чак, керфекләргә эленгән яшь пәрдәсен бармак очы белән тирбәтеп җибәрсәң, аермачык булып, тып итеп каршына килеп басар кебек иде...

Яр куенына язгы ташудан боз кисәкләре, чыбык-чабык, салам чүпләре сыенып калган. Авыл башындагы әлле-мәлле агач күперне, һәр елдагыча, ташу үзе белән алып киткән; аргы якка чыгыйм дисәң, үз кыюлыгыңа чытырдатып ябышырга һәм өстенә кадәр су менеп җиткән торба-басма аша тәвәккәлләргә генә кала. Кардан арчылып кына килгән бакчаның капкасы ачык калганмы, ишек алдыннан чыгып тайганмы — бүген-иртәгә бәрәнлисе олы сарыклары нинди дер могҗиза белән аръякка ук килеп чыккан иде. Хикмәт димә инде, шунда бәрәнләп тә куйган җитмәсә. Кемдер күреп, хәбәр итүгә, әнисе зур кунычлы резин итекләрен киеп, өйдән чыгып та чапты. Сабыйлыгы беләнме, кызык күрергә өметләнепме, кыз да аның артыннан иярде. Әнә аның әнисе, ашыга-кабалана инеш буена йөгерә. Шундый яшь, житез, чәчләрендә көмеш бәсләрнең эзе дә юк әле. Аръяктагы сарыкның бертуктамый ачыргаланып мәэлдәве, күз күреп иләнгән бер карышлык инешнең олы дәрьяга әйләнүе, әнкәсенең басма башында икеләнеп, чарасызлыктан кулын угалап торуы сәбәп булдымы — кызның күңеленә кинәт кенә шом йөгерде. Басма дисәң хәтере калырлык бу торбага аяк басса, әнкәсе таеп китәр дә каралып күренгән әлеге төпсез дәрья аны мәңгелеккә йотар кебек тоелды кызга. Кисәк кенә чәч төпләре тирләп чыкты, аркасына исә салкын йөгерде.

— Әнкәй! — Кызның ачы тавышы инеш буен яңгыратты. — Мин куркам, теге якка чыга күрмә!

— Бәрәне җәл бит, балам, апчыкмасак, өшеп үлә бит нарасый. Ходайга тапшырып, чыгып карыйм.

Бу ярда күзләрен чытырдатып йомган кыз секундларның, минутларның никадәр озын икәнен шул мәлдә аңлады... Әнкәсе яңа туган бәрәнне пәлтә изүенә тыгып, теге ярдан басмага атлыйм дигәндә, янә бер үлеп терелде.

Баласыннан аералар дип коты очкандыр, әлегәчә ярда арлы-бирле йөренгән сарык кинәт кенә җан-фәрман су буена атылды.

— Әй бу инәйләр... Бала дип бозлы суларга төшәргә дә әзер шул... — Әнкәсе, бәрәнне күкрәгенә кыскан килеш, көйле тавыш белән сарыкка эндәште. — Төч-төч-төч, кил әле, жанкаем, көтеп кенә тор менә шушында, сине дә чыгып алырмын. Язгы суларга төшеп әрәм буласың киләмени, бәрәненне ятим калдырып...

Малда да адәм акыллары бар диярсең: сарык бертуктамый кычкырса кычкырды, үзе басма башыннан кузгалмады.

Әнкәсендә куш йөрәк микәнни соң — башта бәрәнне чыгарып, кызның куенына сыендырды, аннан, каяндыр килгән көч белән сарыкны ябык иннәренә салып, тагын басмага аяк басты.

Әнкәсе белән ике арада, күп булса, ун-унбиш адым яткандыр. Ул араның чакрымнардан күпкә озын һәм карышлардан күпкә кыска икәнен кыз соңрак, үсә-үсә аңлаячак. Әлегә — якынаймый тилмерткән ике яр арасы. Әнкәсенең суга карамаска тырышып, аягын шуыштыра-шуыштыра ипләп кенә атлавы, жилкәдәге сарыкның тыпырчынып куюы, бу икәүне үз кочагына алырга теләгәндәй, инеш суының гөрелдәп агуы кызның котын очырды. Баягы кебек күзен йомып утырса, әнкәсе басма өстеннән юкка чыгар һәм ул шушы бәрәнне кочаклап, яр буенда гына түгел, гомумән, бөтен жиһанда берүзе калыр кебек тоелды. Кыз үз-үзен белештермичә, күзләрен шар ачып, кинәт сикереп торды да, бәрәнне жиргә яткырып, басмага таба атлады. Дөньядагы иң газиз кешесен югалтудан курку хисе өстенрәк булып чыкты — аяклары торба өстеннән бер... ике... кечкенә адым ясады.

Шул мизгелдә ул әнкәсенең куркудан күгелжем төскә кергән күзләрен күрде, аның «Кермә!» дип ыңгырашкандай тешен кысып эндәшкәнен ишетте. Басма өстеннән тасмадай шуышкан агымга иелеп карауга, башы әйләнеп киттеме — ә дигәнче карасу ташкын аны үз кочагына алды. Калганында төш белән өң буталды. Ташудан соң тынычланырга өлгермәгән инеш-дәрья йөзендә әнкәсенең жанга якын күзләре генә чагылгандай булды...

...Елганың ике яры болытларда кушыла икән. Алай дисәң, ул болытларга нигәдер аларның өй исе, өй төсе сеңгән кебек. Ул болытларда яна туган бәрәннең бөдрә йоны да чагылган кебек. Ул болытларга әнкәсенең: «Әй бу инәйләр... Бала дип бозлы суларга да төшәргә әзер шул» дип йомшак кына кабатлавы сарылган кебек... Кечкенә кызчыкның гелән дә зурларча итеп: «Әнкәем, газизкәем, кирәксә, мин дә синең өчен утка-суга керермен» дип үзалдына пышылдавы да кайтаваз булып болытлар итәгенә барып бәрелә кебек...

Соңыннан, авыл халкы бу вакыйганы «үзегез генә түгел, малларыгыз да күлмәк киеп тугандыр» дип шаяру катыш искә төшергәндә, кызның башында бер генә сорау бөтерелә иде: гажәп, ә ул сарык бәрәнләгәнче аръякка басмадан ничекләр чыкты икән?..

Менә хәзер, тау елгасының шомарып беткән ташлар өстеннән дулый-дулый акканын күзәткәндә кызның күңелендә әлеге сорау тагын баш калкытты: гажәп, ә ул сарык аръякка басмадан ничекләр чыкты икән?..

— Балам, — диде шулчак әнкәсе кызны уйларыннан бүлдереп. — Кияү аптырагандыр анда, киттеләр дә югалдылар ди торгандыр, теркелдик булмаса.

— Әнкәй, сукмакка чыгыйк та, таудан аркага кочтырып менгерермен, аякларына көч килмәсен.

— Инде болай да бөтен авыл халкы «кызың белән киявең кулларында гына күтәреп йөртә» дип аһ итеп сөйли, балам. — Ананың тавышы калтырап китте, ул, бәхеттән мөлдерәмә күзләре ташып түгелә күрмәсен дигәндәй, башын югары күтәреп, бөдрә болытларга текәлде. Шул болытларга түбәләре тигән мәгърур таулар, әйтерсең, ана горурлыгы алдында баш иярга теләде — кинәт кенә чүгеп, тәбәнәкләнеп куйды. Әле генә зекер әйтеп, шаулашып утырган агач яфраклары да, «бәхеттән елыйлар микәнни» дип аптырап, бермәлгә тын калды. Хәтта тау елгасының гөрелтесе дә шул мизгелдә тукталгандай тоелды. Гүя барысы да каяндыр ишетелер-ишетелмәс кенә булып агылган, колакны иркәләгән моңга, жил канатында тибрәлгән кайтавазга мөкиббән иде.

## Коткаручы

Керфек тибрәтеп язга бакса да, кышның алыш-бирешсез генә жиңелергә исәбе юк иде бугай. Югыйсә, кичтән аяк асты тәмам жепшекләнеп, һавага яз исе таралган, адәм балаларының күңелендә дә ниндидер иләслек, янаруга, дөньяның уянуына, яшәрүенә өмет пәйда булган иде. Ә бүген кышның мәңге

китмәскә килгәндәй кылануын гына күр әле: авыл урамы атлап түгел, шуып йөрмәлегә әйләнгән; кул-аягыңны сындырасың, бармак очларыңны, борыныңны туңдырасың килмәсә, өйдә генә утыруың хәерле. Хәер, күпләр болай да, башын комга яшергән тәвә кошыдай, тирә-яктагы буранның бәла-казасыз үтүен көтеп, тыныч кына бикләнеп утырырга байтактан күнекте инде. Үз биләмәсенә генә зыян килә күрмәсен, калганнар нигә шунда чукынып китми...

— Ком сибештереп керәм әле. Бала-чаганың таеп егылуы бар. – Ибраһим, бер кулы белән иске куфәйкәсен төймәләгән, икенчесе белән киштәдән колакчынлы бүреген эзләп маташкан жиреннән хатынына эндәште.

Рәйханә жан кебек күргән гөлләренә олы якта су сибә иде, бусага аша гына кырку жөмләләрен ыргытты:

— Синең шул булыр инде. Ишегалдына таратсаң житәр. Кирәк кеше үзенекен үзе белер әле. Тавыкларга дигән комны кыш буе авыл урамына ташып бетердең бит инде!

— Күп сөйләнмә! – Ибраһим чал куна башлаган кашын мәзәк сикертеп, жавап кайтарырга өлгермәде, Рәйханә, тәрәзәдән урамга күз ташлагач, итәгенә ут капкандай чабулап, бу якка йөгереп чыкты.

— Тәки тынасылары юк! Тегеләр бугай. Трактор хәтле машина белән килеп туктадылар. Ибраһим дим, базга төшәсеңме әллә? Шәһәргә киткән иде диярмен.

Карты бераз икеләнеп торды да, кулын селтәп ишеккә юнәлде.

— Без күрәсен кеше күрмәс, гомер буе качып йөрер хәлем юк. Капканы ачып керәм.

Ул чыгып киткәч, Рәйханә авыз эченнән белгәннәрен укый-укый тәрәзәгә капланды. Жиденче дистәсен ваклап килсә дә, карты егетләрчә төз гәүдәле, һаман да житез хәрәкәтле, шулай да әллә бозлавык булганга, әллә борчулы уйлар бимазалаганга, бу юлы ул аягындагы чүчинкәсен шуыштырып кына атлый иде. Тимер бикне ычкындырырга ашыкмады бугай, бертын башын иеп урынында каккан казыктай торды, аннан соң гына чакырылмаган кунакларны каршыларга дип капка төбенә чыгып басты. Күп тә үтмәде, алып гәүдәле ир заты белән аның әшнәләрчә чөкердәшеп кереп килгәне күренде. Артларыннан яланбашлы, алтын чәч бөдрәләре тун якасына сибелгән урта яшьләрдәге бер хатын да атлый иде. Рәйханәнең күзе хатынның без үкчәле итегенә тукталды: «Әтекәем, монысы ниндәй көяз курчак тагын?» Биек булып үскән яраннарын уртагарак шуыштырды да йөзен шулар арасына яшерә төшеп, янә ишегалдына күз ташлады. Ниндидер кызыкка тап булгандай, өчесе дә йөзләрен балкытып елмаялар, алып гәүдә вакыт-вакыт Ибраһим өстендәге алама куфәйкәнең жилкәсеннән кагып ала, тегесе нәрсәнедер раслаган шикелле, бик канәгать кыяфәттә ияк селкеп тора. «Ибрайны әйтәм. Ата каз урынына муенын суза-суза артына борыла, иблис токымы. Сары маржа күрдем дигәч тә». Рәйханә, читкә тайпылып, ишек катындагы олы көзгедән үз кыяфәтенә карап алды. Аның өстендә тутырган тавык кебек гәүдәсен, ташып торган күкрәкләрен тагын да мулрак күрсәтүче аркылы сызыклы яшел халат иде, жәһәт кыланып, йокы бүлмәсенә кереп тә китте, ә дигәнче халатын изүе чигүле зәңгәр күлмәгенә алыштырып та чыкты. Башындагы әби яулыгы да шкаф киштәсенә очып, кынага буялган чәчләр өстенә тегендә-монда ашка барганда гына киелә торган кечкенә калфаклы өрфия яулык менеп кунаклады. Ибраһим гөр-гөр килеп кунакларны өйгә әйдәгәндә, Рәйханә хәтта бит очларына кершән тигерергә дә өлгергән иде.

— Карчык! Карчык дим! Рәйханә!

Яшең алтмышның теге ягына чыкса да, кемнең генә карчыкка әйләнәсе килсен – Рәйханә тешен кысып баш чайкады. «Кеше алдында булса да шулай димәсә...» Үзе, йөзенә май кояшы яктылыгы кундырып, кечкенә якка чыкты.

— Әллә үзе базга төшеп качканмы дип торам. — Ибраһим, Рәйханәгә ишарәләп, аңлатма бирүне кирәк тапты. — Ну, апай, курыктык, дөресен әйтим! Баштарак милиция-мазары, аннан кинадагы кебек здаравай жегетләре капка каккач сон... Мин әйтәм, берәр мафиузи булгандыр, мине дә винават итеп калдырырлар, суд юлында йөртерләр...

Алып гәүдәле ир ачык елмаеп, Рәйханә белән исәнләште, елтыр ботинкасын салгач, ике куллап күреште дә:

— Менә, коткаручымны үз күзем белән күрим дип киләсе иттем. Хатыным Гөлсинә белән парлап килдек әле.

Рәйханәнең сары маржа дигәне дә якты йөз белән татарча исәнләште, алай гына да түгел, «и-и апа жаным» дип, иңнәреннән үк кочып алды.

Коткаручым дигәч үк аңлаган иде Рәйханә: чакырылмаган кунак әле Яңа ел алдыннан ук Ибраһим тарган вакыйганың герое иде. Исән калган икән, рәхмәт төшкере. Болай булгач, һәр ишек какканнан куркып яшәүләренә дә чик куелыр, мөгаен.

— Әй, мактап кына йөрисез икән, газ мичена бәрәңге шәңгәсе тыкканыем. Әйдәгез, әйдә, чишенегез дә түргә үтегез әле, — дип күгәрчен урынына гөрли-гөрли, Рәйханә кунакларны олы якка дәште. — Ни, атыңны кем дисәм дә...

— Мансур булам, Рәйханә апа. Хәзер, айн момент. — Мансур түш кесәсеннән телефонын алып, кемгәдер «әйберләрне өйгә керт» дип әмер бирде дә башта хатынының тунын салдырды, аннан үзенең затлы курткасын салып, ишек катындагы шкафка элде. Рәйханә исә Гөлсинәнең зифа буй-сынына күз ташлап, эченнән генә көрсенеп куйды. Кеше хатыннары нәрсә ашап кына яши икән соң ул, менә хикмәт? Югыйсә, яшь-җилкенчәк түгеллеге дә күренеп тора, кырыктан өстәдер. Булмады инде, Рәйханә үзе беренче баласын тапканнан соң ук чүпрә салган камыр кук кабара башлаган иде, күпме кызыкса да, талчыбыктай нәзек билле чагы әйләнеп кайта алмады, хәерле булсын. Югыйсә, авыл җирендә хатын-кызның артына утырып тора алганы бармы? Иртәдән кичкә хәтле аягөсте әйләнәсен-тулганасың, эштән башың бушамый, әле малы, әле бакчасы, әле аш-суы дигәндәй... Юк инде, күпме хәрәкәтләнсәң дә, кимемәсә кимемәс икән...

— Атасы, өстәлне теге якка әзерлик, уртага күчереп куй. Калганын без монда кызлар үзебез карарбыз, әйеме, Гөлсинәкәем? — Рәйханә инде чәчләренә чал кунса да, яшь чагыннан ук килгән гадәте буенча, иренең башка хатын-кызлар тирәсендә янәшә басып торуын да күтәрә алмый иде, ук кебек кадалган карашы белән Ибраһимны тиз генә зал ягына озатты.

— Рәйханә апа, безнең бераз күчтәнәчләр дә бар иде, шофер алып керсен инде, яме? — Гөлсинә болын кыңгыравыдай зәп-зәңгәр күзләрен тутырып, Рәйханәгә елмаеп карады. Ул да булмады, өй ишеге ачылып, җирән мыеклы егетнең кулындагы олы-олы сумкалар идәнгә тезелде.

— Әтекәем! Боларга әллә ярты Чаллыны сыйдырдыгызмы, ни бу? Ибрай дим, атасы, Ибраһим! Күр әле, чык әле! — Рәйханә, әле һаман ишек аша ташыган капларга, сумкаларга текәлеп, шаккатып калды. — И Мансуркаем, никләр болай мәшәкатьләнәсе иттегез инде, шулхәтле расхутланып! Карале, шуферың да керсен әле, чәйләр эчәр, җылыныр. Урамда каңгырап утырмас бит инде.

Җиз мыек:

— Все нормально, апа! Минем барысы да үзем белән: чәй дә, музыка да, — дип тешен елтыратып елмайды да тиен җитезлеге белән чыгып та югалды.

— Ул үз урынын белә, — дип ирен чите белән көлемсерәп, Мансур Рәйханәгә борылды. — Үзегез карарсыз инде, монда ризыклар да, бүләкләр дә. Чын күңелдән дип кабул итәрсез.

Хатын-кызлар гөр-гөр килеп әйбер-кара белән булашкан арада Ибраһим да өс-башын алыштырып, Мансурны кунак бүлмәсенә дәште.

— И апай, болай зурлыйсы түгел иде инде! Шулхәтле акчалар түгеп... — дия-дия, биек гөлләргә күмелеп утырган диванга ымлады.

— Гомер кыйммәтрәк, Ибраһим абзый. Син булмасаң, әллә кайчан жир астында ятасы кеше идем бит... Аннан, менә моны да урнаштырып куй әле. — Мансур куеныннан конверт алып, Ибраһимнын кулына сонды. — Берәр кирәк-яраkка тотарсыз.

Ибраһим корт чаккандай конвертны кире этте.

— Кит, апай, кеше көлдермә. Кесәнә тыгып куй берүк, эт итеп сүгеп ташлаганчы.

Мансур хатыныныкы кебек үк зәңгәр күзләрен балкытып, йөзен тутырып елмайды да урыныннан кузгалды, стена буендагы сервантның пыяла ишеген ачып, конвертны чәй сервизы астына кыстырып куйды.

— Сина кирәкмәсә, Рәйханә апа тотар, хатын-кызның кирәк-ярагы мәнге бетми анын. Башка бу турыда сүз кузгатмыйбыз. Ир, күзләрен хәйләкәр кысып, зал ягына чыгып китте.

Өй хужалары өстәл тирәсендә ыгы-зыгы килгән арада Гөлсинә ире янәшәсенә килеп утырды да колагына иелеп, ялт кына:

— Акча бирденме? — дип сорап алды.

— Бирәм дидем бит — бирдем.

— Ничәне?

— Ярыйсы гына.

— Саранланма, тагын бир. Анын хәтле генә чәчбикәләренә дә туздырасындыр.

Мансур ялт кына хатынынын бит очыннан үбеп алды:

— Нишләптер дүрт ай буена ул чәчбикәләрнен берсе генә дә килеп хәлемне белмәде! Ничә карасам, аяк очында син утырдын!

Өстәл-урындыклар белән әвәрә килгән жирдән, аш бүлмәсенә чыккан арада Рәйханә дә пышылдап кына:

— Ибрай дим, карале, акча-мазар да нитмәгәндер бит? — дип баядан бирле телен кычыттырып торган соравын бирергә ашыкты.

Хатын-кыздан сер яшерә алам дигән ир-ат дөньяга тумагандыр, мөгаен...

— Борынын этнеке белән бер, билләһи... Сервантка куйды. Алмыйм дигән идем, ике сөйләшерлек итмәде.

— Китчәле, биргәннен битенә бакма ди. Берәү кадер итеп биргәч, сал да куй. Күпмеләп икән? — Рәйханә кабалануыннан кулындагы кайнар табасын әйләндерә язды. Кызарып пешкән шаңгәне олы тәлинкәгә бушатканда бармак очларын өтеп алуын да искәрмәде. — Халадилниктан ак майны алып бир әле! Берочтан май канатын да!.. Житәрлек булса, тәрәзә пәрдәләрен алыштырыр идек, күптәннән Сәлимәнеке кебеккә күзем кыза иде...

Ибраһим суыткычтан касәгә салынган майны алып, шап итеп өстәлгә куйды да:

— Карчык! Кесәсенә кире тыктым жибәрдем булыр! Эшенне бел! — дип төксе генә дәшкәч, кәнфит, бал савытларын тотып, залга юнәлде.

Күчтәнәчләрне дә кайсын кискәләп, кайсын турап, кайсын бушатып тезгәч, өстәл тәмам туй табынына әверелде, сыйдан сыгылып тора башлады. Түр башына Мансур алып килгән затлы коньяк та менеп кунаклагач, дөнья бөтенләй түгәрәкләнде. Ибраһим уймак кебек кенә өч рюмка куйган иде, моны күреп, Мансур ана сораулы караш ташлады. Аны сүзсез аңлаган Ибраһим:

— Апагыз эчүен ташлады бит, кадироватса итте, — дип шаяртып куйды.

— Кит, карт шайтан, кеше ышандырырсын. Үз гомеремдә бер стакан

аракы эчтем, анысы да син җуләрне тынлап... Үлгәннән калдым. Әнә, мина сок салыгыз, сезгә иптәшкә чәкештереп утырырмын, — диде Рәйханә, иренә терсәк белән төртеп алды да янына олы бокал китереп куйды.

— Хатын-кыз эчсә, эш харап икән ул, Мансур энем. — Ибраһим ачарга дигән шешәне кунакка сузып, башын чайкады. — Авылга карарга гыйбрәт хәзер, ир-ат айныды, хатыннар егылып эчә башлады. Өйне дә уйлау юк, баланы да. Ирне әйтәсе дә юк инде. Эчәләр, апай. Җыйнаулашып эчәләр. Шулар янына хатынлы ирләр ияләшеп, ничә симия таркалды. Сабакы белән бер бит ул хатын-кыз, әнә безнең хәзерге чапырыш күршене әйтәм әле. Өч баласын ике ирендә калдырып килгән дигәннәр ие, монысыннан тагын бала тапты, тагын ташлап китәр инде. Ике күзендә ат тоягы уйнап тора, минсинәйтим...

Иренең бу сүзен ишетеп, Рәйханәнең дә күзенән яшен уты сибелде.

— Карале моны, әйтәм аны җәй житсә, бакчага су сибәргә кирәк дип, колонка төбеннән керми, шул хатынның күзенә чекрәеп карап тора икән, карт шайтан!

Гөлсинә кып-кызыл иннеккә буялган иренен салфетка белән сөрткәч, көлә-көлә Рәйханәгә төбәлде.

— И Рәйханә апа, Ибраһим абыйны күз карасы кебек саклап кына яшәгәнсеңдер, әйеме! — диде ул сүзне шаяруга борып.

— Гөлсинәкәем, ир-атны алай гына сакларсың, бар! Үз башында булмасамы?! Безнеке егерме биш ел районга йөреп «Скурый» шоферы булып эшләде, янында гел япь-яшь систралар, ниләр булганын Ходай гына белә, үскәнкәем... Кайтып сөйләймени ул сина... Яшь чагында күңел ачуларны ярата иде абзагыз, хәзер генә комы коела башлады... — Рәйханә, уч алган кыяфәттә иренә кинаяле елмайды да кунакларны кыстый-кыстый сыйларга тотынды. Гөлсинәнең рюмканы ирен чите белән генә уртлап куюын күреп, үзенең ни рәвешле кырлы стакан белән аракы эчкәнен исенә төшерде дә түзә алмыйча кычкырып көлеп җибәрде.

Элегрәк авыл җирендә кышларын мал суйгач, зурлап аш үткәрү, бербереңә кунакка йөрешү гадәте бар иде. Ибраһимнар бер көнне үзләре бозау суеп, күрше-тирәне ашка дәште, икенче көнне каршы күршеләренә мәҗлескә керделәр. Иренең отпуск вакыты, шуңа күрә иркенләп туграрылды. Гармуннар белән җырлашып, зәмзәм суын авыз итә-итә утыра торгач, төн уртасы җиткән иде, Ибраһим ничек өйләренә чыкканын да, чишенеп урынга ауганын да хәтерләмәде. Иртән уянып киткәндә бар гәүдәсенә тәмуг газаплары таралган иде. Күзен ачкан уңайга иренең карашы хатынының чәчкәле күлмәгендә берегеп калды. Гәүдәсенең тулылыгыннан качып, учка сыеп бетәрдәй нечкә бил ясарга маташуымы — путалы күлмәккә ушы китә инде Рәйханәнең. Күр инде, иртәдән торып, байбичә кебек көязләнмәсә... Хәер, хатынын иске халаттан, тузган чәч-баштан күргәне бармы Ибраһимның? Кайчан карама, үрелгән озын толымын баш түбәсенә тәгәрмәч ясап җыеп куяр. Очсызлы гына ситсы алып кайтыр да, өйдә кияргә үзенә әледән-әле матур күлмәк тегеп ташлар. Менә хәзер дә, йөзен чытып кына йокыдан торган ирен үчекләгәндәй, кара җирлеккә эре-эре кызыл чәчкәләр төшкән яңа күлмәген киеп, аш бүлмәсендә бөтерелә. Яшь кызлар кебек, уч ясуы каләр киң каеш белән билен буып куймаса соң...

Ибраһимның чатнап башы авырта иде. Җитмәсә, теле кибеп корыган, аңкауга ябышып каткан диярсең. Олы чүмеч белән сап-салкын чишмә суы чөмерсән иде дә шушы минутта...

— Кая, каты итеп чәй ясап бир әле. Олы бокалга яса. — Иренең тавышы карлыгып чыкты.

— Нәрсә, атасы, баш эченә түкран оялаганмы? — Хәленә кереп,

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

кайгырткандай көйләп кенә эндәшсә дә, Рәйханәнең ирен читләренә кинаяле көлемсерәү эленеп калды.

— Син соң... Үзең эчеп карамагач... Кеше хәлен аңлыйсыңмы? — Ибраһим бу минутта бөтен дөньясына ачулы иде, хатынына да гомер булмаганча дорфа итеп эндәште. Ыңгыраша-ыңгыраша урыныннан торып, чәйнек борыныннан гына су чөмерде. Аннан, борын астыннан мыгырдана-мыгырдана, тагын караватка килеп ауды.

Ачуы чыккан Рәйханә дә түзмәде:

— Эчмә, кем куша сиңа! Салган берсен каплап барырга дигәнме? Житмәсә, күзеңне тондырып каршыдагы хатыннарга карап утырасың, мине адәм хуры итеп! — дип кызган табага май өстәп җибәрде.

— Караса..! Кеше хатыннары, ичмаса, синең шикелле кеше эчкәнгә йөзен чытып утырмый, эчә дә, көлә дә белә. Утырасың шунда кара көелеп, минем кабыргага төртеп. Әйтерсең, мин барып чыккан алкаш... Әллә нигә бер ярый инде ул. Бүтән хатыннар шикелле бер рюмка аракы эчә алмаганыңа мин гаепле диярсең. — Ибраһим сүз көрәштерүдән тәмам усалланып китте.

Рәйханә бу юлы бик тыныч тавыш белән: — Эчә алам, нигә эчмәскә. Эчәргә теләмим. Хатын-кыз башым белән шул зәхмәтне күтәреп утырырга... Кит, гыйбрәт, — диде дә чәйнеккә чишмә суы салып, газны кабызды.

Аның һәр сүзенә, һәр хәрәкәтенә жене котыра башлаган Ибраһим бөтен көчен җыеп урыныннан сикереп торды, кухня шкафының өске киштәсеннән яртылаш бушаган шешә үрелеп алды. Аны өстәлгә шап итеп утыртты, чәчәкле чынаяклар яныннан кырлы стакан китереп куйды. Төбе күмелерлек итеп кенә аракы салгач, күзләренә кот кунгандай булды, эһ дигәнче авызына бушатты. Аннан стаканны тутырып аракы агызды да хатынына сузды.

— Эчә алам дисеңме? Синме? — диде мыскыллы тавыш белән. — Мәле, күрсәт, төбенә кадәр!

— Котырдыңмы әллә? Бар әле, теңкәмә тимә, эч тә менеп ят. Колагым тынычланыр. — Рәйханә дөбер-шатыр чыгып китәргә җыенганда Ибраһим аның беләгеннән эләктереп алды. Үз сүзен итәсе килүме, шайтан суының тәэсире идеме — ир бүген танымаслык булып үзгәргән иде. Аның котсыз чыраен күреп, Рәйханә куркып ук калды. Житмәсә, ире өстерәп дигәндәй өстәл янындагы урындыкка китереп утыртты да кырлы стаканны шапылдатып алдына куйды.

— Эчә алам дидең. Күрсәт. Түлке моны эчеп бетерсәң, егылып үләсең бит син, — дип һаман бер сүзне тәкрарлады. — Эчмәсәң...— Ибраһим, кайдандыр ярдәм өмет иткәндәй, күзе белән тирә-якны айкады, таяну ноктасы тапкандай, мыскыллы елмайды. — Тотам да әнә теге яраткан гөлеңне ишегалдына чыгарып утыртам, биш минуттан кәкрәеп төшәчәк. Ана суык ярамый дигән идеңме? Тышта егерме биш градус кына, ничава... — Ибраһим айкала-чайкала түр яктагы ак чәчкәле азалия гөлен күтәреп чыкты да аны да Рәйханә каршысына китереп куйды.

Хатын ни көләргә, ни еларга белми иде. Аның каравы, иренең холкын белә: болай итеп үз киресенә каттымы, сүзеннән кайтыр димә. Хатынының гөл дигәндә жанын бирергә әзер икәненнән ничек файдалана, хәерсез! Рәйханәнең көз көне Казаннан ук керфек какмый саклап алып кайткан затлы гөлен ике дә уйламый кар өстенә чыгарып утыртырга әзер, мөртәт! Нәрсә, әллә чыннан да эчә алмас дип уйлый микән? Рәйханә борын төбендәге аракының эчкәнче үк күңелен болгаткан исеннән куырылып куйды. Шушы шайтанның үзен дә, исен дә, аны эчкән кешене дә жене сөйми, гомерендә бер йотымын авызына капканы юк, бүген килеп ничекләр кулына алсын? Житмәсә, ир кисәге, «эчәлмисең, эчсәң үләсең»

дип, каршында үртәп тора, жан көеге... Әй лә, карап карыйк, кемнең сүзе сүз булыр?! Рәйханә жен ачуы белән иренә мыскыллы караш ташлады да үзе дә көтмәгән житезлек белән кырлы стаканны авызына китерде, күзләрен чытырдатып йомган килеш әле голт-голт итеп, әле сулышсыз калып мизгел эчендә аракыны эчеп бетерде. Тончыкмады да, тынсыз да калмады, тик «эчеп үлгән диярләр инде, хурлыгы ни тора...» дигән уе баш миеннән сызылып үткән арада чыннан да теге дөньяга эләккәндәй булды. Зал ягындагы караватка таба атлаганда телсез-авазсыз иренен шар кебек түгәрәкләнгән күзләрен генә күреп өлгерде Рәйханә...

Шул хәлдән соң Ибраһимны жен алыштыргандай булды: хатынына бер генә тапкыр да тел тибрәтеп «эч» димәде, үзе дә эштән бәләкәй шешә белән спирт ташуын кырт туктатты.

Кунакларга шушы вакыйганы кыскача гына сөйләп бирергә туры килде. Гөлсинә керфек төпләренә яшь бәреп чыкканчы рәхәтләнеп көлде, Мансур каш астыннан гына елмаеп утырды, Ибраһим исә, хатынының хикәятен бөтенләй ишетмәгәндәй, бик бирелеп тавык боты кимерде.

— Ибраһим абый, минем сезгә бик зур рәхмәт әйтәсем килә! — Гөлсинә урындыгын читкәрәк этәреп, торып ук басты. — Сез искиткеч кеше, сез булмасагыз, мин ике баламны кочаклап... — Хатынның тавышы калтырап китте, ул хәзер дә, янәшә утырган ирен югалтудан курыккандай, күзләрен тутырып Мансурга таба карап алды.

Ибраһим үзенә булган игътибардан, мактаудан уңайсызланып, кул селтәде дә Гөлсинәне бүлдерергә ашыкты:

— Апай, исәнлеккә шөкер итеп яшик кенә берүк! Әйдәле, Мансур энем...

Гөлсинә Рәйханәгә таба үрелеп пышылдап куйды:

— Бездә үзеннән олы хатын-кызга гына апай диләр, сездә кызык икән.

— Олысына-бәләкәенә, иренә-хатынына шулай дип эндәшәбез инде, Гөлсинәкәем... Тартынып утырмале, кайнар чагында шәңгәсеннән авыз ит. — Рәйханә, табын уртасындагы тәм-томнарны кунаклар алдына этеп, аларны кыстарга тотынды. Сүз жебе, ниһаять, моннан дүрт ай элек булган вакыйгага килеп бәйләнде...

Декабрь башы иде. Ул көнне Ибраһимның йөк машинасына кышкы тәгәрмәчләр салып, Чаллы базарыннан кайтып килеше иде. Каршысыннан сиреналарын гүләтеп үтеп киткән «Ашыгыч ярдәм» машинасын күргәч, тәннәре чемердәп куйды. Үзе шундый машинада егерме биш ел шофер булып эшләп, инде пенсиягә чыкканына байтак булса да, очрата калса, һәрчак шулай йөрәге урыныннан куба. Тагын кемнең бер газизениләргә юлыккандыр... Инде күрмәгәне дә калмады кебек, күнегергә дә күптән вакыт шикелле, юк, кеше кайгысына, бигрәк тә үлемгә күнегеп булмый икән ул... Авыр истәлекләр белән кайтып килгәндә, Минзәләгә житәрәк юл читендә коточкыч кыяфәткә кергән машинаны, аның тирә-ягына жыелышкан халыкны, инспекторларны күреп, күңел түрен: «Ай-һай, исән калучы булды микән?» дигән ямьсез уй кисеп үтте. Гомер буе кеше кайгысын кайгыртып яшәү канына сеңгән иде, бу юлы да белешми-нитми тыныч кына үтеп китә алмады, читкәрәк чыгып, машинасын туктатты. Жыелышкан кешеләрнең берсен-берсе бүлә-бүлә сөйләгән өзекләреннән шул аңлашылды: хәзер тимер өеменә генә әверелеп калган «Мерседес»ка каршыдан зур тизлек белән килүче «КамАЗ» машинасы бәрелгән икән, ике шоферны да бик авыр хәлдә әле генә «Ашыгыч ярдәм» алып киткән. Жинел машинадагы пассажир үлгән, аның канга баткан гәүдәсен кар өстенә сузып салганнар, өстенә жәймә каплап куйганнар.

Шул минутта Ибраһим, бу коточкыч күренештән тагын да авыраеп, үз машинасына таба атлаган иде бит. Нәрсә мәҗбүр итте аны кире борылырга — ир, бу хәлне, үтерсәләр дә аңлата алмый иде. Әйе, берәүләрнең бәхетенә, ул кире борылды. Беркемгә дә сүз катмый гына мәет янына килеп басты, иелеп, җәймәне ачты. Йөзен-мазарын аерырлык түгел, тоташ кан гына. Ибраһим могҗизага өметләнми иде, шулай да тормышта кеше ышанмастай хәлләр белән әллә ничә тапкыр йөзгә-йөз очрашкан ир кесәсеннән беркайчан да калдырмый торган, үзе белән бергә картайган түгәрәк көзгесен алды. Гаишникларнын берсе «матур гына» итеп аның аяк астында комачаулап йөрмәвен «үтенсә» дә, Ибраһим үтенне сытарлык тозлы-борычлы сүзләрне колак яныннан гына үткәрде. Көзгене башта кайры тунының итәгенә ышкыды, аннан җансыз гәүдәнең борын тирәсенә китерде. Бераздан, үз күзләренә үзе ышанмыйча, кыргый тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Сез нәрсә монда, исән кешене мәеткә чыгарып! Җаны бар бит!

— Синең кебек акыллы башларны гына күргән бар, абзый, зинһар, мишәйтләп йөрмә! Каян килеп исән булсын... Сөякләре чәрдәкләнеп беткән... Врачлар карады инде, исәннәрен төяп киттеләр. Бар, абзый, юлыңда бул! — Түгәрәк гәүдәле, өреп кабартылгандай тук чырайлы гаишник Ибраһимны читкә тартырга маташты.

— Соң, ышанмасаң, үзең кара. — Ибраһим каударлана-каударлана, «мәет»нең төймәләре каптырылмаган курткасын ача төшеп, култык астына көзгене тыкты. Беркадәр вакыттан соң:

— Әйтәм бит исән дип! Көзгене кара, тирләп чыкты! Энем, минем бөтен гомерем шундый эштә үтте, сүз көрәштереп торма, тизрәк бүлнискә илтергә кирәк! — диде башын күтәреп...

— Ну, апай, үзем дә курыктым!.. Кузовка сузып салдык, астына ике кат телогрейка түшәдем, гаишникларның берәрсе кырыеңда утырып бармасмы дисәм... Үзем Чаллыга таба борылып чабам, үзем, мәйтәм, ай-һай, исән калса да, моннан кеше ясый алырлар микән дим... Карарга куркыныч ие бит. БСМПга илтеп житкердем, сине алып кереп киткәч карасам, теге телогрейкаларның икесе дә сыгып алмалы, кан гына. Аларны шунда ташлап кына калдырыш инде... Йөзлек киеп тугансыңдыр, апай, хәзер каршымда пулный парядокта утыруына ышанырлык түгел. — Ибраһим шул көнне кабат хәтереннән уздырып, баш чайкады.

Ул көнге вакыйгалар турында сүз кузгалткач, табын янында барысы да житдиләнеп калдылар. Мансур дәшми генә авыр сулады, Гөлсинә янындагы кечкенә сумкасыннан кульяулык алып, күз яшьләрен сөртергә тотынды, Рәйханә, «бер могҗиза инде» дип кабатлый-кабатлый, ияк кагып утырды.

— Дүрт ай буе сүтеп жыйдылар бит мине, Ибраһим абый. — Мансур, ниһаять, әлегәчә житди итеп кыймылдатмаган сүзен башлады. — Рәйханә апа әйтмешли, бер могҗиза булды ул. Аның бит инде авариясе дә... очраклы хәл түгел, күптән теш кайрыйлар иде. Ярар, монысы башка мәсьәлә. Шуны гына әйт әле: син нигә минем жегетләрдән качып йөрдең, ә? Ничә килсәләр, син юк. То шәһәрдә, то районда... Аныма килгәч, миңа энәсеннән-жебенә кадәр сөйләп бирделәр, аякка басканчы, малайлар аша булса да рәхмәт әйтә торыйм дисәм... Аларны күргән саен чыннан да базга төшеп утырдыңмы әллә?

Ибраһим белән Рәйханә, сүз берләшкәндәй, бер-берсенә борылып карадылар. Аннан, бөтен җаваплылыкны үз өстемә алам дигәндәй, Рәйханә:

— И Мансуркаем, башта милитсә килгәндә абзыең чыннан да өйдә юк ие. Үзем әйттем: шулай-шулай, миңа да сүләде, бүлнискә илткән, исем-мазарын да, кем икәнен дә белми. Гомер буе кирәксә-кирәкмәсә бөтен жиргә борынын тыгарга ярата инде ул, дип тә өстәдем әле. Кәгазьләренә

нидер яздылар да китеп бардылар, алары бүтән күренмәде, — диде тураебрак утырып. Аннан, монысын әйтергә микән, юкмы дигәндәй, тыныбрак торды да, тәвәккәлләп өстәп куйды: — Әллә ниткән олы машинада шкаф хәтле жегетләр килеп төшкәч, курыктык шул. Абзаң да, «юк-бар кеше булмагандыр, мине дә талкып йөрерләр инде», дип борчылды. Шуда күрә бәласеннән башаяк дип, абзагызны базга качырдым. Үзем тегеләргә әйтәм: яшь хатынга ияреп шәһәргә качты, знайт та низнаю, дим... Шулай дигән аркылы да әллә ничә килеп сораштылар...

Хатынының соңгы сүзләрен ишеткәч, Ибраһим бертын тамагына кылчык кадалгандай тотлыгып торды.

— Вәт кортка! Монда да үзенекен кыстыра икән, ә. Яшь хатын имеш... — Ул шулай дип сукрангач, дәррәү көлешеп алдылар.

Мансур алдындагы тәлинкәсен читкәрәк этәреп, терсәген өстәлгә куеп, ияген кулына терәде.

— Ибраһим абый, озын сүзнең кыскасы шул: син миннән җаның теләгәнне сорый аласың. Алтын балык булмасам да, кулымнан килгәнен эшлим. Машинаңны янартасымы, өй-мазарны рәтлисеме — тартынмыйча әйт.

Рәйханә нидер әйтергә теләп калкынган иде, Ибраһим кунаклар күзе алдында аның җиңеннән тартып туктатты.

— И апай, — диде ул гадәте буенча кискен генә итеп, аннан бераз уйланып торды. — Ачуымны китереп утырма әле. Болай да эте-бетенең мал, акча дип күзе тонган... Безгә апаң белән инде бернәрсә дә кирәкми, булганы яшисе гомергә житәр. Чукыша-чукыша булса да, тигез яшәп бетерергә язсын. Син, күреп торам, олы урындагы кеше, тегендә-монда сүзең дә үтәдер. Жаең булса, авылга булыш син. Акча бир диюем түгел, дөрес аңла. Жалкы, апай, күз алдында үлеп бара бит... Урамга чыксаң, жан әрни. Теше төшкән кортка шикелле, анда бер ташландык өй, монда икенчесе тырпаеп утыра. Хәтәр хәл ие әле, мәктәпне бетерәләр дигән сүз таралгач, уптым илаһи кузгала башладылар.

Шушында туган, шушында кендек каны тамган Ибраһим өчен авыл, чыннан да, элек-электән бер изге урын кебек иде. Районда эшләгәндә үзәктән менә дигән фатир да тәкъдим иткәннәр иде үзенә, ир бу хакта Рәйханәсенә әйтеп тә тормады — кайталы-китәле эшләп йөрүен белде. Кубарылып каядыр күченүне күз алдына да китерә алмады ул. Төнге сменадан бушап, иртә белән кайтып житкәч, жәйләрен еш кына авыл башындагы тауда туктала торган гадәте бар иде Ибраһимның: машинасыннан төшә дә яшел чирәм өстенә чалкан сузылып ята. Иртәнге тымызык жил алып килгән бөтнек, жиләк яфрагы исенә хозурланып, күңеленә тулган әйтеп-аңлатып бетерә алмаслык олы хистән исереп, бераз черем итеп ала. Олы хис дигәне — тормышның асылын аңлаудан туган төшенчә. Көннең көнендә каты авырулар, пешкән, янган, сынган; дөнья белән хушлашкан бәндәләр белән очрашып, яшәүнең ни дәрәжәдә татлы тәмгә ия икәнлеген аңлаудан туган хис. Адәм баласының өлешенә тигән гомер шулкадәр кыска, соңгы ноктага котылгысыз тизлек белән якынлашасың, шуны белгән хәлдә тагын да ныграк каударланасың, ашыгасың... Артына әйләнеп баксаң — күкрәк кагып мактанырлык изге гамәл-яхшылыкларына караганда, дөньяның койрыгын тотарга маташып йөгерүең күзгә күбрәк ташлана...

Хәзер дә, инде эштән кайтып килгән мәле булмаса да, Ибраһим жәй көне вакыт-вакыт шул тау түбәсенә менеп, үз-үзе белән гәпләшеп утырырга ярата. ...Күр әле, син ялан тәпи йөргән чагында зур дәрья булып тоелган инеш тәмам кибеп-корып бара, тирә-ягын каймалап алган таллар тирәсен әрсез тигәнәкләр сырып алган. Элегрәк шушы тау битенең уң ягында камышлар арасына сыенган челтер чишмә бар иде, кешеләргә әрнү-рәнҗүе көчле

идеме — ул да юкка чыкты. Ничекләр рәнҗемәсен — ишегалдында кое казытып, рәхәткә тиенеп яшәгән авыл кешеләре аның янына юлны онытты, кемгә кирәк — шул чистартсын дип кул селтәде. Сусаган юлаучыларны тешне камаштырырлык суы белән сыйлаган чишмә — авылның җаны — үз күз яшьләренә буылып, җир куенына кереп югалды... Әнә, кәнсәләр артында былтыр гына төзелгән мәчетнең яшел манарасы балкып күренә. Мәчет белән бергә авылга кот, иман, бәрәкәт кайтыр дип өметләнүчеләр дә булгандыр, әмма һәркем үзалдына «йөрүче юк» дип гаҗәпләнүдән ары узмый, шул бусаганы атлап кереп, калебендә нидер үзгәртергә омтылмый, азан тавышы яңгыраганда эшен ташлап, колак салып торырга да вакыт тапмый. Мәчеттән ерак түгел клубның калай түбәсе кояшта ялтырап китә. Аны түшәме җимерелә дигән сылтау белән ябып куйганнар иде, җиде-сигез ел үтте бугай, хәл-әхвәле белән кызыксынучы гына юк... Аның янындагы ике катлы таш мәктәп, каникул булгангамы, ятимләнеп калгандай күренә. Хәер, җәйгелеккә тавыштан арынып калганга гына түгелдер... Әле Ибраһимның балалары шунда укыганда, урта мәктәп һәркөн сабантуй мәйданыдай гөрләп тора иде. Заманалар үзгәреп, тугызъеллыкка калгач та алай ук ямансуламады, бер башына балалар бакчасын күчереп куйдылар. Эреле-ваклы сабыйлар, тирә-якка ямь биреп, җиһанда тормыш дәвам иткәнен исбатлап, кыңгырау урынына чынлап йөри бирделәр. Соңгы елларда мәктәпне башлангычка калдыру турында сүз китте. Ушлырак гаиләләр, балаларын сигез чакрымдагы күрше авылга йөртеп укытуга караганда, шәһәргә юл тотуны хуп күрде дә алдын-артын карамый ташкалага сыпыртты. Әнә, теге очта Назыймның берничә ел элек кенә салган хан сараедай йорты балкып күренә. Шуны йозакка бикләп, китеп бардылар, шәһәрдә акча түләп кеше фатирында көн күреп яталар хәзер. Ятмый кая барсын, алма кебек өч баланы җил-давылда, кар-буранда ни йөрәге белән чит авылга укырга йөртмәк кирәк? «Элек шулай укыдылар әле, автобус та булмады, ничә ел тәпиләп йөрделәр», дип авыз каплап маташучылар да табыладыр. Элек белән бүгенгене чагыштырырлыкмы? Унике-унөч яшьлек кызыңны йә улыңны көзге кара таңда укырга дип чыгарып җибәреп кара син... Нинди генә бәндәләр очрамас юлында. Автобус дигәннәрен әйтер идем, унынчыларны йөртеп карады инде былтыр. Ибраһимның олы оныгы да күрше авылга йөреп укыды: атнаның яртысын җәяү теркелдәделәр. Йә автобус ватылган, йә бензины юк, йә шоферы исерек...

Аскы урамдагы Рәсимнең өе күренми күренүен. Алар да, шыгырдап торган бүрәнәдән гүрничәдәй өй салдылар да ишегенә йозак элеп, Чаллыга китеп бардылар. Ике баласын гимназиядә укытып, аларның да кеше фатирында акча түләп яшәп ятышлары... Авыл очындагы Рәхимәнекеләр дә китеп барды, бөкре карчык болын хәтле өйдә берүзе утырып калды. Ибраһим үзенекеләр өчен дә кан калтырап тора: улының игезәкләре бишенчегә барырга җыена. Алар да ду килеп кубарылмаса гына ярар иде. Шулай, авылның җанын алам дисәң, мәктәбенә генә балта чап икән. Элгәрәк клубларны ябып, яшьләрне биздерергә маташтылар — берән-сәрән булса да, тамырдан аерылмаучылар табылып, авылны соңгы сулыш алудан саклап килде. Хәзер, менә, мәктәпкә тотындылар... Шунысына гына аптырый Ибраһим: кем белән сөйләшмә, берәү дә борын астыннан зарланудан узмый. Янәсе, кая бара бу дөнья, нигә тезгеннән ычкынды, нигә алай, нигә болай. Ычкындырма, ал тезгенне үз кулыңа, үзеңнең кеше икәнлегеңне, сүз әйтергә хакың барлыгын исбатла! Китеп барганнарны гаепләргә ашыкмаса да, күңеленнән алар белән дә бәхәсләшә Ибраһим: өрлектәй ир уртасы егетләр бит сез, балаларыгыз өчен көрәшергә бер генә мыскал көчегез дә юкмыни? Җыелышыгыз, хакыгызны даулагыз, тамчы

тама-тама боз тишә, диләр, бер ишетмәсәләр, бер ишетерләр. Дәшмиләр — димәк, аларга шулай ошый, дип уйлый бит ул түрә халкы. Өстәгеләрне гаепләп тел чайкау жинел дә, еламаган балага имезлек каптырмауларын да онытырга ярамый бит. Юк инде, аеры-чөере килеп, таркалып йөрергә калгач, юк инде... Куркакка әйләнеп бетте авыл халкы, үз сүзен кистереп әйтү онытылды... Бервакыт ачылып китеп, Рәйханәсе белән шул хакта гәп куерта башлаган иде, үткен телле хатыны бер сүз белән Ибраһимның авызын каплады: «Үзең сон? Баз баскычының кайчаннан алынганы юк...»

Менә хәзер Ибраһимның Мансур алдында авыл дип сүз кыймылдатуы шушы минутта гына башына килгән фикер түгел иде. Туган авылының күз алдында кузы сүрелгән учак кебек сүнеп баруы чыннан да аның жан ярасы иде. Үзенең дә, башкаларның да көчсезлегенә, телсезлегенә жаны әрнегән карт чарасызлыктан алдында яткан саламга тотынырга булды.

— Һм... — диде Мансур гажәпләнүен яшерә алмыйча. — Син, Ибраһим абый, нинди дер эксклюзив кебек... Авылыгызның башлыгы, житәкчеләр бардыр, аларга сүз катканыгыз булдымы сон, ни диләр?

— Димиләр шул, Мансур энем. Берни дә димиләр. Ну әйтсәләр, берәгәйле әйтәләр. Әле беркөн башлыкны күреп, «зират коймаларын төзәтәсе иде, бигрәк адәм ыстрамына әйләнде. Такта ишесен юнәтсән, өмә итеп булса да эшләр идек», дигәнием, йөземә карап көлде. «Скуры үзен дә шунда барып ятасын бит, Ибрай абзый. Коймалы булсани, булмасани ул чагында», дип ыржаеп тора. «Яшькә карап апкитми шул, энем, кемнең беренче барып ятасын Алла белә» дигәч, кара коелып китеп барды үзе. Менә син дә кулынны күкрәгенә куеп әйт әле: үз авылыңның хәл-әхвәлен белгәләп торасыңмы? Сездә нииндирәк хәлләр, ягъни мәсәлән?

Мансур тиз генә жавап кайтармады. Ибраһимның сүзләре аны кинәт кенә уйга салды. Дөрес, үзләрендә мәчет төзегәндә, сабантуйлар оештырганда, мөрәжәгать итсәләр, авылдашларын буш кул белән борганы булмады анысы. Тик шуннан ары авылның жаны, рухы белән кызыксындым дип әйтә алмый түгелме? Ничегрәк яши, нинди мәшәкатьләр белән көн күрә, кай жире сызлый авылның — мондый сорауларны башына да кертеп караганы булмады лабаса. Әти-әнисе яшәгән нигезне гөл итеп тота, алардан зарлану ишеткәне юк — шуның белән шул. Ә бит... ә бит... Ул дүрт ай буе үлем белән көрәшеп ятканда, кәнәфие, белгән дәрәжәсе, даны аркасында тирә-ягында дус булып йөргәннәрнең бик күбесе суга салган тоз кебек эреп югалды, чын йөзләрен күрсәтте. Аякка басмас, урынына кайта алмас дип, яна түрәләрнең аяк табанын яларга ашыктылар. Шул чагында ин тугрылары булып гаиләсе, туганнары һәм... авылдашлары калды түгелме? Ансыз яткан чагында да хәл белешеп алар килгән, соныннан да түбән очлар, югары очлар, күршеләр, балачак дуслары больница сукмагына тузан кундырмады... Мансурның күнеле нечкәреп китте. Ул шул халәтен сиздермәс өчен, вазадан мандарин алып, бик мөһим эш белән мәшгуль кешедәй, ашыкмый гына кабыгын әрчергә тотынды. Авыз суын китерердәй телемнәргә бүлгәләп, бер өлешен Гөлсинә алдына тезде.

— Шунысы да бар бит әле, Ибраһим абый. Соңгы араларда өстәгеләр авылга йөз белән борылып килә. Мәш китереп клублар төзи башладылар әнә, фермерларга юл ачтылар, кешеләргә пай жирләрен бүлеп бирделәр.

Ибраһим йөзен чытып Мансурны бүлдерергә ашыкты.

— Апай, ул фермерларны әйтмә инде син. Үстергән икмәген, итен, сауган сөтен шалкан бәясенә дә аткара алмый тинтерәп бетәләр бит. Әллә син аларга техникасы, солярка сы, ашламасы бушлай килә дип беләсенме?.. Алтыга алып бишкә сат, атың булсын сәүдәгәр кебек инде күбесе...

— Миннән ни көтәсең, Ибраһим абый? Сезнең авыл өчен мин нишли алам?

— Мансур сорауны кабыргасы белән куйгач, Ибраһим тәрәзәгә таба борылып бераз уйланып торды. Аннан карлыкканрак тавыш белән дәвам итте.

— Безнеке өчен генә түгел. Балаларны сакларга кирәк, апай. Мәктәпләрне яптырмаска иде бит, әй! Мәктәп бетсә, башта авылың, аннан килеп татарың үзе дә бетә инде ул, атом бомбасы да кирәкми... Сүзең үтә торган булса, менә шушы мәсьәләне калкыт син, энем.

Рәйханә моңарчы ирләр сүзенә кысылмыйм дип утырса да, ахыр чиктә түзмәде.

— Гаеп итмәссез инде, гомергә шулай кысыр хәсрәт белән кеше башы катырып йөрде... Соң, Мансуркаем, авылда безнең бабайдан башка кеше беткәнме инде, йә? Әле зират коймасы кирәк аңа, әле урам колонкасының борыны ватылган, әле буадагы күпер тактасы ярылган... Үзенең шул күпердән трактор белән йөрисе бар диярсең...Чүкеч-балталарын кыстырып төшеп киткән була, ярдәмгә ник берәрсе килеп карасын. Халык телендәге кушаматы да Хозыр бит аның... Кеше үзе бозылды хәзер, Мансуркаем. Ярдәмләшү дә, хәл белешү дә бетте. Юл өстенә аркылы бүрәнә төшеп ятсын, чирәмгә чыгып урап узсалар узалар, аяк астыннан күчереп куймыйлар... Атта да бар гаеп, Мансуркаем, тәртәдә дә. Башлыкларны сүгеп утырганчы... Әнә, бүген урамда йөрерлек түгел — шул тайгакка һәркем берәр чиләк көл генә чыгарып аударса да иту файда булыр иде. Чыгамы соң... Безнең Хозыр йөри, тавыкларга дип акчага китерткән көлны урамга сибеп, кеше кул-аягын сындыра күрмәсен дип...

Ут өстендә чыжылдап утырган чәйнүк шикелле кайнар дәрәҗәгә житкән Рәйханәне Ибраһим мыек астыннан көлемсерәп кенә тыңлады. Мансур шактый озак уйланып утыргач, ниндидер катгый карарга килгәндәй сүз башлады:

— Мәктәп дисең инде... Сезнең авыл буенча да, үземнеке буенча да министрлыкта сүз кузгатылыр. Монысы — вәгъдә. Аннан минем башыма бер фикер килде әле: мәктәп янында мәдрәсә ачуга ни диярсез? Интернат та төзеп, күрше-тирә авыллардан да килеп укымалы итсәк? Балалар өчен булырмы ул, өлкәннәр өчендәме — монысын яхшылап уйларга кирәк булыр...

— Ала-ай... Элекке чорларда булган да ул, байлар үз акчаларына мәктәп-мәдрәсәләр тоткан, диләр бит... Хәзерге калын кесәлеләр үзен генә кайгырта шул... — Ибраһим, ялгышрак әйттем дигән шикелле, гаепле караш белән Мансурга карап алды.

— Чыгымнар — минем проблема... Беләсеңме, Ибраһим абый, бу дүрт ай минем калган гомеремә житәрлек сабак бирде. Аллаһы Тәгаләнең «артыгын сикерәнмә, малай актыгы» дип кисәтүе булды бугай ул... Шуны аңладым: әҗәл дигәнең чыннан да каш белән күз арасында икән бит. Теге дөнья, анда баргач җавап тотарга кирәклеге уйландыра башлады. Шуңа күрә мин хәзер һәр адымымны яхшы мәгънәдә үлчәп атлыйм. Әүлиягә әверелмәсәм дә, — Мансур ияге белән өстәлдәге коньяк шешәсенә ишарәләп куйды, — намазы да кызыксындыра башлады. Күңелнең чистарынып, сафланып калуын үзем үк күрәм кебек. Өр-яңадан тудым диярсең... Бар нәрсәнең дә Ходай кодрәтендә генә икәнен аңлап алдым... Коткаручы бары тик Ул гына була ала, ә без, кешеләр исә — гади эшчеме, түрәме, барыбыз да аның ихтыярындагы коллар. Авылны гына түгел, упкынга тәгәрәп барган кешелекне дә Ул гына коткара ала. Адәм баласы да, кул кушырып, ярдәм көтеп утырганчы, барысын бизмәнгә салып, иманга килсә, яшәешнең төбе-тамыры үзгәрер иде дә соң. Менә шушыларны балаларга бәләкәйдән үк төшендерсәк, ничек шәп булыр иде, ә? Иман орлыгы салынган бала үскәч үз авылының йөзенә төкерми инде ул, син әйтмешли, картлар сүзенә дә «тиздән зиратка барасын бар» дип ыржаеп тормый... Кешенең кадере артыр иде, бәлкем. Ничек уйлыйсың?

— Ала-ай... — Ибраһим янә сузып кына шулай диде. — Нәрсә дим, апай, кызыл сүз генә булып калмаса, бик әйбәт, мин ике куллап пичәт куям. Без дә беренче класска укырга барырбыз, әйеме, карчык. Алайса, апагыз әлифне таяк дип тә белми...

Язлар, көзләр, кышлар узып, жиһанга җәй аяк баскач, Ибраһим карчыгын ияртеп авыл башына юл тотты. Исәбе — бөтнек җыярсын дигән сылтау белән, Рәйханәсенә тау түбәсеннән торып авылны күрсәтү иде. Әле билем, әле аягым дип зарлана-зарлана булса да, картына каршы килмәде, терек-терек аның артыннан атлады Рәйханә.

— Карчык дим, бәләкәй булса да, хәтәр матур безнең авыл, әйеме! — Ибраһим кулын каш өстенә куеп, кояшта чагылган күзен каплады.

— Уф, хәлкәйләрем бетте, сиңа ияреп йөргән мин җүләр... — Рәйханә, еш-еш сулап, чирәмгә килеп утырды. — Матур булмый ни, төс куна башлады бит. Клубын курчак күлмәге кебек киендереп куйдылар, урамнарын адәм рәтенә кертләр, яна мәдрәсәсе тагын...

— Карале, Назыймны кире кайткан диюләре хак бугай, мунчаларыннан төтен чыкканы күренә.

— Кайтмый ни... Шәһәрдә ай саен кеше фатирына унбиш мең түләп җан асраганчы... Магазинда сүләп торалар ие кичә, хатыны дүртенчесен алып кайтырга җыена ди. Ходай кушып, исән-имин котылсын берүк.

— Элегрәк Ходай исемен телгә дә алмый торган иең, үзгәрдең бит, карчык, ә! Әллә кайчан берәр мәдрәсәгә илтеп укытасы гына калган икән үзеңне... — Ибраһим шаяртып Рәйханәнең җилкәсеннән кагып куйды.

Рәйханә башындагы яулыгын сүтеп бәйләде дә, ире кебек, кулын маңгаена куеп, авыл ягына төбәлде.

— Сиңа әйтәм, чалгыңны эләктереп төшеп, инеш буендагы тигәнәкләрне кыркысаң дим... Элегрәк ул тирәдә басма була торган ие, ташу-мазарда агызды микән... Абзарга дигән яңа такталарыңның бер-икесен кыстырып килсәң... Көтүчеләргә ашарга илткәндә кеше әллә каян урап йөри бит, моннан турырак булыр ие.

Ибраһим аптыраулы караш белән хатынына таба борылды. Аннан, шаяртуын яшерергә тырышып, бик житди тавыш белән:

— Кирәк кеше төшеп салыр әле басмасын. Акчага алган такталарымны күтәреп йөрергә... — дигән булды.

— Ярар, ярар, аннан гына бөлмәссең әле. Аның каравы, савап җыярсың, саранланма, — диде Рәйханә иренең шаяруын аңламыйча.

Әллә каян гына жиләс җил исеп үтте. Ул үзе белән итәгенә тау бөтнеге, җиләк яфрагы исе ияртеп килде дә бу икәүнең аягына сарылып, тынып та калды. Мизгел эчендә исеп үтсә дә, тормыш асылы, яшәү мәгънәсе, аның татлы тәме турында пышылдарга өлгергән җил канатына тулы бер гомер сыенган кебек иде...

## Тау итәгендә

Бу матурлыкны бер селтәнүдә юк итәргә иренең кулы күтәрелмәде. Ул, инде һавага чөелгән чалгысын капыл гына кире төшереп, эшеннән бүленде. Зәңгәр кыңгыраулар, бер-берсенә сарылган кәрешкә, күкчәчәк, тагын әллә нинди, әллә нинди чәчкәләр, үләннәр, төсләр белән чуарланган тау итәгендә, нәкъ менә аның каршысында, үзләре бер кечкенә утрау булып, сары күзле эре-эре ромашкалар тибрәлә иде. «Шуларга ушы китә бит, хатынга җыеп кайтырга булыр». Иренең кояшта янып каралган, шунамы, тагын да кырысрак тоелган йөзеннән ниндидер җылылык йөгереп үтте. «Күр әле, җир җиләге дә мәмрәп пешкән! Кайтышлый балаларга тәлгәше белән өзәргә кирәк». Күнеле нечкәреп китүгә үзенең дә гаҗәпләнүе идеме, табигать хозурлыгына соклануы

булдымы — башын чайкап куйды. Ялангач күкрәгеннән агып төшкән тир тамчыларын уч төбе белән сөртеп алды. «Кыздыра! Кичкә яшенле яңгыр булмасмы әле?!» Алдындагы ак чәчкәле утрауны әйләнеп үткәч, күкрәк киереп чалгысы белән селтәнде. Шышт-шышт, шышт-шышт... Әлеге күнелле көйгә үзе дә борын астыннан гына жыр белән кушылды: «Сарман буйкайлары яшел алан, печәннәре житәр бер заман...» Моны белән әллә ни мактанырлыгы юк иде аның, шулай да тавышы колакны иркәләрлек, чын ир-егетләрчә иде. Юеш аркасына килеп кунган кигәвен генә ошатып бетермәде бугай — әчеттереп тешләргә дә өлгерде. «Каһәрең!» Ир чалгысын сул кулына күчереп, уңы белән шап итеп аркасына сукты. «Кеше кебек. Арттан килеп тешли, җүнсез!» Аннан, күз күреме еракта җәйрәп яткан авыл тарафына карап алгач, авыр сулап куйды. Билгесезлектән тә кыенрак нәрсә юктыр, мөгаен. Бүтән чагында кылны кырыкка ярырдай булып йөгергәндә дә житкереп булмаган вакыт бүген урынында тукталып калган диярсең. Жыелышын да, тапканнар, кичкә калдырмасалар... «Шома ак-караны күрми йөгерәдер инде. Этен-бетен сыйлап чыккандыр». Ә ул, үз-үзенә үч иткәндәй, чалгы күтәреп, тау арасына чыгып качты. Качты? Кемнән, кешеләрдәнме, үзеннәнме? Халык җыелышы җыялар, авыл башлыгы сайлыйлар, имеш... Кызык, аның исеме башлап кайсының теленнән тәгәрәде икән? Янәсе, үз авылыбыздан чыккан кеше, башкалар өчен кайгыра белә... Ничә ел мәктәптә ботаника, химия укытып, авыл халкы арасында, район житәкчеләре алдында абруй казанса да, монарчы карьера баскычы, властька үрмәләү турында уйламаган ирне әллә нишләтте дә куйды бит шушы хәбәр. «Ай-һай, Шома дилбегәсен алай гына бушатыр микән? Ничә ел рәхәтләнеп имеп яткан жиреннән... Чабатасын әллә кайчан киенеп куйгандыр...» Шома дип кушамат тагылган рәис — читтән килгән кеше иде, әшли башлаган мәлендә авыл ирләре белән кул биреп исәнләшкән кеше ярты ел эчендә танымаслык булып үзгәрде. Караш — борын өстеннән, тавыш — бөердән, сүз — теш арасыннан булды да куйды. «Кешенең чын йөзен беләсең килсә, кулына власть тоттырып кара... Власть боза кешене, власть... Күзләренә ак-кара күренми башлый. Иң элек үзләрен кайгыртырга тотыналар шул, авылны түгел... Кара инде, гөрләп торган авылны нишләтте, ә? Сарык фермасы, менә дигән атлар бар иде — берсе дә калмады. Ул амбарларны, техника паркын, комбайн-тракторларны әйтәсе дә юк. Сон, бөтен Рәсәе урлашып, талап, ришвәткә батып көн күргәндә ала карга булып каласы килмидер инде... Ярый әле халыкның пай җирләрен сатып бетерергә өлгерми калды... Жирсез авыл — үләргә яткан карт инде ул». Ир уйга күмелеп, тау итәгенең байтак өлешен чабып чыкканын сизми дә калды. Киң алдырып чабылган печән тезмәләре тигез тасма булып тезелеп ята иде, чалгысын шулар өстенә күзгә ташланырлык итеп куйды да ике тау арасында күгелҗемләнеп күренгән таллык янына атлады. Әйрәнле банкасын, кояшта жылынмасын дип, күләгәдә калдырган иде. Баш очында болыт урынына әйләнгән черки көтүенә кизәнә-кизәнә, таллык эченнән банканы алды, куе үлән арасына аякларын сузып утырды да, бик тәмләп салкынча әйрән чөмерде. «Шоманы әйтәм. Хет шушы авылныкы булса, үземнеке дип жиң сызганып эшләр иде дә... Ун ел эчендә тегесен жимереп, монысын таркатып бетерде — шул булды бөтен кылганы. Килмешәкләр төкерә ул синең урамыңа да, суыңа да... Пычагыма кирәкме ана түбән очтагы чокыр-чакыр, машинасы белән үзенең кереп батасы бармы... Аласын алып, таласын талап бетерә дә, әллүр бүтән хуҗалыкка». Банканың капкачын ябып, үрелеп кенә янә тал арасына яшерде. Бер кулын баш астына куеп, үлән өстенә чалкан ятты. Икенчесе белән нәзек кенә ромашка чәчәген сындырып алды да, сабак очын ирен читенә кыстырды. Карашы күктә берән-сәрән генә агарып күренгән болытларга текәлде. «Өстә утырганнарның мондый матурлыкны күрергә вакытлары юк. Күзләре тонган,

жиде буынга житәрлек мал жыюдан башканы беләләрме дин... Ике гомер яшәрдәй шикелле... Карале, дөньясы нинди ямьле! Һавасы ипигә ягып ашарлык бит, малай! Жыелышларына, сайлауларына, кәнәфиләренә төкер дә хозурланып тик ят. Алай дисән, алай дисән... Кулында бәләкәй генә булса да дилбегәсе бар кеше ял итәр урын эзләп тилмерми инде ул... Әнә бит, Шоманы әйтәм, хатынын ияртеп, кышын Һиндстаннан урап кайтты. Балалары да Казан-Мәскәүдә генә түгел, берсе Төркиядә, икенчесе Америкада укып маташа. Мөмкинлек булса, безнекеләр укымас идеме? Мәктәптә укытуны да әйтер идем... Кәгазь боткасыннан баш күтәрә алган юк. Эш рәхәте калмады. Авылда гына шулаймы дисәм, шәһәрендә ишшу да хуже бугай. Әнә, олы кыз теге атнада гына елардай булып кайтып зарланды. Бүтән һөнәр барын белмәгәндәй, аны да укытучылыкка укытып ялгыштык бугай ла. Ни үзенен күнеле ятмый... Мәктәп белән бетләп беттеләр, детсадларда да шул хәл, ди. Кычкырып әйтергә ярамый, мәктәпнен данын чыгарасы түгел дип, ысылдап кына торалар икән. Вәйт замана диген... Рәсәй мәктәпләрендә яулыктан йөрергә ярамый дип ду куптарып ятарга беләләр... Бот, күкрәк күрсәтеп, муеннарына тәре тагып килсәләр — ярый, яулык ярамый, имеш... Ай, берәр гәжиткә тотып язарга, яулыксыз укучыларнын башын тикшереп кайтыгыз әле, дип. Ата-аналарны әйтер идем, балаларына бармак янасан, тавыш куптарып килеп житәләр, талкавайрак мәсьәләне жыелып хәл итәсе булса, ярыкка качкан тараканнар кебек качышып бетәләр.»

Өрфия яулыктай болытлар да, төпсез тоелган күк йөзе дә, көйдерердәй булып кыздырган кояш та, кырмыскалар сыман ыгы-зыгы килгән кешеләр тормышыннан бихәбәр кыяфәттә, һәрберсе үз вазыйфасында иде. Алар үзләренен ни дәрәҗәдә биектә икәнлекләре турында баш вата, уйлана белми. Ходай Тәгалә тарафыннан үзләренә бирелгән мәгърур көч белән дә мактана белмиләр. Югыйсә, менә бу иркә болытларнын бер күчкә жыелып карангылануы, кояшнын шул болыт юрганы астына кереп югалуы, күк йөзенен мизгел эчендә яшь коя башлавы астагыларнын тормышын төбе-тамыры белән үзгәртергә сәләтле икәнен анласалармы... «Кечкә янгыр килсә, чапкан печәнне әйләндереп мәшәләнәсе була инде... Хатын чәпчи дә ул, көч әрәм иткәнче, сатыйк та алыйк, ди. Сатып алган күпмегә житә инде, йә? Егәр барында рәхәтләнеп кизәнмичә... Быел чапмасан, яренгә камылга әйләнә дә бетә. Авыл кешесе дә әзергә бәзер яшәргә өйрәнеп килә, кара инде, чалгы тотып печәнгә төшкән кеше бармы хәзер? Күбесе шулай сатып алу ягында. Жир кадерен белмичә... Югыйсә, бездә чабам дигән кешегә жире дә житәрлек бит әлегә. Әнә, күрше хужалыктагылар тилмерә, бакча артындагы үләнгә аяк баса алмыйча... Басарсын, бар... Бөтен авылынны алпавыт кулына сатып жибәрсеннәр дә. Пиннек бәйләргә дә, жиләккә барырга да жайлары юк мескеннәрнен. Кешегә әйтсән, кеше ышанмас — көтү чыгарырга жиренне калдырмасыннар инде, гыйбрәт. Кешесе дә мәмкә бит анын, жыелышып ду килеп каршы чыгасы урында, һәрберсе үзалдына шыншып йөри.»

Ир ниндидер ярсу белән авызындагы чәчкә сабагын чертләтеп тешләде. Әчкелтем тәм теш арасына сыланды. Торып утырды. Ирнен башында гәзиттән ясалган башлык иде, — ул ямьшәеп, сытылып калган, — салып, төзәткәләгәндәй итте. Тезенә кадәр сызганган чалбарынын кесәсен капшап карады — янавычы шунда иде. Торып, чалгысы калган тирәгә атлады, аны очы белән жиргә кадап, бик һәйбәтләп янады, бармак бите белән үткенлеген тикшергәч, канәгать елмаеп, билен турайтты. Печәнлеккә нәкъ менә бүген килүе сәгать уздыру, йөрәк дулавын басу өчен генә икәнлеген анык белсә дә, дөньясын онытырга тырышып, бил буе үскән үләнгә кизәнде. Акылы булган кеше төш уртасында, кояшнын өтеп алырдай кыздырган мәлендә печән чабып маташамы инде, йә? Мондый челләдә тан белән бергә кузгалып, чык коелып

беткәнче селтәнсәң генә инде. Ул чагында, ичмаса, чалгысы да үтә, юеш үләнне гали пәкесе урынына кырып кына сала... «Жыелышка барыбер кайтасы булыр, куркып качкан диярләр. И-и, җүләр, минем урында берәү булса, керфек какмый өйдән-өйгә йөреп, вәгъдәләр белән сыйлап, тавыш бирегез дип үгетләп йөрер иде! Ярар, ни булса шул булыр. Изге урын буш тормас әле... Азынды шул Шома, артыгын азынды, ветеранга диган йорт мәрәкәсе белән эләкмәсә, әле дә нәфсесе чик белмәс иде. Кеше ушлы шул хәзер: ветеранның да балалары шухрый-мухрый түгел — башкалага хәтле житкәннәр...»

Чалгының очы дык итеп кечкенә түмгәккә бәрелде. Тынычлыгы бозылган кырмыскалар, әрле-бирле тузгышып, чабыша башладылар. «Каһәр! Күрми калдым ла. Кая, аяк астында чабышмагыз әле, яшисегез килсә, әнә теге яклап»... Ир, эшеннән бүленеп, кырмыскалар белән гәпләшеп алды. «Бер карасаң, яшим диган кешегә җае да бар инде аның. Примергә минем күршене ал: хөкүмәт дотация биргәч, авылда пилорам ачып җибәргән ие, менә диган итеп дөнья көтә. Ничә кешегә эш урыны булды; безнекеләр генә түгел, бөтен тирә-як халкы егылып шунда йөри. Бажайлар бозау симертеп сата, алар да дәүләт биргән илле сигез мең белән башлап җибәргән ие. Әзергә бәзер өйрәнгән халыкның күбесе мал асрап азапланмый бит хәзер, пажалысты, менә сиңа ит... Бу юк, теге юк дип зарланып, тегесен-монысын сүгеп утыруы жинел инде ул, йә шулай балавыз сыгасың, йә җиң сызганып эшкә ябышасың. Эшләп кем баеган дисәләр дә, эшләгәннәр бер дә кеше күзенә карап тилмереп утырмый. Гаеп атта да, тәртәдә дә инде... Ялкауланды халык, ай, ялкауланды. Үзе акча колына әйләнде. Кыз да булсын аңа, буаз да булсын...»

Таллык ягыннан жинелчә генә жил исеп китте. Ир чалгысына таянып, кулын каш өстенә куйды да күккә төбәлде. Бая гына челтәр бизәк булып иркәләнеп йөзгән болытлар бер тирәгә укмашып маташа иде. «Болай булгач, тучны китереп ява инде бу! Их, дөбердәтеп, дер селкетеп коеп үтсә, ә?! Дөньясы үзгәреп китәр, чистарынып калыр иде... Адәм баласы гел шулай дип өметләнә бит ул... Тагын бер-ике рәт чыгарга да кыймылдарга кирәк. Әле жыелышларына иртәрәк иртәсен. Шулай да кайтып, юынып-кырынып, барып житкәнче... Глава килмичә башлавын башламаслар анысы, шулай да, санламаган кебек, сонга калганчы...» Ирнең уйларын бүлеп, пакус башында күлмәк астында яткан телефон аваз салды. «Хатындыр инде. Иртәдән үк бал кортыдай бызылдый башлаган иде. Борчыладыр».

Телефонда, чынлап та, хатыны иде. «Башында әз генә мие булган кеше шушындый көндә печәндә хыялланып йөриме, йә? Глава килеп житкән, кантурдан сине сорап шалтыраттылар!» дип сулуына кабып кычкырган тавыш ирне әллә нишләтеп җибәрде. «Каһәрең! Әле иртә дип торырсың монда! Болай булгач, болай булгач...» Әллә ашыгудан, әллә дулкынланудан, әллә сәер бер куанычтан күзләре томаланган ир кабалана-кабалана күлмәген киде, таллыкта утырган банкасын эләктерергә дип атлады, аннан, ярарсана дигәндәй кулын селтәп, чалгысын инбашына күтәрде, жил-жил адымнар белән чабылган печән тезмәләре арасыннан атлады. Кайтышлый өзәрмен дигән жиләк тәлгәшләре дә, бая түмгәк булып утырып калган кырмыска оясы да ирнең кәлүш табаны астында калып сытылды. Менә ул үзе чапмыйча урап үткән сары күзле ромашкаларга якынлашты, атлаган уңайга инсәсеннән чалгысын төшереп, сукмагында утырган нәзек билле чәчкәләргә селтәнде. Әле генә матурлыкның үзе булып балкыган ак утрау тавышсыз иңрәү белән ирнең аягына ишелеп төште. Тик ирнең күзләре жиргә сарылган гөлләрне күрмәде, ул тау итәге буйлап югарыга ашыга иде.



Сания
Әхмәтҗанова

# АРЧА ПОЕЗДЫ

***

*Яктырак йолдыз янадыр төн кара булган саен...*
Г.Тукай. «Көзге җилләр».

**Арча якларының төне уйчан,
Йолдызлары балкый үзгәчә.
Йолдызга тиң күпме асыл затның
Нуры килеп җиткән безгәчә?!**

**Йолдыз, сүнеп, Җиргә иңгән мәлдә
Көчсезлектән акыл тезләнә...
Юк, аямый Күкләр гамьсезлекне...
Табалмассың, җуйсаң йолдыз эзен,
Гасыр кичеп эзлә-эзләмә.**

**... Бу иртәдә юлга чыгасымны
Давыл чәчәкләре сизенә...
Урман буендагы кырлыкларның
Чыклы балы ягыла тезем,
Әремле яшь тула күземә.**

**Чү! Ерактан әнә ипле көйгә,
Хәтерләтеп йөрәк кагышын,
Тәгәрмәчләр вакыт санап килә,
Җиле башка — әллә кайдан таныйм
Арча поездының тавышын.**

**Бу юлы да аны каршыларга
Соңга калдым, ахры, кичектем...
Тавышлары тынды, борылышта
Югалдымы дисәм... нәкъ артымда
Җил тышавын өзгән вагоннарның
Таныш гөрелтесен ишеттем.**

**Тәрәзәдән кемнәр кулын изи,
Моңсу карап туган якларга?!
Тын да алмый чабам, яулык болгап,
Арча поездында — Киләчәккә
Сәфәр чыккан олпат затларга.**

---

Сания ӘХМӘТҖАНОВА — *шагыйрә; «Оч ирекка җырым», «Пар алма», «Гәрәбә» исемле китаплар авторы; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

**Поезд түгел, Вакыт кәрваныдыр...**
**Ул Җир шарын ничә тапкыр урап,**
**Бүгенгегә юлны сапкандыр.**
**Уятырга теләп безне, әйдәп,**
**Ашыктырып, ярсып, алгысытып,**
**Көнчыгыштан көнбатышка таба**
**Менә тагын кире кайткандыр...**

**Мәңгелектән безгә уйчан йөзләр**
**Өмет белән карап узамы?**
**Бу иртәнең соң сәламе булып,**
**Офыкларда шәфәкъ сызамы?**
**... Мин сәфәргә чыгам, Хәтер буйлап,**
**Рәшәләрдә — йолдыз тузаны...**

## Курса хәзрәт

*Курсавиның исламга һәм шәригать кануннарына иҗтиһади[1], тәнкыйди карашы, ислахчыл уй-гамәлләре, мәдрәсәләрдә дөньяви фәннәр укытуны алга сөрүе үз заманы өчен гаять кыю адым була. Аның алдынгы фикерләре үзләрен галим дип йөргән иске карашлы Бохара руханиларының ярсулы каршылыгына очрый. Алар галимне кяферлектә гаепliләр һәм Бохара әмире Хәйдәр хозурында диспут, ягъни хөкем мәҗлесе оештыралар. Әмир — Курсавига үлем җәзасы белән яный, фикерләреннән баш тартуын таләп итә. Курсави, эзәрлекләүләрдән качып, ватанына кайтып китә.*

Биографик мәгълүматтан.

**Чын асылташ мәңге җуймас бәһасен,**
**Затлы нурын сүрелдермәс вакыт та.**
**Милләтемнең җәүһәрләрен барласаң,**
**Арасында мәрҗән дә бар, якут та.**

**Курса хәзрәт — нуранины[2] сирәге,**
**Хак исламга яңа капка ачучы.**
**Чалмасының һәр чалымы риясыз,**
**Иҗтиһады — Коръән Кәрим ачкычы.**

**Уйлары да, гамәле дә хәзрәтнең**
**Яңарышка, яңалыкка ихласлы:**
**Ул — иң башлап, милләтемнең, халкымның**
**Хөр фикерен дәгъва кылган ислахчы.**

**Буйсынмаган мәхлукларча һәр ымга,**
**Һәр «лязем»гә суфиларча күнмәгән.**
**Курса хәзрәт кебекләрнең нияте**
**Сүрелмәгән, җил-давылда сүнмәгән.**

**Динебезнең Лютеры ул, Ян Гусы[3],**
**Томандагы тансык Кояш шәүләсе.**
**Фәтва[4] аңа — изге Китап сүрәсе,**
**Аң-мәгърифәт — юл күрсәтер мәүласы[5].**

---

[1] Иҗтиһад — мөстәкыйль хөкем чыгару.
[2] Нурани — нурлы, нур белән яктыртылган.
[3] Мартин Лютер (1483 — 1546), Ян Гус (1371 — 1415) — Европаның мәшһүр дини реформаторлары.
[4] Фәтва — дин-шәригать күзлегеннән караганда, бер эшне эшләүнең яравы-ярамавы турында дин әһеле тарафыннан аңлатып бирелә торган рәсми рөхсәт-фатиха.
[5] Мәүла — ия, хуҗа.

**«Кяфер» дигән мөһер җанын өтсә дә,**
**Хак юлыннан тайпылуны белмәгән.**
**Рух иреген хаклар өчен халкының**
**Курса хәзрәт гомере белән түләгән.**

**Әйтче, кардәш, кай тарафта кагъбәбез?**
**Иртәсенеп, юл чыгарга кыймадым...**
**Безләргә дә ният итмәк вакыттыр**
**Курсавиның «Әл-иршад лил-гыйбад»[6]ын.**

## Мәрҗани

*— Шиһабеддинебез бар иде. Кадер вә кыйммәтен белү аның өчен түгел, безнең өчен горурлык...*
И.Гаспринский.
«Тәрҗеман», 1889.

**Кадер киче кемгә хәерхахлы,**
**Кемгә чалма — милли горурлык?**
**Заманына күрә, бер Мәрҗани**
**Ничә «Мин»гә бүген торырлык!**

**Нахак, гайбәтләрдән сыену тапкан**
**Тәкъвалык һәм гыйлем юлында.**
**Хәкиме дә, гадел хөкеме дә —**
**Коръән Кәрим булган кулында.**

**Һәр адымда аңа сиздергәннәр**
**Үз кардәшен — кардәш сатарын...**
**Милләт мәрҗәненә — Мәрҗанигә**
**Кадер күрсәткәнме татарым?**

**Карун Ибрай кебек кара байлар[7]**
**Аермаган яхшы-яманны:**
**Мәдрәсәсен химаядән өзгән,**
**Хур итәм дип Шиһаб имамны,**
**Милләт бизмәнендә үлчәмичә**
**Шәкертләргә салган зыянны.**

**Үз чорының галим вә хадиме**
**(Андый затлар тансык бүген дә),**
**Элгәр тарихыбыз йолдызларын**
**Балкыткан ул дөнья күгендә.**

**Тәкъвалылар таный Мәрҗанидә**
**Курсавиның алмаш-варисын.**
**Рухи иңдәш булып ачкан алар**
**Татарымның яңа тарихын.**

**Милләтемә Ислам нуры иңгән**
**Галәм гөмбәзеннән яңача.**
**(Алга алып беркем сансынмаган**
**Татар исемен әле аңарчы).**

---

[6] «Әл-иршад лил-гыйбад» («Кешеләрне тугры юлга күндерү») — Габденнасыйр Курсавиның шул исемдәге нәсихәте.
[7] Казан байларыннан Озын Ибрай буларак танылган Ибраһим Юнысов күз алдында тотыла.

**Чит мәмләкәт, ерак кыйтгаларда**
**Таныткан ул татар дөньясын.**
**Мәчетенең ае нурын җуймас,**
**Нинди җилгә заман куймасын.**

**Хәзрәтебез рухы тора кебек**
**Татар кыйтгасының сагында.**
**Ул утырткан гыйрфан орлыклары**
**Яшәр, яшьнәр милләт багында.**
**Дин галәме... Күге — Ай әләмле,**
**Дәһриләргә[8] урын юк анда...**
**Ислам нуры иңмәс яманга.**

**Халкың нинди — хакың шундый, диеп,**
**Әйттерәсе килми һаман да;**
**Мәргәне дә житә, мәрҗәне дә,**
**Бер Мәрҗани җитми заманга!**

## Тукай хакыйкате

*Туры Тукай — хакыйкатьнең*
*Нәкъ үзенә текәлгән.*
*Ә без? Камыш төбендәге*
*Өнсез әкәм-төкәмнәр...*

С.Хәким.

**Мин Тукайга хәзер ешрак кайтам,**
**Кайта-кайта отыры уйланам.**
**Тукайлыгын аның «ачкан» саен,**
**Табышыма ихлас куанам.**

**Һәр килүдә мин Шагыйрьне күрәм**
**Әйтерсең лә яңа күз белән,**
**Ә ул мине каршы ала сыман**
**Вәкарь караш, усал сүз белән.**

**Тукай хакыйкате... аңа тиңнәр**
**Табылырмы милләт багында?**

**Әле һаман чүгеп калабызмы**
**Тукай телгә килгән чагында?!**

**Каләменә йөрәк тынын өреп**
**Эреткәндә бозлы карасын**
**Утлы фикер туган.**
**Соң җылыңны милләтеңә бир дә,**
**Тугъры Тукай булмый кара син!**

**Халык гаме, фаҗигасе, моңы —**
**Бар вөҗүде, кальбе, канында...**
**Тукай да бер, хакыйкать тә мәңге ...**
**Ул хакыйкать — халык җанында.**

## Камал

*«Татар тормышының, Казан мещаннарының иң безгә караңгы почмакларын сәхнәдә якты кояш кеби күрсәтүгә каләменең көченнән килгәненә гаҗәпләнеп, аны — Галиәсгар әфәндене — «татар Островские» дигән хөрмәтле һәм тиешле исем белән олылап, сүземне бетерәм».*

Габдулла Тукайның 1910 елда «Йолдыз» газетасына язган мәкаләсеннән.

**Каләмемнең язар көче җитәр микән,**
**Нидән болай Ходай сине камил иткән?**
**Арча суын эчеп үскән, шуңа микән —**
**Бар яктан да камәләтле[9] безнең Камал.**

[8] Дәһри — динсез, Алласыз.
[9] Камәләтле – камил, тулы.

**Татар теле «сөйләм теле» булган көндә**
**Туган телдә иҗат иттең көн дә, төн дә.**
**«Урам теле» диеп хәзер әйтмәс кем дә —**
**Татар телен — Халык теле иттең, Камал!**

**Театрның тәүге нигез ташын салган,**
**Соң көнгәчә аңа тугры булып калган,**
**«Сәхнәбезнең атасы» дип шөһрәт алган,**
**«Яктылыкка, нурга илткән» безне Камал.**

**«Төрле-төрле һөнәр, гыйлем белмәк кирәк...» —**
**Телең гади, үзең — гали, сүзең зирәк.**
**Шагыйрь, нашир, тәрҗемәче... хактыр, димәк,**
**Ул үз сүзен сүз италган сирәк Камал.**

**Яна-яна, яшьли янып беткәнсеңдер,**
**Сезнең «Яшен»[10] гел яшьнәр, дип көткәнсеңдер,**
**Безгә якты өмет баглап киткәнсеңдер...**
**Сезнең нурда коенабыз, кичер, Камал.**

**Без дә, анысы, «театр»ны ким куймыйбыз,**
**«Олы туган» язган рольне шәп уйныйбыз.**
**Буш сүз сөйләп, кәмит сатып һич туймыйбыз —**
**Татарлар бит, бел, «елмаеп үлә», Камал.**

**Милләтемнең зар-моңнары бетәр микән,**
**Каләмемнең язар көче җитәр микән?**
**Күкләр мине шул бәхеткә хөкем иткән —**
**Чырагымда Арча уты көйри, Камал.**

## Бәшир — баш ир

*Изге күңлем кагъбәсеннән көн дә бер таш җимерелә...*
М.Гафури
(Гомәр Бәширов 1939 елгы көндәлегенә
шулай дип язып куйган).

**Синең язмыш, татар язмышыдай, —**
**Сикәлтәле тарих корбаны.**
**Яңа заман яңа таләп куйган,**
**Җимерелгән элек корганы.**

**Җир кадере — ир кадере чакта**
**Гомер гөлең тамыр җибәргән,**
**Совет чоры сиңа каләм биргән,**
**Мөстәкыйльлек җилдә җилгәргән.**

**Туган якның яшел бишегендә,**
**Җидегән чишмәләрдән су алып**
**Үс тә — ыргыл язмыш чоңгылына**
**Һәм чыга бел рухың сау калып...**

**Каләмпәрвәр генә булалдыңмы,**
**«Намус»ыңны акка язганда?**
**Торып-торып «Гыйбрәт»[11]**
**алгансыңдыр,**
**Гасыр буйлап гомер узганда.**

**Күңел кагъбәң кыерчыгын учлап,**
**Үз-үзеңне кабат чарладың;**
**Җимерелгән ташлар арасыннан**
**Халык җәүһәрләрен барладың.**

**Милләтең һәм халкың мәккәсендә**
**Бәшир — баш ир бул син соңында...**
**Синең язмыш гыйбрәт булып**
**калсын**
**«Җидегән чишмә»ләрнең моңында.**

[10] «Яшен» — Галиәсгар Камал — нашире, мөхәррире, рәссамы булган журнал.
[11] «Гыйбрәт»— Гомәр Бәшировның тәмамланмый калган соңгы әсәре.

## Безнең Сибгат

*«...Мин бөтен гомерем буена Тукайга, аны тудырган, үстергән татар халкына, аны юлга чыгарган Казан артына лаек булырга тырыштым...»*
С.Хәким. «Блокнотлар», 1959 ел.

**Шигъри кулларыңда кауры калəм**
**Биетергə, шагыйрь, тугансың.**
**Курач иңнəреңə корал асып,**
**Миналарның итəгенə басып,**
**Ничек кичтең үлем «Дуга»сын?!**

**Иҗатыңда — «командирың Тукай...»**
**Тылың көчле, гадел — «сугышың».**
**Алгы сафтан чыксаң, калəм, тукта!**
**Утлы шигырь булсын кайнар ноктаң,**
**Күкрəгеңдə — миллəт сулышы.**

**Күндəм җаның əгəр кол булдымы,**
**Хөр булалмый, шагыйрь, калəмең.**
**Тукай турылыгын алга куеп,**
**Җəлиллəрнең тугрылыгын тоеп**
**Яулагансың иҗат галəмен.**

**«Тукай — мəктəп. Көче — миллилектə.**
**Андый шагыйрь сирəк», — дигəнсең.**
**Син Тукайны өр-яңадан ачып,**
**Халкың белəн бер үк тында басып,**
**Тукай мəйданына килгəнсең.**
**Бисмиллаң да Тукай, иманың да,**
**«Вөҗданына куйган вөҗданың да» —**
**Шагыйрьлекне хаклый белгəнсең.**

**Синең кебек, чорны чорга куйсам,**
**Кем вөҗданын салыйм бизмəнгə?**
**Горурлыкны җуйдык, ахры, ваклап,**
**Мескенлекне ничек булсын аклап?!**
**Заманага кизəн-кизəнмə...**

**«Тукай яшəр — халкым яшəгəндə!» —**
**Диеп хөкем иткəн Хəким бар.**
**«Безнең Сибгат» дигəн нам[12] алырга,**
**Арча улы булып саналырга,**
**Сибгат ага, хəлəл хакың бар.**

## Гариф

*«Гариф белəн — эш, тырышлык, хезмəт янəшə яшилəр. Ул тормышны ярата белə, тормыш төзүче эш кешесенə аның ихтирамы чиксез».*
А.Гыйлаҗев.

**Хəзинəсен тапкан язучы дип,**
**Кемдер əйткəн белеп... əллə көлеп?**
**Гариф ага, «хуҗалар»ның[13] хəлен**
**Бер куралсаң иде бүген килеп.**

[12] Нам — ат, исем.
[13] «Хуҗалар» — нефтьчелəр турындагы дилогиянең икенче романындагы хезмəт кешелəренə ишарə.

**Җир маеның даны китте ерак,**
**Чит кыйтгага кара алтын ага.**
**Тимбиковның[14] булса, аның юлын**
**Борыр иде менә бире таба.**

**Алтын — чыккан җирдә кадерле шул:**
**Җир мае да белә үз бәясен...**
**Без дә гасыр чиген узып киттек,**
**Көтә-көтә язмыш химаясен.**

**Авыр сулый туфрак, хәлсез чишмә —**
**Хаталардан сабак алалмадык.**
**Сүзебезгә түгел, иң әүвәле,**
**Үзебезгә хуҗа булалмадык.**

**Өчиленең карт таллары елый,**
**Өнсез калган инеш-бөяләре.**
**Авыл булган җирдә ятим бушлык —**
**Рәнҗемәсме нигез ияләре?**

**Нишлисең бит, гомер читтә узган,**
**Иҗат белән хәят арасында.**
**Син — үрнәге хезмәт кешесенең,**
**Кайсы яктан килеп карасаң да.**

**Һәр Гариф та Ахун түгел әле,**
**Һәрбер ахун гариф[15] булалмаган...**
**Бизмәннәргә куймыйк — туннар тузган...**
**Вакыт көле тузгый — көмеш тузан.**

## Мәһдинамә

*«Гаделсезлекләр, тормыш сынауларыннан*
*чиста рух белән чыга алу — кешенең иң*
*зур бәхетедер. Мин ул сынаулардан бераз*
*имгәтелеп чыктым, ахрысы...»*

М.Мәһдиев. «Бәхилләшү».

**«Кеше китә — җыры кала». Син дә киттең...**
**Күпме җырлар ятим калды синнән соң.**
**Нигә болай ашыгыплар бәхилләштең,**
**Мәһди дигәч, дөньяларны сара моң.**

**Бөеклекне кичералмый гаделсезлек,**
**Холкыңа ят — җан хөрләгән югалту...**
**Имгәнсә дә, затлы рухың саф калган, —**
**Җитмәгән шул моны аңлау, юату...**

**Ут чәчәге ачмас микән серләреңне,**
**Торналарга хәлең сорап эндәшәм.**
**Кайтыр өчен мәңгелек яз күкрәвендә,**
**Горур китеп баруыңнан көнләшәм!**

[14] Тимбиков — «Хәзинә» романының бер герое. Ул, хезмәт рекорды куям дип, тыелган алымнар белән бораулау нәтиҗәсендә һәлак була.

[15] Гариф — акыл иясе, тирән фикерле кеше.

Мәһабәт тау, иркен дала, мул елгалар
Минем туган төбәгемне ят иткән;
Тик кайда бар синең кебек, ташка язып,
Тормыш сөяр якташларын яд иткән?!

«Чү! Тукта, җил, болын исен китермәле!»
Кузгатмале иләсләнгән күңелне.
Үзгәрсә дә туган авыл, кешеләре,
Бер үк җырлар кабатлана түгелме?

...Бәрәңгенең сабаклары — ак кырауда,
Эскертләрдә баллы салам исләре.
Шулдыр инде сагынуның, юксынуның
Газаплы да, ләззәтле дә хисләре.

«Кеше китә — җыры кала». Син дә киттең...
Дөньяныкы — дөньялыкта, үпкәләмә...
Җыеп алып вак төенгә төйнәп булмас, —
Синең гомер — кабатланмас мәһдинамә.

## Сау бул, Арча поезды!

Менә шулай... Янәшәдән генә
Дәвер җиле узды — чал агым.
Асыл затлар — үзе бер йолдызлык,
Исемнәрен чүеп барладым.

Вагоннары төрле... Урыннары
Мендәрлеме?.. Әмма мөнбәрле!
Бу «берләр»нең өндәр хакы булган
Күңел хөрлегенә — меңнәрне.

Арча поездының гөрелтесе
Ерагая бара — бу көннән.
Ерагайган саен якыная
Догалы моң — Арча күгеннән.

Тәрәзләрдән безгә сынап карап,
Гали затлар уза шәйләнеп.
Җилә поезд кояш чыгышына,
Кайтыр өчен кабат әйләнеп.

Аксакаллар! Бер җыясы иде
Туган җиргә сезне табынга
(Татар әле — татар чагында),
АРЧА сүзе алкаланып яна
Милләтемнең күңел таҗында.



Хәким
Галидән

# ПАТША СОЛДАТЫ ӘХМӘТНӘСИР

РОМАН

## 1

Төньякны көньякка тоташтырып, Аурупа белән Азияне икегә бүлеп торган мәшһүр Урал таулары Кыпчак далаларына сокланып хәл җыеп ята сыман.

Әби чәченә төренгән киң далада тулы тынлык. Чикерткәләр сайравы бу тынлыкка зәгыйфьлек китерми. Дала кешесенә тынычлык иңдереп, җанга ятышлы аһәң генә өсти.

Мул сулы Олы Кинәле елгасына яшәү мөмкинлеге биргән тар гына ерганак буенда мәрхәмәтсез кыздырган кояш нурларыннан әлсерәп, сарыклар бер-берсенә баш төрткән. Дөнкәчле уйсулык тирәсендә үскән ялбыр карама агачлары күләгәсендә дә урын буш түгел. Шул агачларның берсе төбендә, кәүсәгә сөялеп, унсигез-унтугыз яшьләр тирәсендәге егет тирән уйга чумган. Каш астыннан гына даланы күзәтә. Янәшәдә генә ятучы бүре басардай ике эт, тәпиенә башын куеп, йокы симертә. Атлар тирәсендә үскән Әхмәтнәсир сарыклар көтә менә. Көтүче Ишембай карт эч көзәне белән авырып дөнья куйгач, «Берничә көн генә көт инде», − диделәр аңа. Өч-дүрт көн узды, тагын күпмегә тартылыр, билгесез. Егетнең күңеле тыныч түгел иде.

Дикъкатъ белән бертын кояш чыгышы ягына карап торгач, ул торып ук басты. «Бүре-фәлән түгелме?.. Алай дисәң, бу чорда алар йорт малларына тимиләр... Кем булырга мөмкин?» Карашын егет шул якка борды. «Сәүдә» юлында пар ат җигелгән җинелчә арба күренде, аларга ике җайдак ияргән. Тиз арада якынаеп стан ягына юл тоттылар. Сирәк очрый торган бу хәл егетне сәерсетте: «Кемнәр? Нинди хәбәр алып килешләре?» Күңелгә шом салган шул күренештән соң шактый гына вакыт узгач, стан яклап җан-фәрманга чаптырып килүче атлы күренде. Бу мәрхүм Ишембайның оныгы Мәүлит иде. Ул, тирән сулап: «Синең арттан җибәрделәр. Көтү тирәсендә үзем калам. Сарык чалып алып кайтырга куштылар. Тиресен станда салдырырсың, ашык! − диде җитди кыяфәт белән. Егетнең соравына: кемнәр икәнен каян белим, ул турыда миңа әйтүче булмады, кайткач үзең күрерсең дип кенә

---

Хәким ГАЛИДӘН (1944) — язучы; *әсәрләре вакытлы матбугатта даими басылып килә. Чаллыда яши.*

кул селтәде. Егет кайтканда тирмәннәр тирәсендә җанлылык сизелә иде. Урта урында казан асканнар. Су кайнаган арада егет сарыкны кисәкләргә бүлгәләде, әчәгеләрен этләргә ыргытты. Түземсезлек белән читтән күзәткән эт кавеме, үзара талашып, күз ачып йомганчы эчәкләрне өзгәләп тә бетерде. Кулларын юып, өс-башларын тәртипкә китерү белән егетне олы тирмәнгә дәшеп алдылар. Затлы келәмнәр түшәлгән тирмән эчендә, зур ястыкка сөялә төшеп, хәрби киемдәге ят кеше утыра. Янәшәсендәгесе күзлектән. Икенче яклап ыру башлыгы Сәлимгәрәй урын алган. Кынындагы хәнҗәр сабына кулларын кушырып көрәк сакаллы ике казак ишек катында аягүрә басып тора. Баш иеп биргән сәламгә урыс телендә: «Здравствуй, джигит! Айда, проходи!» – дип баш кактылар. Барсының да карашлары егеткә төбәлгән иде. Киң күкрәкле, озын буйлы, кояшта какланган тут йөзле егет кунаклар күнеленә хуш килде, күрәсең: – Хороош! Хороош! Ничего не скажешь!» – дип, тирән канәгатьлек белдерделәр. Үзара нидер гәпләшеп алдылар. Сәлимгәрәй ишек ягына ымлады.

Тышка чыгу белән аны аш-су тирәсендә кайнашкан төз гәүдәле, урта яшьләрдәге бер хатын читкәрәк дәшеп алды.

– Синен артыннан килгәннәр, балам. Патша хезмәтенә алачаклар.

Көтелмәгән бу хәбәрдән егет каушап калгандай булды.

– Кем сүзе ул, анам?! Аңлап бетермәгәнсеңдер...

– Юк шул, улым, юк сүз түгел. Үз колакларым белән ишеттем.

Егет тиз арада үзен кулга алып анасын юатырга ашыкты.

– Ялчы баласы кемгә хаҗәт, анам?! Әгәр дөрес булса, ишетүем буенча, патша хезмәтенә бай балаларын гына алалар. Башка белән бутагансыңдыр... Солтангол белән.

– Һәй, улым! Син белмәгән ягы да бар шул әле...

Яшен тизлеге белән күнелендә туган уйлардан егет анасының соңгы сүзләренә игътибар итәрлек хәлдә түгел иде.

...Күнегелгән дала тормышы җанга ятыш булса да ник әле чит-ят илләргә чыгып дөнья күрмәскә ди, үз-үзенне сынап карамаска?!. Сәлимгәрәй аны үз малаена караганда якынрак күрде ич... Күнеленә сенеп калган балачагы күз алдына килеп басты. Ап-ак сакал-мыеклы бабай: – «Хәзер улыма яңа ыштан үлчибез» – диеп, йөзен зур сөлге белән каплап, чыпчыгын авырттырды. Зурлар кебек ыштанлы буласы килгәнлектән ул түзде, еламады.Шул ук көнне кулына ширбәт тотып, аның янына Сәлимгәрәй абзый керде.

– Әх ул, карт шәйтан! Әхмәтнәсир улыма ыштан тегәбез диеп баланың кәккүген кисеп алган! Тотсам кирәген бирермен әле, – диеп юатты малайны. Ярасы төзәлеп, йөгереп йөри башлагач, шул ук Сәлимгәрәй абзый, шәпшәрә килеш аны ат сыртына атландырды да, учы белән шапылдатып, атның арт санына сукты. Чаптырып киткән ат ялына ябышкан малай курыкмады, еламады да. Читтән күзәтеп торган бай бу күренештән канәгать иде.

– Хайт, улым! Үземә охшаган! Афәрин! – дип, чын күнелдән соклануын белдерде.

Олылар ягыннан балаларга карата әйтелгән гадәти бу «Улым» сүзен Сәлимгәрәй тагы да ягымлы, йөрәккә ятышлы итеп әйтә иде ич. Үзен үзе белгәннән бирле ул Сәлимгәрәй абзый канаты астында үсте, тормыш житешсезлекләре кичермәде. Башка агайлар, әби-бабайлар да аңа карата мәрхәмәтле иделәр. Шунын аркасында ул төрле үләннәрнең им-томын үзләштереп, кымыз ясауның серләрен өйрәнеп үсте. Өйрәнергә атлыгып торуы, яптәш булуы өчендер дә аны бар нәрсә дә кызыксындыра иде. Үсә төшкәчрәк жәядән төз атарга, кылыч, хәнҗәр белән оста эш итәргә өйрәнде. Бигрәк тә ул атта йөрергә, чабышларда катнашырга ярата иде. Ат караучы Йомагол агай аны атлар телен анларга, атларча сөйләшергә өйрәтте.

Баштарак ул мона ышанып та бетмәгән иде. Әкренләп серне төшенгәч, агайның сүзләре хак булуына инанды. Буталчык чорда үз урыннарын таба алмый кангыраган төрле милләт кешеләре яши иде станда. Шулар арасында урыс милләтеннән дә бер ялгызак адәм бар иде. Төрле илләрдә булып күпне күргән, күп михнәт кичергән шул кеше ярдәмендә урыс телен үзләштерде. Төрки телдә аралаша белгәнлектән, ул егеткә мажаралы хәлләр турында күп сөйләде. Жир йөзендәге күп илләрдә төрле милләт халкы яшәвен, иксез-чиксез дәрья сулары, биек Каф таулары барлыгын аңлатты. Үсмер чагыннан ук аның да илләр гизәсе, шуларның барысын да үз күзләре белән күрәсе килгән иде бит. Бәлкем, менә хәзер, бәлигъльккка ирешкән чорында шул хыяллары тормышка ашыр!?. Сарык итеннән соң кымыздан изрәп төшкән кунаклар, аерым тирмәндә төн уздырып, таң ату белән юлга кузгалдылар.

Шул көнне Сәлимгәрәй стан халкын жыенга жыйды. Яна чапаннан, үзе житди кыяфәттә иде.

— Агайлар, әби-бабайлар! Иртәгәдән өч көнлек бәйрәм игълан итәм. Шул хөрмәттән ике баш елкы суеп казаннар асарга кушам. Тирә-як төбәкләрдән дә кунаклар булачак. Мәжлес алдыннан сезгә житкезәсе сүзем булыр, хуш иттек.

## 2

Сәлимгәрәй тотрыклы Манаш ыруыннан иде. Урыс патшасына хезмәт иткән Булат агасы «Тешә» елгасы буе Арзамаста черкесләр тарафыннан һәлак булганнан соң, мал-туар, жәйләүләре туган энесе Килемханга кала. Сәлимгәрәйгә үндүрт яшьләр тирәсендә кыргыз ат караклары атасы Килемханны үтереп, малларны куып алып китәләр. Кара кайгыдан сырхауга сабышып анасы да дөнья куя. Малсыз, бер терәксез фәкыйрьлеккә төшкән үсмерне тормыш, үч алу ниятеннән, чит-ят жирләргә китәргә мәжбүр итте. Кангырып йөри торгач, Нугай кәрванчыларына барып юлыкты. Буталчык һәм тотрыксыз еллар иде. Олы юлларда кеше талау, кәрваннарга һөжүм итүләр гадәти хәлгә кергән чор. Бер мәлгә бәла-каза аларны читләтеп узды. Үсмер егет әкренләп шул тормышка күнекте, чыныкты. Гәүдәгә артык эре сөякле булмаса да, елгыр һәм көчле иде ул. Көннәрнең берендә, Кытайдан кайтып килешләре иде, кәрван төнге ялга туктады. Таң алларында, татлы йокыда чакта, юлбасарлар һөжүм итте. Көчләр тигез түгел иде. Шуна да карамастан, егет көчле каршылык күрсәтеп, берничә юлбасарны яралады. Арт лепкәсенә сукканнан соң аңын жуйгач, күпме ятканын хәтерләми, күзен ачканда кәрван таланып юлбасарлар кулына төшкән иде инде. Егетнең чаялыгын бәяләп жанын кисмәделәр. Кул-аягын бәйләп дөя сыртына салдылар да, үзләре белән алып киттеләр. Юлбасарлар житәкчесе Артай тәкъдимен кабул итеп, алар юлына басты. Казакъ далаларында ат көтүләрен урлап куып, сәүдә юлларында кәрваннар талап үз-үзен күрсәтте, сынатмады. Бурныкын карак урлый, аның өчен алар барысы да бер калыптан иделәр. Йөрәгенә сеңеп калган үч алу уты сүрелмәгән иде әле. Кыргыз-кайсак очрамасмы диеп өмет итте. Елгыр һәм аяусыз көчле булуы өчен генә түгел, гакыл һәм зирәклеген бәяләп, аны Артай үз канаты астына алды. Эчкерсез туры сүзле, курыкмый үз фикерен ача алган кешенең хыянәт итәргә сәләтсез булуын яхшы аңлый иде Артай. Күзгә-күз калган очракларда егет тартынмый: «Тапкан малның игелеген күрмәгәч, ул байлыкның күп булуы нигә кирәк?» «Дүрт аяклы мал да абына, киләчәген фажигале тәгалләнмәсме?» — дигән сораулар бирә.

Артай, егетнең аркасын бәпләп:

— Синамы, олан, бу турыда кайгыртырга! Дөнья малы — дуңгыз каны, бүген бар, иртәгә юк. Яшь чагыңда жилдереп яшәп кал! Иртәгесе өчен ишәк кайгыртсын! — дия.

Бераздан, егетнең җаваптан канәгать түгеллеген тоеп, җитди кыяфәттә:

— Көчленеке замана, олан. Бер кавым азыкка тилмергәндә каптыручы булмас. Тир түгеп тапкан азыгыңны авызыңнан тартып алырлар. Мине тормыш үзе шулай өйрәтте. Минем өчен мал әллә бар, әллә юк. Уемда байлык түгел, дәрт, азарт. Үлем белән качышлы уйнау үлем көтеп хәрәкәтсез ятканга караганда мең тапкыр артыграк, — дип тә өсти.

Егет биргән сораулар алай да Артайны уйланырга мәҗбүр итә иде. Үз картлыгы шикләндерми иде аны. Аның үсеп килгән сеңлесе, бертуган олы апасы бар. Алар кем кулына калыр да, киләчәкләре ничек булыр?..

Ара-тирә, юлда очраган мосафирлар аша, Дон елгасы буендагы атлы казаклар арасында патшага карата фетнә күтәрелүен ишетеп белделәр. Җитәкчесе Степан Разин атлы кеше, имеш. Авыр тормыштан җәфа чиккән төрле милләт халкы гына түгел, иске динне яклаучы руханилар да аның канаты астына җыелып, патшага каршы сугыш игълан иткәннәр ди. Бу имеш-мимешләр Артайны тирән уйга салды. Халык язмышына битараф булып үз мәнфәгатен генә кайгырткан, байлыкка чумып бәйрәм итәргә күнеккән бай түрәләр гөнаһ шомлыгында, дигән фикердә иде ул. Аларны юк итсәң илгә муллык, җиңеллек килер шикелле иде.

Җаек елгасын кичеп Калмык далаларына юл тоттылар. Идел белән Дон елгалары арасында каты бәрелешләр барган чак иде. Бер төркем калмыкларга кушылып, Царицынны алуда катнаштылар. Җепшек кар йомгагы шикелле ишәйгәннән-ишәя барып, Идел елгасы буеннан өскә, Сарытауга юл тоттылар. Кыска гына вакыт эчендә Камышлы, Сарытау, Балыклы, Самар өлкәләре яулап алынды. Көчле өермә шикелле Иделнең икенче ярына чыгып, Җаек буйсындырылды. Гомере буе татарларны үги туган итеп күргән башкортлар, Казан ханлыгының фаҗигасен кабатламас өчен, заманында үз теләкләре белән урыс канаты астына елышкан иде. Җәйләүдән җәйләүгә күчеп мал көткән бу халык, милләт буларак оешып бетмәгәнлектән, урыста яклау тапты. Бу хәлне югары бәяләп, урыс башкортларга биләмәләрен киңәйтергә мөмкинчелек бирсә дә, үзенә кирәген онытмады. Ясак түләтеп башкортның зыкысын алды. Бәйсезлеген кире яулап алу нияте белән, фетнәчеләргә өмет тотып, гади халык кына түгел, көтү-көтү мал тоткан бай-кураларына тикле комсыз урыс патшалыгына каршы күтәрелде. Үз биләмәләре итеп санаган Җаек буендагы бер авылда Артай, фетнәчеләр җитәкчесе Степан Разин белән күзгә-күз очрашып, төн уздырды. Янәшәсендә Сәлимгәрәй дә бар иде. Халык арасында көчле пәһлеван булып сурәтләнгән адәм гади генә үз кеше икән. Тапкыр сүзле, җор телле, гади генә киемнән. Батырчылыгын туплап Сәлимгәрәйнең: «Бай-түрәләрне үтереп бетереп, патшаны бәреп төшергәч, ил белән кем идарә итәчәк? Яна түрәләр шул ук хәлне кабатламасмы?» — диеп соравына ул шаркылдап көлде. «Әле аларны юк итеп бетерәсе, патшаны бәреп төшерәсе бар, егет! Муең булса камыт табылыр. Синең белән без икәү идарә итәрбез. Ә нәрсә? Булдыра алмабыз дисеңме? Сез җирән чәчле урыска охшамаган. Төрки телне дә яхшы беләсез. Татар кешесеме әллә?»

— Ике йөз ел артыгы белән татарлар идарә итте Русиядә. Хәзерге вакытта теләкләребез, омтылышларыбыз бер икән, димәк, без бер нәсел, бер каннан! Ә калганы алай ук мөһим түгелдер.

Үзара якын итеп, Тимофееч диеп атап йөрткән бу көчле рухлы адәм Сәлимгәрәй күнелендә тирән эз калдырды. Андый кеше белән ул утка-суга керергә әзер иде. Идел белән Җаек буйларын яулап алган дәһшәтле атаманга бу җирләр генә кысан иде. Самар белән Сарытауда зур көймәләр ясап Идел аша дингезгә юнәлде. Өч тәүлек эчендә Әчтерханны алып шәһәр түрәләрен асты-кисте, байлыкларын халыкка таратты. Берничә ел эчендә тагы да зур

көч туплап, дингез аша «Кызылбаш» иленә юл тотты. Дингез яры буендагы авылларны талап, кырып, зур байлык белән кайтты. Дала кешеләре ул сәяхәттә катнашмады, чөнки Разинның бу гамәле аларга бик үк ошап бетмәде. Дон казаклары арасында да ана тәләктәшлек белдерүчеләр артык күп түгел иде. Ул күздән югалып торган вакыт эчендә урыс патшасы, зур көчләр туплап, каты бәрелешләр башлады. Шул бәрелешләрнең берсендә Разин каты яраланды һәм аны үз казаклары ук урыска тапшырды. Кыргый җанвар шикелле тимер читлеккә ябып Мәскәүгә алып киттеләр. Кызыл мәйдан уртасында халык җыеп, кул-аякларын өзгәләп, каты җәзага тарттылар. Җитәкчесез калган фетнәчеләрне эзәрлекләү башланып китте. Башта Әчтерханны, аннары Царицынны камап алдылар. Шәһәр халкы, көчле каршылык күрсәтүгә карамастан, җинелде. Янабаштан асу-кисү, үтерешләр башланып, күп кан коелды. Бу чорда Артай үз төркеме белән Сарытауда иде. Сизгер һәм хәйләкәр ат карагы, атаман Разинның соңгы гамәлләренә үзенчә бәя биреп, бу фаҗигането азагын алдан ук тойган иде. Шуның аркасында, сырхауга сабышып, бер ай алдан элек Әчтерханнан китте. Иркендә яшәргә өйрәнгән дала кешесенә шәһәр кысрыклыгы да этәреш биргәндер, патша гаскәрләре Царицынны алганнар дигән хәбәрне ишетү белән качып китәргә план корды. Акчага салчы яллап, өчәр ат белән өч кеше караңгы төн уртасында Иделне йөзеп икенче ярына чыктылар. Таң атып килгәндә алар Сарытаудан ерак иделәр инде. Артай үзе белән тугры иптәше Каратайны, яшь егет Сәлимгәрәйне алган иде. Калган төркем бу өч кешенең үз араларында юклыгын көн уртасында гына сизенде. Үзара шау-шу, гауга куптарып, таланган байлыкны бүлешеп, алары да кайсысы-кая таралышып беттеләр. Артай, Җаек ныгытмасын әйләнеп узып, елга аша Каратүбәгә юл тотты.

3

Каратүбә! Сәлимгәрәй бу якларда бер булган иде инде. Биек камыш басып алган уйсу үзән. Елак талларга күмелеп тын гына елга ага. Йөрәк итен чеметеп алган тулы тынлык. Тирән көз ае болытка карамастан үзән өсте әле саргаймаган. Камышлык арасында кыргый дуңгызлар салган сукмак аша бара торгач, алдагы калкулыкта каралтылар күренде. Төрле төштә сибелеп утырган ике дистә тирәсе өй. Яртылаш җиргә казылып балчыктан салган өй түбәләре яссы итеп камыш белән ябылган. Яңгыр суы үтмәсен диеп, күрәсең, камыш өстен балчык белән сылаганнар. Исеменә карата җисеме, Каратүбә иде бу.

Килүчеләрне абайлап каршы алган берничә эт белән нигез буенда бөкрәеп утырган карттан башка тирә-якта җан иясе күренми иде. Бертавыштан кычкырып биргән сәламнән карт башын күтәрде. Тоныкь күзләрен килүчеләргә төбәде.

— Ник берүзен, Серкенбай? Башка халык кайда?

Сорау биргән кешене танырга теләгәндәй, карашын Артай ягына борды. Йомырка эчендәге әтәч орлыгы шикелле ак төшкән кысык күзләрендә кайгы, өметсезлек иде. Сөйләшкән тавышны ишетеп, янәшә өйдән бер кортка чыкты. Ят кешеләрне танырга теләгәндәй, учын каш өстенә куеп, якынрак килде.

— Исәнме, Җамал әби! Бу мин, Артай. Ни хәл булды, кешеләр кайда?

— Артай дисеңме? Ә-ә, Артай! Син исәнмени, балам?! Булды, балам, булды. Серкеннең малаен үтерделәр. Малларны караклар куып алып китте. — Якынрак килеп Артайның кулыннан тотты. «Чынлап та бу син икән» дигәндәй, аналарча аркасыннан сөйде. Фикер туплагандай беравык сүзсез торгач, калтыравык тавыш белән тезеп китте.

— Без бит сине үлгәндер диеп уйлаган идек. Бу гомер буе кайда йөрдең?

Ник иртәрәк кайтмадың? Өч-дүрт ел эчендә кайтып китәргә теләгән булмадымыни? Таладылар безне, улым. Берничә атна элек сарык көтүен куып алып киткәннәр иде. Хуҗасыз йортка ияләшкән бүре көтүе шикелле, шушы төнне атларны да урлап качтылар.

– Гөлсыру кайда? Кайда башкалар?

– Гөлсыру яшь оланнар белән каракларны куа киткән иде. Озаклап кайтмый торгач, калган халык китте артларыннан.

Кояш баеп килгәндә халык кайтты. Артай сеңлесе Гөлсыру әйтүе буенча караклар Ахрат ягына киткән. Эзне югалтыр өчен караклар башта Шалкарга юл тотканнар. Уратып йөри торгач Ахратка борылганнар. Шуның аркасында куа чыгучылар адашып йөреп күп вакыт югалтканнар. Төнгә каршы юлларын дәвам итәргә куркып кире борыласы иткәннәр.

Юлда талчыккан булуга карамастан, Артай эзәрлекләүне дәвам итәргә карар кылды. Өчесе янына тагын таза гына ике егетне алып, биш кеше юлга чыктылар. Тирә-якны яхшы белгән Артай, чама белән, каракларның кайда булуларын аңлый иде.

Җан-фәрманга чаптырып бара торгач, таң алдыннан куып җиттеләр. Кыел елгасы башланган уйсулыкка томан төшкән. Таллык арасында төнгелеккә урнашкан караклар тирән йокыда. Бер читтәрәк ат көтүе үлән уртлый. Яккан учаклары сүнеп бетмәгән, пыскытып төтен чыгара. Учак янәшәсендә ике кеше ята. Томан җирдән аерылып өскәрәк күтәрелә төште. Куа килүчеләр, камыш песиедәй сак кына төтен килгән якка якынайдылар. Каратай, туктарга кушып, кулын күтәрде. Учак тирәсен кылдан үргән бау белән уратып алганнар. Кагылу белән кыңгырау тавыш куптарачак иде. Янәшәсендә яткан Сәлимгәрәйгә, Артайга пышылдады:

– Кыргызлар ысулы бу. Алар бер урында күмәкләшеп йокламыйлар, сак бул!

Бу турыда башкаларга аңлатып торасы түгел, читләтеп алга уздылар. Томанның күтәрелә төшүе алар өчен уңай иде. Чама белән караклар ун кешедән артмаска тиеш. Һәр кеше бер каракны юк итә алганда, калганнары күпме булуга карамастан, алар җиңәчәк иделәр. Учактан ары куак ышыгында, төрлесе төрле урында, җиде кеше ята. Куа килүдән шикләнмәгәннәр, күрәсең — ваемсыз йокы симертәләр. Артай, ым белән кемгә кайсы корбанын сайларга ишарә итеп, алга ыргылды. Яшьләрнең берсе һөҗүмгә ташланган җирдән абынып егылды. Берничә адым алдарак яткан корбаны уянып, тавыш куптарды. Каракларның кыргыз икәнен белеп алган Сәлимгәрәй дөрләп кабынган иде. Иләс-миләс йокысыннан арынып өлгермәгән корбанының бугазын кисеп, янәшәсендәге үсмергә ярдәмгә ташланды. Малайны буып алган кыргыз итек кунычыннан хәнҗәрен чыгарган мәлдә Сәлимгәрәй үз хәнҗәрен каракның култык астына батырды. Караклар тугыз кеше булган. Яшен тизлеге белән җидесен юк итеп, икесен кулга алдылар. Алары яшьләре җиткән олылар иде.

– Кыргызлардан үч аласың бар иде бугай, алар синеке, – диде Артай егеткә.

– Аласы үчне алдым. Коралсыз карт кешеләрнең канын кыеп гөнаһлы буласым килми.

Егетнең бу гамәле Артайга ошады. Аңнарына килеп өлгерми катып калган кыргызларга дәште:

– Оныкларыгызга әйтегез, бу якларга юлны онытсыннар. Мондый мәрхәмәтлек бүтән булмас. Сарыкларның дүрттән өч өлешен кире кайтарырсыз. Калганы, аяк хаклык, сезнеке.

«Ара ерак, җәяү йөрер хәлдә түгелсез», – дип, икесенә дә үз атларын алырга рөхсәт бирде. Малларны кире якка борып кайту ягына чыккач, Сәлимгәрәй Артайга:

— Сарыкларны китерерләр диеп уйлыйсызмы? Ә ни өчен дүрттән өч өлеше генә? — диеп сорау бирде.

— Алар минем кем икәнне яхшы беләләр. Мин дә аларны күптәннән беләм. Ә ни өчен дүрттән өч өлеше дисенме? Чөнки алар ул бер өлешне күптән инде суеп ашадылар.

Берара сүзсез барганнан соң:

— Китермәсәләр, хәере белән булсын. Зур югалту түгел. Ин мөһиме — атларны йолып алдык. Гаиләләре бер тоткасыз калды. Алар өчен зур югалту бу, — диеп өстәде.

4

Серкенбай малаен хөрмәтләп җирләделәр. Ыру тоткасы Артайның саусәламәт әйләнеп кайту хөрмәтенә тай чалдылар. Артык ачылып китәргә күнекмәгән тыйнак халыкта тирән канәгатьлек сизелә. Алар өчен Артай ышанычлы терәк.

Бу хәлләрдән соң берничә көн узды. Артай белән егет аерым өйдә урнашканнар иде. Йокысыннан уятып, Артай егетне тышка алып чыкты. Аны ияртеп калкулыкка алып менде. Калкулык артында җиргә түшәрелеп сарык көтүе ята. Тирә-ягында кеше заты күренми. Сарыкларны кире куып китергәннәр булып чыкты.

5

Артайның сеңлесе Гөлсыру артык үзгәрмәгән. Елеккеге какча гына, ябык кыз. Өченче дистәне ваклау эзсез калмаган, ирен кырыенда сызык, күз төпләрен сөрмә тарткан. Беренче вакытта очрашкандагы шикелле дорфа түгел. Егет алдында артык ачылып китмәсә дә, иреннәрендә елмаю сизелә, кунакчыл. Матурлык ягыннан артык күзгә ташланырлык булмаса да, кай ягы беләндер ул егеткә ошый иде. Сагыш иңгән тирән күз карашында гакыллылык чагыла. Иркәләнү тоймый тормышның бөтен авырлыгын татып үскән кыз гүя: «Тормыш юлдашың итеп мине ал, олтаның булырмын», — дия иде. Ил буенча барган эзәрлекләүләр басыла төшүен көтеп, егет беркадәр гомерен шушы авылда уздырырга булды. Кеше күзеннән еракка яшеренгән бүре оясы шикелле, Артай авылында тулы тынлык. Бу тирәгә юл юк. Ялгыш килеп чыгарлар диеп уйларга да сәбәп күренми. Үз тирәсендәге йөз чакрым арада Артай кеше малына тимәде. Киресенчә, ул бу җирләрне башка караклардан саклап килде. Тирә-якта яшәгән халык моны аңлый иде. Шуның өчен моңа кадәр аның ягына бармак төртеп күрсәтүчеләр булмады. Соңгы өч-дүрт ел буе югалып торганлыктан, аны үлгән диеп уйлаганнардыр инде. Андый хәбәрнең башкаларга да барып ирешүе мөмкин иде. Җамал әби әйтмешли, хуҗасыз йортка иялэшкән бүре токымы шикелле, кыргызлар бу форсаттан файдаланып каласы иткәннәр, күрәсең. Тыштан караганда шыксыз күренгән өй эчендә иркен, җыйнак һәм яшәр өчен унайлы иде. Стеналары келәм белән тәрелгән. Җир идәндә катлы-катлы палас, өем-өем юрган, мендәрләр. Түрдә мөһерләп бизәлгән зур сандык. Сандык эчендә кыз бирнәсе, алтын-көмеш, затлы бизәнү әйберләре. Артай сандыкны үзе ачып күрсәтте.

Кунакта яшәү ничек кенә рәхәт булмасын, алдагысы турында уйларга кирәк иде. Көннәрнең берендә Артайга ул:

— Теләгемә ирештем, ага, аласы үчне алдым. Киләчәк турында уйларга вакыт җитте. Дөресен әйтим, мондый кәсеп минеке түгел. Ирексездән кылган гөнаһларымны юып, картлыгымны намазлык өстендә каршылау ниятем. Нәсел тамыры миндә өзелмәсме, дип тә шикләнәм. Һәр тереклекнең үз пары бар. Дөньяның яме балада. Әнә, сеңлегезнең дә чәчәк аткан чагы... — диеп фикерен әйтеп салды.

— Беләм-беләм, — диде Артай, сенел сиңа ошый! Күреп торам, ул да сина битараф түгел. Әнә ничек балкый! Аның мондай чагын күргәнем юк иде әле, — дип, тимерне кызуында сугып калырга ашыкты.

Артайның үзенә өйләнеп тормыш корырга, малай үстерергә насыйп булмады. Теләк туган чаклары да булгандыр. Аның мәнфәгатен аңлап уртаклаша белгән хатын-кыз юлында очрый калса, өйләнгән дә булыр иде... ә хәзер соң инде. Өермә шикелле өерелеп йөреп тынгысызлыкта гомер узган да киткән. Гореф-гадәтен, холык-фигылен тирәннән аңлап, авыр чаклары белән сыналган бу егетне ул үз баласы итеп күреп, канаты астына алды, жылытты, өмет баглады. Бу турыда ачылып үзе сүз башларга горурлыгы ирек бирмәде.

— Уйларымны аңлап теләктәшлек белдергәнең өчен рәхмәт, агам! Мин сезне үз атам кебек күреп якын итәм. Әгәр дә сез бу якынлыкны каннарыбыз белән кушып туганлашырга каршы түгел икән, сездән Гөлсыруның кулын сорап, фатиха бирүегезне үтенәм.

Гомерендә беренче мәртәбә күңеле тулып йомшарган Артай:

— Безнең кәсеп сина тин түгеллеген беләм, иркәм. Бу бүре тормышы синең өчен түгел. Ә мина тормышымны үзгәртергә соң инде. Бәхил-риза! Сенел абруеңны төшермәс. Бирнәсе патшаларныкыише булмаса да, Инша Алла, кыенлыкта яшәмәссез! — диде.

Яз ае иде. Көннәрне жылытып калку жирләр кардан әрчелде. Ачык һава астында казаннар астылар. Бәйрәмгә сусаган халыкның кәефе күтәренке. Никах укытып, артык шау-шу килми генә туй уйнадылар. Яшьләргә үз торагын калдырып Артай Каратай янына күчте. Кәләш куенында сизелми генә яз айлары узды, даланы хәтфә үләнгә күмеп жәй житте. Алдан килешеп кую буенча Сәлимгәрәй юлга жыенды. Ике дистә атлар сыртына төрле жиһаз, байлык төяп, туган ягы, үз даласына төбәп сәфәр чыктылар. Каратай белән дүрт таза яшүсмер озата барырга алынды. Артык күзгә ташланмас өчен олы юлларны читләтеп бара торгач, хәвеф-хәтәрсез генә туган ягына кайтып життеләр. Соңгы вакыттагы болганчык еллар бу тирәләрне дә читләтеп узмаган. Ачлык-ялангачлыктан күп халык кырылып, дала ташландык хәлдә калган. Заманында һаваларны яңгыратып тайлар кешнәгән болыннарда тирән тынлык.

Елга башындагы күнелгә ятышлы урында тирмән кордылар. Урнашып, хәл жыеп, берничә көн вакыт узды. «Бераз вакыттан килеп чыгармын әле », — дип Каратай кире кайтып китте. Төпләнеп киткәнче булышырга егетләр каласы иттеләр. Бу якның дөнья хәлләрен белешү нияте белән Сәлимгәрәй, ат менеп, Тарханга барды. Анда күңелгә шом салган зур үзгәрешләр икән. Башкортлар белән татарлар арасында гауга кубып кан коелган. «Бу безнең жирләр!» — дип башкортлар кысрыклагач, татарларның күп өлеше нугай бае Әсәкәй канаты астына күченеп китәргә мәжбүр булганнар. Колшәрип белән Габдулла авылларында да тыныч түгел икән. Соңгы вакытларда калмыклар яу белән килеп тынгы бирмәгәч, башкортлар казакълар белән килешү төзеп, Шарлык якларында каты бәрелешләр булып алган. Башкортлар арасында да ызгыш-талаш, мал, жирләрне бүлешү бара. Сәлимгәрәйнең мал белән кайтып Кинәле елгасы башында төпләнүе тиз арада тирә-якка таралды. Хәл белешеп, дөреслекне ачыкларга дигән булып, әкренләп халык килә башлады.Тарханнан ике, Әсәкәйгә киткән өч гаилә күченеп килделәр. Базар хәлләрен белешер өчен ике алаша алып Богырысланга барган иде. Бер көтү сарык куып алып кайттылар. Жәй урталарында Каратай килде. «Артай бүләге», — дип, бер көтү ат куып алып килгән. «Артыңнан эзләп килмәсләрме?» —дигән сорауга Каратай: — Шикләнмә, егет! Артай аларны үз акчасына уйгырлардан сатып алды. Дала кешесе атсыз — ике кулсыз. Кыенлык туса, егетләрнең берсе аша хәбәр жибәр. Артайдан сезгә бик

күп сәлам! — дип кире китте дә башкача күренмәде. Ташландык хәлгә төшкән далага янадан жан инде, әкренләп туган-тумачалар күченеп килеп ыру ишәйде, ныгыды. Ярдәм сорап килгән кешеләрнең берсен дә кире бормады, үз канаты астына алды Сәлимгәрәй. Тархан, Габдулла авыллары белән араны ныгытты, Әсәкәй белән дуслашты. Әкренләп еллар узды, ихлас күңелдән корган нигезгә иминлек инде. Шуна карамастан Сәлимгәрәйнең күңеле тыныч түгел.Бишенче ел инде хатыны Гөлсыру балага уза алмый. Төрле үләннәр белән дәвалап та карадылар, им-томчы карчыкларга да күренделәр, файдасы тимәде. Гаепнең кемдә булуын белми торып, ирнең күңеле тынычланмады, ни дә булса уйлап табарга кирәк иде. Ялчы хатын-кызлар арасында өлгереп килгән кыз бала бар. Буй-сыны килешле, унган, тәртипле. Гакыл ягыннан да Ходай мәхрүм итмәгән. Яшьли ата-анасыз калган ятимә. Нугай каныннан. Төпле фикергә килеп Сәлимгәрәй шул кыз аша үзен сынап карыйсы итте. Көч белән алмады ул аны. «Мина бала кирәк. Малай бүләк итсән, муллыкта яшәрсен, бәлкем, хатынлыкка да алып куярмын», — дип, ризалашып кылынган гамәл иде бу.

Ялчы кыз Бану өч-дүрт айлык йөкле чагында үз хатыны да авырга узды. Соңгы мәртәбә бер башкорт карчыгы: яз башында сыерчыклар кайту белән, ата сыерчык атып ал. Итен пешереп ашагыз, дип киңәш биргән иде. Кайсы сыерчыкның ата икәнен ничек аерырга дигән соруга: ана кош өстендә чакта ат, ялгышмассың, диде. Башына төшсә ни хәл итмәк кирәк дип, карчык әйткәннәрне үтәгән иде, файдасы тиде, күрәсең...

Вакыты житү белән Бану томрап торган ир бала тапты. Озакламый Гөлсыру да житлегеп бетмәгән килеш малай тудырды. Авырлык белән вакытсыз туган бала чирләшкә иде, чирләшкә булып үсте. Бану малаена — Әхмәтнәсир, Гөлсырудан туган малайга Солтангол дип исем куштылар. Аллы-артлы ике малай туганга ата кешенең түбәсе жиде кат күктә иде. Сарыклар суеп, казаннар асып, өч көн буена бәйрәм уздырдылар. Күрше-тирә авыллардан да кунаклар чакырылган иде.

Әкренләп көннәр, айлар узды. Атанын күңеле Бану малае Әхмәтнәсирне якынрак күреп, күп вакытын алар тирмәнендә уздырганга, үз хатынының күңелендә көнчелек уянды. Озак гомер бала таба алмагач, икенче хатын-кыздан үзенне сынап кара һич югы, дип иренә үзе үк киңәш иткән иде ич. Үзе дә балага узармын дип уйламаган иде шул. Биргән вәгъдәсен үтәп, Сәлимгәрәй Бануга аерым тирмән корды, авыр эшләрдән азат итеп, бөтен кирәк-ярагын булдырды. Гөлсыруы рөхсәт биргән булса, никах укытып алырга да булыр иде. Ул чакта, карт хатын Гөлсыру, күләгәдә калып, ире яшь хатыны янынннан чыкмас та иде. Моңа кадәр киңәшеп, аңлашып, тату яшәгән ир белән хатын арасында «кара песи» йөгереп узды. Сүз арасында хатынының: «Ялчы хатын түбәнлегенә төшеп дәрәжәмне югалтасым юк!» — дигәненә каршы: «Кай арада буй житмәс дәрәжәгә күтәрелеп өлгердең әле?» — дип әйтешеп тә алдылар. Алай да хатыны сүзеннән чыкмады, өйләнү турында башкача сүз кузгатмады. Малайлар үсеп буйга життеләр. Әхмәтнәсир таза буйлы, елгыр, бар нәрсә белән дә кызыксынучан. Солтангол ябык, бәләкәй гәүдәле, ак чырайлы иде. Анасы шикелле аз сүзле, аралашырга яратмый. Күп вакытын тирмән эченнән чыкмый уздыра.

Сәлимгәрәй катнашкан Разин фетнәсе күптәннән бастырылуга карамастан илдә тынычлык урнашмады. Фетнәчеләрнең күп өлеше, вак төркемнәргә бүленеп, урманнарга, аулаграк жирләргә качып беткән иделәр. Әле бер, әле икенче урыннарда күтәрелеп чыгып, озак кына гомер урыс патшалыгына тынгы бирмәделәр. Фетнәдә катнашкан өчен башкортлардан урыс патшасы йөзен борды. Башкортлар арасында буталыш. Берәүләре бәйсезлекне кире кайтарырга, икенчеләре — урыс ярдәме белән тәртип урнаштырырга өнди.

Тотрыксызлыктан файдаланып уйгыр, кыргызлар мал урлап, кеше талап тынгы бирми. Бөтен ил буенча ачлык, ялангачлык, фәкыйрьлек. Соңгы көннәрдә: «Тәхеткә утырган Петр исемле яшь патша, жирләрен киңәйтү нияте белән, гаскәр жыя икән», – дигән хәбәрләр таралды. Хәлнең асылын ачыклау нияте белән, атлар алып, Сәлимгәрәй Олы базарга китте. Базарда халык күп иде. Алучыга караганда күбесе сатарга килүчеләр. Казакълар бик күп итеп сарык көтүе, дөяләр алып килгәннәр. Ераклардан төрле милләт халкы жыелган. Уйгыр, кыргыз, каракалпаклар, буй-буй чапанлы үзбәкләр дә бар. Үтемле мал – атлар. Сәлимгәрәй базар тамадасы Шамбалны эзләп тапты. Һәрвакыттагыча кочаклашып исәнләштеләр. Хәл-әхвәлләрне сорашып базар хәлләренә күчтеләр. Шамбал, Сәлимгәрәй атларын барлап, тешләрен, көрлеген карап чыкканнан соң: – Менә бу өчесен үзем алам. Калганнары сугымга. Сүз дә юк, аларын да сатабыз, – дип, үз бәясен әйтте. Сәлимгәрәйнең акчасы күп, аны акча кызыксындырмый иде.Сатулашып тормады:

— Әйдә, синенчә булсын, абзый. Яхшы кешегә түбән бәядән дә бирергә була. Тирә-як авыллардан килүчеләр бармы? Жыелышып чәй эчсәк, шул безнең килешү булыр иде, – дип ризалашты.

Хәйләкәр Шамбалга ат малы кирәк түгел. Сәлимгәрәйнең юмарт кеше икәнлеген белгәнгә, «Үземә», – дигән булып түбән бәя тәкъдим итә дә, шул ук көнне икеләтә хак белән сатып жибәрә. «Сугымга» дип бәяләгән атлар да таза, эшкә яраклылар. Кыска гына арада Шамбал, Сәлимгәрәй кызыксынган кешеләрне табып, түшәм астында чәй булдырды.Теләгәннәргә кымыз да бар иде. Озак кына вакыт дөнья хәлләре, яңалыклар турында сөйләшеп утырдылар. Сәлимгәрәй ишетми калган күп кенә яңалыклар ачылды.

Моннан биш ел элек урыслар Кырымга яу белән барган булганнар. Юллары уңмаган. Төрки халыклар белән сугышырга урысларның алымы яраклы түгел икән. Шул вакыттагы уңышсызлыклардан соң хәзерге яшь патша «калмык, татар, башкортларда икән өмет» дигән фикергә килгән. Шушы көннәрдә урыс гаскәриләре бу якларга килеп, патша хезмәтенә яшьләрне жыячак ди. Халык санына карап станнан биш кеше алынырга тиеш. Шуларның берсе, һичшиксез, Сәлимгәрәй малае. Бу хәбәр хатынны өркетмәде, ничә елга алачаклар дип кенә сорап куйды. Егерме биш елга икәнен ишеткәч, салкын канлылык белән: башы исән булса әйләнеп кайтыр. Гомере беткән кеше юк кына чирдән дә үлеп китә. Алсалар алалар инде, ни хәл итмәк кирәк, дип артык борчулык күрсәтмәде. Малаең жәл түгелме, дигән сорауга: синең тагын бер өзелеп яраткан малаең бар. Ә минеке андый авыр эшкә яраксыз. Анасы белән никахлашып халык алдында малаеңны таны. Мин каршы түгел, дип сүзен очлап куйды.

Билгеләнгән көнгә тирә-яктан кунаклар килеп төште. Таң белән торып Тархан мулласын ыру башлыгы үзе барып алып килде. Казаннар асылган, сый-хөрмәт әзер. Түземлелек белән халык яңалык көтә. Хәлнең асылын муллага юлда килгәндә үк сөйләгән иде. Бану белән дә кичтән үк аңлашу булып алды. Бу гамәлнең асылын аңлаган хатын шатланмады. Башын аска иеп күндәмлек белдерде, хатын-кыз тирмәсендә юынып, чистарынып, «бәйрәмгә» әзерләнде. Иртә белән берничә хатын-кыз, чәчләрен тарап үреп, сөрмә тартып, бүләк ителгән затлы киемнәрне киендерделәр. Буласы бәйрәмнең сәбәбен улына Бану үзе житкерде.

— Атаң рәхмәтенне белдерер көн житте, улым. Туган көненнән алып аның канаты астында булдың, юклыкта интекмәдең. Безгә хәзер шуның бәясен түләү көне житте.

Егет гажәпләнмәде.

— Солтангол минем туганым икән! – дип кенә куйды.

Яңалык стан халкын да гажәпләндермәде. Беравыздан хуплап:

— Бик әйбәт, бик мәслихәт! Күптәннән вакыт иде! — дип, тәбрик сүзләре әйтелде. Туй бәйрәме генә түгел иде бу. Тагын берничә көннән Әхмәтнәсирне патша хезмәтенә озатасы бар. Шунын хөрмәтеннән иде бу мәҗлес. Ярлырак гаиләләрдән хезмәткә барасы яшьләргә бай берәр баш ат бүләк итте. Юлга аласы ярты айлык азыкны да үз исәбеннән хәзерләргә кушты.

Кул тегермәнендә талкан ярмасы тарттырып, борай онынннан әбиләр катламалар пешерде. Агайлар сарык суеп учак төтенендә ысладылар. Озагракка саклана торган азык урынына язгы кояш астында какланган елкы итен күп итеп юл капчыкларына салдылар. Китәсе көнне: «Баргач әхфитсирләрне сыйларсыз», — дип, йөк атларына бер курдюк кымыз да тактылар. Әхмәтнәсир уйнаклап торган ике чаптарны атлар көтүеннән үзе сайлап алды. Атасы ана үз хәнҗәрен һәм соңгы базарда үзбәкләрдән зур бәягә сатып алган булат кылыч бүләк итте. Анасы, үз куллары белән чиккән чапан, Гөлсыру апа читек бирде. Билгеләнгән көнне тирә-як авыллардан яшьләр җыелды. Йөзгә якын кеше тирәсендә озата баручылар да аз түгел иде. Тархан мулласы моңлы мәкам белән «Әлһәм» сүрәсен укыганнан соң, яшьләр тәкъбир әйтә-әйтә, дәррәү юлга кузгалды. Озата калучылар арасында елаш, сыкрану.

***

Юл уңаенда татар авылыннан аларга тагын бер төркем кушылды. Кояш баеп килгәндә алар Бозаулык тавында иделәр. Түбәндә, Самар елгасы буенда, киндер ак чатырлар күренде. Чатырлар тирәсе тәртәләрен күтәрткән арбалар белән уратып алынган. Бер читтәрәк атлар белән йөк үгезләре чирәм уртлый. Яна килүчеләрне станда булып киткән күзлекле хәрби каршы алды. Кулында дәфтәр белән каләм. Хезмәткә алынганнарны аерып алып тезделәр. Озата килүчеләргә рәхмәт әйтеп, кире китәргә рөхсәт бирелде. Тылмач аша сорашып, кем, каян икәнен, исемнәрен дәфтәргә теркәделәр. Үзләре белән алып килгән азыкларнын бер өлешен пешекчегә тапшырырга кушылды. Соң иде инде.Кем кая урнашырга кирәклеген аңлатып йокларга әзерләнделәр. Атларны тышаулап, Әхмәтнәсир үз төркеме белән ачык һавада гына йокларга ниятләде. Көз ае керүгә карамастан, төннәр җылы иде әле. Кояш чыгар алдыннан аларны быргы тавышы уятты. Күмәкләшеп инеш буена барып битләрен юганнан соң, рәт-рәт тезеп бастырдылар да,тылмач аша эчке тәртип, көнлек кагыйдәләр турында хәбәр ителде. Иртәнге аш алдыннан барысын да хәрби духтыр карап чыкты. Аштан соң атларны барлап, су эчертеп, күпмедер вакыт узды. Өс киемнәре бик иске булганнар хәрби киемгә киенде.Кемнең нәрсәгә сәләтле булуын ачыклап төркемнәргә бүлделәр. Төшке аштан соң атларда чабышу, ук ату, көрәш уеннары башланып китте. Кичке аштан соң бераз вакыт сугыш тәртипләрен өйрәнергә бирелде. Йокыга ятар алдыннан атларны барлап су эчерү, төнгелеккә әзерләнү. Әнә шулай атна-ун көн вакыт узып көн кичкә авышкан вакытта, зур гына бер төркем башкортлар килеп төште. Өсләрендә кәҗә тиресеннән теккән кием. Кемнен башында бүрек, кемнекендә кыргыз калпагы. Кораллары да төрлечә. Кемдә сөнге, кемдә кылыч. Уклы садак белән җәя барысында да бар иде. Урал якларындагы башкортлар икән. Тылмач аралашырга теләп караган иде, телләрен аңламады. Бу яклардагы башкортлар, татарлар белән аралашып яшәгәнгә, күрәсен, аңлаешлы телдә сөйләшәләр иде. Алар арасында урыс телен аңлаучы да табылмады. Барысы да дөнья күрмәгән, башка халыклар белән аралашмаган яшьләр иде.

Әхмәтнәсирләр станында, Урал якларыннан килеп урнашкан, тимерчелек белән шөгыльләнүче башкорт гаиләсе яши иде. Атлар дагалаганда, комган төпләрен рәтләтергә барганда, тимерче балалары белән аралашып, алар

телен анлый иде. Шунын өстенә урыс телен дә сукалый. Ярдәмгә ул килде. Шул көннән алып башкортлар белән аралашырга аны сайладылар. Бу үзенә күрә бер дәрәҗә иде. Егет башкортларга эчке тәртип, кагыйдәләрне анлатты. Башкортлар зур чатыр эчендә кайнар су белән коенып чәчләрен кырдырудан баш тартмадылар. Өс киемнәрен утта яндырып хәрбиләр киемен кию кирәклеген ишетү белән «Йок!» – дип бер сүз белән каршы килделәр. Төнне дә алар чатырдан читтә, аерым урында уздырдылар.

Жыеласы халык жыелып бетте. Хәрбиләр житәкчесе стольник Туренев Семен Осипович, йокыга ятар алдыннан барысын да рәткә тезеп бастырып, иртәгәдән юлга чыгачакларын әйтте, юлда баруның тәртибен анлатты. Башкортлардан илле кеше сайлап алып авангард төркеме билгеләнде. Төркем житәкчесе итеп ике хәрби драгунны, тәржемәче итеп Әхмәтнәсирне куйды. Иртәнге таннан алар төркеме юлда иде инде. Барасы юл Жаек ныгытмасы ягына. Көз аенын урталары. Юлларда жан әсәре юк. Тирә-як кипкән, корыган. Салмак кына юыртып бара торгач, шактый юл үтелде.Юлдан читтәрәк уйсулыкта төнгелеккә туктадылар. Әзме-күпме ул тирәдә атлар чемченерлек үлән бар иде. Төн уртасында обоз килеп житте. Арбаларны бушатмый гына, атларны тугарып, обоз да ялга тукталды. Тан ату белән авангард төркем юлын дәвам итеп, икенче көнне төш вакытларында тар гына елга буенда урнашкан авылга барып керделәр. Урам буш иде, кеше заты күренми. Төрлечә киенгән кораллы башкортлардан куркып өйләренә яшеренгәннәрдер. Араларында хәрбиләрне күреп, әкрен генә халык жыелды. Узган төнне бер төркем караклар малларын талап киткәннәр икән. Сораша торгач, якынча ничә кеше булуы, кай якка китүләре ачыкланды. Үзара киңәшеп, ун атлы карак артыннан куа чыгарга, калганнары обоз көтеп авылда калырга карар кылынды. Көн буе ат өстендә йөреп талчыккан булуга карамастан, куа чыгарга атлыгып торучылар аз түгел иде. Беренче булып Әхмәтнәсир алынды. Тиз арада төп карарга килеп, халык күрсәткән якка чаптырып китеп тә бардылар. Эзләр төньяк-көнбатышка, Самар шәһәре ягына юнәлгән иде. Карангы төшеп килгәндә эз елга буена алып чыкты. Елга буенда яшел чирәм. Карангыда эзәрлекләү мөмкин түгел, төнгелеккә туктадылар. Тан белән, юлларын дәвам итеп, бераз ара үтү белән учак калдыгына тап булдылар. Көле суынып та өлгермәгән. Димәк, караклар ерак түгел. Маллар эзе инеш яры буйлап көнбатышка киткән. Жаектан Самар ягына бара торгач, юл өстендә эзләр юкка чыкты. Төркем икегә бүленеп ике якны да барлый торгач, эз елганың икенче ягында табылды. Ул тирәдә елга кин. Яр буйлары куе таллык. Озакламый алда көтү күренде. Тыныч кына үлән уртлаган сыерлар арасында атлылар күренми. Яр буенда учак яна. Хужасы юк. Яр астына төшеп яшеренгән булган. Жилкәсеннән сөйрәп чыгардылар. Сакал-мыек баскан илле яшьләр тирәсендәге ир. Сорауларга жавап бирми торгач, арадан бер кызу канлы егет: «Синең белән сөйләшәләр, хәшәрәт», дип камчы белән аркасына сыдырды.

– Ашыкмагыз, егетләр. Бәлки, ул телне анламыйдыр, – дип, арага Әхмәтнәсир керде. – Ты урус? Другой люди эгди? – Яклаучысынын йомшак итеп эндәшүеннән теге адәм, карашын егет ягына борып, авызын ачты. Анын авызында тешләре дә, теле дә юк иде.

– Язык атрезал штоли? Ыхто атрезал? Карова чей? Другой люди эгди?

Көтүче башын кага-кага кояш баешы ягына төртеп күрсәтте. Башкача белешмә алып булмасына төшенеп, егетләр теге мәхлүк күрсәткән якка юлларын дәвам иттеләр. Бераздан, елга борылышы артыннан, усаклар арасыннан өй түбәләре күренде. Кояш офыкка төшеп килә. Карангыга калганчы хәлне ачыкларга кирәк иде. Жан-фәрманга авылга барып керделәр. Елга буена тезелеп утырган агач өйләр. Авыл артык зур түгел.

Тиз арада йортларны уратып алып, халык анга килеп өлгергәнче, тикшерү башланды. Көтелмәгән шау-шудан аннарына килеп өлгермәгән кешеләр сорауларны анлап бетермәделәр, акландылар гына, имеш, без белмибез. Без берни урламадык. Әнә теге кырый йортта чит кешеләр. Алар короллы. Сак булыгыз, алар усал кешеләр... Егетләр дәррәү шул якка чаптырып киттеләр. Шул вакыт аллы-артлы ике мәртәбә мылтыктан аттылар. Әхмәтнәсир килеп житкәндә инде бер егет яраланган, икенчесенең атына ядрә тигән иде. Тиз арада хәлне анлаган егет, тәрәзә ягыннан китәргә кушып, иптәшләренә кул болгады. Кайсысыдыр өй янәшәсендәге салам түбәле сарайга ут төрткән иде. Дөрләп яна башлаган ут өй түбәсенә күчте. Янган сарай эченнән кычкырган тавыш килгәч, ишеген бәреп ачтылар, кул-аягы бәйле кешене сөйрәп чыгардылар. Шаулап яна башлаган өй ишегеннән ике адәм күренде. Тиз арада аларны бәреп егып кулларын бәйләделәр. Егетләрнең берсе жәһәт кенә өй эченә узды. Озакламый ишектә тагын ике карак күренде. Ике як иненә ике мылтык асып артларыннан егет чыкты. Ул чыгу белән, еллар буе утырып чыра агачы шикелле кипкән өй түбәсе эчкә ишелеп төште. Читәннән үреп салам белән ябылган сарай көлгә әйләнгән иде.

Әхмәтнәсир янәшәсенә башкорт егете килде.

— Теге адәм нидер әйтергә тели. Телен анлап булмый, сөйләш үзе белән, — диде. Сарай эченнән коткарылган кеше турында әйтә иде ул. Янган өй тирәсенә халык жыелган, шау-шу киләләр. Егет теге адәмне читкәрәк алып китеп: — Ни әйтергә телисен? Сез бу каракларны белә идегезме? — дип сорау бирде. Анын алдында корымга буялган олы яшьләрдәге кеше иде. Сүз әйтергә дип авызын ачкан килеш ул бертынга тынып калды. Күз карашы Әхмәтнәсирнең билендәге хәнжәрдә иде. Тиз генә үзен кулга алып, басынкы тавыш белән: — Бу адәмнәр бишәү иде. Араларында башлыклары юк. Ерак китеп өлгермәгәннәрдер, эзләргә кирәк, — диде.

Тиз арада егет хәбәрне башкаларга житкерде. Карак кай якка качып китәргә мөмкин булуын урындагы кешеләрдән белешеп, артыннан куа чыктылар. Авылдан читтәрәк урман аланында бер көтү атлар үлән уртлый иде. Тирә-якны барлап,тикшереп чыгу нәтижә бирмәде. Атларны куып алып кайттылар. — Бер ат житешми. Ат өстендә качкан булса эзләүдән файда юк, — диде бу ят кеше.

Күз бәйләнеп килә, юлга кире чыкмый авылда төн уздырасы иттеләр. Янәшәсендәге йорт хужасы, без күршеләрдә кунарбыз дип, егетләргә фатир тәкъдим итте. Яралы егет иптәшләреннән аерым йокларга теләмәде. Ярасы култык арасыннан үтеп беләге белән күкрәк чите жәрәхәтләнгән. Атнын да жәрәхәте зыянлы түгел иде. Каракларнын кул-аякларын бәйләп, фатир хужасынын сараена яптылар. Карангы төште. Өй эчендә Әхмәтнәсир белән теге олы адәм генә иде. Шомартып эшләгән такта өстәл өстендәге шәмне кабызып, егет юл капчыгыннан ризыклар чыгарды. Көн буе авызына валчык капмаган, ашыйсы килә иде. Кынысыннан хәнжәрен чыгарып каклаган сарык итен кисәкләргә кискәләде.

— Синең дә тамак ачтыр, булганыннан авыз ит, — дип картка ишарә итте.

Күренеп тора, картнын да ашыйсы килә. Тик ул иткә үрелергә ашыкмады. Биргән соравым урынлы булырмы дигәндәй, тыйнак кына сорап куйды:

— Бу хәнжәр каян эләкте сина, олан?

— Нәрсә? Ошыймы? Атам бүләге бу!

— Ә син кай яктан килеп эләктен бу тирәгә?

— Патша хезмәтенә алдылар безне. Ерактан без. Юл унаенда караклар турында белгәч, куа чыгасы иттек. Ашагыз, аша! Тартынмагыз. Бу безнен жәйләү сарыгы ите.

Карт бер кисәк ит алып авызына капты. Бер яктан икенче якка әүмәкләп бертын сүзсез утырды һәм, көтмәгәндә генә:

— Атаңның исеме Сәлимгәрәйме? — дип сорап куйды.

Егет ашавыннан туктап калды.

—Әйе. Ә сез каян беләсез?

— Анаң исеме Гөлсырумы?

— Юк. Бану. Гөлсыру апа атамның олы хатыны.

— Алай икән... Шулай булыр дип уйлаган идем.

Кызыксынудан егет ашавын онытты.

— Сез кем? Аларны каян беләсез?

Карт тирән канәгатьлек белән сорауга каршы сорау бирде:

— Кай яктан диден әле син үзеңне?

— Тархан якларыннан мин. Манаш токымыннан.

— Атаңның Артай дигән кеше турында сөйләгәне булмадымы?

Ник булмасын, булды! Кышкы озын төннәрдә Сәлимгәрәй, алар тирмәненә кереп, Артай атлы атлар карагы турында әкиятләр сөйли иде ич. Кыпчак далаларын дер селкетеп торган ул адәм турында күп нәрсә ишетеп үсте ул.

— Артай турындагы хикәятнамәләрне сез дә беләсезме? — диде егет, ни дә әйтергә сүз тапмыйча.

Карт көлемсерәде:

— Аңлашыла. Хикәятнамә итеп булса да искә алгалаган икән. Ул адәм мин булам. Артай мин.

Ышаныргамы, юкмы дигәндәй, ни әйтергә белми катып калган егет алдында үз сүзенең хак икәнен исбатларга ниятләде бугай.

— Атаң белән без утны-суны кичтек. Күп нәрсә күрергә, кичерергә туры килде. Заманында дәһшәтле Степан Разин белән дә очрашу насыйп булды безгә. Әнә синең билеңдәге бу хәнҗәрне үз кулы белән атаңа Разин бүләк итеп биргән иде. Бу затлы әйбернең бәясе хәнҗәр буларак кына түгел, олан. Атаман буларак Дон казаклары белән төрекләргә каршы яу барган җирдә кулга төшерә ул аны. Чулак Әхмәт паша хәнҗәре!»

Бу турыда да ул сабый чагында ук ишетте. Тик күңел ышанып бетә алмый. Әкият батыры Артай үземе?!

— Ничек сез бу адәмнәр кулына эләктегез? Кемнәр алар?

Ризыкка рәхмәт әйтеп, карт дога кылды. Сакал-мыегын сыпырып стенага сөялде. Нәрсәдән башларга белми бер тын уйланып торып, ашыкмый гына сүзен башлады.

— Моның тарихы зур, олан. Бер кичтә барысын да сөйләп бетерү мөмкин түгел. Кыскасы шул, Степан Разин җитәкчелеге астында патшага каршы сугышырга туры килде безгә. Соңгы чиктә аны тотып алып җәзаладылар. Котүчесез калган маллар шикелле кайсыбыз кая таралыштык. Иң якын кешеләрем белән өчәү үз төркемебездән качып китәргә булдык. Бөтен байлык алар белән калды. Без үзебез яшәгән якка кайттык. Атаң үз якларына кайту теләге белдергәч, сеңлем Гөлсыруны хатынлыкка алып, үз даласына озаттык. Берничә ел хәбәрдәшле булып торган идек. Әкренләп ара өзелде. Соңгы мәртәбә ишетеп белүемчә, сеңел балага уза алмаган. Синең икенче хатыннан булуың мина аңлашыла, олан. Ни хәл итәсең, атага бала кирәк. Ә мин, кәсебемне ташлап, картлыкны тыныч кына каршы алырга җыенган идем... Уйлаганча килеп чыкмады.

Карт сөйләвеннән туктап калды. Урыныннан торып, почмактагы чиләктән су эчте. Үз урынына барып утырып, сүзен дәвам итте.

— Сез бүген кулга алып сарайга япкан бәндәләр заманында минем сабандашларым иде. Сарытауда ялгыз калгач, үзара кырылышып мал бүләләр дә кайсы-кая таралышалар. Эзәрлекләүләрдән качып йөреп,

күпмедер вакыт узгач, берничәсе тагын күмәкләшә. Яшьли башка төрле һөнәргә өйрәнмәгән, кеше талап иркен яшәргә күнеккән кеше буларак, алар янабаштан шул кәсеп юлына басалар. Араны өзүгә биш-алты ел вакыт узгач, малларны урлап алып киттеләр. Кемнәр эше икәнен белдем. Хәерле булсын дип үч тотмадым. Тагын берничә елдан килеп атларны да куып алып киттеләр. Анысы да алар эше иде. Түздем. Аларга минем алтын кирәк булган. Шул елның көзендә, халык тирән йокыда чакта, үзәндәге коры камышлыкка ут төрттеләр. Уратып алган көчле ут эчендә өйләребез белән утырып яндык. Барлыгы берничә кеше генә котылып кала алды. Карт-коры, бала-чага, хәлсезләр тотендә тончыгып янды. Аксайга китеп урнаштык. Янган төнне якын иптәшем Каратай авылда юк иде. Бераз вакыттан безне эзләп тапты ул. Тыныч яшәргә ирек бирмәсләр. Үзләрен эзләп табарга, чарасын күрергә кирәк дип ул үгетләгәч үч алырга ниятләдем. Үзем белән исән калган егетләр дә шул фикерне куәтләде. Яшәгән җирләрен эзләп таптык. Гаиләләре генә иде. Кайтырлармы дип ике тәүлек буе сакта көттек. Еракка киткәннәрдер, кайтмадылар. – Сөйләвеннән туктап карт тынып калды. Узганнарны күз алдыннан кичереп, күрәсен, дулкынланган иде ул. Калтыранган тавыш белән аклангандай сүзен дәвам итте. – Яшьлектә күп кан коярга туры килсә дә балаларга кул күтәргән булмады. Ачуыбыз бик көчле иде шул. Кычкырышып утта янган гөнаһсызларның әҗәлен күрегез сез дә дип, берсен дә исән калдырмадык. Йортларын утка тоттык, малларын алып киттек. Арттан куа чыгып очрашмабызмы, араны бөтенләйгә өзәргә мөмкин булмасмы, – дип Чалкар күле камышлыгында яшеренеп көттек. Килмәделәр.

– Ә хәзер ничек алар кулына эләктегез?

– Шакал токымыннан яралган бүре була алмый. Күзгә-күз очрашырга йөрәкләре җитмәде. Астыртын юл сайладылар. Тирә-юньдәге авылларны талап, утка тотып, Артай исеменнән золым юлына бастылар. Өстәвенә, ялган хәбәрләр таратып, халыкны мина каршы күтәрделәр. Яман хәбәрләр Сарытауга барып ирешкән. Мине тотып тапшырган кешеләргә биш йөз тәнкә акча вәгъдә иткәннәр.

– Акланырдай чара табып булмадымы? Һич югы китәргә иде еракка, Актүбә, Арал якларына.

– Һәй, олан! Яшь шул әле син! Солыны чәмчүктән аера белмәгән чагың. Аклану ир егет эше түгел. Үз шәүләңнән качып китеп котылу мөмкинме?.. Ир егетенең көче аяусызлыкта гына түгел, олан. Кылган гамәленә дөрес бәя бирә белергә дә кирәк. Халык көчленең канаты астына елыша, көчлене ихтирам итә. Шакал кебек үз шәүләңнән куркып халык алдында көчсезлегеңне күрсәткәнче, арысландай көрәшеп үлү мең тапкыр гаделрәк. Узган елны очраштык без алар белән. Бәрелеш каты булды. Алар ишле иде. Без барлыгы алты кеше идек. Алар ягыннан югалту өч мәртәбә артык булуга карамастан, без барысы икәү генә калдык. Көчле яра алып, аңымны җуйганмын. Юлдашым Каратай төн караңгылыгында мине коткарып калган. Үзе дә яралы иде. Уел елгасы буенда яшәгән бер таныш гаиләдә кыш кышладык. Җәй башлары җитеп хәл кергәч, Аксайга кайттык. Ышанычны югалткан халык арасында яшеренеп яшәү кыен. Төрле җирдә урын алыштырып җәй уздык. Эзгә төштеләр.Унлап кешегә ике кеше каршы тору җиңел түгел. Алай да өчесен үтердек, икесе каты яраланды. Ә мин якын, ышанычлы кешемне, Каратайны югалттым. Яралы арыслан шикелле көрәшеп һәлак булды. Үз кулым белән күмә алмадым, шунысы аянычлы.

– Ә сезне ничек исән калдырасы иттеләр?

– Алар уенда, олан, мине хөкүмәткә тапшырып акча эшләү иде. Биш

йөз сум ул бик зур акча.Тик хикмәт акчада гына түгел. Акча белән бергә аларнын ирек аласылары килде.

– Андый уй булгач, ник алар юл унаенда кеше талаганнар?

– Бүрене бүреккә салсаң да урманга карый дигәннәр борынгылар. Нәфесләре көчле, гакыл аз. Зиһененә шайтан оялаган кеше тиз генә айный алмый. Иркенлек алгач андый мөмкинлек булмас, урлап калыйк дигәннәрдер.

– Юлда килгәндә бер адәмне очраттык. Теле кисек. Ул да бу төркемнәнме?

– Анысын белмим, олан. Гөнаһысына керә алмыйм. Урланган малга күз-колак булучы кирәк бит. Тапканнардыр берәрсен. Азмы хәзер ил буенча каңгырып йөрүчеләр...

Ике тәүлек ат өстендә йөреп талчыккан егетне йокы басты. Эч маеннан тундырылып ясалган шәм эреп бетеп, бертын кагынгалап алды да, өй эчен карангылык басты. Төннең икенче яртысы, соң иде инде. Арыганлык үзенекен итте. Картның тыныч кына мыңгырдап сөйләве, бишек көе шикелле тибрәндереп, күз кабакларын авырайтты, йокы үзенекен итте.

Көтелмәгән бу очрашу Артайның үзен дә дер селкетте. Үз гомерендә болай иркенләп утырып эч серләрен бушатканы булмады. Әнә ничек бит ул язмыш дигән нәрсә! Ничә дистә еллар узып, онытылып беткәндә генә Сәлимгәрәй тагын бер мәртәбә үзен искә алдырды. Малае да үзе шикелле. Кызганычка каршы, онык Гөлсырудан түгел. Картның йокысы качкан иде. Җинелчә хәҗәтен үтәргә дип ишек алдына чыкты. Сарай ягынарак барыйм дисә, күрә – сарай ишеге янында кеше шәүләсе. Ишеген ачарга азаплана бугай. Артай утынлыктан капшап кулына күсәк алды. Кыр песие шикелле йомшак кына атлап якынайды да гөрселдәтеп тегенең арт лепкәсенә сукты. Җиргә капланып төшкән гәүдә өстенә иелеп кесәләрен капшады, итек кунычын барлап чыкты. Карт эзләгән нәрсә тегенең кулында булган икән. Ишекне ат кылыннан үргән аркан белән бәйләгәннәр. Тиз арада гына пычак белән кисә алмаган. Артай, киселеп бетмәгән арканны чишеп, сарай эченә узды.

8

Егет, төртеп уяткандай, йокысыннан уянды. Күргән төшеннән арына алмыйча бертын аңга килми торды. Ат караклары... Артай... чәчәккә күмелеп утырган дала... уйнаклап чапкан атлар...

Тышкы яклап кабатланган тавыштан айнып китеп торып ук басты. Тәрәзә аша тоныкына булып яктылык иңгән. Үзенең кайда икәнен тәгаен төшенеп урамга чыкты. Елганың икенче ягында күк йөзе агарган, яктырып килә. Сарай алдында берничә кеше, кызып-кызып үзара нидер сөйлиләр. Иртә таңнан нәрсә күтәргән аларны аякка? Йөгерә-атлый сарай янәшәсенә килде. Йөзтүбән капланып җирдә ят кеше ята. Сарай ишеге ачык.

– Ни булды? Бу кем? – дигән сорауга араларыннан берсе:

– Кичә кич качып киткән караклар башлыгы бу. Иптәшләрен йолып алырга килгән, күрәсең.

Күңеле нидер тойгандай егет сарай эченә узды. Кан укмашкан сарай идәнендә кул-аяклары бәйле килеш дүрт мәет ята. Егетнең күңелендә туып өлгергән сорауны тойгандай, йорт хуҗасы:

– Теге карт өй эчендәме? – Егетнең «юк, ахры», – дип җилкә кагып куюын күреп: – Бу – анын эше. Гәүдәсе аныкына охшаган иде. Шикле ыгы-зыгы тоеп тышка чыккан идем. Офык яктысында шәүләсен күреп калдым. Чаптырып киткән ат тояклары тавышын ишеттем.

Димәк, карт Артай аласы үчен алган. Картлыгында ялгыз башы кая барып сыеныр?.. Бу дошманнарыннан котылды, ә башкалардан, урыс

эзәрлекләвеннән тынгылык табармы? Егет күнелендә шундый уйлар йөгереп узды. Шулай да, анын күнеле тыныч. Артай ирекгә! Тормышнын бар ягын да татыган кеше үз жаен табар!... Инша Алла! Хәерле юл сина, әкият батыры!

Озакламый халык уянды. Егетләр дә аяк өстендә иделәр. Халык белән кыска гына әнгәмә булып алды. Каракларлан алган ундүрт баш атнын дүртесен өе янган гаиләгә бирәсе иттеләр. Ярдәм иткәннәргә өчен авыл халкына рәхмәт әйтеп, үзләре белән һәрберсе берәр ат тагып, юлга кузгалдылар.

Маллар көтүе шул урында иде. Көтүчегә малларны кире якка куарга куштылар. Теге мәхлүк, каршылык күрсәтми ризалашып, башын кагып калды.

Кормыш авылында аларны яналык көтә иде. Өч йөз кешедән торган төркемгә тагын бихисап халык өстәлгән. Үз обозларын табып, егет булып узган хәлләрне йөзбаш Туреневка житкерде. Хәрби житәкче егетләрдән канәгать иде. Ике менгә якын кешене рәтләргә бастырып, булып узган хәлне сөйләп, егетләргә рәхмәт белдерде. Башкаларга да алар төркеменнән үрнәк алырга, илгә тугрыклы хезмәт итәргә өндәде. Йөзбаш сүзләренә караганда, үзләре белән алып кайткан ун баш ат күтәрде аларнын дәрәжәсен. Яна килгән халык арасында атсызлар да аз түгел иде. Яна кушылган төркем Жаек ныгытмасы ягыннан килгән. Барасы юл өстендә калмыклар далага ут төрткәннәр. Малларга азык юк. Үзләре белән алган мал азыгы да Царицынга кадәр житәрлек түгел. Егетләр кайтып хәлне сөйләгәч, Олы Иргиз елгасы буйлап Балакайга, аннан ары Сарытауга узарга карар кылынды. Елга буе үзәнлегендә малларга азык булуга карамастан, обоз өчен юл начар. Баткак, сазлы урыннар бар. Жайлы юл күрсәтергә Кормыштан ике кеше алынды. Шул унайдан,үз малларын аерып алыр өчен, тагын унлап кеше иярде. Икенче көнне иртә белән юлга кузгалдылар. Самар ягына барган юл тирәсендә мал көтүе очрады. Кормышлылар үз көтүен аерып алып, калганнарын, патша галижәнапләре исеменнән, обоз малларына куштылар. Әхмәтнәсир үтенечен кире какмыйча, теге телсез мәхлукка да маллар белән калырга рөхсәт ителде.

Маллар аягы белән әкрен генә атлый торгач, карангы төшәр алларыннан, Иргиз елгасы буенда урнашкан шул ук исемдәге авылга життеләр. Балакайга кадәр ара ерак иде әле. Төнгелеккә, авылдан читкәрәк чирәмле үзәнлектә, ялга туктадылар. Әхмәтнәсирләрнен илле кешедән торган авангард төркеменә тагын илле кеше өстәлде. Иргиздан туры юл булганлыктан, калган юлны тиз арада узып, көннен икенче яртысында алар Балакайда иде инде.

Талларга күмелеп утырган Идел ярындагы әлеге шәһәр искиткеч матур, жанга ятышлы. Шәһәрне читләтеп алар Идел ярына төштеләр. Менә нинди икән Идел! Дөнья күргән кешеләр аша ишетеп, балачактан зиһенне дулкынландырган дәрья суы! Бу гажәеп күренеш дала кешесен өркетте, тетрәндерде. Шул кадәр сунын кайда башы да, кайда азагы?!. Дәрәжәсен тоеп тын гына аккан агым күнелгә шом сала. Ә үз Иделләре булган башкортлар, тиз арада чишенеп, яссы яр буенда шау килеп, атлар йөздерә иде инде. Үзләрен һәрчак иркен һәм бәйсез тоткан бу халыкка карата үзеннән-үзе ихтирамлы гажәпләнү, соклану хисләре туды күнелдә. Бер яктан үзсүзле, кыргый һәм аяусыз булсалар, чынбарлыкта чая һәм житез, батыр йөрәкле халык.

Төн урталарында шәһәр читенә чыгып обозны каршы алдылар. Төнгелеккә чатырлар корып тормадылар. Балакайда озак тоткарлану каралмаган иде. Өч тәүлек буе рәттән саллар белән елганы кичеп чыгып, Сарытауга юнәлделәр.

Тәртип буенча Әхмәтнәсирләр төркеме алда иде. Ярты юл өстендә тагын бер елга суын кичеп, кичке буйда Сарытауга барып керделәр. Өсте-өстенә өеп салынган икешәр катлы өйләр, чуерташ түшәлгән тар урамнар. Бер-беренә сыенышып утырган өйләр арасыннан мәчет манарасы калкып тора. Ахшам намазына чакырып азан әйттеләр. Күнелләргә сары май булып яткан шул мәкамнән хозурланып, төркем, ашыкмый гына бара торгач, урам чатында алар каршысына атлы казаклар чыкты. Әхмәтнәсир, кулын күтәреп, үз төркеменә туктарга әмер бирде.Каршы алучылар кычкырып биргән сорау урыс теленә охшаш булуга карамастан, егет аңламады. Шулай да, җавапсыз калмас өчен: «Наше Сарытау иди. Наше командир Туренев. Он зади иди. Скуры эздис будит», — диде. Шәһәр сакчылары үзара сүз алышып, араларыннан берсе алгарак чыкты.

— Сез татарлармы?

— Без башкортлар. Мин үзем татар кешесе.

— Кай якка юл тотасыз?

— Безне патша хезмәтенә җыйдылар. Балакайдан чыктык. Командир Туренев обоз белән арттан килә.

Төркемдәгеләр тагын үзара гәпләшеп алдылар. Шуннан соң гына теге татар кешесе: «Безнең арттан иярегез», — дип, елга ягына алып китте. Урамнар буйлап боргалана-сыргалана торгач, шәһәр чите күренде. Сөзәк ярдан аска, елга белән ике арадагы үзәнлеккә төштеләр. Шәһәр яклап калкулык итәгендә чатырлар тезелеп киткән. Тагын да арырак бер көтү ат үлән уртлый. Яңа килгән атлыларга игътибар итүче булмады.

Аска төшү белән теге татар җайдагы Әхмәтнәсир янына килде.

— Минем исемем Сафуан.Үзегезгә охшаган урын табып урнашыгыз. Калганын иртәгә хәл итәрләр, — диде.

Җайлы урын эзли торгач, шактый гына ара узылды. Шәһәр яклап калкулык итәгендәге җир артык дымлы, тагын да арырак — күлләвек. Инеш буе калкулыгында туктыйсы иттеләр. Караңгыланганчы урнашып өлгерәсе иде. Туктау белән Әхмәтнәсир, юл капчыгыннан җиз чәйнеген чыгарып, янәшәсендәге егеткә елгадан су алырга кушты, калганнарына учакка утын хәстәрен күрүне йөкләде. Озакламый дөрләп учак кабынды, өстенә чәйнекләр элделәр. Кемдә нәрсә бар, юл капчыкларыннан ризыкларны чыгарып, капкалап алырга утырдылар.

Балачактан табигатькә яраклашып ат өстендә үскән дала кешесенең юлда кирәк булган бар нәрсәсе дә үзе белән. Ат тиресеннән эшкәртелгән җинел ияр. Ияр астында икегә бөкләгән киез. Иярнең арт җаясенә юл капчыгы, алгы җаягә салак белән ук җаясе беркетелгән. Кәҗә тиресеннән теккән ыштан белән кәзәки, аякта җинел читек. Баш киеме — бүрек яки киез калпак. Җылы вакытта бүреге капчыкта. Юл капчыгында да артык нәрсә юк. Төреп бәйләгән сарык тиресе. Ул аска җәеп йоклар өчен. Какланган ат ите, төрле үлән, чәчәкләрдән җыеп киптерелгән төнәтмә-чәй. Юка каеш бау, без һәм җиз чәйнек. Хәнҗәр белән кылыч билдә, сөнгесе кулда. Аңа йомшак ятак кирәк түгел. Баш очына ияр, аска сарык тиресе. Йомшак киез белән төренә дә яту белән гырлап йокыга да китә. Төрле очракка яраклашкан нәзберексез сугышчы. Тәүлек буе керфек какмый, ашамый-эчми йөргәндә дә жегәрген җуймаган, түзем җан иясе ул дала кешесе. Аның өчен иң якын, иң ышанычлы нәрсә — ат. Атсыз ул — ике канатсыз.

## 9

Көннең икенче яртысында обоз килеп житте. Кичтән авангард төркем сайлаган елга буенда чатырлар кордылар. Тәртәләрен күтәреп арбаларны тирә-яктан тезделәр дә, уртага ике зур казан элделәр. Үзләре белән куып алып килгән малларны, атлар белән бергә ерагракка илтеп, ике дистә кешедән сак куелды.

Беренче көн юынып, чистарынып, ял итеп узды. Бу урында озак тоткарланырга туры киләчәк иде, өч баш сыер суйдылар.

Быргы тавышына йокыга ятып, уянып, атларда чабышып, сугыш уеннарына өйрәнеп, ике айга якын вакыт узып та китте. Ноябрь урталарында тундырып җибәрде. Меңләгән баш мал-туар үзәнне кыркып бетереп, утардагы азыкка күчтеләр. Бу тирәдә артык тоткарлануның кирәге калмады, көн өстендә җыенып юлга кузгалдылар. Барасы юл көньякка, Царицынга таба иде. Авангард төркемне тагын йөз кешегә арттырдылар. Җитәкчесе итеп йөз башы Туренев үзе алынды. Бу юлы авангард төркеменә тагын бер эш йөкләнелде. Юл унаенда азык әзерлисе бар. Кирәк була калса дип үзләре белән биш-алты баш ат алган иделәр. Бу бик урынлы булды. Акчага караганда ат малы үтемле. Ул атларны Камышлы базарында он белән фуражга алыштырдылар.

Царицында әле җылы иде. Идел белән Дон елгалары арасындагы үзәнлектә маллар өчен үлән азыгы да җитәрлек. Юлга чыгуга биш тәүлек дигәндә әнә обоз да килеп җитте. Җайлы урында чатырлар корып кышны шунда кышладылар. Тәртип шул ук иде. Атларда чабышу, сугыш уеннары. Өч мең тирәсе кеше. Татарлар күп түгел. Меңгә якын башкорт атлылары, мең ярым тирәсе калмыклар.Йөзәр кешене төркемгә бүлеп, башлыклары итеп татарларны билгеләделәр. Бу хәл барысына да ошап бетмәде.Торып-торып арада ызгышлар чыккалый.

Апрель азакларында өстән фәрман килеп ирешә. Көн өстендә юлга җыенып, Дон елгасы буйлап, Азов диңгезе ягына юнәлделәр. Аларга кырым татарларыннан Азов ныгытмасына юлны кисү бурычы йөкләнгән иде.

Май ае уртасында урыс гаскәриләренең бер өлеше, Дон елгасы буйлап йөзеп төшеп, Азов ныгытмасы янәшәсенә урнаштылар. Июнь азакларында шул ук юл буйлап, төп көчләр килде.

Головин белән Лефорт җитәкчелек иткән бу көчләр арасында яшь патша үзе дә бар иде. Азов ныгытмасын камап алып эреле-ваклы туплардан атулар башланып китте. Соңгы елларда төрекләр бу ныгытманы өстәмә рәвештә ныгытып, тирә-ягына чокыр казып, җирдән валлар өйгән булганнар. Өстәвенә, тагын бер кат стена белән уратып, дүрт почмакка дүрт каланча да куелган иде. Атышлар вакытында урыслар стена астына чокыр казырга керештеләр, бер каланчаны яулап алдылар. Икенчесен төрекләр үзләре ташлап китте. Шул төнне бер урыс хәрбие төрекләр ягына качып чыга, урысларның төшке аштан соң иркенләп ял итәргә яратканлыгын әйтә. Ике каланчаны кулга төшерүне зур җиңү дип, урыс гаскәриләре тынычланып кала. Төшке аштан соң черем иткән вакытларында төрекләр һөҗүм итә. Күп кан коела. Каланча киредән төрекләр кулына күчә. Вал астында казып дары шартлату да нәтиҗә бирми. Кирәк урынга кадәр казып, эшләрне җиренә җиткереп эшләмәү нәтиҗәсендә, утызлап урыс гаскәрие үлә, йөзләп кеше авыр яралана. Тагын берничә кат һөҗүм итү аркасында төрекләр арасында югалтулар булса да, үзара килешмәү, төп стратегия булмау теләгән нәтиҗә бирми. Атлы көчләр белән дә шул ук хәл. Башкорт атлылары Кырым татарлары белән сугыш алып барганда калмыклар хәрәкәтсез тик тора. Төрекләр белән калмыклар бәрелешкәндә башкортлар ярдәмгә ашыкмый.

Көзге карлы яңгырлар башланып, юллар баткак хәлгә төшә һәм ныгытманы камау туктатыла. Артка чигенеп, кайту ягына борылалар. Форсаттан файдаланып Кырым татарлары һөҗүмгә күчә.Төрле көтелмәгән урыннарда һөҗүм ясап, чигенеп барган урысларга кыенлыклар тудыра. Җитмәсә — атларына азык юк. Күп җинелүләрдән төшенкелеккә төшкән атлы гаскәриләр артык каршылык күрсәтүгә сәләтсез була.

Азов ныгытмасында беренче поход уңышсыз тәмамлануга карамастан, күп кенә житешсез якларны ачыкларга, яңача уйларга мөмкинлек туа. Мона кадәр сугыш уеннары гына уйнап үскән яшь патшага бу зур сабак иде. Су йөзгечләре, көймәләр, галералар булмау аның өчен иң зур аяныч иде. Җәйге сугыш барышында, ничек итеп төрек дингезчеләре Азов ныгытмасына ашамлык һәм яна көчләр белән ярдәм итеп торганын үз күзе белән күреп белгәнгә, дингез аша ул юлны кичми торып җиңеп булмасын аңлый. Ил буйлап белгечләр җыеп, көймәләр, зур галералар төзү эшен башлап җибәрә. Гади эшче булып үзе дә бу эштә катнаша. Башкортларның бер өлеше, шау-шу куптарып, туган якларына кайтып китә. Әхмәтнәсир белән Бозаулыкта тупланган төркем калмыкларга ияреп далада кыш уздыра.

## 10

1696 елның кышында, Петр I каты авырып түшәккә ята. Шул айларда тәхеттәге туганы Иван үлә. Элек ил белән ике туган идарә иткән булса, тәхет тулысы белән яшь Петр I кулына кала. Ниһаять Кремльдә тамыр җәйгән иске кагыйдәле тормышка чик куела. Үз вазифасыннан файдаланып, патша бөтен көчен яна походка әзерләнүгә багышлый. Сугыш осталары, дингез көймәләре төзүчеләр, жир казып ныгытма шартлатучылар, камау белгечләрен эзләп ышанычлы кешеләрен Европага җибәрә. Туганын күмү белән, үзе Воронеж өязенә барып, дингез йөзгечләре төзү эшен җайга сала. Төрле качакларга, төрмәдә утыручыларга ирек биреп, гаскәр җыя башлый. Төзелеш башында Воронеж тирәсендә җитмеш мең чамасы гаскәр җыела. Күбесе Украина белән Дон казаклары һәм өч мең калмык атлысы. Дон казакларының бер өлеше зур көймәләргә утырып Азовка йөзеп төшә. Төрекләр белән дингездә беренче бәрелеш уңыш китерми. Көчләр тигез булмауга карамастан, көчле батырлык күрсәтеп, икенче бәрелештә туксанга якын тәпән дары, өч йөз авыр ядрә, он, ярма һәм бик күп мануфактура кулга төшерәләр. Иң әһәмиятлесе шул: дингез яклап ныгытманы тулысынча камап алырга мөмкинлек туа. Май азакларында төп көчләр килеп житеп, Азов ныгытмасын икенче кат камап алалар. Килгән вакытта меңләгән Кырым татарының атлы гаскәре обозга һөҗүм итә. Бер идарә кулы астында укмашкан калмык атлылары, бу һөҗүмне кире кагып, каты каршылык күрсәтә. Июнь ае уртасында камау эшләре төгәлләнеп, эре туплардан атулар башланып китә. Шул ук вакытта ныгытмадагы төрекләргә бирелергә мөрәҗәгать итеп хат юлланыла. Австриядән ялланып килгән унсигез белгеч тә камау эшләрендә зур булышлык күрсәтә.

Ныгытманы саклап калып булмаганлыгын тоеп, төрекләр урыслар мөрәҗәгатен кабул итәргә мәжбүр була. Мөрәҗәгатьтә әйтелү буенча төрекләргә ныгытмадан иркенләп китәргә мөмкинчелек бирелә. Унтугызы көнне төрекләр ныгытманы калдырып китә. Әнә шулай, Петр I нең хыялы тормышка ашып, Азов дингезе аша Кара дингезгә юл ачыла. Сигез меннән артыграк гаскәри белән бер өлеш калмык атлылары Азовны сакларга кала, башкалары Мәскәү каласында уздырылган зур җиңү бәйрәмендә катнаша.

Ул төркемдә Әхмәтнәсир дә бар иде.

## 11

Мәскәүнең үзендә җиңү тантанасында катнашу Әхмәтнәсир өчен очраклы хәл түгел. Азов ныгытмасы камалышта вакытта меңнән артык Кырым татары һөҗүмгә ташланды. Бу әле җәй башы гына иде. Бер мәлгә алар чигенергә мәжбүр булдылар. Әхмәтнәсирләр төркеме һөҗүмгә күчеп,

Кагалник елгасы буенда ике дистәгә якын кырымлыларны Нуретдин ханнары белән бергә кулга алдылар. Ике арада кыска гына сөйләшү булып алды. Тәржемәче Әхмәтнәсир иде. Хәлсез яралыларның канын кою егетлек түгел дип уйлап, тәржемәне үзенчә борып, әсирне иреккә җибәрәсе иттеләр. Төнгелеккә сугыш тукталды.

Тан атып килгәндә кырымлылар яна көч туплап, һөҗүмгә ташланды. Җинү бәйрәмен иртәрәк тантана итеп, хәмердән айнышмаган казаклар иркенләп ял итәргә туктаган иделәр. Көтелмәгән көчле басым астында кире чигенергә туры килде.Төркем җитәкчесе Туренев яраланып татарлар кулына эләкте. Ике яктан да авыр югалтулардан хәлсезләнеп, көннең икенче яртысында, сугыш бер мәлгә тынды.

Форсаттан файдаланып, җитәкчене йолып алу нияте белән, Әхмәтнәсир кырымлылар ягына узды. ...Ханның уң кулы Солтан морза каршына китерделәр егетне. Әхмәтнәсирнең сүзенә колак салучы юк, Солтан морзаның күз карашы егетнең билендәге хәнҗәргә төбәлгән иде.

— Бу хәнҗәр сезгә каян килеп эләкте?

Сорауны егет үзенчә аңлап:

— Атамның бүләге. Туренев әфәндене азат итсәгез, мин бу бүләкне сезгә бирергә әзер, — дип, хәнҗәрне морзага сузды.

Алтын-көмеш, мәрҗәннәр белән бизәлгән хәнҗәр кынысының бер ягына: «Кирәксезгә чыгарма! Чыгарсаң — кулың калтырамасын!» Ә икенче ягына: «Әхмәт пашага тиңсез батырлыгы өчен!» — дип фарсы хәрефләре белән бизәп язылган иде.

— Атагызга ничек эләккән бу затлы хәнҗәр?

— Бу хакта сорашканым булмады атамнан. Урлап алу гадәте юк анарда. Сугыш кырында яулап алгандыр.

Шулчак, чатыр эченнән көч-хәл атлап, Нуретдин хан үзе күренде.

— Ә, бу сез икән, олан. Гаскәр җитәкчесен йолып алу нияте белән килдем, дисенме?.. Мактауга лаеклы гамәл, хуплыйм.

Башын морза ягына бормый гына әмер бирде:

— Егетнең таләбен үтә. Хәнҗәрне үзенә кире кайтар. Мондый пәһлеван бала тәрбияләп үстергән атаның бу хәнҗәргә ничек ия булуына шигем юк.

Туреневның ярасы авыр иде. Дыңгылдап ат өстендә кайту хәлен тагы да авырайткан. Күп кан югалтудан хәлсезләнгән булуга карамастан, ул аңында иде әле. Үз дәрәҗәсендәге йөзбаш Кафтыревка:

— Константин Дементьевич, Ахмет хороший и надежный воин, положись на него. Он никогда не подведет, — дип әйтү белән аңын җуйды.

Туган ягы ерак дала тирмәнендә беренче мәртәбә очрашып, ике елга якын бергә утны-суны кичкән, ышанычлы остазына әверелгән кеше, башкача аңга килә алмыйча, җан тәслим кылды.

Икенче көнне иртә белән, барлык көчләрне туплап, һөҗүмгә күчтеләр. Егетнең яңа җитәкчесе Кафтерев шул бәрелештә яра алды. Ярасы куркыныч түгел иде. Шулай да ул:

— Ахмет, бери командование в свои руки и продолжайте преследовать врага! — дип идарә итүне егеткә тапшырды.

Бер төркем башкорт атлылары белән куыны дәвам итеп, дошманны җиңүгә ирештеләр. Солтан морза белән бергә күп кенә кырымлылар кулга төште. Нуретдин ханның үзен дә кулга алу мөмкинлеге бар иде, егет эзәрлекләүне дәвам итмәде.

Төрекләр Азов ныгытмасын калдырып киткәннән соң, унтугызынчы июль көнне, Кырым татарлары тагын бер мәртәбә һөҗүм иттеләр. Бу — соңгысы иде.

## 12

Урыс патшасы Петр, Азов ныгытмасын алу тантанасын уздыру ниятеннән, Мәскәү каласында «Жину капкасы»н төзетте. Октябрь аеның жидесендә, тантана башланыр алдыннан, сугыш барышында золымлык кылучыларны җәзага тарту тамашасы булды. Азов ныгытмасын камау барышында төрекләр ягына качып серне ачкан Якушканың башын кисеп казыкка элделәр. Татарларга сатылган Кубань казагы Осалык белән тагын берничә сатлык җан шул ук җәзага тартылды. Золымнары азрак булган унбишләп драгунны чишендереп камчы белән суктырдылар.

Сөрнәй-корнай, барабан тавышлары астында төркем-төркем булып, кызыл киемдәге укчылар, ат менгән казаклар, урыс драгуннары, бер төркем калмык, башкорт атлылары, «Жину капкасы» аша уздылар. «Таш күпердән» узганда күпсанлы туплардан атып сугышчыларны тәбрикләделәр. Тантанада катнашучыларның дәрәҗәсенә карап акчалата бүләк өләшенде. Югары дәрәҗәдәгеләргә халкы белән бергә авыллар, җирләр бүлеп бирелде. Ул елны корылык булып игеннәр уңмаган. Мәскәүләр җину бәйрәме уздырып ятканда тирә-якта ачлык хөкем сөрә иде. Шул тикле гаскәрне генә түгел, атларны да ашатып тотар өчен күпме азык кирәк. Тантанада катнашканнарны төркемнәргә ваклап, төрле өяздәге алпавытларга йөкләргә әмер чыкты. Үз утарлары бар кенәзләр, сугыш җитәкчеләре дә хәлдән килгәнчә бу гамәлдә катнашырга тиеш иделәр. Йөзбаш Кафтырев күрсәтмәсен кире какмый, ике дистә башкорт атлылары белән Әхмәтнәсирне драгун полковнигы Кропотов үз карамагына алды.

Кропотов Семен Иванович чыгышы белән Тамбов өлкәсеннән. Аның атасы отставкадагы полковник. Егерме тугыз хатын-кыз, егерме дүрт ир-аттан торган үз авылы, үз утары бар. Унтугыз тулы гаиләдә кырыкка якын бала тәрбияләнә. «Вишневка» исемле бу авыл «Каргалы» елгасы буенда урнашкан. Җирләре артык ишле булмаса да печән үскән болыннары киң. Урманы да бар. Җәйгелектә гаилә авылдагы йортларында яши. Шәһәрдә ике катлы өйләре тора. Әлегесе вакытта кыш кышларга шәһәргә кайтканнар. Семен Ивановичның атасы Иван Егорович тыныч холыклы кеше. Ил хәлләрен барлап, белешеп торганлыктан, улының бер төркем ят милләт кешеләре ияртеп кайтуына гаҗәпләнмәде. Үзе егетләрне авылга алып барды, халык белән таныштырды. Кешеләргә карата хуҗа кырыс булмаганлыктан, авыл халкы җитеш тормышта яши иде. Калкулыктагы иген басуыннан тыш һәр гаиләнең йорт тирәсендә үз ындырлары бар иде. Егетләрнең уй-фикерен тойгандай, Иван Егорыч эшләп торган кеше юклыкта интегергә тиеш түгел, ач кешеләрне чыбыркы астында эшләтеп көн күрмәссең дип сөйләнә-сөйләнә, утары белән таныштырып чыкты. Сарайлар белән уратып алынган иркен йорт. Эре нарат агачларыннан буралган бер катлы зур өй. Мунчасын да өч бүлмәле итеп агачтан эшләгәннәр. Унлап баш сыеры, алты баш бия белән ике алашасы һәм биеп торган алмачуар айгырлары бар.

Ел коры килде, әмма бу авылда җитешсезлек сизелми. Әхмәтнәсир бу турыда искәрткәч, икмәкне дә берничә көнгә алданрак чәчеп, үлән басуына маллар кертмәдек. Көтү урман тирәсе, аланчыкларда йөрде. Безнең болыннар язгы ташу вакытында су астында кала. Бу елны су артык күтәрелмәсә дә болын дымны җитәрлек алды. Мал тоягы таптамагач, үләннәр күтәрелде. Иген дә, узган елларга караганда артык ким булмады, дип, үз серләрен ачты. Әхмәтнәсирнең: «Кабыла мнугы, кымыз делаете штули», дигән соравына каршы, полковник: «Андый уй бар иде, ясарга тырышып карадык, рәте чыкмады. Аның серен белүче кеше кирәк иде дә, каян табасың аны», дип җилкәсен кашып куйды.

Ике елга якын кайда туры килде шунда, кыр-далада йоклап гомер

уздырган егетләр үзләрен җәннәткә эләккәндәй хис иттеләр. Авыл халкына, хуҗа малларына авырлык килмәсен дип җиң сызганып үз атларына кышкылыкка азык әзерләү хәстәренә керештеләр. Көзге яңгырлардан соң камылы шаулап күтәрелгән. Чалгы белән ялап диярлек иртә таңнан кичке караңгыга тикле үлән чаптылар. Саран җылыткан көзге кояш астында үлән киптерү мөмкин түгел һәм аның кирәге дә юк иде. Җирдә ятып күгәрмәсен өчен, елга тирәсендәге әрем, куакларны кисеп, шунда җәйделәр. Салкыннар башланып туңдырып җибәрсә кипмәгән үләнгә зарар килмәячәк иде.

Мәскәүдә чакта һәр егеткә унбишәр, ә Әхмәтнәсиргә егерме биш сум акча биргәннәр иде. Бер рәттән аларга ярты еллык хезмәт хакын да түләделәр. Кесә төпләрендә беразын калдырып, утар хуҗасы ярдәме белән үзләре өчен дә азык-төлек юлларга карар кылынды. Бу сөйләшүне ишетеп, карт полковник: «Үзебезнең карамакка алганбыз икән сезне, ашатып кыш чыгарлык кына азык табылыр», — дип кырт кисте.

Ноябрь азакларында туңдырып җибәреп, кар төште. Биш йөккә иген төяп барып, Каргалы елгасы буйлап унбиш чакрым ары Кирсановка тегермәнендә он тарттырдылар. Тегермәнгә килгән халык аша күп кенә яңалыклар ишеттеләр. Күрше Пенза, Сарытау өязләрендә ачлык икән. Авыллары белән мал-туарларын сатып, Чулман елгасы якларына китәләр ди. Анда корылык юк, буш җирләр күп, имеш. Тегермәннән кайткач, егетләр үзара киңәшеп, шул якларны әйләнеп кайтырга булдылар. Тирә-якны яхшы белгән авыл Пенза якларына юлга чыкты. Авылдан авылга эзләнеп йөри торгач, өшән булса да мал мал булыр, берәр ай ашатсаң шулпага өресе чыгар әле дип, ике сыер белән ун баш сарык сатып алып кайттылар. Тапаган саламны кайнар су белән пешекләп, бераз көрпә өстәп ашата торгач маллар күзгә карап көрәйде. Шулпага өйрәнгән дала кешесенә тотрыклы азык, ит кирәк. Раштуа алдыннан маллар суеп, шау-шу килеп ятканда, гаиләләре белән хуҗалар килеп төште. Егетләрнең тормыш көтәргә сәләтле булуларын күреп Семен Иванович бик канәгать калды: «С такими ребятами любого врага одалеем, не то что турков!», — диде.

Төрле яңа хәбәрләр дә алып килгән. Илдә ачлык, буталышлар икән. Үтереш, талау, караклык. Караклыкта тотылганнарны үлем җәзасына биреп, көн дә дистәләгән кешене асалар, казыкка утырталар ди. Дәрәҗәгә, чинга карау юк ди. Хөкүмәт казнасына кул сузган өчен полковник Обухов, кенәз Горчаков, Тула воеводасы Логовщиковны кузлага бәйләп каеш чыбыркы белән кыйнаганнар. Кунаклар, берничә көн буе мунча кереп, ял итеп, бик тә канәгать булып киттеләр. Гади тормышка сусаган егетләр, кыш күзе караңгы дип, эшсез тик ятмадылар. Утар хуҗалары сарык малы тотмаса да авыл халкында сарык күп иде. Капчык-капчык язгы йон үз чиратын көтеп ята. Җон эрләп оек бәйләү, итек басу эшләре егетләргә ят эш түгел. Бер рәттән чабата үрү һөнәренә өйрәнделәр. Бу яңа һөнәр бигрәк тә Әхмәтнәсирдә көчле кызыксыну уятты. Алла аны тагы да дулкынландыргыч, җанына ятышлы мәшәкатьләр көтә иде. Февраль башларында сыерлар бозаулады. Артларыннан ук бияләр колынлады. Беренче көннән үк атларны саварга өйрәтеп, колыннарны кулдан сөт эчәргә ияләштерделәр. Март азакларында тайларга сыер сөтен кушып ашата башладылар. Беренче апрель көнне гөбеләрдә бия сөте талкытып Әхмәтнәсир кымыз өлгертте. Иван Егоровичның туган көне иде бу.

## 13

Азов ныгытмасын алу, илдәге корылык Русиянең экономикасын какшатты. Илдә тотрыксызлык, халык арасында ризасызлык көчәйде. Шуның өстенә Петр Iнең башында тагын бер уй яралып килә: көнбатыш чикләрдән шведларны куып Балтыйк диңгезенә чыгу, Аурупага туры юл ачу. Моның өчен Көнбатыш

илләр белән теләктәшлек табу, төрекләр белән араны ныгыту кирәк иде. Шул теләктән ул ин дәрәҗәле илчеләрен Аурупага озатты. Көчле дипломат Прокопий Богданович Возницынны төрекләр белән килешү төзергә билгеләде. Тик бу килешүләр бик озакка сузылды. Төрекләр Азов ныгытмасын кире кайтаруны таләп итә. Сатулаша торгач, соңгы чиктә, төрекләр — Азовтан, урыслар Керчьтан баш тартып, ике арада ике еллык солых төзелде.

Азов сугышына әзерләнгән көймәләр, галералар дингездә йөзәргә сәләтсез булуын күрсәтте. Шуның өчен зур йөзгечләр төзергә кирәк иде. Яңабаштан зур төзелеш эшләре башлап җибәрделәр.

1699 елның ноябрендә Дания белән солых төзелде. Көчле дипломатия аркасында 1700 елны Саксония белән дә бердәмлекне ныгыттылар. Русия, үзенә карата Швеция илендә шик тумасын өчен, Яков Федорович Долгорукийны, берничә югары дәрәҗәле дипломатлар белән, Швециягә илче итеп җибәрә. Бер уңайдан Андрей Яковлевич Хилковка чик буе шәһәрләрен барлап, корылмаларын өйрәнеп, сер җыю йөкләнде. Алдынгы Аурупа илләре, Бөекбритания, Голландия, Австрия һәм Франциянең башка илләр кайгысын кайгыртуга нияте юк. Чөнки аларның уенда чирле Испан короле үлсә сугыш ачу, мал бүлү иде.

Шведларга каршы сугыш башлар өчен иң уңай чор. Житмәсә, швед иленең үзендә дә тотрыклык юк. Карл XI үлеп, тәхеткә Карл XII утырды. Замандашлары биргән бәягә караганда, ул яшь һәм җиңел акыллы, пырдымсыз иде. Чынбарлыкта, уйлаганча килеп чыкмады. Саксония короле Август II, 1700 елның 12 февралендә, сугыш белгертмичә генә, Лифляндиягә бәреп кереп, Рига шәһәрен камап алды. Бу очракта ярдәмгә киләсе урында Дания генералы Флеминг Саксониягә китеп өйләнде, туй уйнады. Август II үзе дә, үзара килешми генә башлап җибәргән сугыш уенына салкын карап, аучылык белән шөгыльләнә, Варшавага барып күңел ача, төрле тамашаларга йөри. Соңгы чиктә, акчасы бетеп, гаскәриләрне тотарга хәле калмагач, Риганы калдырып китәргә мәҗбүр булды. Дания белән Шведлар арасында башланган сугыш уены да әҗәллеккә дучар ителә.

Шведларга каршы Август IIнең сугыш башлаганын ишетеп, Дания короле Фредерик IV, март аенда уналты мең гаскәр белән, Голштейн-Готтопорск герцоглыгына каршы сугыш белән юлга чыга. Дания башкаласы яклаусыз калганын белеп, Швед короле, унсигез яшьлек Карл XII, дингез караблары белән Копенгагенны камап алды. Шәһәрне утка тоту белән янап, Дания королен ике арада тынычлык солыхы төзергә күндерде. Бу солыхта Саксония белән араны өзү каралса да, Русия белән астыртын төзелгән солыхка кагылмый. Бу вакыт эчендә Русия өчен иң мөһиме Стамбулда барган килешүләр иде. Төрекләр белән тынычлык солыхы төзелми торып, төньякта сугыш башлау мөмкин түгел. Ике фронтта сугыш алып барырга Русиянең көче дә, мөмкинчелеге дә юк иде.

Ниһаять, «Төрекләр белән ике арада утыз еллык солых төзелде», — дип, Емельян Игнатьевич Украинцевтан хәбәр килеп төште. Бу хәбәр шведларга каршы сугыш башларга юл ачты.

## 14

«Балта хәл җыйганда, түмәр ял итә», — дигәннәр борынгылар. Югарыдагы түрәләр, ил кайгысын кайгыртып, үз хәрбиләрен берничә ел буе онытып торды. Әхмәтнәсирләр өчен бу бик кулай иде. «Солдат спит, служба идет», — дигән әйтем, бәлкем, шул чорлардан калгандыр. Тик егетләр йокы симертеп гомерне бушка уздырмадылар. Язгы чорда бераз кыенлыклар булып алса да, беренче кышны алар зарланусыз кышладылар. Көзге якта әзерләнгән камыл үләне бик тә ярап торды.

Кыш карлы булып, елга сулары күтәренке иде. Бу елның уңышлы булуына Вишневка халкы шикләнмәде. Ә ил буенча бу елны да икмәккә кытлык көтелә иде. Чөнки чәчәргә орлык юк. Булганы да түбән сыйфатлы. Бу очракта да авыл халкы югалып калмады. Чәчүгә дигән орлыкны тагын бер кат берәмтекләп барлап, жылы мунча эчендә жылытып, чәчүгә ныклап әзерләнделәр. Жирне көздән сөреп калдырганнар иде, тырмалап ярты жиргә бодай, икенче яртысына арпа чәчтеләр. Урман артындагы көз чәчеп калдырган арыш басуы да матур гына күтәрелеп китте.

Май урталарында Кропотовлар гаиләсе жәйгелеккә авылга күченеп килде. Егетләр, бер читтәрәк матур урын сайлап, чатыр кордылар. Алар бу көнне түземсезлек белән көтеп алган иде. Казан элделәр. Сарык ите белән катыш ботка пешереп, хужалар белән берлектә, бөтен авыл халкын жыеп, ул көнне бәйрәмгә әйләндерделәр.

Ул елны чалгы белән каерып алмаслык булып печән унды. Авыл халкы белән бергә егетләр дә дәррәү күтәрелеп печәнгә чыкты. Шау килеп печән чабып ятканда, Тамбовтан «кунаклар» килеп төште. Тамбов өязе жирләре белән идарә итүче Шашин һәм Мәскәү Суды хөкемдары Урусов Юрий Семенович иде бу. Кропотов Семен Иванович утарда юк иде. Кунакларны әтисе Иван Егорович каршы алды. Башта аны-моны әйтми генә иген кырларын, каралты-кураны карап чыктылар. Печән чапкан халык янына, болынга төштеләр.

— Ходай ярдәм бирсен! Эшләр барамы? — дип сүзне беренче Шашин башлады.

— Яхшы яшисез! Башкаларга үрнәк булырлык! — дип сүзне Урусов күтәреп алды.

— Тырышабыз, хәлдән килгәнчә, Юрий Семенович, — дип утар хужасы кунакларга кымыз тәкъдим итте. Авыз тидереп бер йотым эчү белән Урусов:
— Oho! Бик шәп кымыз бит бу! Кем шулай оста итеп кымыз ясый белә сездә?

— Бар андыйлар. Әнә ул, аның ин остасы, — дип Әхмәтнәсир ягына ымлап күрсәтте.

— Чакыр әле үзен монда! — диде кунак, кымыз эчүен дәвам итеп.

— Ахмет, кил әле бире. Синең белән кызыксыналар.

— А он, что, татарин?

— Татарин.

Кайда гына булмасын, егетнең, «Әссәламәгаләйкүм!» — дип исәнләшә торган гадәте бар иде. Бу юлы да ул, кунаклар янына килү белән:
— Әссәламәгаләйкүм! Капрал драгунскага палка Ахмет, сын Сәлимгарая, яслушаю Вас! — дип сәлам бирде.

— Алейкум салям, джигит! — дип егетнең сәламен алу белән кунак саф татар теленә күчте.

— Кем син? Кай яклардан буласың?

— Аскы үзән даласыннан. Тархан ягыннан. Манаш ыруыннан мин, әфәндем.

— Күптәннәнме хезмәттә?

— Тагын ике айдан өч ел була, әфәндем.

— Сугышта катнашырга туры килдеме?

— Азов ныгытмасын алдык, әфәндем.

— Молодец! Продолжай служить в таком же духе! — дип, Урусов сүзен урысча тәмамлады.

Кунаклар куна калмадылар, Кирсановкага сугыласы бар, шунда кунарбыз дип якты көндә ашыгып юлга чыктылар. Иван Егоровичның күнеле күтәренке иде. «Сыну, Семену Ивановичу, землю дали!» — дип, кунакларның яхшы хәбәр белән килүләрен кичке аш вакытында халыкка житкерде.

Узган елны, жиңү тантанасы хөрмәтеннән Кропотов Семен Ивановичка жир бирмәк булганнар. Гаиләдән ерак урында булса, кирәк түгел. Атам Кропотов Иван Егорович утары тирәсеннән бирсәгез иде, дигән.

Эш кәгазьләрен актара торгач, «Кропотов Прохор – вор и мошенник», – дигән исемгә тап булалар. Драгун полковнигы Кропотов С.И. бу кешегә туган-тумача түгелме дип чокчына башлыйлар. Соңгы чиктә хәл ачыклана. Шуның аркасында жирне бирү кичектерелгән булып чыга. Утар тирәсендә киңәергә мөмкинлек юк. Килгән кунаклар, кирәк кадәр жирне елганың икенче ярыннан алырга рөхсәт биреп киткәннәр. Атна-ун көннән кадастр белгече килеп, законлаштырып, кирәк язулар төзеп китәчәк.

Икенче көнне иртән, ике башкорт егете белән Әхмәтнәсирне ияртеп, утар хужасы елганың икенче ярын барлап кайтырга ниятләде. Ике чакрым өстәрәк, кичү аша чыгып, урын сайлау эшенә керештеләр. Яр белән бер чакрым арада, шомырт, балан, чия куаклары басып алган лапылык иде бу. Ара-тирә аланнар да очраштыргалый. Арада карама, кәрлә имән белән усак агачлары да күренгәли.

Ат өстендә булуга карамастан, арып-талып, суга сусап, төш вакытларында утарга әйләнеп кайттылар.

– Ни уйлыйсыз, егетләр? Рәт чыгарып булырмы ул жиргә? Бәйләнергә кирәк түгелдер, бәлкем? – дип, утар хужасы егетләрнең уй-фикерен беләсе итте.

– Бирәләр икән, алырга кирәк. Агач-куакларын төпләп, маллар өчен җәйләү ясарга мөмкин. Бик әчкә узмый гына яр тирәсен алсаң, эше баш бетәрлек түгел, – дигән фикерләр әйтелде.

– Сүз дә юк, алырга кирәк! Безне моннан тиз арада куптармасалар, булышырбыз. Ин элек жайлы урында күпер салырга кирәк, – дип, соңгылардан булып Әхмәтнәсир дә үз фикерен әйтәсе итте.

## 15

Кыш башында тегермәнгә баргач,авыл егетенең тегермәнче кызына күзе төшкән иде. Печәнгә төшәр алдыннан, утар хужасы рөхсәте белән, кызның кулын сорап бардылар.Тегермәнче Вишневка халкын яхшы белгәнгә, яучыларны кире бормады. Шул төркем белән өлгереп килгән ике Вишневка кызы да барган иде. Шуларның берсенә Кирсановка егете күз салды. Яучылар әйләнеп кайту белән икенче көнне үк Вишневкага да яучылар килеп төшә. Кызның ата-анасы: «Кызыбызны чит авылга бирмибез. Товар шәп, үзебездән артмый. Әгәр «сатып алучы» үзе безнең авылга күчеп килергә теләк белдерсә, без каршы түгел», – дигәннәр.

Печәннәрне жыеп бетерү белән, ярәшү туе уздырырга булдылар. Полковник искәрткән башкарасы план әнә шул иде. Сөйләшенгән көн житү белән, дугаларга кыңгыраулар асып, кыз артыннан киттеләр. Килен тиешле кыз белән бергә кияү буласы егетне дә алып кайтканнар. Егет бу авылда нигез корырга ниятләп ризалыгын биргән.

Туйларны кыр эшләре тәмамлангач уздырырга каралды. Ә әлегә килен белән кияү егет үзләрен эштә күрсәтергә тиеш иделәр. Ике хужа да, хәрби киемнән, ипи-тоз тотып, яшьләрне каршы алды. Җыйнак кына мәжлес тә булды. Иван Егорович үз исеменнән ике парга да йорт торгызырга сүз бирде.

Авыл зурая. Авыл артындагы жайлы урында күпер салырга керештеләр. Ике ярны күтәртә төшеп терәкләр кактылар. Уртадагы терәкләрне кагар өчен сал ясарга туры килде. Иген өсте башлануга ин авыр эш төгәлләнгән иде инде. Игеннәрне жыеп алу белән, жин сызганып, яңа жирдә агач төпләү эшләре башланды. Әнә шулай, шау-гөр килеп, эш белән мавыгып, тагын ике елга якын вакыт узып китте.

Чит-ят авылда дүрт елга якын гомерләрен печән чабып, иген урып, күпер салып, ике ел рәттән агач төпләп, үз кешегә әверелеп беткәч кенә, егерме башкорт белән бер татар егете, өстән әмер килеп төшүгә янә ат иярләде. 1700 елның беренче август көне иде бу. Күп елларга тартылачак сугыш башланачагы халыкка билгесез иде әле. Булачак фаҗигане күнелләре белән алдан тойган авыл кешеләре, елашып, изге теләкләр теләп, егетләрне озатып калды.

Шведларга каршы Русия 19 августта сугыш башлавын игълан итте. Шул ук көнне Стамбул белән килешүне бәйрәм итеп, Мәскәүдә көчле фейерверклы тантана уздырдылар. 22сендә Петр I юлга чыкты. Аның үе борынгы урыслар төзегән Ругодив ныгытмасын, хәзерге Нарваны яулап алу иде. Армияне өч өлешкә бүлеп, өч генералга тапшырдылар. Берсе генерал Артомон Михайлович Головин житәкләгән, ун жәяүле, бер атлы драгун полклардан торган ундүрт мен жиде йөз егерме алты кешелек армия иде. Икенчесен генерал Адам Адамович Вейде үз канаты астына алды, монысы тугыз жәяүле, бер атлы драгун полкларыннан торган унбер мен ике йөз егерме жиде кешене берләштерде. Өченчесен үсмер чактан бергә сугыш уеннары уйнап үскән, Петр Iнең якын ярдәмчесе, Никита Иванович Репнин әйдәкләде, монысында ун мен сигез йөз утыз дүрт кешедән торган тугыз жәяүле полк иде.

Петр I барысы өстеннән житәкчелекне Федор Алексеевич Головинга тапшырды. Көн өстендә чыккан фәрман белән фельдмаршал дәрәжәсе алган Головин Федор Алексеевич чынбарлыкта дипломат иде. Гаскәрләр белән идарә итеп сугышларда катнашкан кеше түгел. Аның кулы астында дворяннар катламының тагын унбер мен биш йөз утыз өч кешедән торган ополчение бар иде. Бу көчләрдән тыш Украинадан гетман Обидовский житәкчелегендәге ун мен биш йөздән торган казак гаскәре килергә тиеш.

Петр I Нарва ныгытмасына егерме икенче сентябрьдә килеп житте. Генерал Вейде көчләре — өч көннән, тагын бер атнадан сон гына генерал Головин килде. Генерал Репнин белән гетман Обидовский көчләре бөтенләй дә күренмәс булды. Нарва тирәсендә алтмыш өч мен биш йөз егерме кешедән торган көч жыеласы урынга, гаскәрләр саны егерме тугыз мен тирәсе генә иде. Мәскәүдән чыккан обоз, юл буйлап өстәлә барып, ун менгә житкән. Йөкләрдә дары, ядрә, туплар һәм азык-төлек. Янгырлар башланып, юллар бозылганлыктан, обоз дистәләгән чакрымнарга сузылган.

Обоз көтеп, бер хәрәкәтсез жыелган камаучыларга каршы, егерме алтынчы сентябрьдә, Нарва ныгытмасыннан көчле ут ачтылар. Атна буена сузылган бу көчле атыш камаучылар арасында югалтуларга китерде. Октябрь ае урталарында гына обоз килеп житте. Беренче ядрәне унсигезенче октябрьдә генә Нарва ягына аттылар. Анысы да тупны сынап карау ниятеннән генә иде. Егермесендә, бөтен булган туплардан атып, көчле һөжүм башланды. Ике атна буе барган бу атышлар көткән нәтижә бирмәде. Дарының сыйфатсыз булуы аркасында ядрәләр ныгытмага зур зыян китерми. Ядрәләрнен кайберләре ныгытмага барып та житә алмыйча шартлый иде. Шуның өстенә, дары ике атнага гына житте. Һөжүм нәтижәсез булды — гади сугышчылар һәм офицерлар сугышка сәләтсез иде. Илдә булган корылык та үзен сиздерде. Гаскәрне тукландырыр өчен азык житешми, ә алда озын кыш көтеп тора.

Әле житмәсә Дания короле Фредерик IVнең шведлар белән солых төзеп, сугыштан чыкканлыгы ачыклана. Саксония короле Август IIдән дә ярдәм көтәсе юк.

Урыслар арасында швед короле Карл XII Балтик дингезен йөзеп чыгып, Ревель белән Пернау[1], тукталган дигән хәбәр таралды. Бу очракта, сугышны

[1] Хәзерге Таллин белән Пярнуда

кичектерергә, кышкылыкка ялга туктап, өр-яңадан тулысы белән һөҗүмгә әзерләнергә кирәк иде. Урыс патшасы Петр I бу уйны хупламады, сугышны дәвам итәргә карар кылды. Аурупа илләре каршында үзен көчсез, булдыксыз итеп күрсәтәсе килмәде.

Яңа хәбәрне алу белән, шведларга каршы разведкага биш мең атлы гаскәр җибәрелде. Җитәкчесе итеп Борис Петрович Шереметьев куелды. Өч көн буе юлда булып, чит-ят җирләргә үтеп кергәч, авангард төркем шведлар белән очрашты. Көчләр тигез түгел иде. Төп көчләр килеп җитү белән дошманны тар-мар итеп, күбесен кулга алдылар. Әсирләр әйтүе буенча утыз меңлек швед армиясе Нарва ныгытмасына ярдәмгә чыккан. Шулай булуга карамастан, Шереметьев гаскәрен кайту ягына бора. Соныннан ул бу гамәлен, куркаклыктан түгел, атларга азык, кешеләргә кунар өчен фатир булмау белән аклый.

Нарва ныгытмасына ярдәмгә чыккан швед короле Ревель белән Пернауда якорь сала, чөнки диңгездә көчле шторм күтәрелә. Гаскәре дә утыз мең түгел, ә барлыгы ун мең тирәсе генә. Аның да бер өлеше Ревельдан, икенче өлеше Пернаудан, аерым-аерым төркем булып юлга чыккан иде. Әгәр Шереметьев дошманны каршы алып, һөҗүм иткән булса, финалы фаҗигале бетмәс иде. Нарва ягына кайтып барышлый күперләрне шартлатсалар да шведларга кыенлык тудырган булыр иде.

18 ноябрьдә Шереметьев Нарвага әйләнеп кайта. «Үкчәгә басып утыз меңле швед армиясе килә», – дигән сүз тарата. Патшаның үзе белән очрашырга туры килми аңа. «Оборонаны ныгыт. Шведларга Нарва ныгытмасына үтәргә ирек бирмә, каршы тор!» – диеп, аның исеменә язу калдырып, Петр I Мәскәүгә алданрак кайтып киткән була.

Ныгытманы камап тоту бик авыр шартларда бара. Ноябрь ае. Кар катыш салкын яңгырлы ачык һава астында, азык-төлек җитешми. Сыйфатсыз дары аркасында туплардан ату нәтиҗәсез. Ата торган тупларның да сыйфаты түбән. Кайберләре бер ату белән җимерелеп юкка чыга. Шереметьев кайтып шау-шу күтәрү белән Петр патшаның яраткан кешесе Ян Гуммерт камаучыларны калдырып кача. Бу икейөзле кешене, соңгы чиктә, шведлар үзләре үк дар агачына асалар.

Унсигез яшьлек Карл XII Нарва янәшәсенә якынаю белән, гаскәренә ял да итәргә мөмкинчелек бирмичә, һөҗүмгә күчә. Иртәнге сәгать унбердән төш вакытына кадәр туплардан ату башланып китә. Сәгать икеләр тирәсендә, тугыз-ун адымнан күреп булмаслык булып, куе кар ява башлый. Җиде чакрымга сузылган камаучыларга бу хәл тагы да нык кыенлык тудыра. Форсаттан файдаланып, шведлар канауга чытыр-чатыр бәйләмнәре ыргытып, камаучылар рәтенә үтеп керәләр. «Немецләр безне сатты!» – диеп, кычкырышып, урыслар арасында паника куба. Бу хәлне күреп Шереметьев үз атлы гаскәре белән елга аша качып китү ягын сайлый. Елганы кичкәндә, күпер ишелеп, күп кенә халык батып үлә. Урыска ялланган немец фон Крум, чынлап та, үз гаскәре белән шведлар ягына чыга.

Шуңа да карамастан, Преображенский, Семеновский һәм Лефортовский полклары паникага бирелми. Обоз арбаларыннан корылмалар корып, дошманга каршы сугышны дәвам итәләр. Төнгелеккә сугыш туктала. Швед гаскәре күпме көчкә ия булуын белмәгәнлектән, аз көчләр белән озак каршы торып булмаслыгын тоеп, урыс генераллары Яков Федорович Долгорукий, имеретин царевичы Александр Арчилович, Автомон Михайлович Головин һәм Иван Иванович Бутурлин, каршылык күрсәтүне туктатып, шведларга килешү тәкъдим итә. Килешү буенча шведлар, урыс гаскәрен җинел коралланган килеш, әләмнәре белән елга аръягына чыгып китәргә мөмкинчелек тудырырга сүз бирә. Төне буе урыс гаскәриләре Нарва елгасы аша күперне торгызу эшләрен алып бара.

Иртәнге сәгать тугызлар тирәсендә князь Долгорукий, царевич Александр белән Головин, шведлар ягына чыгып, швед короле белән очраша. Карл XII кичтән биргән сүзен тагын бер кат раслый. Беренчеләрдән булып гвардия полклары Головин дивизиясе белән күпер аша чыгып китәләр. Бу көчләр ярның икенче ягына чыгу белән шведлар калган гаскәргә каршы һөҗүм итә. Обозларны талап, киемнәренә тикле чишендереп, житмеш тугыз генерал һәм офицерлары белән күп кенә халыкны әсирлеккә төшерә. Карл XII үз сүзенә үзе хыянәт итә.

Бу сугышта урысның бөтен булган туплары, күпсанлы офицер составы югалтуга дучар була, алты мең тирәсе кешесе ярадан һәм ачлыктан үлә. Петр I Аурупа илләре алдында үзенең дәрәҗәсен жуя.

## 16

Беренче август көнне урыннарыннан кузгалган Әхмәтнәсирләр төркеме, полковник Семен Иванович Кропотов житәкчелегендә, башта Тамбовка, аннан ары Мәскәү ягына юл тотты. Юл уңаенда алар төркеменә әкренләп тагын йөз утыз атлы өстәлде.

Августның жидесендә алар Мәскәүдә иделәр. Икенче көнне, биш йөз кешедән торган атлы драгуннар белән кушылып, Ржевка уздылар. Кай якка барачакларын белмичә, Ржевта тик ятып, ике атна вакыт узды. Полковник Кропотов үзе дә билгесезлектә иде.

Вешневкадан чыкканда алар үзләре белән ике йөк азык-төлек, атларга фураж алганнар иде. Әкренләп азык бетеп килә, ә аны тулыландырырга мөмкинлек күренми. Казна сыена ышанып башкалар белән азык-төлекне уртаклашканнар иде, юкка булган, күрәмсең. Егерме икенче августта, кич, Мәскәү ягыннан кызыл яу булып укчылар гаскәре килде.

Төнне Ржев янәшәсендә уздырып, иртән Новгород ягына юлларын дәвам иттеләр. Алар китеп күпмедер вакыт узгач кына, бу Преображенск полкы булып, араларында бомбардир ротасы капитаны Петр I дә барлыгы ачыкланды. Тагын атна-ун көн тирәсе вакыт узгач кына, бик күп санлы обоз белән Борис Петрович Шереметьев килде. Аның кулы астында атлы драгуннар, патша сараен саклаучы черкеслар иде. Ниһаять, Ржевтагы төркем дә аларга кушылып, юлга чыкты.

Чуен туплар, эре ядрәләр, дары һәм башка сугыш кирәк-ярагы төялгән арбалар авыр йөктән сыкранып, дистәләгән чакрымга сузылган. Торып-торып арба тәгәрмәчләре ватыла. Ак күбеккә баткан йөк атлары барырга теләми туктап кала. Акырыш-бакырыш, шау-шу. Андый йөкләрне юл читенә сөйрәп чыгаралар, калган арбалар баруларын дәвам итә.Төнгелеккә бер урынга жыелу юк. Кем кайда туктаса — шунда төн уздыра. Атна тулыр-тулмаста Великие Лукига барып житеп, бер көнлек ялга тукталдылар. Великие Лукидан Псковка бару да шул ук вакытны алды. Псковта өч көнлек ялга тукталып, төзәтәсен төзәттеләр, азык-төлек хәстәрен күрделәр. Юлга кузгалган көнне Смоленск ягыннан зур обоз килде. Тамбовтан кузгалганнан бирле Әхмәтнәсир үз кешеләре, таныш башкортлар очрамасмы дип, караштыргалап, эзләнеп килде. Псковта да якташларын очрата алмады. Смоленск ягыннан яңа көчләр килә башлау белән, полковник Кропотовтан рөхсәт сорап, үз обозыннан калды. Яңа килгәннәр арасында бер баштан икенче башка чаптырып йөреп, күпме генә эзләнсә дә, беркемне таба алмады. Соңгы чиктә, түзмәгәннәрдер, туган якларына кайтып киткәннәрдер дип башка эзләмәс булды. 1700 елда башланган «Төньяк» сугышында, Әхмәтнәсирләр төркеменнән кала, башка татар-башкорт та, калмык гаскәрләре дә юк иде.

Псковтан ары төньяклап яңгырлар явып узган. Баткак-чумгак, юллар

бик начар. Псковның үзеннән дә күпсанлы гаубица, мортира һәм пушкалар белән озын обоз өстәлгән иде. Кайбер урыннарда пехота ярдәменнән башка үтәрлек түгел. Икенче көнне, кичке яклап, янадан янгырлар башланды. Бер мәлгә хәл жинеләйде. Балчык авыр булып тәгәрмәчләргә уралмый. Үтәдән-үтә чыланып өлгергән хәрбиләр өчен генә бу жинеллек китермәде. Коры чакта, төнгелеккә туктаганда, учаклар ягып жылынырга, су кайнатып тамак ялгарга була иде. Сентябрьнең әле икенче яртысы гына булуга карамастан, төннәр салкынайтты. Чи агачтан учак кабызырга, жылынырга мөмкинчелек юк. Туктап учак кабызган урыннарда өерелешеп халык жыела. Дистәләгән чакрымга сузылган обозның төрле жиреннән килеп каен агачлары кисәләр, жилкәләрендә ташып учаклар кабызалар. Төннең күп өлеше утын әзерләп, учак ягып уза. Иркенләп ял итәргә вакыт та калмый. Офык агарып таң ата башлау белән янадан юлга кузгалалар. Күз күреме арада, урман киселеп, шәрә бушлык кына утырып кала. Ржевтан кузгалып киткәндә кемдер жыр башлап жибәрсә, башкалар күтәреп ала иде. Нинди дә булса кызыклы хәл сөйләп, шау-гөр килеп, көлешеп тә ала иделәр. Ә хәзер обоз өстендә тулы тынлык. Янгырдан бүрткән тәгәрмәч чәкүшкәләре дә «ыңгырашмый». Аратирә генә, урыны белән туктап калган атларга кычкырынып алулар, «матур сүзләр» әйтеп «эч бушатулар» гына ишетелеп куя.

Әхмәтнәсир якташларын эзләп йөргән арада драгун гаскәрләре шактый гына ара китеп өлгергән икән. Икенче көнне төш вакытларында гына ул үз төркеменә барып житте. Алдагы төнне обоз тирәсендә, жәяүлеләр яккан учак янәшәсендә уздырды. Учак тирәсендәге халыктан күп кенә яналыклар, яшь патшага карата тәнкыйть сүзләре ишетте. Аның атлы гаскәр сугышчысы икәнен белеп алгач: «Ә менә син, егет, ук һәм кылычың белән анда ни генә кырырсың икән?! Бу сиңа киң далада чаптырып йөрү түгел. Саескан хәбәр итүгә караганда, без Нарвага барабыз. Аның бер ягында дингез, икенче ягында күл, елга, – дип егетнең күңеленә шом салдылар. Патшага карата да алар артык тартынып тормыйлар. – Пацан гына әле. Хыялдан башы әйләнгән чоры. Бер мөгезен сындырсалар, акылга утырачак. Ә аның михнәтен без күрергә тиеш. Нигә ул бу эшне көзгә калдырган? Коры вакыттарак уйлаган булса, без монарчы ул ныгытманы күптән яулап алган була идек. Бүгенгесе көннәрдә ныгытма эчендә жылы да, тамак та тук булыр иде», – дип, шаулашып, башка житезсезлекләрне дә сүгеп, төн буе эчләрен бушаттылар.

## 17

Арып-талып, зур кыенлыклар белән октябрь аеның башларында Нарва ныгытмасына барып життеләр. Төне буе йокламый обозны күпер аша ныгытма ягына чыгарып бетергәч кенә, башта атлылар, аннары пехота узды. Иртәдән кичкә кадәр ныгытма ягыннан көчле атышлар булып торды. Алдарак килеп урнашкан көчләр арасында, югалтулар булуга карамастан, каршы жавап бирүче юк иде. Туплар урнаштырып, һөжүмгә әзерлекләр алып барып ике атнадан артыграк вакыт узды. Атлы гаскәр позицияләрдән артта — ядрәләр очып житмәс урында урнашты.

Полковник Кропотов тәкъдиме белән Әхмәтнәсирләр төркемен һәм тагын утызлап чая егетне Борис Петрович Шереметьевның алдынгы авангарды итеп билгеләделәр. Чынбарлыкта алар, аерым бер урында берничә зур чатыр корып, генералитик төркемнән торган штаб сакчылары иде. Көн буе жыелышып, шау-шу килеп, бәхәсләшеп генераллар үзара сөйләшү, киңәшүләр алып бара. Кичләрен шәраб эчеп, күңел ачалар. Башка халык ачлы-туклы килеш ачык һава астында интеккәндә, өлкән дәрәжәле төркемнең оятсыз кыйлануы егет күңеленә тагын бер «китек» өстәде. Азов

сугышы вакытында атлы гаскәр ныгытма тирәсенә жыелып, кул кушырып утырмады ич. Аларның төп вазифалары бар иде. Кырым татарлары, төрекнең атлы гаскәрләреннән ныгытма камаучыларны сакладылар. Ә монда бөтенләй башка хәл. Алар кемне кемнән саклый соң? Ук, кылыч, сөнге белән ныгытма эчендәгеләргә ничек итеп каршылык күрсәтергә мөмкин? Юлда килгәндә олы яшьтәге хәрбиләрдән ишеткән сүзләр Әхмәтнәсирнең зиһенен буталап һич тә исеннән чыгарга теләмәде.

Ниһаять, әзерләнүләр тәмамланып, камаучылар һөҗүмгә күчте, көчле атышлар башланып китте. Төннәрдә дә туктамый ике атна буе атыштылар. Атышлар ноябрь ае башларында әкренләп сүрелеп, бөтенләй дә туктап калды. Сәерсеткән тулы тынлыкта генераллар штаб чатырына жыелды. Разведка китергән хәбәр буенча, Нарвага ярдәмгә чыккан шведлар, диңгездә көчле давыл купканлыктан, Ревельдә якорь ыргытканнар. Коры жирдән Нарва ныгытмасына ярдәмгә кузгалачаклар ди.

Бу көнне генераллар арасында сүз көрәштерү, шау-шу булмады. Барысы да бер карарга килә: дошманны көтеп ятмыйча, аларны үз жирләрендә каршы алырга.

Регуляр булмаган биш меңлек атлы гаскәрне житәкләп Шереметьев юлга чыкты. Көнбатышка төбәп өч көн буе йөз егерме чакрым тирәсе юл уздылар. Ике йөз атлыдан торган авангард төркеме һәрвакыттагыча алдарак иде. Көтмәгәндә бер төркем дошман гаскәре күренде. Ике арадагы тынлыкны аңга килеп өлгергән дошманнар бозды. Авангард төркеме ягына бер-бер артлы мылтыклардан аттылар. Берничә атлы яраланды. Әхмәтнәсир алдагы рәттә иде. Яра алган ат сөрлегеп китеп башы белән жиргә төртелде. Ат башы аша жиргә мәтәлләп төшкән Әхмәтнәсир аягын каймыктырды. Калган төркем, кычкырып, тавыш куптарып алга ыргылды. Көчле дошман утыннан аларның да бер өлеше юк ителде, калганнары жиргә сеңергә мәҗбүр булды. Дошман ягында, кыргый җанвар тавышына охшатып, быргы кычкырттылар. Үз көчләрен тоеп өлгергән шведлар һөҗүмгә ташланды. Исән калган бер төркем башкорт уклардан атып, кылыч, хәнҗәр белән дошманны каршы алды. Көчләр тигез түгел иде. Шведларга ярдәмгә тагын бер төркем көч өстәлде.

Аяк авыртуын онытып Әхмәтнәсир урыныннан күтәрелде. Янәшәдә яткан авыр яралының сөңгесен алып, жан-фәрманга чаптырып килгән эре гәүдәле дошманның күкрәгенә төбәде. Теге гөрселдәп жиргә егылып төшү белән, аңына килеп өлгерергә ирек бирмичә, хәнҗәрен дошманының бугазына батырды. «Ак Кашка! Ак Кашкам өчен!» — дип, икенче чаптырып килгән атның ал аякларына кизәнеп сөңге белән сукты. Ат абынып китеп, хуҗасы жиргә егылып төшүгә, дошманның башына сынган сөңге сабы белән орды. Яралы ерткыч кебек өстенә ыргылып бугазыннан буды. Шул вакыт көчле итеп «Ур-ра» кычкырган тавышлар ишетелде. Бу — урысларның төп көче иде.

Дошманнар өерелеп кире якка борылдылар. Әнә, берсе егет янына якынаеп килә — авыр киемнән, күзе-башы тонган. Әхмәтнәсир хәнҗәрен алып аягына басты. Соңгы вакытта кичергән кыенлыкларны, күңел әрнүен нәкъ менә бу адәмнән күргәндәй, яман кычкырып корбаны өстенә ташланды. «Юк! Үз иркемнән түгел! Мине мәҗбүр иттеләр!» — дигәндәй, теге адәм ике кулын югары күтәреп, каршылык күрсәтмәде. Катлы-катлы кием аша, янган утлы кисәү шикелле тәнгә үтеп кергән хәнҗәр ярасыннан жиргә ауды. Кулларын җәеп чалкан яткан бу ят кешенең күз карашында, «Юкка булды бу, юкка! Мин бит сиңа үч тотмыйм», — дигәндәй, тирән әрнү иде. Үз гомерендә беренче мәртәбә жаны чыгып барган дошманның эчке кичерешләрен тойгандай: «Гафу ит, брат! Минем дә сиңа үчем юк! Мине

дә мәҗбүр иттеләр!» – дигән хис уянып өлгергән Әхмәтнәсир, «авырттыра күрмим», – дигәндәй, хәнҗәрен саклык белән генә суырып чыгарды. Шул ук вакытта, артык җылы киенгәнсең, бу килеш ничек итеп сугышырга була дигән кызыксыну белән, киемнәренә күз салды. Муенны каплап торган йон тукымалы кием өстеннән тыгыз сукно пинҗәк. Пинҗәк өстеннән тагын бер кат тиредән теккән өс киеме. Зур, иләмсез күн итек. Башында тимер чүлмәк. Җитмәсә, аркасына авыр капчык та аскан.

Чаптырып килгән жиреннән янәшәсенә атлы туктады:

– Что, Ахмет, ранен?

Егет башын күтәрде. Бер урында биеп торган ат өстендә полковник Кропотов иде.

– Юк, полковник әфәнде. Аякны авырттырдым. Аттан егылдым.

Шунда гына ул Ак Кашкасын исенә төшереп, аты янына килде. Хуҗасын күргәч, ат башын калкыта төште. Торып басарга теләгәндәй ал аякларын җыерып куйды. Ядрә күкрәгенә тигән. Мул булып аккан каны суынып та өлгермәгән, пар күтәрелә. Яна туган тай чагыннан назлап үстергән, ничәмә еллар буе хуҗасының телен анлап, утны-суны кичкән иң якын җан иясе, мөлдерәп торган яшьле күзләрен хуҗасына төбәп, гүя: «Их, ничек итеп авыртканны белсәң иде, хуҗам!» – диеп нидер өмет итә иде. Күз яшьләренә буылып егет аты өстенә иелде, тезләнеп башын кочты: «Ак Кашкам! Берүземне япа-ялгыз калдырып китәсеңмени!?»

Җаны телгәләнгән егетнең үкереп елыйсы, янәшәсенә ятып атының әрнешүен үзенә аласы, онытыласы килде. Аңына килепме — хәнҗәрен чыгарды. Башкача ярдәм итә алмыйм, малкай, – дигәндәй, «Бисмилләһы Аллаһу Әкбәр!» әйтеп атны чалды. Ак Кашка каршылык күрсәтмәде. Үпкәсендә калган соңгы сулышыннан өске иренен тибрәтеп, тын гына кешнәгәндәй итеп куйды да, арт аягын сузып, тынып калды.

## 18

Ике йөз кешедән торган Авангард төркеменнән утыз алты кеше үлгән, сиксән бере яраланган иде. Шулар арасында ике дистәгә якыны авыр яралы. Урман янәшәсендә җир эрү иде әле. Зур гына чокыр казып мәетләрне күмделәр. Әсир төшкән шведларның икенче төркемендә унбиш җигүле йөк арбасы бар иде. Дару, бинт һәм ашамлыкларын кулланып, шул арбаларга яралыларны урнаштырдылар. Атсыз калганнар, җиңел яралылар швед атларына атланды. Өч йөз кешедән торган сак астында яралылар төялгән обоз Нарва ягына кире юнәлде.

Әсирләрнең әйтүенчә, шушы юл белән утыз мең коралллы гаскәр юлга чыккан. Кулга төшергән трофейлар шведларның яхшы коралллануын күрсәтә иде. Мылтыклары да сыйфатлы. Урыс хәрбиләре бер мәртәбә мылтык корган арада, тегеләр ике, өч мәртәбә алдарак корып, атып өлгерәләр. Азык ягыннан да алар күпкә аерылып тора. Киптергән, какланган балык, ит, ярма.

Әхмәтнәсир төркеменнән алты кеше үлгән, унысы яралы. Ә икесе бөтенләй дә авыр хәлдә. Кузгалып киткәндә: «Тегеләй-болай була калса, бәхил булыгыз. Исән-сау туган якларга кайтырга насыйп булып, бездән хәбәр җиткезегез!» – дип, бәхилләшеп аерылыштылар. Килгән яклап ярты чакрым арттарак җайлы урын бар иде. Шунда чигенеп, позицияне ныгыттылар, төнгелеккә әзерләнделәр.

Начар киемлеләр мәетләрдән салдырып өс-башларын яңартты, кайберләре коралланды. Әхмәтнәсир дә үзенә ошаган атны сайлап алды. Үлгәннәрдән кием салдырмады. Обозда кием-салым бар иде. Каймыккан аягы шешенеп бүртенгән — читекне кисәргә туры килде. Шунлыктан ул аягына яраклы итек, сарык йонынннан эрләп бәйләнгән өс киеме белән

мылтык та аласы итте. Яралылар белән китәргә теләмәде. Анда кайттыммы, монда калдыммы, анын авыртуы басылмас диеп, полковник Кропотовнын тәкъдимен кире какты.

Дошман килә калса күренмәсен өчен учак якмадылар. Йокылы-уяулы төн бик авыр узды. Бигрәк тә Әхмәтнәсир сызланып чыкты. Тынычка калган аяк ут кебек яна, сулкыллап сызлый. Урман өстенә ай күтәрелеп, ачык урыннарга зәңгәрсу яктылык инде. Титаклап булса да аяк өсте йөргәндә сызлау азрак сизелә диеп уйлап, көндез сугыш барган урынны күреп килергә дигән уй узды башыннан. Төнге каравыл житәкчесеннән рөхсәт һәм пороль алып, ат менгән килеш шул урынга китте. Ак Кашкадан ерак түгел генә тагын бер ат күренә иде — аны чигенеп барган жирдән атып үтергәннәр.

Ядрә ал аяк яклап билдән кергән, бугаз сөяген ватып чыккан. Жирдә яткан килеш атканнар, күрәсең.

Сакланып кына атыннан төште. Уйланып бертын басып торгач, төп карарга килеп, эшкә кереште. Тиресен тунап тормый гына арт санынннан зур ике кисәк сум ит кисеп алды. Авырлык белән атны икенче ягына әйләндереп, икенче боттан да берничә кисәк кисте. Кирәге чыгар дип кулга төшергән обоздан ике күн капчык алган иде, шуларга иплэп тутырды. Ак Кашкасы янына килеп бертын басып торганнан соң, китәргә жыенганда урман эченнән нинидер жан ияләре күренде. Аяк асларын иснәнә-иснәнә, саклык белән генә ат гәүдәсе янына якынайдылар. Болар бүреләр иде. Өчәү. Тагын бераздан урман кырыйлап калганнары да чыкты. Алдарак килгәне, башын аска иган килеш, өске иреннәрен ыржайтып, тешләрен күрсәтте. Син үз өлешенне алдын, калганы безнеке дигәндәй, тыныч кына ырылдап та куйды. Үзеннән-үзе егет күңелендә, «Менә кемнәргә унай ул кан кою, үтереш», — дигән уй йөгереп узды. Кыргый җанварлар өчен бәйрәм иде ул төнне.

Генерал Борис Петрович Шереметьев, өч төн рәттән ял итмәгән килеш, бу төндә бөтенләй дә керфек какмый уйланып чыкты. Ничек вакыт уздырырга белми аптыраганлыктан, полковник Кропотовны иптәшкә ияртеп, сакта торучыларны барлап чыгасы итте. Соңгы постны барлап кире китәм дигән чакта, юл борылышы өстендә атлы күренде. Каравыл башлыгы тиз арада үзен кулга алып: «Ахметтыр бу. Миннән рөхсәт сорап ул киткән иде шул якка», — диде аклангандай. Парольга дөрес жавап алып, егет якынаю белән:

— В чем дело, солдат, что там искал? — диеп кырыс кына сорау бирде генерал.

Шереметьевны читтән генә күргәләгән булса да егетнең аның белән йөзгә-йөз очрашып сүз катышканы булмады. Шунлыктан ул, бераз каушый төшеп, ни әйтергә белми:

— Ваши благаруди! Капрал Ахмет, сын Салимгарая, хадил туда, мясы брал. — Бераз тын ала төшеп, — Дабра прападает. Мясы харуши еда, — дип өстәп куйды.

Егетнең каушаганын күреп, полковник Кропотов ярдәмгә ашыкты.

— А что, в самом деле! Зачем добру пропадать?! — Генералга икеләнергә урын калдырмас өчен. — Почему-то сами мы об этом не догадались, — дип өстәде.

Ат өстеннән төшкәндә, онытылып китеп, авырткан аягына баскан иде егет. Көчле авыртудан бер якка кыйшаеп калды. — Что, ранен? — диде генерал, тавышын йомшартып. Бу юлы да полковник ярдәмгә килде. — Ул бүген өч дошманны үтерде. Аты яраланып егылганда аягын каймыктырган. Ул — курку белмәс сугышчы. Азов сугышында күрсәткән батырлыгы өчен капрал дәрәҗәсенә күтәрелде.

— Ты татарин?
— Так тучны, Ваш Блгароди.
— Почему с раненными не поехал?
— Пучтәк эты, Ваш Блгароди. Прайдет. Эты же ни раны.
— Как не рана!? Ты же на ногах стоять не можешь!

Татар егетенең үзен тотышы генералны бөтенләй эретте.

— Как думаешь, шведов одолеем?
— Кәнишне, Ваш Блгароди! Они сыты, тяжила адеты. Как бутты гуляйть собрались. Ну, аружи хараши! Порох харашо эстриляет, еда многы.
— Ну, ладно, иди отдыхай, капрал.

Үз урынына барып бераз вакыт үтү белән, бер шешә аракы тотып, полковник килде.

— Это тебе от генерала. Намочи тряпкой и намотай на ногу. Что от компресса останется, выпей. Легче станет.
— Водка пить нам грех, гаспадин палкауник. Что нагам памагает — галавам дурны делает. Бальшой спасибы.

Чынлап та, чүпрәккә чылатып аракы япканнан соң, аякның сулкылдавы басыла төште. Узган көннең мәхшәрен күз алдыннан тагын бер кат уздырып уйлана торгач, изрәп йокыга талды.

Дала өсте. Әллә кич, әллә иртәнге як. Ни өчендер бик суык. Тирмәннәр тирәсе буш. Халык кая китеп беткән? Ни өчендер ул жиргә бөгәрләнеп яткан, ә жир суык. Үзе жәй ае да шикелле... Аяк-куллары оеган, торырга итеп карый, тора алмый. Ни өчендер аягы авырта. Әллә елан чактымы икән?.. Кайдадыр якында гына бер-берсен уздырып дала бүреләре улый. Маллар кая? Маллар да никтер күренми. Бүреләр төшкән станга, бүреләр! Һәй кешеләр, сез кайда?!

«Һәй, һәй!» — дия-дия кычкырып, Әхмәтнәсир йокысыннан уянды. Таң атып килгән чак. Якында гына урман эчендә бүреләр улый. Аларның тавышында жанны өшеткән елау юк. Алар бүген тук. Карашларын күккә төбәп, жан бирүчеләргә юнь биргән Олы Көчкә тәсбих әйтүләре иде бу.

Ап-ак булып жир өстенә кырау төшкән. Юлның ике ягында, урман эчләрендә, өем-өем булып бер-беренә елышып яткан халык әкренләп уянды.

Бер урында сикергәләп, бер-берен төрткәләп хәрәкәткә килделәр. Арт яклап урман эченнән чокыр сузылган. Чокыр төбендә шарлап чиста чишмә ага. Генерал рөхсәт биргән, күрәсең, чокыр янәшәсендәге бушлыкта учак кабыздылар. Обоз тирәсендә кешеләр кайнаша. Казан элделәр бугай. Янәшәдә генә тагын берничә учак кабынды. Капчыгыннан бер түтәрәм ит алып, Әхмәтнәсир авырлык белән генә аксаклап, учак янына узды. — «Мясы каши ни портит», — дип, пешекчегә итен сузды. Әле чыерап та өлгермәгән итне кулына алып пешекче: «Ого! Совсем свежее мясо! Где раздобыл?» — дип, рәхмәт әйтте.

— Генералски запас, — диде егет, сүзне куертмас өчен тыныч кына. — Не хватит, ишшо найду.

Ничә көнгә бер бүген кайнар аш ашады халык. Итле өйрә халыкның күнелен күтәрде, төнге унайсызлык эреп юкка чыкты. Кайберәүләр, ат ите икәнен белеп алгач: «А что, съедобно! От говядины не различишь!» диеште. Кайсылары: — Еще вкуснее! — диеп өстәделәр. Итле өйрә генералга да хуш килде, күрәсең, бер төркем халыкны ит артыннан жибәрде. Бүреләр, Әхмәтнәсир итен кисеп алган атны ботарлаганнар, башка атларга кагылмаган иделәр.

Шереметьев офицер составын кинәшкә жыйды. Ни хикмәттер, Әхмәтнәсир дә катнашты анда. Генерал сорауны турыдан куйды:

— Дошман килгәнен көтәбезме, әллә кире китәбезме?

Арада төрле фикерләр әйтелде.

— Алты мәртәбә артык дошман белән көрәшү үлем белән бер.

— Без Нарва ныгытмасын алырга килдек, ә бу очрашу каралмаган.

— Безгә ул ныгытма да теш үтәрдәй чикләвек түгел.

— Бөтенләй җыенып Нарвадан ук китәргә кирәк. Кышка карап дошман Рәчәйгә кермәс.

— Киләсе елның җәй аенда, ныгытып җыенып килергә булыр, — диючеләр дә булды.

— Ну, что? Трогаемся тогда! Собирайтесь в путь! — диде генерал, сүзне йомгаклап.

Кайту унаенда ике күпер үтәсе бар иде. Дарының күп өлешен икегә бүлеп, күперләрне шартлатырга ниятләделәр. Күпер шартлатырга калган төркем, дарыны убай астына тыкканда, куллан ычкындырып, дары мичкәсен чылаттылар. Бөкесе ачык иде. Болай да дым тарткан дары шартларга теләмәде. Икенче күпер астында мичкәне чылатмадылар да. Барыбер ул көткән нәтиҗә бирмәде. Гөпелдәтеп болыт зурлык төтен генә чыгарды — күпергә зур зыян китермәде. «Тудый-судый мать!» — дип, дарыны сүгеп, күпер шартлатучылар үз вазифаларын үти алмады. (Тарихка ул вакыйга «Борис Петрович Шереметьевның, дошманнан качып барышлый күперләрне шартлатырга уена да кермәгән», — дигән уйдырма булып калды.)

Нарвага әйләнеп кайттылар. Шереметьевның бомбардир белән күзгә-күз очрашып хәлне уртаклашасы килгән иде, кичә кич Мәскәүгә кайтып китте диделәр. Калдырган язуы буенча, гаскәр белән идарә итүне Борис Петровичка йөкләп калдырган. Шереметьев тиз арада генераллар составын киңәшмәгә җыйды. Хәлне аңлатып биреп, башкаларның уй-фикерләрен тыңлады, үз фикерен дә ачып салды. Карашлар икегә бүленде. Генералларның күп өлеше, Долгорукий, Головин, Бутурлин һәм башка сугыш кырында дан казанырга атлыгып торган яшь офицерлар дошманны тар-мар итәргә өндәде.

Ул көнне төп карарга килә алмадылар. Шул арада сугышчылар арасында: «Утыз ике меңле, көчле коралланган швед Нарвага җитеп килә икән», — дигән хәбәр таралып өлгергән иде. Берәүләр ашыгыч рәвештә ныгытмаларын барлый, икенчеләре, чигенергә әмер булмасмы дип, өстән хәбәр көтә.

Икенче көннән иртәсендә шведлар килеп җитеп, урыслар ныгытмасыннан ике йөз адым читтәрәк урнашты. Озак та тормый, сәгать унберләр тирәсендә туплардан көчле ут ачып, сугыш башланып китте.

Шереметьевның үз сүзен бирәсе килмәде.

— Кто прав, а кто нет — история рассудит. Нужна ли нам героическая смерть?! Лучше бесславно отходить, нежели неоправданно губить армию! — дип, үз кулы астындагы гаскәргә, елганың икенче ягына чыгып, сугыш кырын калдырырга әмер бирде.

Алдан уйланып хәл ителмәгәнлектән, бу хәбәр гаскәриләр арасында ыгы-зыгы тудырды. Шул кадәр халыкны күпер аша үткәреп бетерер өчен вакыт кирәк иде. Көчле атышлар астында башланган бу чигенү качып китүне хәтерләтте. Баштарак Шереметьевның үз җитәкчелеге астында икенче ярга чыгу тыныч, хәвеф-хәтәрсез узды. Тора-бара хәл кискенләште. Узып өлгермәгән арбалар белән бергә ат менгән гаскәриләр этешә-төртешә күпергә кереп тыгылдылар. Кырый як арба тәгәрмәче читкә чыгып китеп йөк суга ишелеп төште. Үзе белән бергә кырый бүрәнәне куптарып алган иде, тотрыксыз калган башка бүрәнәләр дә таралышып, күпер ишелде. Арттагылар басымы аркасында алдагы рәтләр суга чумарга мәҗбүр булды. Бер-берсе өстенә ишелеп төшеп, тапталганнар шунда ук батты.

Ярга йөзеп чыга алганнары да, тайгалак ярдан күтәрелә алмыйча, тәнне

куырган салкыннан өшеп, һәлак булдылар. Бердәм житәкчелек булмау, вакытында дөрес карар кылмау Нарва сугышын әнә шулай хәл итте. Ул чорның тарихчылары, хәлнең асылын аңлап бетермичәме, әллә яшь Петр Ігә ярау теләгеннәнме, Нарва язмышын Шереметьевка бәйләп күрсәттеләр. Кемнең кем икәнлеген ачыклар көннәр алда иде әле.

## 19

21нче ноябрь көнне Карл XII тантаналы рәвештә Нарва ныгытмасына керде. Ныгытманы урысларга бирми саклап калганы өчен полковник Горнны генерал-майор дәрәҗәсе белән бүләкләде. Җиңел бирелгән бу җиңү швед патшасының башын әйләндерде, сугышны дәвам итәсе килде. Аның алдында ике сорау тора. Урысларның үкчәсенә басып Мәскәүгә юл тотаргамы, әллә Август IIгә каршы борылыргамы? Генералитет таләбе буенча фәкыйрь Русиягә каршы сугышу файда китермәячәк. Польша бай. Анда керем дә, трофейлар да күп. Швед патшасының үзенең дә Август IIгә кулы кычытып тора. Русиягә каршы сугыш башлауның Карл XIIне шикләндергән ягы да бар. Русия җирләре киң. Юллары начар. Обозны тулыландырырга мөмкинлек юк. Иң шикләндергәне — Август II. Урысларга караганда аның коралы югары сыйфатлырак. Шведларга арттан һөҗүм итүе мөмкин. Шул вакытта Дания, аңга килеп, урыслар белән мөнәсәбәтләрне яхшыртырга омтылачак.

Нарвада өч атна тоткарланганнан соң Карл XII Лифляндиягә юл тотты. Швециядән яңа көчләр килгәненең көтеп биш ай вакыт узгач, 1701 елның җәендә саксоннарга каршы сугышты. Анда җиңүгә ирешеп, утыз алты туп, әләмнәре белән биш йөз гаскәрне әсир төшерде. Лифляндиядә полковнигы Шлиппенбах кулы астында сигез меңлек гаскәрен калдырып, Речь Посполита җирләренә бәреп керде.

Нарвадан соң дәрәҗәсен югалткан Петр I, бөтен көчен, мөмкинчелеген эшкә җигеп, бу мизгелдән тулысынча файдаланып калу ягын эзләде. Аурупа илләре җитәкчеләре аннан мәсхәрәле көлде, Карл XII дә: «Шереметьевның атлы гаскәре арттан һөҗүм итәр дип курыктым. Ул чакта безнең хәлләр хөрти булыр иде. Ә ул качып китеп миңа зур ярдәм күрсәтте. Урыслар сугыш алып барырга сәләтсезләр», — диеп, ут өстенә май өстәп, мактанып йөрде. Узган хаталардан дөрес нәтиҗә ясап, Петр Ігә, шведларны гакылга утыртып, үз дәрәҗәсен торгызу кирәк иде. Шуның өчен ул үз-үзен жәлләми ары чапты, бире чапты, гаскәрне рәткә салу, кораллану, матди якны кайгырту буенча армый-талмый эш алып барды.

Идел буе өлкәләрендә гаскәр җыеп, Самар шәһәреннән алга кузгалган кенәз Репнин Никита Ивановичның ун мең сигез йөз кешедән торган тугыз пехота полкы, елга буйлап әйләнгеч юл узганлыктан, Нарва ныгытмасына бик соң килеп житте. Шунлыктан аңа ул сугышта катнашырга туры килмәде. Гетман Обидовский белән дә шул ук хәл иде. Шунлыктан кораллы егерме ике мең тирәсе гаскәр сакланып калынды. Шведларга каршы яңа сугыш башлар өчен болар гына бик аз. Петр Інең фәрманын үтәп, Борис Алексеевич Голицын кыш буена берәр меңнән торган ун драгун полкы туплауга иреште. Алардан башка тагын Нарвадан исән-сау котылып кайткан ике мең тирәсе сугышчы бар иде.

Бишенче декабрьдә, Нарвадан кайтуга тәгәл ике атна вакыт узгач, Шереметьев исеменә Петр Ідән фәрман килеп төште. Патша, Нарвадагы гамәлен җинаять дип санаса да, башкача тәҗрибәле таяныр сугыш җитәкчесе булмаганлыктан, Шереметьевны юаткан, хәлен уртаклашкан. Шул ук вакытта, бөтен көчен туплап шведларга каршы сугышырга, үч алырга өндәгән. «Фәлән исемле майор куркаклыгы аркасында җәзага тартылды»,

— дип, хатны очлап куюы — «Мин әйткәнне үтәмәсән сине дә җәза көтә», — дип кисәтүе иде, күрәмсен.

Хатны алу белән Шереметьев патша әмерен үтәргә ашыкмады. Эчке халәте белән ул мона әзер түгел иде әле.

Кушкан эшне озакка сузмаска, ил алдындагы изге бурычны онытмаска кушып, икенче хатны алгач, «Бог видит, мое намерение сердечное, сколько есть во мне ума и силы, с великою охотою хочу служить, а себя я не жалел и не жалею!» — дип җавап хаты юллады. Яшь патшанын теләген анлый иде ул, тик шул ук «мөмкинчелек» кенә патша «теләген» анларга теләмәде. Уныш китермәгән вак-төяк авантюраларга бирелә торган кеше түгел иде ул. Декабрь азакларында Алыста шәһәрен алырга теләп караган иде, шведлар көчле каршылык күрсәтеп, чигенергә туры килде. Вак-төяк төркемнәргә бүленеп, чик буе авылларын тынгысызлау аз-маз булса да уныш китерде, шведларның азык-төлек базасында ыгы-зыгы тудырды.

Шведлар да тик ятмады. Ара-тирә һөҗүм итеп, Псков җирләрен таладылар, җимерделәр. Печера монастырена һөҗүм итеп карадылар, тик тешләре үтмәде.

1701 елнын март аенда Архангельск тирәсендә берничә фрегат белән десант төшерделәр. Уйлары, шәһәрне җимереп, азык-төлекне талап, урысларнын каршылык көчләрен юк итү иде. Алар анда берничә фрегатларын югалттылар. Шулай итеп, ике як та Нарва хәлләреннән сон җинүгә ирешә алмады.

Җаваплылыкны арттыру ниятеннән Петр I Шереметьевны башкомандующий итеп билгеләде. 1701 елның сентябрь ае башында Шереметьев егерме мен кешедән торган көчне дошман җирләренә юнәлтте. Арада зур булган унбер мен кешелек гаскәр белән җитәкчелек итүне улы Михаил Борисовичка йөкләде. Ряпина кырында алты йөз кешелек швед гаскәрен кырып бетереп, беренче мәртәбә сизелерлек җинүгә ирештеләр.

Псков-Печерск монастыренда җинүчеләрне зур тантана белән каршы алдылар. Тантананын төп батыры Михаил Борисович Шереметьев иде. Калган ике төркемне андый бәхет читләп узды. Алар, Рыуг борынында җинелделәр. Бу турыда кичекмәстән мактанып, Шлиппенбах Карл XII гә юллама җибәрде. Янәсе Рыуг борын саклаган мен дә ике йөз кешелек гаскәргә каршы урыслар йөз менле гаскәр белән һөҗүм иткән. Алты мен кешене үтереп, урысларны җингәннәр. Чынбарлыкта урысларнын гаскәре өч мен җиде йөз ун җиде кешедән генә торып, барлыгы берничә дистә хәрбие генә үтерелгән иде.

Шуңа карамастан, урыслар Ряпин борынында ирешелгән җинүне тантана иткән көнне, шведлар Рыуг борынында җинүне зурлап бәйрәм итәләр.

Булып узган бу бәрелешләрдән сон, шымчылары хәбәр итүенчә, Шлиппенбах Эрествер борынында зур көчләр туплый. Биш мен тирәсе хәрби, өч менләп хәрби булмаган халык, Лифляндия чикләре буена урнаштырыла. Егерме өченче декабрьдә Шереметьев юлга чыга. Өч көнлек юл үткәннән сон, сиздерми генә дошманга һөҗүм итү уе белән, пехота һәм обозны артта калдырып, Эрествер борынына якынлаша. «Караклыкта йөрүче төркем генәдер», — дип уйлап, авангард көчләре артык игътибарлык күрсәтми. Раштуа бәйрәме уздырып яткан исерек шведлар тирән кар ерып урыслар һөҗүм итмәс дип уйлаганнардыр инде. Икенче көнне алар үзләренә каршы зур көч килүен белеп алалар. Сәгать унберда сугыш башланып китә. Драгуннар бер мәлгә җинүгә ирешә. Озакламый анга килеп өлгергән шведлар, туплардан картечь белән атып, аларны чигенергә мәҗбүр итәләр.

Пехота белән артиллерия ярдәмгә килгәч кенә хәл кискен үзгәрә. Биш сәгать буе барган бу сугышта шведлар тулысынча тар-мар ителә. Калдык атлы сугышчылары белән Шлиппенбах, көч-хәл качып котылып, Дерпт

ныгытмасында бикләнә. Урыслар кулына йөз илле әсир, уналты данә пушка һәм шведларның кышкылыкка әзерләгән күп кенә азык-төлек, фуражлары кулга төшә. Качып таралган шведларны Шереметьев эзәрлекләми. Бу турыда ул Петр Iгә: «Кар катламы үтә алмаслык калын, атлар сугыш кырында арып хәлдән тайган иде», — дип акланды.

1702 елның 4 гыйнварында Псковка әйләнеп кайттылар. Аларны зурлап, туплардан, башка кораллардан атып, тантана белән каршы алдылар. Бу турыда хат язып, Шереметьев улы Михаилны башкалага җибәрде. Мәскәүнең үзендә дә, фейерверклар белән туплардан атып, бу җиңү бәйрәмен зурлап бәйрәм иттеләр. «Мы можем наконец бить шведов!» — дип, Петр I үзенең шатлыгын яшермәде.

Үз чиратында Шлиппенбах та, Карл XII алдында акланырга теләп: «Урыс гаскәре йөз мең иде», — дигән сылтау тапты. Чынбарлыкта урыслар швед гаскәреннән өч мәртәбә артык иде. Өч мең ике йөзгә каршы ун мең тирәсе.

Бу җиңү Петр I нең рухын күтәрде, ул алга зур планнар корды. Лифляндия белән Эстляндия чикләреннән бик еракта, Нева елгасы тамагында сугыш ачуны күз унында тотты.

## 20

Нарва елгасын беренчеләрдән булып кичеп алга киткәннән соң, Әхмәтнәсирләр яралылар белән бер обозда, биш тәүлек буе юлда булдылар. Карау юклыктан, юл кыенлыгыннан авыр яралыларның күбесе үлде. Шулар арасында ике башкорт егете дә бар иде. Әхмәтнәсир аларны юлда ташлап калдырмады. Егетләрнең хәле мөшкел иде. Вишневкада чакта ул шифалы үләннәр җыеп киптергән иде. Тукталып учак кабызган урыннарда, шулардан төнәтмә кайнатып яраларына япты, чәй урынына эчерде. Кулыннан килгәнчә ярдәм итеп, хәлләрен җиңеләйтте.

Төн уртасында Псковка килеп җиттеләр. Каршы алучы булмады аларны. Гөбе кебек шешенгән аягының сызлавыннан төнне керфек какмый чыкты. Иртәнге якта гына аларны түбә астына керттеләр. Җылы бүлмәдә түшәккә борын төртү белән онытылып тирән йокыга талды. Икенче көнне төш вакытларында аны бер кыз бала уятты. Авыр яралыларны барлаучы түгәрәк ак сакаллы табиб, аяк шешенә баскалап, ничек яралануын сорашты. «Каймыгу белән сина аяк өсте йөрисе булмаган. Яралану белән кысып бәйләп ятып тору кирәккән. Гангренага әйләнеп аяксыз калуың бар, молодой человек», — дип, хәл уртаклашты, киңәшләр бирде. Ул китү белән теге кыз бала егетнең аягын юды. Зәңгәр-кара төскә кергән шешкә нииндидер май сөртеп, кысып бәйләп тә куйды. Кайнар шулпа белән ботка китерделәр. Мөлаем йөзле табиб белән шәфкать туташының мәрхәмәтлегеннән һәм җылы азыктан эреп китеп, егет янадан йокыга талды. Нииндидер дару да эчерткән иделәр. Иләс-миләс уянып азык капкалый да янә йокыга чума. Әнә шулай, бер атна тирәсе вакыт узды. Аяк әкренләп төзәлде. Табиб карт соңгы каравында егеткә торып йөрмәскә кушып китте. Алай да ул таякка таянып аягына басты. Башка яралылар яткан бүлмәләргә кереп, үз егетләрен эзләде. Сораша торгач, аларның икенче өйдә булулары ачыкланды. Ул көнне тышта каты суык иде. Аягына кием дә булмагач, чыгып йөри алмады. Шәфкать туташына исемнәрен әйтеп, барлап килүен үтенде. Икенче көнне аның янына ике егет үзләре керде. Яралары төзәлеп килә икән. Йөрерлек булгач, көрешергә рөхсәт биргәннәр. Калганнарның да хәлләре терелүгә бара икән. Әхмәтнәсир өчен бу бик тә шатлыклы хәбәр иде.

Декабрьнең җидесендә ул аяк өстендә иде. Дәваланып чыгар алдыннан киез итек белән тун бирделәр. Тагын атна-ун көннән башка егетләр дә терелеп чыкты. Аларны да шундый ук киемгә киендергәннәр иде.

Сонынннанрак ачыклануынча, бу полковник Кропотовнын тырышлыгы аркасында булган.

Полковник, егетләрне җыеп, кыска гына әңгәмә уздырды. «Отдохнули, силы восстановили, пора и честь знать», — дип, ул алга куелган бурычны искәртеп узды. Кенәз Никита Иванович Репнин гаскәре Псковта урнашкан булган. Араларында атлы өч йөз калмык та бар икән. Кенәз шуларны ике төркемгә бүлде, бер төркемне полковник Кропотов җитәкләде.

Әнә шулай, икешәр йөз кешелек диверсион төркемнәргә бүленеп, дошман җирләренә рейд белән чыктылар. Кропотов төркемендә якын-тирәне яхшы белгән озата баручы бар иде. Тан белән юлга кузгалып, егерме чакрым тирәсе тирәнлеккә, дошман җиренә үтеп керделәр. Кичке якта, Мариенбург ягына бара торган олы юлга чыгып, юл тирәли яшеренделәр.

Төнне шунда уздырып, икенче көнне иртәнге якта юл өстендә унлап йөктән торган обозга тап булдылар. Обозны иллегә якын атлы озата килә иде. Хәрби киемдә булмаган атлы төркемне күреп, алар бертын буталчык хәлдә калды. Мылтыктан атып, шау-шу килеп, егетләр тегеләр өстенә ташлану белән, каршылык күрсәтмичә качып киттеләр. Дошман анга килеп өлгергәнче дип, тиз арада обозны кайту ягына бордылар, төркемнен бер өлеше юлда калды. Куа чыгучы булмады. Ике көн эчендә хәвеф-хәтәрсез башкарылган бу гамәл, егетләрнең канын уйнатып, рухларын күтәрде. Кулга алган обозда азык-төлектән башка дәвалану кирәк-яраклары, бинт һәм чирекле шешәләрдә спирт бар иде. Әсир алынган хәрбиләр әйтүенчә Мариенбургта шведлар көч туплый икән. Кулга төшкән бу әйберләр дә шул ук сүзләрнең дәлиле иде. Башка төркемнәр дә, күп кенә азык-төлек, кием-салым, дары мичкәләре кулга төшерделәр. Бу хәлләрдән соң дошман да кул кушырып тик ятмады.

Декабрь ае азагында урыслар зур көч белән Мариенбургка һөҗүм итеп карадылар. Һөҗүмне көткәннәр иде, көчле каршылык күрсәттеләр. Зур булмаган югалтулар белән чигенергә туры килде. Шул хәлдән соң шведлар Гдова шәһәренә юл тотты. Тик шәһәргә һөҗүм итүдән баш тартып, тирә-як авылларны таладылар, яндырдылар.

1701 елнын беренче яртысы, вак-төяк бәрелешләрне искә алмаганда, тыныч узды. Ул елнын икенче яртысы Әхмәтнәсир өчен шатлыклы булды. Идел елгасынын өске өлкәләреннән бер меннән артык гаскәр килде. Аларнын күбесе Уфа ягы һәм Сарытау татарлары. Уфа татарлары арасында Богырыслан белән Әсәкәйдән дә берничә егет бар иде. Ул якташлары белән якын туганнарын очраткандай, күз яшьләрен тыя алмыйча, кочаклап исәнләште, яналыкларны, туган-тумачаларынын хәлен сорашты.

Әсәкәй егете Әхмәтнәсирнен атасы Сәлимгәрәйне белә икән. Күп яналыклар мәгълүм булды. Беренче хатыны Гөлсыру бала тапканда үлгән. Икенче хатыны белән Богырысланга киткәннәр. Ул хатыннан ике малае туган. Олы малае Солтангол Әсәкәй белән ике арада, Кинәле яры буйлап, тау итәгендә нигез корган. Сәлимгәрәй, олыгаеп барам, мина тынычлык кирәк дип, бөтен малларын Солтанголга калдырган.

*Дәвамы киләсе санда.*



Фарис
Фәсхи

# ҖАННЫ ПАКЬЛИ ТОРГАН ЯКТЫЛЫК

## Шагыйрь чабуы

*Шагыйрь Роберт Әхмәтҗан истәлегенә*



**Шагыйрь бара шәһәр урамыннан,**
**Озын пәлтә салган иңенә, –**
**Чабулары тузан сибә–сибә**
**Урам ташларында тибенә.**

**Күз карашы офык хозурында,**
**Күрми артта тузан тузганын.**
**Кемнең күргәне бар сандугачның**
**Койрыгына тузан кунганын?!**

**Хыяллары кебек сузылган да**
**Җилфер–җилфер шагыйрь артыннан,**
**Нечкә муенын кочкан озын шарфы**
**Чагылып ала урам чатыннан.**

**Чәйханәгә кайчак килеп тисә**
**Пәлтәсенең итәк читләре, –**
**Шагыйрь чабуына чиный–чиный**
**Ябышалар шәһәр этләре.**

**Шәһәр урамыннан шагыйрь бара,**
**Чабулары ташка орына,**
**Каршы җилләр чишкән шарфы белән**
**Җырсызларны чорнап җырына...**

Фарис ФӘСХИ (1948) – *шагыйрь, сынчы-рәссам; «Буталган буяу»,«Ник болай?»,«Иҗат хәле» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Төнге юлчы

*Шагыйрь Мөдәррис Әгъләм истәлегенә*



Бүгенгенең үзәк өзгеч җиле
Хәтер дәфтәрләрен актара,
Уйны ак каеннар арасына –
Үткән көнгә куып кайтара...

Җилнең суык кулы каерып–каерып
Кар тутыра эзсез сукмакка, –
Төнге юлчы айлы сукмагыннан
Килеп йөрми хәзер бу якка.

Яккан учагы да әллә сүнгән, –
Күмерле көл ята таралып.
Утсыз тәрәзәсе шәүләсенә
Бер ай гына йөри каранып.

Сердәш каеннары арасында
Җилләр җылый аны юксынып.
Аккош күле айсукмакка карап,
Һаман көтә төнге юлчыны...

## Ачуланма җилгә, тузганак...

*Җырчы Таһир Якупов истәлегенә*



Май килер дә, яшьнәп күк гөрелдәр,
Җилләр йөрер җирдә юргалап, –
Бакчабыздан күрше түтәленә
Болыт булып күчәр тузганак.

Сандугачның җырын күралмыйча,
Кубарылыр чәүкә өере;
Мамык тузганакка түзалмыйча,
Куырылыр күрше бөере.

Язгы бакчаларда җилләр чаба,
Түтәлләрне баса тузганак.
Кычыткannar ал гөлләрне чага,
Бәгъзе җанны сыра сырганак.

Мамык тузганаклы ак җилләргә
Бик аз гына сабыр итәсе, –
Ак язлардан кара көзгә кадәр
Ике адым бары... үтәсе.

Тимә, чәүкә, җырчы сандугачка,
Ачуланма җилгә, тузганак...
Син дә, күрше, тимә тузганакка –
Тузгысыннар җирдә юргалап.

## Җан яктысы

*Ватанпәрвәр Шамил Закиров истәлегенә*



Кыйбла яктан килеп буранлы җил,
Тетрәндереп Казан каласын, –
Ак карларга төреп алып китте
Татарның бу моңлы баласын...

Гомер юлы ак теләкле булды, –
Туган халкын әйдәп хаклыкка;
Бакыйлыкка күчкән чакта шуңа
Күкләр төрде аны аклыкка.

Йөргән эзләренә гөлләр яуды,
Ак моң яуды Күктән иңенә.
Ә үзеннән җанны пакьли торган
Бер яктылык калды Иленә.

## Илаһи моң

*Музыкант Рифкать Гомәров истәлегенә*



Һаваларда очкан кошлар җырын
Үтәли җил кискән бер мәлдә, –
Хыянәтле хәбәр иңрәп ятты
Илаһи моң иңгән Иделдә.

Чал талларның шәлъяулыгы чите
Килеп тиде Айның битенә...
Үги ана яфракларын япкан
Кай ягын соң Татар иленә?

Ялгыз аккош шул көн Идел–суда
Вәкарь белән никтер йөзмәде...
...Исемсез бер кошчык кына талда
Тетри–тетри нидер сөйләде.

## Еллар һәм Юллар

*Сынчы Нәүфәл Адылов истәлегенә*



Бу гомернең тиз узуын
Ник сизми икән йөрәк?
Аласы иде иңнәрдән
Елларны көрәп–көрәп.

Җыелды Еллар җилкәгә,
Сеңде иңнәргә эреп, –
Иңнәрнең авырлыгыннан
Шул Еллар тора көлеп.

**Еллар гомер елгасының**
**Кимерә текә ярын.**
**Бервакыт зилзилә килеп**
**Җимерә икән барын.**

**Җиһанга илаһи Юлдан**
**Күкләр аша җитәсе...**
**Үзең салган Юллар буйлап**
**Янә күккә китәсе.**
**Янә күккә китәсе...**

## Ак гөләп

*Шагыйрь һәм нәфис сүз остасы*
*Эльс Гаделев истәлегенә*

**Җилләр киткән, бакча тып–тын калган, –**
**Гөлләр, үләннәр дә селкенми.**
**Алмагачлар бәкәленә сары**
**Келәм япкан иде ул көнне...**



**Моңлы таушың иңгән шигырьләрең**
**Гөлләр өсләренә үрләде.**
**Сагыш сибеп торган сары келәм**
**Аксыл түшәк булып үзгәрде.**

**Тузганаклар синең соңгы язны**
**Әллә сиздe, әллә сизмәде...**
**Шул яздан соң уйчан карт алмагач**
**Ак күлмәген бүтән кимәде.**

**Син шигырьләр укып яткан җирдә**
**Үрсәләнеп шытты ак гөләп, –**
**Һәр яз саен керфекләрен ачып,**
**Теләп тора безгә ак теләк.**

---

...Биредә бирелгән барельеф-портретларның авторы — Ф.Фәсхи үзе.



Рафаил
Газиз

## ТӘРӘЗӘЛӘР

БӘЯН

Урта мәктәп тәмамлаган Зөлфәтне әнисе Казанга җибәрмәде:

– Улым, авыл китапханәсендә укымаган китабың калмады, мәктәптә дә яхшы укыдың, әллә эшләп карыйсыңмы соң...

Мәктәп директоры әтисенә якын дус булган. Директорның кызы тугач, ике фронтовик баласының колакларын да тешләткәннәр – бергә кушылып яшәрләр дип өметләнгәннәр...

Зөлфәтнең әтисе үлгәнгә дә инде унбиш ел тулды. Аңа фәкать 32 генә яшь иде. Әтисен исенә төшерсә, хәзер дә йөрәгенә кан сава. Сарайга чыкса да, күршеләренең су буендагы мунчасына төшсә дә, муенына атландырып йөрде әтисе. Ул аның чәченә ат ялына тотынган сыман чат ябыша, егылып төшүдән курка иде. Аннан әтисе колагына тотындыра, шундый йомшак иде ул колаклар. Бөтен иптәшләренең күзе ут яна, чөнки бер аны гына бөтен авыл буйлап шулай йөртәләр ич! Атта гына йөрү түгел, әти муенында йөрү!

Әле әтисе «Алмагачлары» көенә кычкырып җырлап та бара:

> Әй, алмагачлары, сайрый сандугачлары,
> Сайрый, сайрый, сайрый, сайрый
> Сагындыра башлады...

Очраган апалар, әбиләр елап калалар. Моны өч-дүрт яшьлек малай ничек аңласын? Мин егыла дип елыйлар, ахры, дигәндер. Егылыр, бар, әтисенең җилкә аша сузылган каешына да беркетелгән бит әле ул.

Хәзер генә аңлый Зөлфәт: ул апаларның ирләре, уллары, туганнары сугышта үлгән, югалган булганын. Аның хәрби киемле әтисен күргәч, моңлы җыр ишеткәч йомшаганнардыр. 142 ирен фронтта югалткан сала шул Көмеш Чишмә.

Дөрес, директор кызы белән боткалары пешмәде малайның. Кыз тыйнак, әдәпле, зәп-зәңгәр күзле, чибәр иде. Урман авылыннан төшеп укучы якын

Рафаил ГАЗИЗ (1947) — *шагыйрь, прозаик; «Бөре керфекләре», «Кичер, кичерә алсаң», «Ак болыт» һ.б. китаплар авторы, Г.-Х.Андерсен исемендәге халыкара почетлы диплом иясе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның атказанган укытучысы. Мамадышта яши.*

дустына үстергән икән кызын директор абыйсы. Анламассын бу гыйшык-мыйшык эшләрен. Туры дисән кыек килеп чыга, кыек дисән, тора-бара турая да куя. Ул кыз да дусты белән гаилә корды, ачуым килмәгәе.

***

Физкультура укытырга фәрман алып, туган авылы Көмеш Чишмәдә сигезьеллык мәктәптә эшли башлады Зөлфәт. Авылда спортчы дигән даны бар. Инде бишенче сыйныфта укыганда ук ике километрлы дистанциядә район чемпионы булды. Ә бер елны мәктәпнең чаңгы командасы «Пионерская правда» газетасы оештырган СССР күләмендәге ярышта җинде, күчмә кубок һәм грамота алды.

Авылның беренче спорт фанаты Фаил абыйсыннан үрнәк алды, спорт белән шөгыльләнде, махсус китапханә туплады. Үзе ясаган турникта уйный, штанга күтәрә, гантельләр белән сикерә.

Мәктәптә параллель сыйныфлар бар. Көненә бишәр сәгать физкультура укыта, һәр дәрестә укучыларны әйдәп йөрү дә аны ардырмый. Физкультура укытучысы ул бит бүтән мөгаллим түгел, һәрдаим матур йөреше, күнегүләрне күрсәткәндә төгәл хәрәкәтләре белән үрнәк күрсәтергә тиеш. Бар ул бәрәңге капчыгы кебек бүселгәннәр, спорт тирәсендә тамак туйдыручылар, значок җыючылар.

Зөлфәт әле өйләнмәгән егет тә. Укучы кызларга бу бик ошый. Кызлар алар малайлар түгел, ун ел алдан күрә.

Биш ел физкультура укытты Зөлфәт, армады, ялыкмады. Мәктәп командасы районның чаңгы ярышларында гел беренче булды.

Физкультурадан дәрес планнары озын түгел, дәфтәр тикшерәсе юк. Вакыт тренировкаларда уза. Көзен, язын йөгерәләр, таяк белән этенеп кулны-аякны чыныктыралар. Кышын исә чаңгы шуалар.

Ул малайларны биергә дә өйрәтте. Дәрестән соң һәммәсен мәктәпкә чакыра, беркем белергә тиеш түгел, «дәүләт сере»! Класс ишеген эчтән шатырдатып бикли дә, боларны парта рәтләре арасына сирәк-мирәк бастырып куя. Ике кул белән парталарга таянып, аякны әле алга, әле артка җибәрәләр. Үкчә белән идәнгә бәреп тыпырдыйлар. Биюдән өй эше дә бар. Май башына биергә өйрәнмәгән малай экскурсиягә бармаячак. Кайталар малайлар өйләренә эт булып, бию бит ул кешене хәлдән тайдыра икән. Ләкин лапаста аяк болгарлык урын эзлиләр, булмаса, ясыйлар да, тыпырдый башлыйлар.

Ай буе репетиция ясап, май буе биеп тә йөрде әле бишенче сыйныф малайлары. 1 Май бәйрәменә концерт куйдылар. Иң шәп номер малайлар биюе булгандыр. Дәүләт сере югарылыгындагы эш җимешләрен мул бирде. Ничек биергә өйрәнүләрен хәтта кызлары да белмәде.

...Алып баручы сәхнәгә чыгып берни әйтмәде. Рифкать абыйлары хромкала сыздырды гына, бишенче сыйныфның бар малае биеп чыкты. Пардан киенгәннәр. Торып басмаган бер укучы да калмады залда. Укытучылар да орышмады дөбердәгәнгә, алар да шаккаткан иде. Башларында түбәтәй, өстә ак күлмәк, билдә кызыл билбау, үтүкләнгән кара чалбар, аякларында читек. Читеге олырак булуын да сизмәделәр. Урманда, саф һавада репетиция ясау килешкәнме, абыйлары бик таләпчәнме, мәктәпне тәмамлаганда гына ирешәсе осталыкка болар инде хәзер ирешкән иде. Бөтенесендә бер үк хәрәкәт, чөнки бар да Зөлфәт абыйлары кебек тыпырдый. Мәктәпне бетергәннәренә кырык ел үтсә дә, алар хәзер дә нәкъ шулай биләр!

Әле мона кадәр авыл клубының мондый алкышны ишеткәне юк иде. Әй, күңеле булды Зөлфәт абыйларының да! Галәттә, тәнәфестәге җырлы-биюле уеннардан да кача бит ул малайлар. Ә хәзер исә алар сыйныфында гына ун биюче малай бар. Менә сиңа мә!

Концерт өчен рәхмәт әйткәндә, сәхнәгә чыгып тезелгән «артистларны» директор абыйлары бөтен дөньяга танылган мәшһүр биюче — адашы Мәхмүт Исәнбаевка тинләде.

Ул бөек биюче чүгәләгән жиреннән ярты сәгать тора икән, ә үзе биюен бер секундка да туктатмый. Аның патша, король, хан, солтан, тагын әллә нинди затлы кешеләр бүләк иткән алтын, энже, мәржән белән бизәлгән киемнәре, мылтык-кылычлары, мөгез һәм бокаллары, сәгать һәм чылбырлары галәмәт тә күп ди, аларны музейга куйганнар икән.

Менә нинди дәрәжәгә иреште бишенче сыйныф малайлары! Шуннан сон ничекләр тынламыйсың ул Зөлфәт абыйларын! Тәмам кеше итте бит!

Күрше сыйныфта Әсгать исемле бер киребеткән малай бар. Физкультура дәресендә, үзе гаепле булса да, иптәш малаен кыйный башлый бу. Зөлфәт абыйлары килеп араламаса, эш нәрсә белән бетәр иде, бер Алла гына белә! Эш Әсгатьнең күлмәге умырылып төшү белән тәмамланды. Күлмәк өр-яңа иде. Авыр еллар, авыр яшәүче ишле гаилә. Ничек күлмәк алырлар, дип борчылды Зөлфәт абыйлары.

— Абый, үзе гаепле бит, — дип тынычландырырга маташкан Расихка болай дип әйтте укытучы:

— Ул алай санамыйдыр, акырып елап өенә йөгерде, сумкасын да алмады, әләкләргә инде. Хәзер әнисе төшеп житәр.

Зөлфәт абыйларының кәефе китте, Расих классташларын җыйды да:

— Теге әләкләргә менеп китте, күлмәк алдыртам ди, Зөлфәт абыйны гаепләячәк, укытучының бер гаебе булмаса да. Әйдәгез, өенә менеп төшик әле.

— Ярар, — диде барысы да.

Әсгатьнең әнисе, ару киемнәрен киеп, капкадан ыжгырып кына чыккан иде, малаенның классташлары аны камап алды, янгыр явар алдыннан пырылдаган чәүкәләр кебек чәрелдәргә дә керештеләр. Вәгыйзә апа, бер-ике тапкыр ана каз кебек ысылдап карады, егерме чәүкәгә каршы тора алмады. Әсгатьнең арт шәрифләренә берничә тапкыр тамызудан, куенына кыстырып мәктәпкә алып төшәсе ертык күлмәкне йөзенә бәрүдән узмады.

Бишенчеләрне бу кадәр берләштергән вакыйга юк иде әле. Әсгать тә басылды, яна күлмәк тә тәтемәде, иптәшләренең сөймәс, сөйкемсез сөягенә әйләнә язды бит.

***

Вакыт тиз үтә. Иң истә калганы «Ажаган» уены булгандыр. Инде Миннәхмәтләр жиденчедә укый иде. Март ае. Хәзерлеккә Зөлфәт абыйлары житәкчелек итте.

Сугышта батырлык күрсәтеп, орден-медальләр тагып, офицер булып кайткан мәктәп директоры хәрби уенны оештыруда зурдан купты. «Ажаган» өчен авылдан ике чакрым ераклыктагы «Йөрәк Өе» басуы сайланды. Кышын куян белән төлке эзеннән башканы күрмәгән, көньяк-көнбатыштан урман белән каймаланган кырны директор белми сайламагандыр. Офицер кеше бит!

Малайларга автомат, сапер көрәкләре, кәчтерүл, тәлинкәләрне имгәтеп каска ясау дисенме, кызларга ак халат, санитар сумкалары, аларга кызыл хач билгеләре тегү дисенме... Яралыларны табу һәм эвакопунктка ташу өчен мендәрләр салынган кул чаналары хәстәрләү дисенме, яна елдан сон гел шулар белән матавыкландылар.

Совет Армиясе көненә хәзерлектә дә «Ажаган» уены үзәктә иде. Мәктәптәге «Б» класслары һөжүм итүчеләр булды, «А» сыйныфлары крепость төзүчеләр һәм аны саклаучылар. Монысын жирәбә хәл итте.

Алтынчы «А»ларның җитәкчесе, хезмәт укытучысы Габделхәй абыйлары «дошман» һөҗүм итәсе крепостьны шундый итеп төзетте ки! Аның биеклеге, аның матурлыгы, манараларының дәһшәте! Берничә атна дәвамында крепостьның һөҗүм буласы ягына текә үр ясалды, ул су сибеп шакрандай катырылды. Анда чебен дә аягына басып тора алмый, кая анда Миннәхмәтләр!!! Ул ату тишекләре, ул җепшек карны әвәләп ясаган, «атака» дип йөртелүче кар йомарламнары, атышканда, тисә дә тимәсә дә, һәр дошманны кырыкмаса-кырык үтерерлек иде.

— Иван Грозный Казанны алган, тик бу крепостьны ала алмас иде! — дигән, кирмәнне күрү өчен махсус рәвештә ерак басуга менгән тарих укытучысы Фәүзия апалары. Билләһи менә!

Уенның катгый кагыйдәләре бар. Габделхәй Васыйлович гарнизоны саклаган крепостька бары маңгайдан, авыл ягыннан гына һөҗүм итәләргә тиеш. Кар йомарламы тиеп сафтан чыккан һәр сугышчыны санитарлар госпитальгә ташый. Уен барышын, кагыйдәләр үтәлешен класс җитәкчесе булмаган укытучылар бик таләпчән хөкем итәчәкләр, имеш.

Һөҗүм итүчеләрне, саклаучыларны ашату белән интендант взводы шөгыльләнә: учак хәстәре, бәрәңге пешерү, ипи кисү, чәй эчертү — алар өстендә. Барысы да исәпләнгән, чөйләнгән-көйләнгән. Һөҗүм итүчеләрнең авылдан өстерәп менгән озын баскычлары да бихисап иде.

Уен башланырга сигнал биреп ракета чөелүе булды, биш-ун минуттан уен бетте дә. Шунысы кызык: җиденче класстагы Рафаил: «Үтерә генә күрмәгез, сатылам!», дип кычкырып һөҗүм итүчеләр ягына качты. Аның инде өч ел буе дусты Миннәхмәт укыган класска күчәсе килә, һич җае гына чыкмый иде.

Бөтен эшне «Аҗаган» уены кагыйдәләрен укымаган, әллә инде санламаган, чын сугыш белән чагыштырганда чүпкә генә санаган мәктәп директоры бозган икән. Ул һөҗүм итүчеләрдән торган утыз кешелек удар төркем оештырган да, крепостьны тылдан алу өчен әйләнгеч урман юлыннан җибәргән. Партизан-диверсантлар уен башланганчы ук юлга чыккан, берничә чакрым кар ерып, крепостьның тылына төшкән, урман эчендә сигнал ракетасын шакаллар кебек көтеп ятканнар.

Ракета оча гына, уен шарты буенча тылдан һөҗүм көтмәгән гарнизонны аптырашта калдырып, ике яклы һөҗүм башлана. Габделхәй Васыйловичның коточкыч тавышы да берни майтара алмый. Дәһшәтле крепость алына һәм тар-мар ителә.

Әллә кайдан директорга ысылдап килгән Габделхәй Васыйлович: «Уеныгыз уен түгел, мәче ние», дип авыз тутырып әйтә дә, кул селтәп, авылга төшеп китә.

Директор: «Сугышта алай булмый ул, ха-ха-ха!», — дип акланырга маташса да, «Аҗаган» турында сүз чыкса, йөзе кара көйгән Габделхәй Васыйлович теге гыйбарәне генә ысылдый иде: «Уеныгыз — уен түгел»...

***

Өй кыегыннан, болдыр түбәсеннән, ат сарае саламнарыннан чәнти бармак нечкәлегендәге, баздагы бәрәңге үсентесе сыман гына җылы бозлар чөмгереп чыкты. Аны Миннәхмәт күрмәгән дә булыр иде. Түбәнге зират елгасында, аунамаган бер уйгылны калдырмыйча, буран малае булып кайтты. Әнидән эләгә инде, шулай да кагылганын каккалап, кырылганын кыргалап, салынганын салып, шакрандай каткан чалбар балакларын яньчеп-сындырып сау-сәламәт хәленә кайтарырга азапланганда гына муенына тамчы тамды. Мунча ташы кебек кызган тәнне ул калтыратып җибәрде дә, Миннәхмәтнең башында даһи уй туды: әнине өйдән чакырып чыгарып,

язның беренче бозын күрсәтим әле! Яз килә икән бит! Март азагында чаңгы ярышына барасы бар, анысы. Ләкин эш андамыни? Тамчы тама!

Малайның әсәрләнеп өйгә керүе булды, «әни, әйдә бер нәрсә күрсәтәм!» — дип кычкыруы булды...

— Каяле, каяле, кем-кемгә күрсәтер әле монда! — дип уклау йомарлап чыккан Фәйрүзәтти малае күрсәткән нәни генә бозны кулы белән сыйпап кеткелдәп көлеп тә җибәрде.

— Күрсән, син генә күрәсең инде, улым. Күренерлеге дә юк бит әле монын, — дип малаеның сизгер йөрәгенә, нечкә күнеленә куанып уклавын кая куярга белмичәрәк торды да, кисмәктәге онга кадады.

Миннәхмәтнең өстеннән киемнәрен, ташбаканың кабыгын салдырган сыман, кубарды да мич башына сөяп куйды. Чалбар да шунда басып тора...

Табынга бер коштабак дучмак та килгәч, Миннәхмәт, зират елгасында булган мажаралар белән майлап, дучмакны сыпырды гына. Ризыгын яратып, мактап ашаган кешедән дә якын кеше юк пешеренгән хатын-кызга. Ул андый бәндәгә йөрәген дә ярып бирә. Эреде дә акты әнисе, онытылды кисмәктәге уклаулар.

Әллә кемгә охшаган бу Миннәхмәте, теге якта да, бу якта да сүзне бөккән кебек сырлап, бәлеш кебек майлап-җайлап сөйләшүче юк кебек. Ә бу, кычыткан чыпчыгы, әнә ничек мактый әнисенең дучмагын!

— Бу бәрәңге кояшы бит, нишләп пычак белән турадың син бу кояшны, әнием? — дигән иде, Фәйрүзәттинең күзеннән яшь бәрде. Ниндидер сылтау тапты, почмак якка кереп күзен сөртеп чыкты да:

— Ярар, кабат турамам, улым, кояш килеш ашарсың, — диде.

Рәхәт иде төпчек улы белән кара-каршы утыру. Олы кызы Аргыякта кияүдә. Эшләп яшиләр, хәләл көч белән, Аллага шөкер. Кияү — акыллы кеше. Язын чәчүдә, көзен — комбайнда, куян кебек кетердәтеп арыш-бодай ура. Кышка кердеме, фермага эшкә менә — терлек арасына кучә. Ходай балалар да биреп сөендерде үзләрен. Көмеш Чишмәнең кояш чыккан урамында, аның да иң беренче өендә иртәнге көтү чыгып китә торган шомыртлы тау янында яшәп яталары. Табыннарында үзләре үстергән, күпереп торган хуш исле икмәк, парлары чыгып торган сөт, уалма бәрәңге, инештән тотып алган балык дисенме. Келәтләре тулы капчык-капчык бодай, арышның күпме икәнен белүче дә юк. Сарайлары тулы сыер да, бозау да, сарык. Чөнки терлекне кай якка кусалар да иртәнге чыгы биленә кадәр коендыра торган җиләкле-печәнле тау битләре, әрәмәләр, уйгыллар. Ярга дулкын лыпылдатучы инешләр, чишмәләр.

Олы кызы житез, булдыклы бала Фәйрүзәнең. Ни персидәтел янына, ни авыл Советына, ни пучтыга, ни тегермәнгә ирен йөртми, юк-бар белән ирен борчымый. Персидәтел янына менсә дә, — хуҗаның кәефе ничек, гаиләсендә иминлекме, колхозда ул-бу юкмы, ишеген шакысам үзе генә микән? — дип, керергә чират торган кешеләрдән сорашыр. Хуҗа бүлмәсеннән ишетелгән күк күкрәүне чамалар да, кире борылып төшеп китәр. Димәк, әле хуҗа янына керү өчен Ходай насыйплаган мизгел өлгермәгән. Фагыйлә рәис янына кереп чыгуны олы бәйрәмгә әйләндерә белә. Нәкъ вакытында кирәк!

Персидәтел дә Фагыйлә апасы кергәч рәхәтләнеп сөйләшеп утырсын. Дөрес, кайчан керсә дә кире бормыйлар. Хикмәт андамени?! Ана, гади эшчегә, колхоз рәисе әллә нинди кинәшәсе мәсьәләләрен житкерә һәм ин дөрес жавабын да ала иде. Югыйсә бит, идарә утырышы бар, белгечләре бар, үз тәжрибәсе бар. Телефон чылтыраса да алмый, дөньясында бер жайлы кеше белән гәпләшә ич.

Әнә, күрше авылга торбадан басма салу да Фагыйлә апасы белән сөйләшкәндә килеп чыкты. Бөтен кеше аны персидәтел Минлегаян салдырды дисә дә. Салдыруын ул салдырды да, ә очкынын Фагыйлә апасы очырды бит.

Кайсы көтүне кайчан, кайда чыгарасын да тач әйтә дә сала. «Менә Саурыш елгасында чемчендерә башласак шушы җомгада?» — ди Минлегаян Каюмович.

— Өлешләп-өлешләп кенә ашат, үләннен тамыры да ныгымаган, кавырсыны чыкмаган сабый кебек. Ләкин фермада тирес, газ эчендә дә яткырып булмый, бетләрен коеп кайтсалар да ярый, яфрак та чемченерләр, ябагалары да очар, каен суы аккан агачларга ышкынып кышкы ялкаулыкларын да коярлар, — дип җибәрүгә, Фагыйлә апасына нәрсә сораса, шуны бирә Минлегаян Каюмыч. Бу инде: шул нәрсә кирәк ие, бу нәрсә кирәк ие, дип, булмаса, ярар, дип чыгып китә торган ирләр түгел. Фагыйләдән котылам димә. Ул тиешлесен генә сорый һәм вакытын туры китерә, бирә алганнан бармак калынлыгы булса да кимрәк сорый. Аласы әйберенә кәгазь яздырып менгәч тә Фагыйлә апасы: «Алла, бигрәкләр дә күп сорадым түгеме сон, бу кадәрле инде, бу кадәрле», — дип матур гына чигенеш тә ясый.

Фагыйлә апасы изге теләкләр теләп чыгып киткәч, Каюмыч бүтән кешене кабул итми. Моны һәркем яхшы белә. Ул «УАЗ»игына утыра, күнеленә хуш килгән белгечләрнен берсен ала да Саурыш елгасына юнәлә. Әйләнгеч юл була дип тормый, теге күрше авылга төшкәндә елга аша салынган тимер басма янына туктый, теге якка, бу якка чыгып бер әйләнеп керә. Култыксага шап-шоп суккалый. Анын бу гадәтенә ияләнгән кешеләр — шофер да, зоотехник та — бер сүз дәшми, ял итәләр. Чөнки үзләренен дә зур, файдалы эшләр майтарганнан сон күнел балкышы кичергәннәре бар. Артык сүз ычкындырып, шатыр-шотыр куак сындырып килеп чыккан пошый буласылары килми.

Аларны Саурыш елгасынын дымлы үзәне, чәчәкле тау битләре, яз көнендә чәчәк аткан шомыртлары белән күкне томалап чатыр хасил иткән Бурсык елгасы, анын бала йоннары чыгаручы салкыны, исертерлек хуш исе көтә.

Язгы сулар юып шомарткан ак ташлар балкый, кайдалыр, кояшны кире кайтарып, пыяла ватыклары күзне чагылдыра. Хуҗа да көтү чыгарунын, язгы чәчүнен кайбер борчуларын шушы уйгылларда адаштырмакчы була. Аз сүзле персидәтел. Сандугачнын сайравын озак кына тынлагач: «Сайрыйлармы?», ә Саурыш чишмәләренен суын уртлагач: «Агалармы?», — диюдән узмый. Аннан Бурсык белән Саурыш елгалары кисешкән җирдә җылы комташка утыра да, тәмәке кабызып җибәрә. Төпчеген сүндереп кесәсенә сала. Юк, ташламый бу матурлыкнын күзенә чүпне. Хәтта иртәгә көтү чыгасы булса да.

Аннан сон, ерганак башларында силәдә сикергән сыман очынган машинага утыра, Хәсән чүнниген, Рәхимулла умарталыгын урыйлар. Казыган тау башына кайтып туктый да Минлегаян өченче җөмләсен кысып чыгара:

— Йә, нишлибез?

Ана җавап кирәк тә түгел. Бу инде кимәленә китерү өчен генә эшләнә. Болай да анлашыла: алардагы кебек чишмәләр дөньяда юк. Бурсык елгасындагы сыман шомыртлык СССРда юк, Хәсән чүнниге почмагындагы кебек сайраучы сандугач галәмендә юк. Димәк, көтүне иртәгә чыгаралар...

Фәйрүзәнен олы улы Муллахмәт тә өйләнеп башка чыкты. Рәсимәсе

белән Югары очта чүкелдәтеп яшәп яталар. Ни өчен чүкелдәтеп, чөнки малае алачыкта тимерче. Чүкеч белән коя язмышын, чүкеч белән бөтәйтә хуҗалыгын. Килене тупырдаган балалар да апкайта. Чыр-чу өйләрендә. Татулык-тигезлектән аермасын Ходаем, дип битен сыпырганын да сизмәде Фәйрүзә.

— Әни, бер сынык дучмак ашауга әппәр итәләрмени? — дип эндәшкән Миннәхмәтенә:

— Ярар, улым, апаң белән абыеңа дучмак илтеп кайтырсың, үзебез генә авыз күтәреп ашап утыру ярамас. Табында алар булмагач әллә ничегрәк. Онытылып киткәнмен. Әйдә, капкалыйк әле! — дип табакка үрелде Фәйрүзә.

Әтисез үсә малае, ир-атта булган холык йоксын өчен әйбәт булды әле: класс житәкчеләре итеп Зөлфәтне куйдылар. Ул да ятим үсте. Тормышны жигелеп тарта, өйләрендә ат жигүче юк. Печән, салам, утын хәстәрләү дә үз жилкәсендә. Егет кеше дип тормый, көянтә-чиләк белән чишмәдән су ташый. Әнисе бик булган хатын, авыл Советында эшли. Уфалла тарталар, кешегә ялынмыйлар. Мал асрыйлар, өй салалар. Үзе дә, энесе дә чиста киенә. Әйбәт укыдылар. Үрнәк гаилә инде.

Миннәхмәт гел абыйсы турында сөйли:

Абый болай әйтте, абый тегеләй кушты. Йоклаганда: «Мин капитан Немо!», дип кычкыра. Кәжә тәкәсе белән бокс уйный, койма, каен башыннан төшми. Гомер булмаганны ботинкасын чистарта, галстугын бастырып куя башлады. Ә бер көнне биеп тә күрсәтте. Менәтрәк! Нәселдә ир-атлардан бер биегән кеше юк бит, югыйсә! Кимәленә китерә.

Китапханәдән китап ташый. «4»кә, «5»кә генә укый. Галстугын өй түрендәге иң биек кадакка элә. Үзгәрде малай, менә шуңа сөенеп бетә алмый Фәйрүзә.

Болдыр түбәсеннән жиргә сикерергә жыенучы язны да күреп алган бит, Аллага шөкер. Маллар исән-сау, өй базында бәрәңге күп, озакламый бакчадагы орлык базын да ачып карыйсы булыр. Су гына төшә күрмәсен. Сәндерәләрендәге салам-печән дә басудагы эт эчәгесе кармавычына эләгерлек. Үзләре исән-сау. Каралты-кура өскә ишелерлек түгел. Утын киләсе кышны башларга да житә, әле китерерләр дә.

Табында түгәрәк икмәк, табагы белән дучмак. Аллага шөкер, дими ни дисен. Менә малае белән кызына авыз иттерсә, күңелдәгечә булачак. Әнә, алтын баганасы ачыгып кайтты да, сыпырыпмы сыпыра! Бер карап торган малай инде, башка балаларының үз тормышы.

Ишек кашагасында — такта чәй укасы белән каймаланган Аятел Көрси. Диварда герле сәгать текелди. Тәрәзә араларындагы диванда кызы Мәгъсүрә чиккән чәчәкле-чуклы кул эшләре. Тәрәзә төбе тулы гөлләр. Моны бәхет дими, ни дисең! Ирсез килеш, бик авыр заманда үстерде бит ул балаларын. Сугышы да калмады, суыгы, ач-ялангачлыгы да. Кабат Ходай күрсәтмәсен, бала хәсрәте күрергә язмасын, дип дога кылды бәхетле ана.

«Кич белән абый гәжит чыгарырга чакырды», — дип Миннәхмәте дә кузгалды. Рәхмәтен әйтте, әппәрен итте. Кем малае дип торасыз сез аны, Фәйрүзә анысын гына өйрәтә, Аллага шөкер.

***

Зөлфәтнен бу уку елында иң истә калган вакыйгасы — балалар белән чыршы бәйрәме үткәрү һәм 31 декабрьдә мәктәптә хезмәттәшләре белән яңа елны каршылау булгандыр. Ана бераз кыен да әле, үзен укыткан мөгаллимнәр белән бер табында утыру бит... Дөрес, инде туган мәктәбен тәмамлагач өч ел шәһәр мәктәбендә укыды. «Райүзәк башкачарак — офыгы

биегрәк, — диде әнисе. — Ул мәктәптә колхоз рәисе, мәктәп директоры, нәчәлство балалары белем ала, укытучылары көчле, бәхетенне сынап кара, улым», — диде. Мамадыш шәһәренең данлы педучилищесын япкач, урта мәктәпкә әйләнгән уку йорты лабаса.

Билгеләре, характеристикасы шәп булгангамы, әллә спортчы икәнен белгәч, шигырьләр язуына игътибар итепме, ятим булгангамы — алдылар бит! Бик еш искә төшә шәһәрнең икенче санлы мәктәбендә укый башлаган көннәр.

Китте башка мәктәпләрдән килгән укучылар белән танышу, сынашу. Математикадан, бигрәк тә телдән исәпләүдән ана тин юк икән. Укытучы мисалны әйтеп бетерә алмый, ул җавабын бирә. Хәтта Иске Комазан мәктәбен гел «5»кә тәмамлаган Кәүсәрия дә авызын ачып кала. Шәп укыткан икән аны Шамил абыйсы. Моны шәһәргә килгәч кенә беләсең икән. Математикадан Наһар Галиевна укыта. «Алпавыт кызы, каныгызны эчә әле! — диде унынчылар, — яртыгыз укуын ташлый әле».

Тиздән аларның сыйныфы да моны үз җилкәсендә татыды. Гаҗәп таләпчән, математикларга хас булганча, яшен тизлегендә җавап бирү яки гамәл көткән апалары Комазан, Көек, Дүсмәт ягы кызларының «яшен»енә әйләнде. Әллә малайлар шома, әллә беләләр, әллә апа кызларны сөйми, әллә математика кызлар фәне түгел, сөрмә күзле, алсу йөзле кызлар белән укытучы кәнфитләнеп тормый:

— Нәрсәгә килдегез монда, юл тиресләп, бар кайтыгыз, фермагызда сыер савыгыз, бөтен кыяфәтен шуна килешеп тора да!

Үтә дә рәхимсез карар чыгарылганнан соң нечкә җанлы, математика дәресенең генә түгел, чәчәкле болынның бер гүзәле булган бу кызлар ашкынып аккан чакта улактан сикергән тамчы кебек укуын ташлый, тораклагы тумбочкасыннан әйберләрен елый-елый җыя да өенә кайтып китә. Кая микән сез, безнең белән берәр ай гына сабак алган фәрештәләр? Язмышыгыз ничек булды микән? Сез хәтердә бик рәнҗегән кебек яшисез.

Наһар апа авырдымы, әллә укырга киттеме, аларны бераз Минкин абый укытып алды. Аның исеме Динмөхәммәт булган икән. Менә бу кеше, ичмасам! Ул математикадан халык җырчысы Мингол Галиевка гел «5»ле генә тезгән. Мисал, мәсьәләләр белән борчымаган, дәресендә җырлаткан гына.

Зөлфәтнең исенә күптән түгел генә булган бер вакыйга төште. Географияне мәктәптә иң кирәкле фән дәрәҗәсенә күтәрергә тырышкан мәктәп директорына математик Шамил Нургалиевичның бик эче поша, түзә, дәшми. Чөнки ул белә: арифметика — математика патшасы, математика — фәннәр патшасы. Бетте-китте! Бүген сүз бик төчеләнгәч һәм озынга киткәч, түзмәде Нургалиев. Директор бит географиядән башка ашап та, яшәп тә, хәтта печ итеп тә булмый, дигән соңгы чиккә житте.

Тянь-Шань тауларында өшерлек, Камчатка гейзерларында пешәрлек, Ниагара шарлавыгыннан мәтәлеп төшәрлек, Үле дингезнең суын эчәрлек итте. Бар кыюлыгын, тәвәккәллеген җыйган яшь математик:

— Нәрсәгә ул география! — диде. Билет аласың, хет Владивостоктан, хет Ташкенттан, хет Лондоннан, хет обратномы? Станциян килеп житүгә стюардессамы, бортпроводницамы, кондуктормы, йоклап ятсаң, якаңнан алып, качсаң эзләп табып, тибә дә төшерә! — Дулкынланган математик, үзенең кыюлыгына шаккатып, дер-дер килгән кулларына папирос алып ишектән чыгып китте.

Әле ул тартып кергәндә дә директорның авызы ябылмаган килеш иде...

Минкин абыйсын үз итте Зөлфәт. Бу кешенең сөйкемле сөяге бар. Аның бар ачулануы: «Менә әкәмәт!» — булып, бу сүз «Афәрин! Афәрин!» — югарылыгында әйтелә, кешене мескенләтми иде. Ул ачуланудан бигрәк: «Бездә, укытучыларда гаеп, бигрәкләр дә укыта алмаганбыз шул, гафу итегез!» — сыман ишетелә.

Биология укытучысы Мөнир Закировичның зирәклеге, зыялылыгы да аны гомер буе сокландырды. Ул укытучысы белән хәзер дә кала урамында очраша, аерылышып китә алмыйлар. «Ярар инде, энем, син эш кешесе бит, мин генә ялда булгач та», — дип гел кабатлый Мөнир абыйсы, ләкин бер ярты сәгать гәпләшкәндәй итәләр. Соңгы очрашканда ул үзе язган саусабагай гына шигырь укыды.

Зөлфәт хәзер инде биология дәресләрен төгәл хәтерләми, ләкин Мөнир аганы искә алса, ул һәр дәрестә ике-өч тапкыр: «Үлән исе житми мина, балалар!» – дип әйткән кебек. Кешелеккә үлән исе житми!..

Тарих дәресләрен аеруча ярата иде малай. Нәселе ил тарихын язуда катнашкангадыр ул. Авыллары борынгы Ак Кирмән ханлыгының төньяккөнбатышындагы хәрби ныгытма булгангамы, белмәссең. Әллә түбәнге зиратта кеше гәүдәсе биеклегендәге серле язулы кабер ташлары янында озак басып торганмы?!

Әллә бакыр рудасы эзләгәндә кәйлә астыннан аваз салган Бакырчы чишмәсенең суын эчеп үскәнгәме? Нинди җәйге челләдә дә суын чүмеч белән тотырып эчәләр, бу чишмәнең суы суык тидерми, хәтта төчкертми дә. Ә үзе сап-салкын, чиләкне өшетерлек!

***

Аларның мәктәбе шәһәр үзәгендә, ә торак бер чакрым өстәрәк, ә ашханәләре тораклан ике чакрымда бардыр. Көнгә өч мәртәбә торакашханә-мәктәп, мәктәп-ашханә-торак, торак-ашханә-торак маршруты буенча юырталар. Километры шәп чыга.

Торак ике зур бүлмәдән тора, аларга ике ишектән керәсең, әле Зөлфәт яшәгән бүлмә янында җыештыручы Надя апаның гаиләсенә дә бүлмә бүленгән. Бинаның ике башында да такта болдыр бар. Торакта урысы, татары бергә яши. Керәшен малайлары да күп.

Малайларның ин яраткан урыны — «Мамадыш» совхозының утыз гектарлы алма бакчасы. Алма пешкән, өзелеп төшкән вакытта укырга киләләр! Мәктәп юлы да бакча кырыеннан уза. Андагы төрле зурлыктагы, төрле төстәге пешкән алмаларны күреп кем генә авыз суларын гол-голт йотмагандыр?!

Алтмышынчы еллар башында Көмеш Чишмәдә алма бакчалары берничә кешедә генә иде. Югары очта Хәсән абыйда, Шәйхи картта, Пулый Рәфәгатендә. Авыл уртасында Миннехан Гаянында, Бәдигылҗамал апада, Түбән очта Минегаяз, Хәсбәтулла абыйларда, Хәбибрахман бабайда. Шуның белән шул. Зур авылга бит ул. Авыз тотырып бәрәнге генә ашаган малайлар алар. Тагын мәктәп бакчасы бар. Аның каравылчысы Вафа абыйдан котыла алмыйсың, тотыла гына аласың.

Ә монда утыз гектарлы, меңләгән алмагачлы бакча! Аның коймасы гына да ничә чакрым. Алманы башта совхоз җыя. Бераздан шәһәр кешеләре капчык-капчык ташый. Шуннан инде алар да кушыла, бер-ике көннән иркенләп ашап йөри башлыйлар. Өч ел буе шулай, бер тапкыр да куганнарын хәтерләмиләр. Торакта алма атышалар, кеше идәндәге алмага баса да тәгәрәп егыла. Тәрбиячеләре Өмбел апа дежурга менгәнче дип, кизүләр чиләк-чиләк алманы чүп базына ташый.

Иң кызыгы: шимбә көнне биштәргә, сәпид багажнигындагы сумкага

тутырып авылга алма алып кайту. Аннан бәлеш пешертү, торакка алып килү...

Торакта шаян, олы кеше күзлегеннән караганда сәер тоелган уеннар бар иде.

Киеменне яшерәләр. Табып бирүче табыла, ләкин син ул малайны жилкәнә атландырып сәяхәткә китәсен, караваг араларында, хәтта торак ишегалдына чыгып утын лапасында йөрисен, яналан торакка кереп жәфаланасын. Ә ул бәндә борын төбендә бармагын уйнатып тегендә, монда күрсәтеп бара. Кунак ашы кара-каршы, билгеле. Икенче көнне ул сине күтәреп йөри.

Бик озын һәм нәзек Ринат исемле малай бар иде күрше бүлмәдә. Йоклавы була, аяк бармагы арасына мамык кыстырып ут төртәләр. Ринат янган мамыкны кулы белән алып ташлый да йоклавын дәвам итә. Иртәгесен пешеп кабарган аягына нәрсә булган, дип аптырый, хәтерләми дә.

Ин гыйбрәтле кылану Илдус исемле Урта Кирмән малае белән. Ул – лунатик. Илдусны иртәнге икедә уяталар, ашханәгә бәрәнге әрчергә төшәргә дип. Малай әйбәт сөйләшә, киенә, сумкасын кулына тоттыралар. Өч малай торактан чыгып китәләр. Илдус сөйләшеп төшә, авторотаны, биш йөз метр ераклыктагы фабриканы да узалар, аннан егетне кызганып, кире торакка алып кайталар. Чишендерәләр, йокларга яткыралар. Илдус икенче көнне бернәрсә дә хәтерләми...

Көчсез, юаш малайларны кыерсыту да бар иде, билгеле. Рәим белән ярышып ике потлы герне егерме тапкыр күтәрүме, бокс белән шөгыльләнүме, чанғы буенча мәктәп командасында булуы — болар һәммәсе дә Зөлфәткә бармак белән дә чиртмәүгә китергәндер. Бәлки сабыйчак дусты Нургаян Әгъләмов торак укучыларынын күпчелеген тәшкил итүче авылдашларына малай чактан бергә үскән Зөлфәт турында сөйләгәндер.

Аннан, торакта ин зур бәяләнгән кеше — юмарт кеше иде. Су-Елгадан килеп укучы Габделбәрдә чемоданнын ин зурысы, чемоданындагы йозагы да ин зур, асылмалы йозак, әле анын янәшәсендә кечерәге дә бар. Ләкин һәр дүшәмбедә ин беренче булып анын чемоданы бушый. Юк ла, сез нәрсә! Йозаклар, күгәннәр исән, эчтәге ризык кына кимегән. Ә Зөлфәт беркайчан да чемоданын бикләмәде. Классташы Рифкать килеп әйтә иде: «Малай, ачуланма инде, ике телем ипи кисеп алдык». «Кирәксә тагын ал, Рифкать», — ди иде Зөлфәт. Юк, алмый, кагылмый иде Рифкать иптәшләре кабат. Торак тулы чемодан бит әле анда. Аларнын барсы да планлаштырылган.

Шәһәр малайлары, кич белән урамда саклап торып, торак малайларыннан акча кыса. Бу Иске Комазан малайлары Хөрмәткә һәм Рифкатька бәйләнгәнче дәвам итте. Бер атна үткәч, малайлар торагы янына, трактор арбасына төялеп, баһадир гәүдәле ирләр килде. Мамадыш Сабан туе батырлары Ахун, Заһит, тагын әллә кемнәр шунда. Кичен шәһәргә төшеп киттеләр тәпиләп. Шул кичтән сон шәһәр малайлары торакта торучыларны ерактан әйләнеп уза башладылар. Юаш, бигрәкләр дә юаш шул ул иске комазанлылар...

***

...Кызлар бар бит әле дөньяда. Классташы Фәния Зөлфәткә карый да катып кала. Зөлфәт борылуга ялт итеп икенче якка карый. Шул гына житмәгән иде. Тугызынчыда укыганда ана өлкән сыйныфта укучы кыз гашыйк булды. Үзе чибәр, үзе жырчы. Сәхнәгә чыгып балан турындагы жырны башкарганда күзе гел Зөлфәттә генә. Янәшә утыручылар егеткә төртәләр дә төртәләр. Әле мәхәббәтнен гүзәллеген шигырьләрендә генә язучы үсмер үзеннән олы яшьтәге кызнын мәхәббәтенә ничек итеп жавап

бирсен соң?! Ләкин вакыт үткән саен ул бу кызның исемен, йөз-кыяфәтен, үзенчәлекле тавышын юксыначак. Ә хәзергә, иптәшләре төрткәләгән саен үртәлеп, кызарганнан-кызара бара, башы һаман да аска иелә.

Ә шулай да Зөлфәтнең дә йөрәге дертләде берчакны. Спортзалда күңел ачу кичәсе булды. Татар һәм рус классларында укучылар да бергә җыелды. Параллель сыйныфлар гына да алтышар — «а», «б», «в», «г», «д», «е» иде.

Шәһәргә терәлеп торучы Чура Тау авылында районда нефть эзләүче геологлар яши икән. Менә шул авылның рус сыйныфында укучы кызына күзе төште егетебезнең. Кызның әтисе татар, әнисе рус икән. Мәхәббәтнең нәрсә икәнен шактый сиздерде Ходай. Бик оялчан да итә, бик кыюлата да икән ул әкәмәт. Чәчәк-чук булып балкып торган, спортзал түренә җыелган рус кызлары янына барып биергә чакырды теге алма битне. Кызның буй-сыны бик килешле, көлгәндә чокыраеп китә торган бит алмаларына сандугач оялардлык иде. Икенче тапкыр чакырырга килгәндә бер рус малае ыржая башлаган иде дә, Зөлфәт: «Еще хочешь валяться в грязи, как тогда?!», — дигәч, агарды, күгәрде теге, ләкин чалырга сузган аягын тартып алды.

Иске Комазан көрәшчеләре, Хөрмәт белән Рифкатьтән акча сораган өчен, суга манчый-манчый кыйнаган теләнчеләрнең берсе иде ул.

Эшнең кая таба барганын күрсә дә, Зөлфәт үтенгәч, кыз биергә чыкмыйча кала алмады. Алар кебек пар килгән егет белән кыз спортзалда булмагандыр да!

Класс житәкчесе Асия апасы барысын да күзәтеп торган икән. Килде дә: «Зөлфәт, безнең кызлар бик үпкәли, әйдә, Фәния белән бие әле», — дип, иркәләп-сыйпап зал уртасына икесен чыгарып та җибәрде. Шуннан соң егет үзе белән нәрсә булганын да хәтерләми. Зал уртасында берничә генә пар биегәнлектән, халык барысын да күреп торган: Зөлфәт Фәнияне зал уртасында ташлап калдырган да, Фаягөлне биергә алырга киткән. Фәния елап чыгып йөгергән. Боларны үзенә әйткәч, Зөлфәт: «Китегез әле, булмаганны», — ди. Асия апасы янына килгәнне генә белә. Их ул Фаягөлне!

Чура Тау авылына Фаягөлләргә төшә иде Зөлфәт. Капка төпләрендә көнбагыш чиртеп утырган урыс малайларын аралап кереп китә. Әтисе Рәхим абыйдан сорап кызны урамда йөрергә алып чыга. Әнисе Наташа: «Нишләп миннән дә рөхсәт сорамый соң ул бу әдәпле егет», — дигәч, «шәригать буенча эшли», — дигән кызның әтисе.

Их, ул Фаягөл! Аның кулына тотынуга ук ток суга. Аның чәченнән килгән хуш ис тә торакка кайтып ауганчы бетми.

Ләкин Фаягөлләр геологлар белән күчтеләр дә киттеләр, уку елы беткәнне дә көтмәделәр. Их, ул Фаягөлне...

Бу аерылудан дөньялыкка кайту озак дәвам итте. Кыз яшәгән өй тирәләреннән дә урап менде егет, тик Фаягөл генә очрамады. Ә, югыйсә, Зөлфәт аның үзен яратуын назланып куенына сыенуыннан ук сизгән иде. Аны күрүгә кызның йөзеннән елмаю китми, өйдән ашкынып йөгереп чыга. Зифа, сыгылмалы гәүдәсен өрфиядәй очыртып кына Зөлфәткә ашкына һәм алар житәкләшеп йөгереп китәләр иде.

***

Унынчы класста укуын тәмамлап каникулга кайтты Зөлфәт. Әле шәһәрдә тагын бер ел укыйсы бар. Иртән уникe чакрымны йөгереп кайтып килә иде, әле сәгать иртәнге жиде генә. Трайт чишмәсендә юка, жилфердәвек күлмәк кигән кыз су алып маташа, эшен бик булдыра алмый. Кәефе искиткеч күтәренке булган Зөлфәт йөгереп тә килде, чиләкне кыз кулыннан тартып та алды. Кыз курыкты, каушады. Зөлфәт су алып биргәннән соң йөзенә

алсулык йөгерде тагын. «Рәхмәт!» — диде. Аның сүзе дә «ряхмат» булып ишетелде. Шәһәр кызы, ахры. «Исән бул», — дип йөгереп китмәкче дә булган иде, теге зәңгәр күз:

— Кая барасың, мин тагын килям бит әле, — дип шаркылдап көлеп җибәрде. Кыз Фаягөлгә шулкадәр охшаган иде.

— Син караңгы төшкәч менә бу имән төбенә кил, сөйләшербез, — диде дә Зөлфәт, йөгереп китеп барды.

Көне буе нинди генә авыр эш майтармады Зөлфәт, ләкин ару тоймады. «Нәрсә булды әле минем белән?!» — дип, үзе дә аптырады.

Нинди кыз микән ул, әллә инде күземә генә күренделеме? Фаягөлне югалту ачысын киметү өчен Ходай чүлдәге шикелле мираж гына күрсәттеме? Алай дисәң, Трайт чишмәсендәге басмада янәшә басып тордылар бит. Ул кызыкайның сәгать тагылган нәни кулының матурлыгын кара син!

Әнисе майда кетердәтеп пешергән ап-ак кабартма инде менә! Бизәнмәгән-нитмәгән, ләкин инде һәр нәрсәсе үз урынында—нечкә билле, омтылышлы күкрәкле, алсу йөзле, зәп-зәңгәр күзле гаҗәп чибәр кызыкай икән лә Трайт чишмәсе фәрештәсе, әле кыю да:

— Кая барасың, мин тагын килям бит әле! — дип чәчрәп тора.

Килер микән ул кичен Трайт чишмәсе янында үскән имән төбенә?!

***

Кичен Чегән бөгәсендә юынды, тәненә шап-шоп бәрә-бәрә, муеннарын сузып, түшләренә су йөгерткән ата каз шикелле, озак мыштырдады Зөлфәт. Белә инде: тән зыңгылдап торырга тиеш, әле генә ун чакрымны йөгереп кайтты. Күнел күтәренкелеге өйләре каршындагы куш каен биеклеген күптән узган, хәтта Казыган тау түбәсе дә шактый тәбәнәк күренә, игенче күнеленә сайраган саен бер чүмеч бал агызучы тургай биеклегендә. Сез ышанмыйсыз мәллә?! Аны бит, әгәр дә бәхетен Куян Хөсәеннәре үгезе сөзмәсә, Хәбыйк Хөсәеннәренең мамык тәкәсе бәреп екмаса, яки Чүлмәк Гамиләсе чәлмәсә, Точка Хуҗасы үзенең гаҗәеп матур җырлавы белән ияртеп алып китмәсә, тальянчы Зөфәр абыйсы борынгы Кирмән көенең борылмаларына чорнап гармун күрегенә ябып куймаса, Трайт чишмәсе янында, анда гынамы соң, бөтен Кирмән буенын иң күркәм агачы булган серле имән ышыгында зәңгәр күзле, елмайганда алма битендә күбәләк канат җилпи торган, бар булганы йөрәк шикелле талпынып, бер кысылып, бер очынып торган җан иясе, исемен дә белмәгән кызыкай көтеп торачак! Ләкин килер микән?

Тик... кызыкай киләсе чишмә янына барырга бераз гына иртәрәк икән. Әле имән дә ерактан күренеп тора. Авылда сөю-яратышуны, урысча әйткәндә — «на показ», шәрә килеш күрсәтүне өнәмиләр. Хәзер генә ул... Кендегеннән бер чирек астагы җирен дә күрсәтергә азапланалар. Әйтерсең, белмиләр инде анда нәрсә барын. Серлелек тота бит дөньяны, ачылмаган фәнни серләр һәм ул кысаларга мәңге сыймаячак мәхәббәт һәм алиһә хатын-кызларыбызның бөек сере тота! Галимнәр мәхәббәткә тарихи, физик, биологик, химик, математик, астрономик, медицина һәм башкача миллион яктан килеп карыйлар, серен ача алмыйлар. Аны һәркем үзе генә ача һәм аның нәрсә икәнен аңламаган килеш үлеп тә китә. Рәхәтен, михнәтен тоя, ә эчке хасиятен аңлата алмый. Менә үбештек, ди, менә бала туды, ди. Менә икенче берәүгә күз төште, ди, аерылыштык, ди. Һаман мәхәббәт әзли үзе, вакыт уфаллага салып картлыкка илтеп мәтәлткәч, караңгы урманда төнлә йөргән шикелле, хисләре арасында буталып йөри. Ерактан әзли. Үзен чәчәк-чук итеп яшәтәчәк, табын түрендә утыртачак, ничә кирәк шулкадәр тупырдаган бала апкайтачак авыл кызын куллан ычкындыра.

Ниһаять, каршыга килгән кешене биш-алты адымнан гына абайларлык карангы төште. Китте Зөлфәт кырыйлары яшел чирәм белән чигелгән дымлы сукмактан.

Авыл кичләренең моңы үзе бер кабатланмас симфония, бер композиторның, шагыйрьнең дә әле аны тасвирлап бирә алганы юк. Анда-санда су буе моңының берәр «Ах!»ын эләктергән җырлар җемелдәп китә. Анысы да ярый. Зөлфәт Трайт чишмәсенә куйган ак бетон бөҗраны абайлады, су челтерәгәнен ишетте һәм тау итәгендәге имән көүсәсенә сөялде.

***

Әтисе үлгәндә аңа дүрт яшь иде. Эшләп үсте. Әнисенә бик авырга туры килде. Ирен югалту хәсрәтеннән урынга егылды, көн-төн дару эчте. Йөрәк авазы кычкыртып идәнгә авып китә торган булды. Болай яшәп булмасын үзе дә аңлый. Ике улы бар. Берсенә яшь ярым, икенчесенә дүрт яшь. Авыл Советында секретарь булып эшләп маташа. Ярый әле гел авылдашлары арасында.

Әнисенең энесе Сөнгатулла терәмәсә, ауган булыр иде аларның тормыш агачы. Сыерга печән дә әзерли алмадылар. Әбисе Шәмсурый белән Сөнгатулла абыйсы сыерны үзләренә алып төштеләр. Җәй буе ике сыерлык печән хәстәрләделәр. Үсмер Сөнгатулланың беләкләре өзелеп чыгарлык булгандыр. Аның урман хуҗалыгында атлы эштә йөргән чагы. Җиккән аты «Орлик» иде. Чөнки ул елларда авыл клубына күчмә кино килде һәм шунда немец поездын куып җитә торган «Орлик» исемле атны күрсәттеләр. Колхозның ярты атына «Орлик» исеме ябыша язды. Ә колыннар, тайлар барысы да «Буян» исеме белән туды.

Өйләрендә ат булмагач, күрше малае Рәфәгать әтәчләренә дә «Орлик» исеме кушты, чөнки тавык куганда кызыл кикрик тә әйбәт чаба иде. Әтисен күмгәндә Сөнгатулла абыйсы Зөлфәтнең кулын балчык өеменә батырып туфрак йомарлатты да ак такталар өстенә сиптерде. Шулай итеп, дүрт яшьлек улы әтисен күмде. Аңламыйдыр әле ул, бигрәк бәләкәй, дип сөйләнгәләделәр берничә ир-ат. Күбесе эндәшмәде, чөнки дүрт яшьлек малайның маңгаенда беренче җыерчык ятканын күрделәр ахрысы алар...

«Житез малай булдың син, җиде айдан тәпи йөреп киттең!» — ди иде аңа әтисе Мамадыштан алып кайткан прәннекләрне биргәндә. Аннан гел әтисенең муенында үсте ул, аның җырлаганын тыңлап.

Әтисе аны сәкегә салып әвәли, эченә авызын куеп өрә дә, әллә нинди шартлаган тавышлар чыгара. Сакал-мыегы малайның битенә кадала, ә шулай да рәхәт. Түшәмгә чөя, ишегалдына чыккач күккә чөя.

Аңламый ул, бәләкәй дигән булалар...

Сугыштан алып кайткан медальләрен, алтын сәгатьләрен чүкеч белән төйгәч тә әтисе аңа бер сүз әйтмәде. Йөзе агарды, анысы. Әй, әнисе орышты, йомшак җиренә түбәтәе белән бәргәләп тә алды.

Әтисенең танкта янганын белә Зөлфәт, пешкән урыннарын да күрсәткәне бар. Танк рәсеме ясый-ясый күпме кәгазь бетерде. Кызыл йолдызлысы малайныкы, кара тәрелесе әтисенеке була да, әй сөзештерәләр, әй сөзештерәләр! Кызыл йолдызлысы җингәнчегә кадәр инде.

Әтисе үлгәнннән соң байтак газаплар кичерергә туры килде шул. Тугыз яшендә өй салган малай ул, әнисе үзенчә төзеде, акчасын, ризыгын кайгыртты, төзү материаллары тапты. Сөнгатулла абыйсы белән урманга йөрде малай. Атны бүрәнә ташый торган арбага җигәләр дә иртә таңнан кузгалалар. Усакны кисеп аударалар. Әй мактый инде аны Сөнгатулла абыйсы. Тартыпмы-тарткан була Зөлфәт ике саплы пычкыны. Авыш

күсәкләр куеп арбага тәгәрәтеп менгезергә дә булыша. Чи усакларның да төрлесе бар, кайберсе шулкадәр авыр икән. Кызыл эчле усак бу, энекәш, ныклыкка нык, ләкин әбеченә тия инде, ди абыйсы. Әбечнең нәрсә икәнен Зөлфәт белми. Бәйлиләр берничә бүрәнәне. Агач очларын чистартып, ботакларын дүрт казык кагылган урынга өяләр, утынга ярарлыкларын өйгә ташырга әзерләп куялар да кайтырга кузгалалар. Урманда абыйсы дилбегәне үзе тота, Зөлфәт арба артыннан теркелди. Их, усак агачыннан чыккан иснең тәмлелекләре! Әллә алар өен сипләргә алып кайтканга хуш ис тарата микән соң бу бүрәнәләр?!

Бер минут буш вакыты булмаган әнисенең яшәү рәвеше, теше-тырнагы белән ир-атлы гаиләләрдән ким-хур яшәмәскә тырышуы, күршедәге алтын куллы, олы йөрәкле тимерче Габделбарый абыйларының бар эшкә дә ияртеп, өйрәтеп йөрүе шәп булды. Өйләрендә мантырга тырышучы апалар яшәве, ир-ат эшенә бик иртә җигелү дә Зөлфәтне зиһенле итте. Авылдагы тавык чүпләп бетермәслек эшләрнең барысын да башкарырга, балта, чалгы кайрарга, койма тотарга, таш чыгарырга һәм тагын, егет булып үскәч тә, көянтә белән су ташырга өйрәтте. Эшкә батыр булу михнәттән дә коткара, башына төшкәч башмакчы буласың.

Ин кимсеткәне, ат сараендагы тиресне сәнәк белән иләп, салам ташу иде.Син мәктәптә яхшы укучы, менә дигән спортчы, әле шигырь дә язасың, инде кызлар озаткалыйсың. Авылның карап торган ипле егетләреннән, ә үзең идарә урамыннан мескен чана белән ат шаралары арасыннан иләгән салам апкайтасың. Баш иелгән, өскә иске кием киелгән. Нечкә күңелле малайны бу үтерә иде. Әле син күз атып йөргән кыз очрый, теләмәсә дә, аның йөзенә кызгану галәмәте чыга. Менә бу—горур хәерчене ату белән бер икән. Башкаларның әтиләре ат җигә. Акмаса да тама хуҗалыкларына печәндер, саламдыр, утындыр. Ул малайлар рәхәттә, кайсы гомер буе эш рәте дә белми, теле булмаса карга күптән күтәреп алып киткән булыр иде.

Теге Зәңгәр Күз Зөлфәтнең ачык түшен кайнар сулышы белән өтәгәндә яшен тизлегендә хәтердән үтте бу күзаллаулар. Рәхәтлектән оеп торган егетнең әллә ниләр исенә төште, борчыды. Нишләп хәтергә киләләрдер? Шушы кызны кочаклап торудан да зур бәхет юк бит инде, югыйсә.

Бер елны Галия апасының улы Рәүф абый Кытайдан ефәк яулыклар апкайтты. Балдак аша да чыгарып карадылар. Чыга, малай! Юа торгач унсалар да озак еллар сакланды яулыклар. Ә Галия апаның кече улы Кәнәфи абыйлары, аларга менә дә, бәйрәм ясый. Тальянда үзе уйный, үзе җырлый.

Өйләрендә гел кеше булыр иде. Домино уйныйлар, шал бәйлиләр, дөнья хәлләре, укыган китаплары турында гәпләшәләр. Бу кичләр малайларга тирән белем бируче мәктәп булган икән. Менә Габделбарый абыйсы немецчаны шәп сукалый, сугышта үзлегеннән өйрәнгән, шуңа Мамадыш урта мәктәбендә немец теле дәресендә Зөлфәткә тиңнәр юк. Шартлатып җавап бирә. Гомер буе урманга, елгаларга печәнгә йөргәндә, тимерче алачыгында эшләгәндә немецча сөйләшкән Барый абыйсы мәктәбен үткән шәкерт ич ул!

***

...Зәңгәр Күз Зөлфәтне дөньялыкка кайтарды. Онытмады ул аны, бәхетеннән оеп хатирәләр урманында гына адашкан.

– Йә, чибәр апасының исемен кем дип белик инде?

– Кайсы апаның? – диде кыз.

Юк, авыл кызы күңеленә юл табучы ышанычлы алым шәһәр кызына ярамый икән.

— Сезнен исемегез ничек? — дип сорады Зөлфәт.

— Апаныкымы, минекеме? — диде кыз. Ах, менә монысы ярады! Икесе дә пырхылдап көлеп җибәрделәр.

— Мина әбиегезнен исемен генә сорарга калды инде, — диде Зөлфәт.

— Мин бабайларга кайттым, кунакка, — диде кыз. — Исемем Зөлфия, ә синен?

Менә бит ул тырбайчыклансан. Сез дип сөйләшкән була бит әле, янәсе, шәһәр кызы алдында авылларын аяк астына салып таптамый, ана ботинкасын сөртми. Югыйсә кая инде Сез, икесе бер-берсенен кочагында ничә ел торалардыр, үзе инде бөтен тормышын хәтерләп бетерде. Син дип сөйләш тиле бәрән орлыгы ашаган нәрсә, ангыра сарык, сугылган борчак саламы! — дип үзен сүкте Зөлфәт.

Кызартты бу кыз аны, акыллы булырга охшый.

— Апан күптән әйткәндер инде, барысын да сөйләгәндер, беренче очраган егетнен сүзенә ышанып төнлә имән янына чыкмас иден, — диде егет.

Кыз көлеп җибәрде. Чегән чишмәсенен тимер торбасыннан аккан суда чуерташ челтерәгән тавыш таралды.

— Ападан сорарга оялдым, Вәккас абыйдан сорадым. Ул сөйләде, ай, ярата ул сине, ай, сөйли Вәккас абый!

— Бик ышанып бетмә, безнен туган ул, шуна мактагандыр.

— Юк, Вәккас абый әкәмят шәп егет, — диде. — Нәрсә ул «әкәмят»?

— Очрашуга иртәгә дә килсән, әйтермен.

— Үлям, иртәгә дә киләсемени, — диде кыз, — күрше кызы белән клубка менәм дип чыгып киттем.

— Син Зөлфәт янына чыгам, дип әйт апана. Борчылмасын.

— Ай, үтерәләр бит мине, апа әнигә әйтсә.

— Үтерсәләр, эт оясына чылбыр белән бәйләп куймас әле.

Кыз тагын көлеп җибәрде.

Алар инеш буенын дымлы сукмагыннан янәшә атладылар. Кичке тынлыкны ярып кычкырган бака тавышынын матурлыгына исе китте Зөлфәтнен. Ничек элек ишетелмәгән бу? Ишетелгәндер, тик ул кичләрдә Зөлфия булмагандыр.

— Менә без йөргән җирләрдә йорт урыннары, бәрәнге, җиләк-җимеш бакчалары иде. Синен әниләрен кебек читкә китте бит авылдашлар. Хәзер бер кайтырга тилмереп ятучылары күп.

— Әни дә гел елый кайчакта. Әби-бабай да еш чирли. Булышырсын да, сине алырга дигән сылтау белән кайтырмын дип, Хәсән абыйга ияртеп җибәрде. Авыр әнигә дә. Мин Уралда туган, кайткач, авылнын матурлыгын күрдем. Ай, матур авылыгыз!

— Мин очрагач кына матур ул! — дип, теленә салынды Зөлфәт.

...Капкадан кертеп җибәрде дә Зөлфияне, өенә атылды Зөлфәт, оча инде, аяк тигән җиргә тия, тимәгән җиргә юк.

Иртәгә чыкмыйм димәде әле кайнар кул, лепелдәп торган йөрәк, янгыравыклы кынгырау. Инешне, Бакырчы чишмәсе шәрләмен дә бер генә сикерде егетен.

Иртәгә көн матур булыр төсле. Күк йөзе ачыла, болытлар тарала. Томанлы үзәндә йоклап яткан җилләр уянган да Казыган тау, Саурыш елгаларындагы җилләрне өмәгә дәшеп, авыл күгендәге болытларны куа...

***

Бер-ике атна гына очрашканнар иде, Зөлфәтне Кама елгасы аръягындагы болынга җибәрделәр. Күмәк хуҗалыкнын печән җыю бригадасы белән инде. Ат җигәсе, печән җыйгыч тырма белән эшлисе. Атчылар чапкыч белән эшли,

алар керә алмаган куак араларын кул белән чабасы, диме. Берәр йөк печән бирәселәр икән, ул да зыян итмәс. Аннан Яке елгасында моннан сигез ел элек уфаллаларын ватып аткан кансыз персидәтел дә әнисенә бәйләнгән. Малаенны төшерәсен булгач, төшерәсен, дип. Ярар, без күрәсен кеше күрмәс. Берүк паром белән чыкканда суга бата күрмәгез. Косилкага, чалгымазарга киселә күрмә, тагын әллә нәрсәләр—әллә нәрсәләр, дип сеңдерде, күршедәге Кәримә карчыкка кереп хәерләр бирдерде әнисе. Анысы Ходай ризалыгы өчен. Бик тә теләп бирде Зөлфәт, бу көнгә каләр Ходайның аларны ташлаганы юк бит әле. Өйләрен янарттылар, әнисе әзме-күпме хезмәт хакы ала. Мәрхүм этиләре өчен пенсия килә. Ә колхозчыларга хезмәт көненә әле генә акча түли башладылар. Әй, сөенде дә сон авыл халкы!

Менә авылга кино килә. Урамда моторы эшләп тора, аппараты клуб эчендә. Кино куючыга булышып барабанга кино тасмасын ураган берничә малай бушка кино карый, анысы.

Шулай бер елны, әкәмәт зур буралар бурап, яна клуб салдылар, түбә астына да керттеләр, ләкин җәй буе нигезе комташ тезгән килеш торды. Кино килә авылга, балаларга керү бәясе биш тиен булса да, каян аласын ди аны?!. Ул бит янгыр түгел. Ләкин Көмеш Чишмә малайлары гомергә башлы инде алар. Бер төркеме, тавык ояга менгәнне саклап торып булса да, йомырка эләктерә дә Хәбри картка чаба. Кинога керерлек акча бирә картлач.

Икенче төркем, кесәсенә ипи кыстырып килә дә, клуб эчендә эшләүче балта осталарына булышкан булып йөри. Көндез сәхнә астына кача һәм... берничә сәгать тын да алмыйча кино башланганны көтә. Сәхнә астына сыймаган Мидхәт белән Илфатны залдагы йомычка өеменә күмәләр. Киномеханик тешен казырга дип шырпы эзләп баргач Мидхәтнен эченә баскан, малай йөрәк өзгеч тавыш белән кычкыргач чирләгән киномеханик Равил абыйлары.

Ә Дарият, Рифат кебек малайлар өйләреннән очлы көрәк алып чыга, клубнын нигезендәге бер олы ташны казып алалар да тишектән клубка кереп китәләр. Җәй буе сайгак җәелмәде клубка, бөтен авыл идән җәю өчен тезгән өрлеккә утырып кино карады. Җайлы тагын үзе.

Сәер бу кино, авыл малайлары өчен ят нәрсә. Бер көнне, экраннан поезд килә башлагач, беренче тапкыр кино карауч Вәчкә Илдусы: «Каравыл!» кычкырып чыгып та качты. Ул поезднын дәһшәте сон!

Ул кино белән төрле сәер хәлләр була иде. Моторы тышта. Зөлфәтнен дусты Дөлкәфил нәрсә эшли диген син?! Иң элек Кәримә әбисе сукранасукрана биргән биш тиен акчага клубка кереп билет ала, кире урамга чыгып дерелдәп эшләп утырган моторны карап тора.

— Йә, ничек? — дип сорый Агмал абый, кино карап егет булып, кеше рәтенә кереп кайткан малаеннан.

— Шәп, әти, дерелдәп эшләп утыра, берүзем карап тордым, берәү дә комачауламады.

Ел буе шуны сөйләп мәзәк ясап йөрде Агмал абый. Тамаша карау хакына киномеханикның полицаена әйләнүче дә табылды. Ул безнен яшьтәге малай-шалайның канын эчә торган Әхмәтгаян абый иде. Малайларнын фуражкаларын җыеп ала да, аппаратны әйләндереп, тасма чорната. Сәхнә артына качканнарны таба, өстерәп алып чыга, клуб ишегеннән артларына тибеп кала.

Теге Дөлкәфил хозурланып төшкән мотор бар бит әле. Әйе, ул да күрде инде, бичара. Кинога кертелмәгән кешеләр анын ягулык багына ком да, шикәр дә салдылар, свеча чыбыгын да ычкындырдылар.

Сәнгать корбаннар сорый иде.

Күрше малайларга Зөлфәт белән Илсур гел акча биреп тордылар, аны кире сорамадылар да. Әниләре: иптәшләрегезне дә алып керегез, савабы булыр, дип акча бирә.

— Ходай биргәнгә мәрхәмәтен сала, балалар, — дип җилкәдән сөеп кинога озатып кала.

Аларның урамга чыкканын дуслары көтеп тора. Менеп җиткәнче чабалар клубка, аларда шундый тәртип.

***

Бер ай буе Кама буендагы алпавытлар казыткан түп-түгәрәк күлләрдә иртә һәм кичен балык тотты һәм коенды, болыннан җиләк ашап рәхәтләнде Зөлфәт. Гел уйнап йөргән икән, дип уйламагыз тагын — монысы эштән бушаган араларда.

Болын бит ул һәрвакытта да матур. Су чигенүгә ләмне мең җирдән чатнатып үсентеләр килеп чыга. Дым да җитәрлек, җылы да. Күзгә күренеп үсәләр. Бүген карыйсың бер төрле, иртәгә инде ул урынны танымыйсың да. Яшел дулкын гүзәллекне уч төбенә салып изге күккә якынайта бара. Аннан чәчәк ату китә, бал кортлары, әллә нинди шөпшәләр, быжаннар, чабата кадәр чикерткәләр кисәк өстенә сикерсә, үзеңне юк дип сана.

Ә инде калкулыкларда җиләк пешкәч, әрәмәдә кара җиләк өлгергәч, Кама буеның серле ешлыкларында кошлар сайраганда, яки менә Куян Хөсәене куйган печән Таҗ-Мәхәлләре болында калыккач! Кибәннең нигезенә генә мулдан өйдерә печәнне Куян Хөсәене. Аннан «эхе, эхе!» килә башлый. Аның болай көлүен иптәш Вафин яратмаганны ни өчен авылдашлары яратырга тиеш ди әле?! Иптәш Вафин бәхетле ул, чөнки бу көлүне ничә елга бер ишетә. Печән урлаганда Куян Хөсәененең «эхе-эхесен» ишетер иде. Аполлон һәм Майкоп исемле колхоз кассасын шәрләм хәленә калдырган нәсел атлары алсалар да, Куян Хөсәененең кинодагы Орлик, Буян кушаматлы атлардан да елгыррак Дөл-Дөлен куып җитә алмагач каян ишетсен ул аны?!

Күтәрелә кибән, бер чокырлы җире юк, әйләнәсенең бер бүселгән урыны юк. Өстерәткечләр белән күпме печән китерелгән — шуны сыйдырып та бетерә. Дилбегә атып каршы яктан биш-алты ир-ат тота да, Хөсәен абыйны кибән очыннан төшерәләр, аяк эзләренә кадәр сыпырып, кулы белән тигезләп, пөхтәләп төшә ул.

Коя да куя инде! Мәскәү Кремлендә авышлык, төгәлсезлек булырга мөмкин, ә монда юк!

Галәү абыйның атчылары көн дә исерек. Бригадага ашамлык алабыз, дип, печән саталар. Ашамлык дигәннәре аракыдыр инде. Быел печән өч тапкыр күбрәк чыккан. Элек кул белән чабылмаган куак асларын да, бәләкәй аланнарны да чалгы белән чаптырды Точка Хуҗасы. Ул — кул белән чабучыларның җитәкчесе. Галәү абыйга бунт ясый Точка Хуҗасы, ничә ат йөге печән төяп җибәргәнне барлый. Аз-маз эчеп кайтканга сүз әйтмәсә дә, урыслардан апкайткан аракы шешәләрен, балыкны кабул итә дә, уртак табынга куйдыра. Бер йөк печәннең бәясен Старый городка барып белгән һәм бөтен акчаны учына салдыра. Салмый кара Точка Хуҗасының мичтән ипи ала торган көрәк кадәр кулына! Күз ачып йомганчы теләсә кемне чәкүшкә итеп арба күчәренә тыга да куя. Аның беләкләренә карап торсаң да баш әйләнә башлый. Кылый күз белән чекерәйсә, елгага чумып та котыла алмыйсың. Кама төбендә дә онытып булмый ул күзләрне.

Зөлфәтне бухгалтер иттеләр. Иң белемле кеше, ун классны бетергән кеше ул икән. Киреләнеп тә караган иде. Точка Хуҗасы үз малае шикелле күреп әйтте:

— Кәкә, Зөлфәт, бу дуңгызлар бөтен хезмәтебезне эчеп бетерә бит.

Үз өлешләрен күптән эчеп бетерделәр. Менә синекен, Саимә апаң белән Миннур апанныкын эчәләр, минекен эчәләр, тагын унбиш кешенекен! Бу гаделмени сон?! Колхозчыга акча тиенләп кенә бирелгәнен беләсен, болында эшләгән акчаны ашаганга тоткач өскә дә чыга әле безнен. Нишләп йөрим мин монда, центнердан артык гәүдәмне селкетеп?! — дип, ачынып әйтте. Бу инде хатын-кызнын үкереп елавына тин кызгандыру иде.

—Нәселегездә караклар юк, булмас та, барыбыз да сина ышанабыз, ничек эшләвенә карап түгел, тигез итеп бүл, бер сөенсен әле колхозчылар, — диде. Хужа абый акчаны атчыларнын бугазларыннан буып алып кайта. Берсе ажгыра башлаган иде. «Балык ризыгы буласын килә мәллә, монда биек ярдан ялгыш мәтәлүенне көт тә тор. И, точка!» — диде Точка Хужасы. Зөлфәтнен эше бик жаваплы, кәгазьгә һәр көнне кергән акчаны яза, кеше санына бүлә, кул куйдырып бирә. Кулын кысып, жилкәсеннән сөеп чыгып китә кытыршы куллы абыйлар, апалар.

Галәү абыйнын күзе бар икәне беленә башлады. Эшнен төгәлләнүе дә, кесә төбендә тиенле акчалар чылтыравы да, Әгъзәм абыйнын рәхмәт әйтүе дә булгандыр, авылдан төшерелгән сарыкны суеп, итен пешереп Сабан туе ясадылар. Шәп инде ә, бер жәйдә ике Сабан туе! Ул сыздырып жибәрә Шәһәр Рәфәгате тальянында, ул жырлап жибәрә Мамадыш төбәгендә тине булмаган Точка Хужасы! Хәтта елганын аръягындагы Вандовка маржалары да яулыкларын таякка элеп аларны сәламли. Белә инде алар Сабан туе ясаганны. Шалаш түбәләрендә сөлгеләр, чүпрәк-чапрак жилферди. Кама жырларны, эчкерсез авыр хезмәт аша яуланган сөенечне дулкыннарына төрә дә элек башыннан ахырына кадәр татар жире булган Идел тугайларына, аннан Хәзәр дингезенә, тагын әллә кайларга алып китә.

Әнисе көтә, энесе көтә, Юлдаш исемле эте көтә аны авылда. Ә теге Зәнгәр Күз нишли микән? Бер генә егеткә озаттырган булса да ташлаячак ул аны! Соңгы кичтә:

— Син нәрсә, Зөлфәт?! — диде дә күкрәккә башын салды. Чәченнән килгән хуш исне болындагы мен чәчәк хушбуе да оныттыра алмады.

— Мин бит аңлыйм. Син кайтканчы клубка да чыкмыйм. Кайтуынны ишеткән көнне менә шушы имән төбендә көтям, — диде дә ухыллап куйды. Бик тә ямансулап, муенга асылынып, тәнгә сыланып кереп китте. Зөлфәт, жебегән тәре, бер үбә дә алмады инде кызыкайны. Ай буе шуна үкенеп яшәде, нәрсә, янагына сугар иде мени, анын да жаны бар бит. Әнә, Точка Хужасы: «Маржанын да бар жаны», — дип жырлый. Шалашлар сүтелгән, кибәннәр болын каравылчысы урыска кул куйдырып тапшырылган. Паромга чапкычлар, тырмалар, арбалар, атлар, казандыр-чалгыдыр төялгән, ирләр кәефле. Һәркем да шатлыктан балкып тора.

Болыннан ераклашкан саен печән кибәннәренен матурлыгы, сөйкемлелеге арта гына бара.

Хужа абый «Мәрфуга»ны сузып жибәрә. Зират янында жырлаудан туктый да белгән догаларын укый.

Бераз киткәч карлыккан тавышы белән «Мәрфуганы» дәвам итә. Ул инде Урта Кирмән урамында да туктамый, кибет янында атларны бәйләп куйгач та жырлый, Урта Кирмәннән танышлары килеп чыга да, кочаклашып жылый башлыйлар, бергә әсирлектә булганнар икән.

Үзе жырлый, үзе кесәсеннән алып акча тартә дә, кибеткә ымлый Точка Хужасы. Бүген анын көне, бүген ул — Патша! Жырчы Патша. Патша кеше кибеттән кильки алып чыгамыни? Кибеттән баеп, балкып килеп чыккан Рәфәгать абый жырлый хәзер. Хужа абый вакытлыча ял ала, кибет бакчасындагы агач төбенә кереп чүгәли дә, әсирлек мәхшәрен кичкән дуслары белән бераз гәпләшеп ала. Ул озак тормый.

— Киттем, точка! — ди, сау булыгыз, дими. Шуннан жырлап та жибәрә, бөтен Урта Кирмән белә инде көмеш чишмәлеләр болыннан кайтканын. Норма кибетенә кадәр жырлый Хужа абый, Миннулла абыйның аяклары ял итә.

Норма кибетен дә ачтыралар. Күнелләр күтәренке, араларында бер исерек тә юк, олаулар тәртиптә. Бераз теш арасына нәрсәдер кыстырып, тел астына нәрсәдер агызып алган Миннулла абый Нормадан өенә кадәр биеп кайта, ә Хужа абый өенә кадәр жырлый, соңыннан Шәһәр Рәфәгате дәвам итә: үзе уйный, үзе жырлый, әнисе Шәһәрбану апа ачкан капкадан атын кертеп тугаргач та бер-ике жырны авыл кочагына очырта. Шуннан соң, болын симфониясе таңга кадәр ял итә.

***

Абыйсы кайтуга нишләргә белмәгән энесенең жилкәсенә шапылдатып суга-суга, Зөлфәт ишегалдына узды. Анын сугуы әнисенең күәстәге ипи камырын онга манчыган куллары белән әле берсенә, әле икенчесенә күчергән сыман гына инде.

Каяндыр әнисе дә кайтты, тагын да үсеп, ныгып, кояшта каралып беткән олы улын күргәч, балкып китте. Ә инде Зөлфәт әрекмәннәргә төреп алып кайткан бер чиләк кара жиләкне биргәч, өч олы балыкны да тамаша кылгач, хәйран калды әнисе. Сирәк сөендерәм шул әнине, дип монсулана башлаган Зөлфәткә чәй эчерттеләр, болын хәлләрен сөйләттеләр, чөкердәшеп утырдылар. Бик сагынган иде шул туган өен егет. Хәзер инде ул үсте, йөгереп килеп әнисен дә кочакламый, ир кеше, янәсе. Ә кирәк иде. Менә хәзер әнисен кочакламаганга үкенеп утыра.

Энесе учына жылы су салып тора. Пошкыра-пошкыра юынган абыйсы ана су чәчрәтә. Бүтән көнне мона ризасызлык белдергән энесенә Зөлфәт:

— Тоз түгел, эремәссен, — дип тә әйтми, чөнки бүген башыннан бер чиләк су койсан да үпкәләмәячәк, сагынган икән ул абыйсын. Хәзер өйдә ана эш тә азая. Абыйсы эшкә тотынсамы — андагы житезлек, андагы көч, андагы...

Әнисе трусик, майка, оекбаш китереп бирде, бик вакытлы булды бу. Рәхмәт әйтеп яна киемнәрне кигәндә жанына кайнарлык йөгерде егетнен. Ул монда кирәкле кеше икән, аны көткәннәр. Адәм баласына кирәклеген тоюдан да зур нәрсә юк һәм булмаячак та. Менә кирәк микән ул теге Зәнгәр Күзгә? Клубка да чыкмыйча ятты микән, кунакка кайткан килеш?

Болында, Кирмән инеше сыман озын көн дәвамында эшләп, арырга тиешле гәүдәсенә игътибар итте Зөлфәт. Әллә нәрсә булды шунда. Югыйсә, көне буе кайттылар бит. Сәфәр ялыктырырга тиеш иде. Сабан туе ясау жанны тугарганмы, әллә туган авылын күрүгә, фәрештә канаты белән таушалганлыкны сыпырып төшергәнме? Әллә инде әнисе белән энесен күрү сөенече дәртләндергәнме — бер дә арыганлык сизми егет. Этләре Юлдаш та нишләргә белми, уйнаклап тора бит. Су буена ияреп төшмәкче иде дә, анда сиңа кызлар юк шул, дигәч, күзләрен бер-ике тәгәртте дә анлады, чирәмгә ятып калды.

Мәтә Гарәфләре чатыннан борылдымы-юкмы, хәтерләми дә, исенә килгәндә Чегән тавыннан, Мансур абыйлар киртәсе кырыеннан төшә иде.

Әллә нинди сизгер йөрәк, нечкә күнел биргән ана Ходай Тәгалә. Көянтә белән су ташыган чаклар, шушы Чегән тавыннан ашкынып менүләр сагындырды. Ул Чегән чишмәсеннән су алулары! Тау уртасыннан, шактый текә булган улактан су ашкынып төшә дә чиләк төбенә балык сыман бәргәләнә, тыпырчына башлый, менләгән тамчыны дөньяга сибә.

Ул тамчылар тамсамы? Котыптагы ак аю да калтыранып китәргә мөмкин — шулкадәр дә саф, шулкадәр дә өшеткеч ул иртәнге тамчылар! Шул иртәнге тамчыларны төштә күреп аптырады. Тамчының муенына сикерүе була, марля чыбылдык эчендә яткан Зөлфәт уяна да китә. Шушы Чегән чишмәсе ничә тапкыр йокысыннан йолкып уятты микән аны? Ә хәзер чишмә булды микән соң ул, әллә теге Зәңгәр Күз булды микән дип тә шикләндерә. Ин беренче очрашкан кичтә имән төбендәге үрдән йөгереп төшеп Зөлфәтнең кочагына сеңгән килеш яшәде хәтердә кызыкай.

Их, бу Куян Хөсәеннәренең бакча башы! Киртәләренә якын килеп булмый, кычыткан өтә дә ала. Авыш тау битендә алмагачмы, шомыртмы күренә. Шушындый текә җирдә дә бәрәңге үстереп маташа бит ул авыл кешесе. Үзенеке, янәсе, өй яны бакчасы. Көрәк белән булса да казый. һәр елны бакчадан гөрләвекләр балчыгын агызгач, уңышы да әллә ни түгелдер.

Бу авыш бакчада тереклек итү өчен Куян Хөсәене белән Фатыйх Мансурына башкаларга караганда биш тапкыр күбрәк эшләргә кирәк. Юк, ташламыйлар текә тау битен. Үз җирләре, балалары тәпи йөрергә өйрәнеп, бәрәңге ызанында тәгәрәп үскән бакчалары шул. Бакчаң таулы булса да ярый, күңел күле тыныч булсын да, жаның саекмасын...

Бакырчы чишмәсенең дә хәлен белү кирәк! Теге Зәңгәр Күзгә берике бөтнек тә әләктерер. Бөтнек бит ул чәчәк кенә түгел, шундук хисне мәлҗерәтеп җибәрә. Менә Вандовка болынына ит алып төшүче хуҗалык мөдире Таһир абый аптөшеп тоттырсын, ди, кырык биш чакрым юл үткән, арбадагы балта каешына кыстырган, кипкән генә, таушалган гына, башы бөкрәйгән генә Бакырчы чишмәсе бөтнеге! Сагындыра икән шул ул туган як. Гомер буе күңел чоңгылында менә атам, менә атам дип кайнап торучы Камчатка гейзеры кебек. Һәм ата да...

Исән икән Бакырчы чишмәсе, таныды! Якынайган саен яңгыратыбрак сәлам бирде. Горур патшалар да иелә шул чишмәгә. Гомер буе иелдерә ул чишмәләр...

Учларына су алып иреннәренә тидерде егет. Гаҗәп хәл! Су җылы иде! Нәрсә бу! Мондый хәлнең беркайчан да булганы юк иде. Чиләк өшетә торган чишмә. Ә, аңлашылды: теге Зәңгәр Күз белән очрашу шатлыгы аның җанын өтидер. Монда хикмәт чишмәдә түгел шул — кызыкайны үбәргә омтылган иреннәрендә чишмә суы кайныйдыр.

Бүген үбә инде аны Зөлфәт, болында ук сүз бирде. Беренче очрашкан көнне үк пәпелдәтмәсә, кабат бөтенләй булмый инде. Килеп тә керде, сугып та екты, дигәндәй.

Пәпелдәтерсең Зәңгәр Күзенне, әле очрашуга килсә ярый. Иманне кочаклап, аның кытыршы кайрысын гына кымтырыклап кайтып китмәсәң. Борының белән инеш буен сукалап, сукасын күтәрергә онытка тракторчы кебек.

Иртәрәк килмәдемме? Әйдә, килсә Трайт чишмәсе тавышын тыңлар, сердәш имән яфраклары леперләвен, дип агач төбенә килеп кенә басты Зөлфәт, кыз каяндыр очып та төште, ана сыенып елап та җибәрде.

Тора хәзер калтыранган, үксеп елаган кызыкайны кочаклап, бәхет дәрьясында үскән имәнгә сөялеп. Дөм караңгы булса да ап-ачык күрде Зөлфәт. Әле генә елап туктаган сабый бала хәлендә иде кызыкай, керфегендә тамчылар ялтырый, үзе дер-дер калтырый, Зөлфәтне чытырдатып кочаклаган.

Үзен белештермичә, аның башын артка иде дә, иреннәреннән суырып үбә дә башлады, җаны дертләп китте.

Конфетны, прәннекне, балны тәмле, диләр...

Пучтәк икән...

Әйрәнне, әче балны мактыйлар. Ярый инде...

Өрәнге суын, алманы, пешкән жир җиләген телне йотарлык, диләр.

Коймакка, дучмакка, бәлешкә табыналар. Шулайдыр...

Каклаган каз, тутырма, казылык, диләр. Юк ла инде...

Әниеннең күкрәк сөте тәме, чишмә, каен суын әйтәләр. Болары изгедер...

Ләкин әле беркем тарафыннан үбелмәгән, хәтта үбешә дә белмәгән, дер-дер калтырап торган кызны, үзең дә тетрәгән хәлдә, бөгелеп-сыгылып тирбәлүче җаның белән үп тә, аның сусыл татлы иреннәрен тоеп мәрткә китмә, ди! Менә кадәр кичермәгән ләззәт, тетрәнү, күккә ашу халәтенә кер дә... Сулышлары кабып, тончыгып үлә язган егет белән кыз иманнең аларны күрү өчен иелүен дә, Трайт чишмәсенең тыныч кына агуыннан туктап калуын да, соңгы ыргым сунын, бер ай элек өзми-куймый сайраган сандугач моны булып улактан сикерүен дә күрмәделәр. Үз хәлләре хәл иде.

Алар икесе дә бер-берсенең иңбашына башларын куеп тынып калдылар. Кыз һаман да елый, яшьләре егетенең күлмәгенә агып төшкәнен дә тоймый. Тыймады аны Зөлфәт, еласын, тынычлансын дигәндер.

Гәүдәсенә сыланып, омтылышлы күкрәге белән егетнең йөрәгенә орынган үсмер кызның биле гаҗәп нечкә, хәтта Зөлфәтнең ике кулы белән аның билен үлчәп карыйсы килде.

Кызның сулкылдавы пароход үтеп киткәндә көчәеп, аннан салмакланып, кабат хәлсезләнеп болын итәгенә килеп егыла торган дулкын сыман тына барды. Ә калтыравы һаман дәвам итә һәм Зөлфәтнең җанын тетрәтә иде. Менә ничек көткән аны кызыкай, ничек сагынган. Хәзер инде сөйләмәсә дә ярый, бер ай буена имән янында очрашмауның кавырсынын чыгардылар.

— Мин монда һәр кичне килдем, көннәр буе су ташыдым. Вәккәс абый минем капка төбендә утырганымны күргәч: «Бетәсең бит, әллә болынга төшереп ташлыйммы? Әйдә, сал ясыйм да агып төшеп кит, нәкъ шул болын турына килеп чыгасын», — дип котырта. Апа да: «Юләр, вечерга чык, — дип куа! Конверт эченә салып, Уралына җибәрәм», — ди.

Көндезе үтә, кич белән имәнне кочаклап кайтам. Чишмәсенең салкын суы белән юынып кына чыдадым үлүдән, — ди кызыкай һәм чыркылдап көлеп җибәрә.

Димәк, селкеп ташлады бер айлык сагышын. Хәрәкәтләре җитезләнде, бер сүз белән әйткәндә, озак авырудан терелгән бала кебек, өй кыегына беркетелгән, җил көчәйгән саен көчлерәк зырылдаучы тегермән булды да калды. Зөлфәтнең дә никадәр сагынганын, Хуҗа абыйсы кебек өлкәннәр алдында сынатмыйм дип печән чабып эт булып аргач та, черкиләр тешләвенә дә исе китмичә аны уйлап ятканнарын белә микән? Хат та язып булмый шул ул болыннан. Сәетов Таһир абый артыннан сәлам әйтеп җибәргән иде дә, оныткандыр.

Шул ук минутта Зөлфия:

— Таһир абый сәлам әйтте мина, шуңа гына үлмәдем, — дип чынлады.

Менә сиңа кирәк булса, Ходай бер үк уйларны да уйлата түгелме соң аларга? Егет белән кыз алга таба нәрсә сөйләштеләр, ник көлештеләр, үзләре генә беләдер. Зөлфәт кызны инеш аркылы күтәреп алып чыкты. Су уртасындагы ташка баскан килеш Зәңгәр Күзне үбә башлады. Күпме үбешкәннәрдер, анысын сер саклый белә торган тал тирәк күрде. Аяк араларыннан челтерәп аккан елгыр су гайбәтне авылга таратырга мөмкин дә, печән өстендә аны кем ишетсен. Яр буе кыегына тотынган бака

аягы белән инеш суына күпме үбешүләрен язып бара да, суга язганга кем ышансын...

Гел үбәсе генә килә бүген бу зифа буйлы кызны. Сагынган, шуна узына Зөлфәт, артыграк кыйланганын да сизә, үзен тыеп кала алмый.

— Бүген ярар, үп инде, дип, — тагын шаккатырды кызыкай. Тагын бер үк уйны уйлыйбыз икән дип инеш уртасында туктаган жиреннән ярга чыкты Зөлфәт.

— Юри алып керден үбү өчен, суга төшмәсемне беләсен, — диде Зөлфия.

— Бардыр инде, бүген нәрсә эшләгәнемне белмим. Сагындырган Трайт чишмәсе белән теге имән, үбәм дә үбәм шуларны.

— Бер дә аларны үпмисен әле.

— Минем Трайт чишмәм син бит инде, челтерәп, гел үзенә чакырып торасын.

— Шагыйрьләр кебек сөйләшәсен.

— Бардыр инде, яр буендагы баканы күрсәм, нәрсә сөйләшкәнемне белмим.

— Үләм. Бака кебек мени инде мин.

— Гажәп бака, бөтен су буена, дөньясына бер — гөберле бака!

— Нәрсә ул «гөберле?» Вәккәс абыйдан сорыйм әле иртәгә.

— Гажәп чибәр дигән сүз ул, — диде дә, Зөлфәт кычкырып көлеп жибәрде. Анын бәхетле тавышы аръякнын дымлы сукмакларын, гөлләрне, үлән башларын сыйпады, Муллин Нуруллаларнын койма тактасын көтүче малайлар чыбыркы сабы белән тырылдатып барган сыман тавыш чыгарды. Инеш аша салынган басмада Көмеш Чишмәнен сихри кичен үз жилкәмдә тотам, дип мактанып утыручы бака сискәнде дә суга сикерде. Анда гына туктап калмады бу эчкерсез көлү, зираттагы бер кабер өстендәге ак каен ботакларыннан савылып төште дә, кабердә ятучы әрвахка ишетелде...

Зөлфәтнен Аргыякка кунакка кайткан сандугач тирәсендә әйләнүе бар дөньяга янгыраган, ахры.

Аек вакытта синен ун соравына да бер күз салу яки ым кагудан узмый торган Мәтә Гарәфе белән Сәләхи тавында очраштылар, инде йөгерүдән туктаган, атлауга күчеп, тынычлана башлаган Зөлфәт Чирай Исмәгыйльләре тавына кадәр ат белән янәшә кайтты. Аннары Мәтә Гарәфе авызыннан ике сүз кысылып чыкты:

— Күрше, утыр! — Аек вакытта дөньяга көненә ике сүз, биш-алты ишарә бүләк итеп сөендерә торган агай анын колагына шишара әлле:

— Син беләсен микән, юк микән, менә бу Аръякка кунакка кайткан кызны әйтәм, кичә Йосып Ибрае малае Хәнифкә сорап төшкәннәр бит. Килешкәннәр, ди.

Йөрәгенә ут капкан, ә тәненә бер мичкә бозлы чишмә суы сибелгән Зөлфәт арбадан сикереп тә төште, йөгереп тә китте. Мәтә Гарәфе атына чыбыркы белән суктымы, әллә анын «ха-ха-ха-ха!» дигән кыргый көлүе бахбайнын жанына ордымы? — Әй, чабыштылар Мәтә Гарәфе аты белән Зөлфәт! Алар кузгаткан жилдән Бакырчы чишмәсе бөтнекләре суга тиеп тажларын чылатты, чәчәкләргә кунып бал жыючы умарта кортларынын ефәк канатына энже сипте...

Уза алмады Зөлфәтне Мәтә Гарәфенен аты да, ышандырмады олы мичкә белән аударылган гайбәте дә. Үзенне дә кызык итәм әле мин сине, карт шайтан. Баш авыртып теләнеп кергәч төзәтермен мин синен ватылган башынны. Юк! — дип башына кувалда белән биргән шикелле итәрмен. Бөгештермә! Әти-әнисе Уралда булган кызны Йосып Ибрае әби-бабасыннан сорап төшәмени? Хәнифенен бер ун жәпле пәкесе бар, кичке уен вакытында

шуны чалбар кесәсендә бөтереп утырудан узмый. Бер алып халыкка күрсәтә дә, кире кесәсенә сала. Мәктәп бәдрәфенә шуңа төшеп китте аның ул пәкесе. Кызлар каргышы төшкәндер. Кызлар бит аның ул пәкесен күрү өчен жыелмый кичке уенга, бүтән берәр нәрсәсен күрсәтсен. Гел пәке дә пәке. Яз да. Жәй дә. Кыш та.

Әти үтерә инде малай, дип бер сәгать казынса да, таба алмады малаең Алла каргаган мактанчык пәкесен...

Кая әле аңа өйләнергә йөрү...

***

Утын әзерләп, печән жыеп үтте дә китте жәй. Авыл кешесе эшкә ничек түзә диген син?! Анысына да түзәрсең, әле шәһәрләр мыскыл иткән була.

— Сездә бөтенесе дә бушка, нишләп бай яшәмәскә сезгә?! — дигән була, бер нәрсәне дә сатып алмыйсыз, янәсе. Акчаң булмагач, алып булмый инде аны. Ә үзләре чыгып киткәч әйләнеп кайтмый. Кайтарырсың, ферма ишегалдында тирес ерган эржинкә итеген салган, эт тә иснәмәс фуфайкасын чүплеккә ыргытып качкан кешеләрне!

Туфли кия, үтә күренмәле күлмәк белән кайбер тар жирләрен каплап ала да, тек-тек басып асфальттан юырта бирә.

Авыл кешесеннән әйбәт ашый, ел буена жыйгач, сыер асраучыдан күбрәк сөт, катык, каймак, ит сыптырган була. Өшкереп бирә ул синең малыңны, нәрсәгә аңа синең бура каләр сыерыңны ашатып маташуын. Вакыты-вакыты белән ул сыерны өйдән каядыр олактырасы килә. Туп-турыга туп пошел, дип.

Шәһәрдән кунакка кайткан авылдашлар нигә юлыгыз, күперегез юк, урамыгыз сазлы, дип тә кытырдата. Шул юлларны, күперләрне, тагын әллә нәрсәләрне бергәләп төзисе урында, биредән чыгып качкан бәндәләр инде, югыйсә. Кайтсыннар да салсыннар! Безгә бүтән эш тә житәрлек! Шушы авылның ризыгын ашыйлар, суын эчәләр, һавасын сулыйлар, ә үзләре б... чәйниләр, дип кенә жибәрә андыйларга Габделхай абый.

Жәйнең тиресен күпме тартсаң да өч айдан узмый инде ул, ертыла да, яфраклар арасыннан көз малаеның сары башы күренә. Трайт чишмәсенең челтеренә, сердәш имәннең яфраклары лепердәшүгә кушылып шаулаган көннәр сентябрьгә гажәп тизлек белән агылды. «Бәхет» белән «бетте» бер хәрефтән башланганга күрә шулайдыр ул...

Соңгы көнне алар бик ямансулап аерылыштылар. Зәңгәр Күз елый, бер сүз белән әйтсәң, елаган саен чибәрләнә бара. «Иртәгә сәгать биштә абый ат белән Югары Ушмы турына автобуска чыгара», диде. Монысы инде капка төбендә әйтелде.

Суырып үпте дә кызыкайны Зөлфәт, капкадан кертеп жибәрде. Инде яктырып та килә, әй, бу авыл төннәре! Костюмын жилкәсенә болгап салган иде, кесәсеннән шыбырдап тимер акча коелды. Борылып та карамады, әкрен генә кайтып китте егет, акчага гына терәлгәнмени дөньясы?!.

Китә кызыкай. Көпә-көндез, халыктан оялмыйча, аны юлга чыгып озатып калу гаеп саналгач, ни хәл итәсең?!

***

Гажәп күңелсез булды Зөлфәткә. Кичләрен клуб бакчасында волейбол уйныйлар, кирәмәйләп суга тупка. Егетләр: явызландың син хәзер, диләр. Явызланырсың монда, хаты да килми. Барып житүгә язам дигән иде. Бер атнада үзе кайтсынмы, хаты килеп житсенме?! Егетнең анда эше юк.

Утын турап өяләр, бәрәңге алалар. Мал белән мәш киләләр. Эш житәрлек анысы авылда. Апасы да очраган иде, бер сүз дә әйтмәде, димәк, аңа да әле Зөлфиядән хат килмәгән.

Килде хат. Аннан аңкыган хуш ис! Кызлар хатны хушбуйга манып яза икән. Әллә язып бетергәч хушбуй сибәме?!

Бик сагынып-саргаеп язган иде кызыкай. Бернича жиренә яшь тә тамган, рус сүзләре Рәсәйнен үзе кебек җәелгән. Аңлады һәм сөенде Зөлфәт: кыз аны әкәмәт сагына икән. Кайда булганнар, нәрсә сөйләшкәннәр — берсен дә онытмаган.

Сентябрьдә Мамадышка китте, унберенче класста укуын дәвам итәргә. Әнисе булдырды, кара сукно табып, костюм-чалбар тектерде. Ялга кайткач, клубка да киеп чыкты Зөлфәт. Клубка керүгә күтәрми торган калай белән тышланган озын өстәл бар. Шунда домино сугалар. Кереп утырмакчы иде, өстәл атынмасын өчен кагылган тимер тарткыга чалбары эләкте, умырылып төште. Өйгә кайтып китте Зөлфәт, ялтырап аягы күренеп тора. Әй, әни тиргәр инде, дип борчылулары! Әнисе алтын шул — бер сүз дә әйтмәде. Әйбәтләп текте дә бирде. Җөе беленә инде, нихәл итәсен, күрәчәктер.

Мәктәптәге кызлар Зөлфәтнең үсеп, чибәрләнеп, кояшта каралып килгәнен күргәч, тагын да ягымлырак сөйләштеләр.

Авылдаш малай аяк киеме урлап тотылган. Директор яныннан класс житәкчесе Асия апа да елап чыкты. Куам, дигән Мирсаяф Мөхетдинович.

Аннан Зөлфәт керде Мирсаяф абыйсы янына. Кире бормады директор абыйсы. «Караклар дигән хурлыгы ни тора, калдырып булмыйммы теге дуңгызны», — диде ул, сөйләшүе яралы кеше ыңгырашкан кебек. Белә инде Мирсаяф абыйсы Зөлфәтне, йөгерештә, чаңгыда җиңгән өчен генә түгел, Тукай көннәре үткәрү унаеннан да Көмеш Чишмәгә язмача рәхмәт юллаганы бар. Райком секретаре Нәжип Шәкүрович якын иткәнне дә белә.

Аннан Зөлфәт:

— Мирсаяф Мөхетдинович, мина үзебезнең шушы икенче урта мәктәпне тәмамларга кирәк. Әти фаҗигале төстә үлгәч, әни йөрәк авыруы алды, укуны ташлап аны борчыйсы килми иде, — диде.

Гомер булмаганны икесенә дә чәй китертте директор абыйсы.

— Ярар, үзең барла ул малайны. Көмеш Чишмә исеменә карак сүзен ябыштырмаска тырышуың ошады. Бар, Арчага зона ярышына әзерләнүенне онытма, Мартынов белән Ишмуратовка да әйт, — диде.

Менә бит ул чын укытучы һәм житәкче. Әкрен генә сөйләшә үзе, ә сендерә.

Бу вакыйгадан соң Зөлфәт сыйныфларында гына түгел, бөтен татар секторында да дәрәҗәле санала башлады. Яхшы укыды, мәктәп чаңгы командасы белән тренировкаларга, ярышларга йөрде. Район, Казан гәҗитләрендә шигырьләре, мәкаләләре басылды.

Аның хыялы журналист булу иде. Югары уку йортларында татар журналистикасы бүлеге юк икән.

Димәк, рус телендә бик күп сочинениеләр язарга, матур әдәбият укырга, тарих фәненнән ныклап әзерләнү сорала. Гел русча имтихан тотасы булу, һичшиксез, кыенлык тудырачак иде.

***

Классташы Фәния дә бик чибәрләнгән, бер килмәгән жире юк, нинди эшкә тотынсалар да Зөлфәт белән янәшә булырга тырыша. Тәрбияле гаиләдә, татар халкының күркәм гореф-гадәтләрендә тәрбияләнгән кыз буларак бер артык ишарә ясамый, күзенә чекерәеп кереп йөрәгенне оккупацияләми. Гәҗит чыгарган чакта кулы Зөлфәт кулына тиеп китсә дә, кып-кызыл була. Гаҗәп тә кыз инде син, Фәния, ләкин мин башканы яратам дип, рәхимсезлек күрсәтергә Зөлфәтнен йөрәге житми.

Фәниядә өмет элеккегә караганда да көчлерәк. Чөнки нефтьче кызы Фаягөл хәзер алар арасына керә алмый, күчеп киттеләр. Мәктәпнең клуб урынына да кулланылучы спортзалында кичәләр булганда да Фәния гел янәшәдә. Ә Зөлфәтнең ни биисе, ни әйләнәсе килми. Гәүдәсе йөри инде шунда.

Бер кызык итте аны кызлар. Нәсимә белән Фәния: «Әйдә, совхозның алма бакчасын күрсәт, үзегез генә ашап ятасыз, җитте сезгә», — дип тагылып меңделәр, Зөлфәтнең торакка сумкасын кертеп куйганын көтеп тордылар.

Кереп киттеләр алма бакчасына, каравылчы да, шайтан да юк, алма әллә ничә тапкыр җыелган, ләкин ашау өчен җитәрлек иде. Ашадылар, көлештеләр.

Энгер-менгер төшәр алдыннан теге чукынчык Нәсимә юкка чыкты. Калдылар Фәния белән икесе генә алмагач урманында. Кулыннан алырга җай чыккан саен кочакка елышырга торган кызны, шәһәр үзәгендәге кызлар торагына озатырга туры килде. Матур гына саубуллаштылар, кертеп җибәрде кызлар торагына Фәнияне.

Икенче көнне Нәсимәгә тәнәфестә: «Кая югалдың син, котны алдың», — дигән иде, Нәсимә:

— Дурак. Бозау! — дип ике сүз ысылдады да, пырлап китеп тә барды.

Имтиханнарын тапшыргач, иптәшләре белән аттестат алган көнне төшкән карточкаларын кадерләп саклый. Сурәттә райком секретаре Нәҗип Шәкүрович, Мирсаяф Мөхетдинович, класс җитәкчесе Асия апасы бар. Анда да Фәния үпкәләгән кыяфәттә. Белә инде Зөлфәт кемгә үпкәләгәнен.

Чыгарылыш кичәсе көнне дә Фәния берүзе аңа ияреп торакка менде, шәһәр читендәге тау башында йөрделәр. Алмагачлар арасыннан атладылар. Арыгач Зөлфәтнең курткасын җәеп Фәния белән чирәмгә утырдылар. Фәния Зөлфәт кочагына мәче баласы кебек сыенды да дерелди башлады. Башлары әйләнеп китте егетнең, ул ничек итеп үлән исе килеп торган йомшак җиргә тәгәрәүләрен һәм үзенең берзаман Фәния өстендә ятканын аңлап, айнып китте. Кызның куллары артка ташланган, күзләре йомык, күкрәге Зөлфәтне бишегендә тирбәтә иде.

Ир кеше булып, шушы кыз өстендә ятып та, аңа кагылырга тиеш булмаганын җанны ымсындыручы мең-мең кылның кайсысы сиздерде микән?! Алла саклады. «Торыйк, Фәния, сиңа суыктыр», — дип мыгырданды ул. Моннан да мәгънәсезрәк сүз таба алмады.

Кая суык булсын инде ул ут эчендә янып, вулканнарда чөелеп, күкрәгендә өзелеп сөйгән яры яткан кыз балага! Күктә гашыйклар төненә генә хас мең-мең йолдыз кабынган, тагын кайдадыр, хәтта ерак Чилида да меңләгән мәхәббәт утында янган меңләгән кешеләрнең күз карашлары бар галәмне җылыта!

Нишләсен ул кыз бала?! Сөйгәне кабул итмәгәч, иркәләмәгәч, җирдән ничек торсын ул?! Җир йотса гына ярар иде.

Күзен ачарга оялып яткан, күтәреп торгызсын, дип кулын да сузмаган Фәниянең янына утырды да тын калды Зөлфәт. Нәрсә әйтергә дә белмәде. Кыз елый, тавышы да чыкмый, ә ике күзеннән яшь ага да ага. Җанны телгәләгән унайсызланудан нишләргә дә белмәде егет, Каф тавы янәшә булса, йөрәген Эльбрус түбәсендәге бозга терәп торыр иде. Үзен өч ел буе өзелеп сөйгән кыз алдында исикиткеч гаепле тойды.

Аны үзенеке итеп бөтен тормышын җимерергәме? Яратам, дип шашып үбәргәме? Бик тә лаек кыз да инде ул саф мәхәббәткә, назга. Шул ук вакытта хөрмәткә дә. Тик аның да кияүгә чыгасы, балалар табасы, иренең күзенә туры карап яшисе бар.

Зөлфәт Фәнияне кызлар торагына кадәр озатты. Кереп киткәндә кыз юкә агачы төбендә шундый кысып кочаклады, суырып үпте дә:

— Рәхмәт сиңа, барсы өчен дә! — диде.

Шул рәхмәтнең мең тонналы газабын күтәреп яши хәзер егет. Кая микән ул Фәния дигән гүзәл кыз? Нишләп Ходай шундый җәзага тартты микән аны? Аны да, Зөлфәтне дә.

***

Зәңгәр Күз бу җәйдә кайтмады. Зөлфәтнең туган көненә китап җибәрде. Берөзлексез хат яза. Хатларыннан сагыш агып чыга да авылның барлык чишмәсенең җырын саңгыраулата, йолдызларын тоныкландыра, гөлләрен сулдыра.

15 августта мәгариф бүлегеннән боерык алып кайтты, мәктәптә эшли башлады. Зөлфәт физкультура укытачак, урта мәктәпне әйбәт тәмамласа да, әле махсус белеме юк. Ленин укыган университетның журналистика факультетына керергә исәбе. Шигырьләре район, республика матбугатында басыла, мәкалә-хикәяләре чыга. Бу факультетка кергәндә гәҗит-журналда чыккан әсәрләр алып килү мәҗбүри икән, шуңа аерым папкага туплап бара. Үзенә бик катгый таләпләр куйды. Шулай булмаса, укырга керергә әзерләнүе барып та чыкмаячак. Республиканың иң дәрәҗәле уку йорты, җитмәсә барлык сынауларны русча бирү — татарча укыган кешегә авыр булачак.

Өстәвенә, көнгә өч тапкыр йөгерә, аннан 6-7 сәгать укыта, класс җитәкчесе. Колхозның «Комсомол прожекторын» чыгару да аңа йөкләнгән. Шагыйрь, диделәр, булачак журналист!

Клубка чыгып кичке уеңга да күңел тартмый калмагандыр. Менә шуңа да үзенә бик каты торды Зөлфәт. Ятим үсү, авыр эштән курыкмау, спорт белән шөгыльләнү дә үз эзен салгандыр.

Клубка шимбә һәм ял көннәрендә генә чыга. Шимбә җырлый, бии. Ял көнендә кино карый. Ике көнне дә егетләр белән туп суга.

Калган вакытта университетка керергә әзерләнә. Авыл һәм районда булмагач, Нурфига апасы китапханәара абонемент аша дистәләгән китап кайтартты.

Зөлфәтнең такта белән бүлеп алган аерым почмагы бар. Энесе белән стенага шүрлек ясадылар, анда шыгрым тулы китап.

Сочинениегә 25 тема бирелә икән, язып алып кайтты университеттан. Зөлфәт болай уйлый: иң башта бу темага кагылышлы китапларны, мәкаләләрне укый, өйрәнә дә мөстәкыйль рәвештә һәр сочинениенең планын төзи.

Укырга керү белән бәйләнешле документларын имтихан комиссиясенә тапшырып та кайтты. Бер танышы юк, бер булышучысы юк. Шул үзенә, белеменә, хәзерлегенә, әбисе Шәмсурый әйтмешли, бер Ходайга инде ышаныч.

— Сине дә алмасалар, ябабыз аны, ди Шәмсурый әбисе, шул да җитә өмет иткән күңелгә. Балкып китә Зөлфәт, күп тырышты инде, соңгы вакытларда клубка бөтенләй чыкмады. Сәламәтлек нык иде ме, аз йоклавын да җиңел кичерде. Салкын су белән әллә ничә тапкыр юына. Үзен йөгереп тә җәфалый. Ябыкты, каклаган каз инде менә.

Әбисе Шәмсурыйга дога укытты, күршедәге Газизә апага бөтен ипине хәер итеп кертте, 30 май көнне Казанга китеп барды егет, ашамлыклар, көчтәнәчләр төяп.

31 май көнне, шактый гына чиратта торганнан соң, кабул итү комиссиясе бүлмәсенә керде. Факультет исемен, фамилиясен әйткән иде, бер кызый:

— Вас не можем принять, у Вас нет двухлетнего стажа, — дип барлык

документлары, гәжит-журналларда басылган әсәрләре тупланган калын папканы кулына тоттырды да:

— Следующий! — дип кычкырды.

Аны башка абитуриентлар этте-төртте. Анга килгәндә коридорда, тәрәзә төбенә бар хуҗалыгын ташлаган, аптырап басып тора иде. Нишләргә, кая барырга? Югары уку йортларына читтән торып укырга керү имтиханнары иртәгә, иртәнге 8дә башлана. Ул Казанда йөргән кеше мени? Берсен дә белми һәм башы да эшләми. Коелып төште Зөлфәт. Авылга укырга керә алмыйча кайтуы ни тора! Гомергә башлы малай бул да, Казан университеты йөзенә калын папка белән чалтыратып куып чыгарсын әле!

Ике ел стаж кирәк! Нишләп аны алдан әйтмәделәр? Кабул итү шартларын җентекләп укыган сыман иде Зөлфәт, анда андый шарт юк иде. Нишләргә? Башка бер юньле уй да килми, чүкеч белән сугып миңгерәүләткән үгез кебек басып торды Зөлфәт...

***

Кинәт янәшәдә генә ишек ачылды, аннан татарча сөйләшә-бәхәсләшә ике ир кеше килеп чыкты. Нәрсәгәдер рәхәт булып китте Зөлфәткә. Ирләрнең берсе уртача буйлы, икенчесе калку, мәхәббәт гәүдәле иде.

— Нишләп торасың, егет, балтаң суга төшкән шикелле? — диде күзлексезе.

Алар Зөлфәткә якын килделәр. Күрәсең, егетнең кыяфәте чакырып китерерлек булгандыр.

— Минә журналистика факультетына имтихан бирергә килгән идем, ике ел стажың юк, дип документларымны кире бирделәр. Нишләргә дә белгән юк, иртәгә бөтен вузларда имтиханнар башлана.

— Әйе, — дип җибәрде күзлеклесе.

— Син нишләп урыс журналистикасына керәсең, анда саргайган гәҗит-журнал актарып матбугат тарихын гына өйрәнәләр бит. Менә безнең татар әдәбияты факультетына кер. Шуның ишек төбендә басып торасың, әйт, нишлибез?

Нишләсен инде Зөлфәт?! Аның эченә җылы йөгерде. Аны күзлекле ир үзенә ияртеп бүлмәгә алып керде, татар теле һәм әдәбияты факультетына укырга алуны сорап үтенеч яздырды һәм документларын кабул итү комиссиясенә тапшырып та чыкты.

— Энем, — диде ул, — иртәгә менә шушы бинага киләсең, сочинение язабыз. Синең әйбәт язасына ышанам. Сәгать иртәнге сигездә монда бул.

— Рәхмәт, — диде дә, күнеле тулган, сөенеченнән нишләргә белмәгән Зөлфәт очты гына университеттан, аның мәрмәр баскыч-клавишларында җемелдәгән аяк табаннарыннан көй чыгып калды...

Кабат беләчәк әле Зөлфәт ул изге кешеләрне. Күзлеклесе Нил Гафур улы Юзеев, мәхәббәт гәүдәлесе, чибәре Мөхәммәт Мәһдиев икәнен.

Очып кайтты Шәмсегаләм апасы янына.

— Менә Ходай Тәгалә бар ул, — диде апасы да, — әзерлән, иң яхшысы — иртә ятып йокла, Алла ташламас!

Озак йоклый алмый ятты Зөлфәт. Шәһәр ыгы-зыгысы, кабул итү комиссиясендә башка күсәк белән тондыру һәм изге кешеләр очрап фаҗигадән чыгу юлы табылу җанны тетрәткән иде.

Авылдагыча иртүк торган, ишегалдына чыгып салкын су белән юынган егетне Шәмсегаләм апасы тагын:

— Безнең нәсел ул төшеп калганнардан түгел, язасың сочинениене, кәгазь генә житкерсеннәр, борчылма, — дип юатты, кайнар ашлар белән сыйлап, җилкәсеннән кагып озатып калды.

Кунакка килгән Фатыйма апага хәер бирде. Аннан, ишек бусагасыннан капканы да сул аяктан атлап чыкты.

Университет коридорлары актан киенгән егетләр, кызлар белән кайнап тора. Таныш-белеш үзара сөйләшә, нәрсәдер планлаштыра.

— Юньләп әзерләнеп тә булмады, жәй буе авылда эшләп, дип тә жибәрә.

Йә, Аллам, кем генә юк монда. Болар бит инде кая барганнарын белеп, нәкъ менә татар факультетына укырга килгәннәр, әзерләнеп, шпаргалкалар кыстырып, иксез-чиксез күп сандагы китаплар укып. Ә ул урысча әзерләнде. Ә хәзер татар әдәбиятыннан сочинение язасы.

Ниһаять, аларны зур бүлмәгә чакырдылар. Китте әзерлек кыштырдавы, шикләнеп-шөбһәләнеп темаларны тактага язганны көтү. Темаларның барсына да яза аласы икән Зөлфәт,  барсы да ул укыган, теге яки бу дәрәжәдә таныш язучылар, аларның халык тарафыннан йотлыгып укылган әсәрләре.

Ул ирекле теманы сайлады. Туган як, аның кешеләре, табигате, тарихыннан кадерлерәк тема буламени?! Караламага план төзеде, менә бу сыер савучы, игенче, сугыш батыры — Татарстанның беренче Советлар Союзы Герое — авылдашы Гафият Нигъмәтуллин турында язам, диде. Чөнки мәктәбендәге пионер дружинасы да аның исемен йөртә.

Жиң сызганып эшкә керешкән егетнең кәгазь битләрендә туган авылның ике йөз чишмәсе челтерәде, тау башындагы Ризван каеннары шаулады, сугыш вакытында иң алдынгы уракчы Нурлы апасының көмеш урагы кетердәтеп арыш урды...

Дәртләнеп, шунадырмы ашыгып, ару-талуны белмичә язды Зөлфәт. Эпиграфын да яттан белә. Караламага язып бетерде дә, тикшерә башлады. Бу тема ана шулкадәр якын, кадерле. Ул хәзер һәр көнне өч тапкыр йөгереп әйләнә торган кырларда йөри, хөрмәтле, күз алдында һәрберсе үз сөйләме, холкы белән жемелдәүче авылдашларын мактый, чишмәләргә салып жанын чайкый, алар турында яза.

Акка күчереп, сочинениесен тапшырып чыгып киткәч кенә бераз тынычланды Зөлфәт. Кабул итү комиссиясеннән документларын макулатура сыман күтәреп чыгарып салган тәрәзә төбенә йодрыгы белән сукты. Зур эшне майтарып нокта куйган шикелле булды бу.

Әле берничә көн тикшерәселәре булмагае. Кеше күп, һәркем зур күләмле итеп яза. Ул да жәелеп китте, илһам килгәндер, күрәсең.

Ә шулай да төшеп калганнардан түгел әле ул танкист малае. Туган як турында язды, фамилияләрне дә саф татарча сырлады. Аннан Гафият Нигъмәтуллинны белсәләр дә, бүтән кешеләрне, аларның уңышларын университет укытучылары белми, бәйләнә дә алмый, тегеләй-болай язгансың, дип.

Үзен шактый акыллы тойды коридорда тәрәзә янагына сөялгән егет. Иң әһәмиятлесе — имтиханга әлегә алды, калганын тикшергәндә карарлар профессорлар.

Ә алдагы көннәрдә грамматикадан, әдәбияттан, тарихтан һәм чит телдән имтиханнар бирәсе, чөнки аның аттестатында немец теленнән куелган билге дә бар. Их, уңышлы тапшырса икән имтиханнарны! Берәрсеннән «2»ле чәпәп, өенә кайтарып жибәрмәсәләр...

***

Зөлфәт консультацияләргә йөри. Сочинение билгесен белмәү һәрдаим борчый, шуны баштан чыгарып ташлап булмый. Укырга керә алмыйча кайту зур фажига иде шул ул елларда. Тормышлар гел икенче якка борылырга,

син үзеңне түбән сорты кеше итеп санарга мөмкин. Монысы инде иң хәтәре. Аннан гайбәтчеләр: менә яклап билге куеп барганнар да чыкты хәзер ялганнары, дип, икенче елга кадәр кинәндерәләр инде. Әнисе: «Улым, керә алмасаң кайгырма. Ходай саулыктан аермасын, югалмассын», дисә дә, бер дә алай түгел шул ул... Гомер буе өйләрендәге эти эшлисе эшләрне дә ул башкарып, аталы малайларга махы бирмичә укы, йөгер, тырыш та менә сина мә!

Өч көн үтеп киткәч кенә чыгарып элгәннәр сочинение билгеләрен. Зөлфәт килгәндә, кайбер кызлар елап чыгып бара, кайсылары кып-кызыл булганнар, кайсылары кара коелган... ә кайсысы, аны-моны уйламыйча, урында сикергәли иде. Бераз тукталып исемлеккә якын килмичә торды Зөлфәт.

— Кил, юләр, нишләп торасың анда, синең икесе дә «5»ле бит, — дип кул болгаган Яшел Үзән кызынын сүзенә ышанасы килмәде.

— Юләр булсам булыр идем әле, сүзең дөрес булса.

— Менә инде, бәхет башына ишелеп төшкән дә башын тишкән дигәндәй, кил инде монда. Бер стакан морс алып эчерәм, дип әйт, ичмасам, — дип кыю кыз аны тотып белдерүләр тактасы янына өстерәде.

Башта фамилияләр күз алдында биешсә дә, кабат туктап калдылар. Ходай Тәгалә бар икән!!! Күз аллары яктырып китте егетнең. Исемлек аңа бик тә мәрхәмәтле һәм Яшел Үзән кызының сүзе дөрес иде.

— Кабат гел синең яныңда утырырга рөхсәт итәрсең бит, галиҗәнап Тукай әфәнде?! — диде ул.

— Карарбыз, — диде Зөлфәт Көмеш Чишмәдәге колхоз рәисләре әйбер сораган кешегә әйтә торган сүзне кабатлап.

Бәхетле кеше кайчагында бернәрсә дә күрми, яки бар нәрсәне дә күрә, кызнын кулына «Расих» дип язылган иде.

— Кулыңдагы Расих дип сырлаган кара исемне бетерсәң һәм дә минем исемне язсаң, туташ, — дип, теленә салынды сочинение билгеләре күкнең җиденче катына чөйгән һәм гомер буе шаярырга яраткан Зөлфәт. — Карарбыз, гүзәлкәй. Синең ише Яшел Үзән кызына каршы килеп буламы соң?!

Шулкадәрле кызарды кыз, кулын кая куярга белмәде.

— Әем лә, — диде дә, дәфтәре белән битен каплады.

— Әйдә, тәрәзә төбенә утырыйк, йә чайкалып китеп, профессор Хатыйп Госманга бәрелүең бар.

Коридордан, һәр адымын идәнгә кадаклаган сыман атлап, татар шигъриятен тикшерүгә зур көч куйган, элек үзе дә күренекле язучы булган олпат галим килә иде. Зөлфәт аны беренче күрүе булса да таныды. Үзе дә шигырь язу белән җенләнгән кеше буларак, аның рәсеме белән чыгарылган китапларны, мәкаләләрне өйрәнгәне бар.

— Әллә нәрсәләр беләсең син, малай, — дип пышылдады кызыкай.

Галим үтеп киткәндә тәрәзә янында үрә катып калдылар.

— Очрашырга насыйп итсен, әдәбияттан имтихан аладыр, аңа кадәр телдән имтихан биргәндә башны ашамаслар — дип, Зөлфәт кызны күтәреп тә алды, тәрәзә төбенә утыртып та куйды.

Ах итте кыз, тагын кып-кызыл булды. Ләкин Зөлфәтнең егетлеге аңа бик тә ошады.

— Минем эти зур житәкче, әллә кайларда укытам, дип башны әйләндереп бетерде. Ә минем монда укыйсым килә. Читтән торып монда укысам, икенчесендә көндезгедә укырга исәп бар.

Бай кызны бар байлыгы белән күтәреп утырткан икән әле тәрәзә төбенә Зөлфәт. Монда кеше берсенә керәмме, юкмы, дип баш вата, ә ул ике югары уку йортын йөгәнләмәкче.

Хәзер генә ныклап күз салды егет тәрәзә төбендәге кызга. Зәвык белән киенгән, биле өзелеп китәргә торган бу гүзәлгә ни кершән, ни иннек сыланмаган. Бу татар кызлары менә нинди була дип күрсәтерлек, Ходай бар уемын да җанны тетрәтерлек итеп иҗат иткән кызыкай иде. Бай кыз, юк, киемендә түгел байлыгы, кызара белә, зур житәкче кызы булса да саф татарча сөйләшә, битен-күзен буяп, табигый гүзәллеген имгәтмәгән чын милли кыз—туташ.

Кыз аның уйларын сиздеме:

– Кулга энекәшкә «Расих» дип үзем яздырдым. Әтинен аралашкан житәкчеләре гел яһүд тә урыс. Әле бер урыс дустын улы белән өйгә чакыра, жай ясап теге сары чәчле егет белән икебезне аулакта калдыра.

Танышсыннар, якынайсыннар, янәсе. Мина татар егетләре ошый. Шул эти инде. Әни минем яклы. Шул сары урысның бәбәгенә төртү өчен «Расих» дип яздырдым әле кулга. Расиха ул авылдагы әбиемнен исеме.

Рәхәтләнеп көлештеләр. Менә бит, дип уйлый Зөлфәт. Инде бу кызның бар әйберсе дә бар: акча дисенме, затлы кием дисенме, өйләре болын кадәрдер инде. Урыс ягына өстерәсә дә, хәтта, әтисе дә бар.

Зөлфәтнең акчасы да, затлы кием дә, олы өйләре, әтисе дә юк. Ә Ходай аларга Ленин укыган, Казанның гына түгел, СССРның дәрәжәле югары уку йортында — университетта бергәләп имтихан бирергә, укырга керүдә бер-берсенә көндәш булырга һәм тәрәзә төбендә аяк болгап, шайтан чакырып утырырга насыйп иткән.

– Кая, төш әле, салкын бит бу тәрәзә төбе.

Зөлфәт Казансуда юынып кайтырмын дип алган йомшак сөлгесен тәрәзә төбенә җәйде дә, кызны янадан күтәреп утыртты. Ай, нинди рәхмәтле күз карашы бүләк итте бу кыз аңа. Күзләрен бер-берсеннән ала алмыйча тәрәзәнең ике ягына икесе сөялеп утырдылар. Кыз кызарганнан-кызара барды, күзен күлмәк итәгенә төшерде. Аның күлмәге Зәңгәр Күз киеп кайткан күлмәк төсендә иде.

Эш нәрсә белән беткән булыр иде, консультациягә чакырдылар.

Кыз аның янына утырды. Аннан бәреп торган кайнарлык, хуш ис, күз яктылыгы, Зөлфәткә рәхәтлек бирә, ләкин укытучының сөйләгәнен тыңларга комачаулый иде. Ярый әле белгән әйберләрен сөйлиләр: исем дә фигыль, баш кисәкләр дә иярчен кисәкләр. Бай кызның иярчен кисәге булып китмәсә, ярый инде. Бу кызда түгел эш. Чибәр булганга ул гаепле мени, яки әтисе житәкче булганга, шәп киенсә ни булган?! Зөлфәт тә баш тартмас иде.

Кыз аның җиңеннән тартты. Такта янында лекция сөйләүче галим, аның тәрәзәгә карап утырганын эче пошып, әллә ничә тапкыр сөзәрдәй булып чекерәеп алган икән. Зөлфәт, «рәхмәт» — дигәндәй баш какты, кыз «ярар» — дигәнне аңлатып, керфек сирпеде.

Тәнәфестә кыз: «Әйдә, буфетка төшеп меник әле», — дип өстерәсә дә, Зөлфәт риза булмады. Ул шәһәр кызларына ярап булмас, чәнечке, пычак белән ашарга туры килер. Кесәдә акчасы да аз. Ә хатын-кыз хисабына ашарга горурлыгы рөхсәт итмәячәк.

– Ярар, алайса, сочинениедән «5»ле алган изгеләр ашамый икән, — диде дә өстәлгә башын куйды кыз. Сөйкемле йөзен Зөлфәт ягына борган да керфекләрен жемелдәтә генә бит.

– Ярар инде, — диде Зөлфәт, кызарганын тоеп. — Мин бит синен алда да сынау бирергә килмәгән. Алай карап торма, болай да йөрәк туктыйм-туктыйм дип сулкылдый монда. Берәр өтерме, фигыльме, тартык авазмы кысылса, ватылып та чыга.

– Менә анысы булмас, сөйләшүенне күптән тыңлыйм, мин — шагыйрь

дисән, гаҗәпләнмәячәкмен. Яшел күзле кешеләр талантлы була, ди, минем әни. Ә ул инде ялгышмый.

Сүз кая кадәр барып җитеп аяк салындырган булыр иде, лекция башланды.

Янында шундый чибәр кыз утырганда, июнь тәрәзәдән юкә ботагы сузганда кемнең туры һәм кыек иярчен җөмләләр турында тынлап утырасы килсен?! Тынласа да тынлады, тынламаса да тынлады Зөлфәт. Әле хәтта язып та барды. Язын бакчада эшләп көрәк, китмән, балта сабы кысып яссыланган бармаклар сыгылмалылыгын җуйган, нечкә ручканы тоймас хәлгә килгән иде. Аннан физкультура укытучылары ручканы юньләп кулга да алмый ич.

Кыек-мыек җөмләләр турында барган лекция уңышлы тәмамланды, адашмый гына тәнәфескә барып чыкты.

Укытучылар көчле, ахры, монда дигән фикер туа. Сеңдерәләр, малай. Көмеш Чишмә, Мамадыш мәктәбендә өйрәнгәннәр дә искә төшә. Күнелендә булганны уятып, уйлатып, егет белән кызларны имтиханга ныклап әзерлиләр. Сөйләүләре аңларлык, кабул итәрлек, әзерләнеп килгән кешегә шул җитә. Менә ул әзерләнмәде шул. Сөйләгәннәре бар да аңлашыла, җөмлә тикшерә дә белә, баш белән иярчен кисәкләрнең астына да сыза, анысы. Ләкин махсус әзерләнмәү, шикләнү һәрдаим борчып тора.

— Син дә кайтасыңмы, Зөлфәт, әйдә, бергә чыгабыз, — дип, Яшел Үзән кызы Гадилә аны ишек төбендә көтеп тора иде.

— Әйдә, — диде Зөлфәт.

Бу кыз белән коридордан барулары да бәйрәм. Аның җитезлекләре, аның адымнары. Мәрмәр баскычтан төшкәндә дә оста гармунчы телләрне өстән аска таба сыдырган кебек до-ре-ми-фа-соль-ля авазы чыгарып төшә инде, малай.

Зөлфәттә дә ак күлмәк, кара чалбар, затлы каеш. Узган-барганнар, көлешеп, яшьләгән ташкын сыман ыргылдырып килгән бу парга борылып карамыйча булдыра алмый. Егете папкасын хәтәр генә болгап, уйнатып килә, ә кыз аның артыннан тыр-тыр йөгерә. Үзләре нидер сөйләшәләр, лекция укыган укытучыларның кызык якларын хәтерләп көлешәләр, аларның әзерләнегез дип кисәтүләрен онытып, баскычлардан очып төштеләр, ишекне бәреп-атып сагындырган урам кочагына ташып чыктылар да, Гадилә икеөч бөтерелергә генә өлгерде.

— Их, Чистай урамына кадәр җәяү кайтсаң иде! — дип кычкырды егет.

— Кем белән кайтасың килә, Зөлфәт! — дип чытлыкланды Гадилә.

Зөлфәт күреп торды: алар килеп чыгуга юл кырыенда торган кара, күз явын алырдай «Волга» әкрен генә кымшанды да Гадилә янына килеп туктады. Рульдәге абзый, ашыгып төште дә, машинаның ян ишеген ачарга йөгерде.

Гадилә арткы утыргычка утырды да:

— Әйдә, Зөлфәт, Чистай урамы ягына кайтабыз, өенә кертеп үк китәр Гафур абый, — дип аңа кулын сузды.

Монысы ук кирәк түгел иде. Шофер абый әле ишеген япмаган. Бер яктан ялварулы-ягымлы караш белән Гадилә төбәлгән, икенче яктан әле генә бер бүлмәдә лекция тынлап чыккан унлап кыз нәрсә булыр микән дип, карап тора.

— Юк, рәхмәт. Яп, абзый, ишекне, миңа икенче якка, — дип әйтергә көч тапты Зөлфәт. Үзе, су тирәнлегеннән соңгы һавасын сулап бетереп чыккан, күкрәккә күкнең яртысын суырып алган водолаз шикелле, ухылдап куйды.

Машина кузгалып китте. Тәрәзәдән карап баручы Гадиләнең кояшы

сүнгән, ае баткан, күзендәге сагыш түгелсә, университет Иделгә агасы иде...

Әйткән ди аннары бу вакыйганың шаһите булган теге кызларның берсе:

– Егетнең тормозы тота, беркемнең дә олтаны булмаячак, үзе «Волга»ларда йөри торган кеше булачак. Бирмик килмешәк бай кызларына! – дигән.

Моны Зөлфәт каян белсен? Икенче көнне аудиториягә килеп өстәл артына утырды гына, бер кызыкай килде дә бирәсе имтихан турында нәрсәдер сораша башлады. Сорашу гына түгел, янында утырып калды. Бу Зөлфәткә күңелле генә, игътибарга мохтаж шул һәр җан иясе.

Ә Гадилә лекция башланыр алдыннан гына килде, алгы өстәлгә кунаклады. Тәнәфестә ике-өч кыз Зөлфәтне камап алдылар да тагын нәрсәдер сорашып, Гадилә белән күрештермәделәр. Хәзер инде аның янында икенче кыз утырып калды, чөнки аның белән сөйләшкәндә укытучы керде, чираттагы лекция башланды.

Өченче тәнәфестә тагын кызлар камалышында иде Зөлфәт. Бу хәтта аңа ошап та китте. Сорауларга җавап бирә-бирә имтиханга әзерләнә түгелме соң ул! Кызлар да үз белгәнен сөйли. Артистлар. Каян белсен Зөлфәт аларның Гадиләгә каршы заговор оештырганнарын? Кайсы кыз үзеннән матур киенгән, чибәррәк булган көндәшен өнәгәне бар?! Әле җитмәсә, тегесе кара «Волга»да килсә, кара «Волга»да китсә. Аны, Алланың кашка тәкәсе санап, көне буе бер эш эшләмичә, өрлектәй шоферы белән хөкүмәт машинасы көтеп торса. Кирә инде ул укырга, анысын беләбез. Ләкин Зөлфәтне аңа бирү юк, берәр кара машиналы кеше малаена кияүгә чыксын. Авыл егетләре безнең үзебездән дә артмый, беребез дә кияүгә чыкмаган ич, дигәннәр кызлар. Имтиханда барыбызны да мәтәлтә алмаслар әле, кайсыбызга булса да булыр теге чибәр, башлы егет, ләкин Гадиләгә түгел, дигән кызларның атаманы Камилова.

Өч тәнәфестән соң гына очраштылар. Гадилә теге тәрәзә төбендә аны көтеп тора иде.

– Нихәл, Зөлфәт? – диде ул. Бүтән бер сүз дә әйтмәде.

Берни булмагандай, җитез генә килде дә Зөлфәт, кызны тәрәзә төбенә күтәреп утыртты. Кып-кызыл булган кыз шуннан ачылды да китте. Яңадан кичәге Гадиләгә әйләнде дә куйды. Очынып сөйләшә. Нәрсә такылдаганын абайлый микән, юк микән?

– Мин бүген монда килгәндә Урман аръягы авылында каенлык күрдем. Бер бүтән агач юк, шундагы каеннарга тотынып әйләнгәләп йөрсән иде, – ди. – Башкалага дистәләрчә тапкыр килеп тә бер дә игътибар итмәгәнне, нәрсә булды микән мин юләркәйгә? – дип күкрәгенә матур куллары белән кагылып ала. Бу кызның мәхәббәт аңлатуы булгандыр.

Сизде Зөлфәт. Ләкин нәрсә дип җавап бирсен инде ул аңа?! Хат алыша торган кызым бар, дисенме? Без синең белән пар түгел. Синең райкомың да, әтиең дә бар. Ә минем райкомым түгел, әтием дә юк, дисенме? Аннан, алай рәхимсез була алмый бит инде Зөлфәт. Гадиләнең укырга керәсе билгеледер. Беренчедән, кыз төпле белемле, сөйләшүе килешле, имтихан биргәндә кызларның чибәрлеге, бигрәк тә һәрдаим кояш төшеп торучы тезләре, сукылдап торучы күкрәкләрендә уянган хушбуй исләрен әләктереп ир-ат укытучылар җанына китереп бәрә дә имтихан алучы исемлеккә ничәле куйганын да абайламый. Җанында ничә баллы тетрәү була – шуны куя инде, кая барсын? Ул бит синең доцент, профессорыңа карап тормый. Аннан бер-берсеннән, фәненнән, өйдә мыжгылдаучы хатыныннан туйган ир чәчрәп торган милли татар кызларын, аларның ин булдыклыларын күргәч, ни өчен җанын сыгылдырмасын да, аңын җуеп егылмасын һәм, гел «5»ле, «4»ле генә куймасын, ди. Кайда язылган ул?

Гадиләдә барысы да бар. Бизәнмәгән, имгәтелмәгән, зыялы гүзәллек. Аннан ул бит көндезге уку йортына да керә ала, дәрәҗәле, акчалы һөнәр бирә торган, житәкчеләр әзерли торганына да. Кабат монысын, бәлки, ташлар да. Укырга кергән исәптә алар елга ике тапкыр гына: җәен утыз, кышын ун көнлек сессияләрдә очрашачаклар. Юк, канатын сындырырга ярамый кызыкайның. Өендә дә рәт юк икән шул бичарага: әтисе урыска кодалый. Алтын читлектәге кош булмагае...

Лекциягә кереп баручы укытучыны күрүгә Гадиләне тәрәзә төбеннән очыртып төшерде Зөлфәт. Иң арткы өстәлгә кереп утырдылар. Егетнең дәфтәре, ручкасы алда калган иде. Элек янәшәдә утырган кызый борылып чакырды да.

— Ярар инде, — дип, кул селтәде Зөлфәт.

Ә кызый аңа ручка һәм дәфтәренең уртасыннан суырып алып, ике кушбит кәгазь бирде дә, «Гадиләдән—Зөлфәткә» дип язды. Әйе, язмышның ике исем арасына бер текә сызык сызасы калды.

— Автобус белән килдем. Әти белән ачуланыштык. Гафур абый синең турыда әйткәнме, әллә әти үзенчә аңлаганмы, сүз зурдан булды.

— Синең сары салам белән ябылган чиркәвең кирәк түгел, Горький заводы каршына бастырып куй да чукынсыннар шул малаеңа карап, — дигәнмен. Кирәк бит, ә, гаиләбездә булмаган хәл. Әни, мескен, ул авыл кызы, дини, абыстайда сабак алган хатын, мине дә кызгана, шәригать буенча ирнең хакы да бик олы шул, кызым, ди. Менә үзең уйла инде, Зөлфәт. Әтием ил күләмендә әһәмиятле районда секретарь булып эшләсен дип, Мәскәүдә Ваняларның зур кешеләре бар дип, Ваняга аяк чолгавы булыйммы? — Гаҗәп кызганыч, мескен иде ул бу мизгелдә.

...Зеленодольскига автобуслар тимер юл вокзалыннан китә икән. Очы һәм ботаклары кыркылган, яңа яфраклар җибәргән түгәрәк агач янында гөрләшеп торган парны күреп күпләр көнләшерлек иде.

— Иртәгә киләсемне дә белмим. Еракка олактырам мин сине, барыбер кеше ясыйм мин синнән, рәхәттә яшәрсең, ди әти. Ничек рәхәттә яшим инде мин Ваня белән. Менә синең белән... — дип авыз ачкан иде Гадилә, автобус килеп тә туктады. Чиләкләр, кечкенә бидоннар күтәргән базарчылар килеп бөгелде һәм ишекне яулый башлады.

— Их, Зөлфәт, — диде Гадилә. Аның тавышында елыйсыны китерә торган, җанны телә торган үкенеч бар иде.

Ул кисәк кенә: «Билемнән тот әле», — диде. Зөлфәт, аны биленнән алып үзенә якынайтуга, кочаклап та алды Гадилә, суырып та үпте, кып-кызыл булып тукталышка йөгерде. Ишектән килеп тә керде, автобус кузгалып та китте...

Ул Гадиләне кабат беркайчан да очратмады. Ә гомер буе күрәсе килде ул зыялы, хисле, гаҗәп тә кызганыч кызыкайны.

Күнелгә Казан зурлыгындагы ташны салып, Гадиләнең аңа томырылып караган күзләрен хәтерләп, иләс-миләс кайтты да апасының бакчасына чыкты, эшкәртелми калган җирне ярсып казырга кереште. Ике сәгать эчендә казып, тырмалап бетергәч кенә апасы кайтты да, эшне күргәч ах итте: «Менә ул безнең нәсел...», — дип такмаклый башлады.

Татар теленнән дә «5»ле алды. Әдәбияттан да «5»ле эләктерде. Нил абыйсы сынауны үзе алды әдәбияттан, язучыларның иҗатын чагыштыруны таләп иткән сораулар бирә дә, дөрес җавап алгач, бераз тын гына утыра. Җавап бирүчегә бер дә комачауламый, кысылмый, акыллы гына, сабыр гына, Зөлфәтнең әнисе җиз иләктә он иләгән кебек, или инде.

Ярата үз фәнен белгән кешене Зөлфәт. Белгән кеше бит ул һәр әйбернең үзәген, мәгънәсен тоя да, юк-бар сорау белән сине таламый.

Нил Гафурович та, тимерче бәләкәй чүкеч белән кызган тимерне нәкъ кирәкле жиренә китереп суккан кебек, мәгънәле соравын чекелдәтә, аннан олы кувалдасын күтәреп Зөлфәт орырга тиеш. Нәкъ ул күрсәткән урынга. Сукты Зөлфәт, дөрес сукты, ахрысы. Нил абыйсы аның белән әллә иркенләбрәк тә утырды инде, гаиләләренә кадәр сорашып бетерде. «Шәйхи ага Маннурның туган жиреннән син, язганнарынны күргәнем бар, өмет бар синдә!» — диде Нил абыйсы. Моннан да зур бәя буламы авыл малаена?!

***

Нил абыйсының аның турында энесе Илдар белән сүз кузгатканын Зөлфәт белми иде, билгеле. Ә Илдар Юзеев әйткән: энесе Илсур да, үзе дә «Ялкын» конкурсларында жинделәр, берничә битле китапчыклары да чыкты. Матбугатта да күренәләр, ятим малайлар, дигән.

Рус теленнән диктантны да «5» легә язган Зөлфәтнен шатлыгы зур. Ә Шәмсегаләм апасы аны да уздырып куана. Өенә кем генә кермәсен: «Менә авылдан энем килде, университетка керергә. Шуннан «5» ле, моннан «5»ле, тегеннән «5» ле. Безнең нәсел ул, каракайлар, чибәрләр...» дип, гел бер монологны сөйли. Бу Зөлфәтнең шактый тетрәнүләр кичергән жанына жәйнең чилләсендә эчкән салкын әйрән кебек рәхәтлек бирә.

***

Апасына иксез-чиксез рәхмәтләр әйтеп, эшләрендә булышып, зур эшләр майтарып өйгә кузгалды Зөлфәт. Автовокзалга төшеп билет алды да, очлы борынлы Мамадыш автобусына кереп утырды.

Сикертмәле таш юлга автобусның арткы саны дөбер-шатыр бәрелә дә коточкыч тавыш чыга. Салон эчендә авызга-борынга тузан тула, китә төчкерү-төкеренү, көлешү, сукрану. Теләчедә автобус туктап хәл алды. Юлчылар ашханәгә кереп капкалап та чыктылар. Казан–Мамадыш маршрутының нәкъ ярты юлы иде. Инде өч сәгать кайттылар, әле дүрт сәгать кайтасы бар, үтәсе юл тагын да начаррак. Автобус, давыл вакытында өзелмәскә тартышкан кораб сыман, чайкала, төчкерә, зарлана, ыңгыраша...

Менә, ниһаять, ул да кайтып житте! Автобустан төште. Урманчы Хәбиргә һәйкәл булып яшәүче каенлык, яфракларын лепердәтеп, аны сәламли иде. Шәкерт кайта, югары уку йорты шәкерте, әле вузның нинди бит! Казыган тауга да элдертте Зөлфәт, тау башына утырып туган авылына күз салды. Кайдадыр мотор гөрелди. Күктә, якында гына, тургай сайрый. Ниндидер таныш моң ишетеп таудан үрелеп карады. Әйе, ике йөзләп чишмәсе булса да, ул биш чишмәнең тавышын яхшы аера. Берсе гомер буе суын эчкән Чегән чишмәсе, икенчесе Сабан туе мәйданын кочагына кысып челтерәүче Бакырчы булса, өченчесе Таз Минни тавы каршындагы житмеш-сиксән метр озынлыктагы тоташ чишмә оркестры тәшкил иткән агып ята торган тау, дүртенчесе моннан алдагы жәйдә ике ай буе Зәңгәр Күз белән тыңлаган Трайт булса, бишенчесе биек тау башында утыручы Зөлфәтнең жанына да орынырга дәрте житкән Алмагач чишмәсе иде. И, агып та күрсәтә инде ул Алмагач чишмәсе! Көтүчеләр аның суына манып ипи ашый. Югыйсә, биштәрдә сөт тә бар. Хикмәте шул: чишмә суында ипи баллана, авызны гына түгел, жанны сихәтләндереп салкыная. Ләкин ипиенне, күз ачып йомган арада гына тыгып алмасаң, шаулап, ургылып төшкән су кылычы өзеп ала да балыкларга ризык итә. Ни салкын бит чишмә суы, ә балыклар шунда кайнаша. Без белмәгән хикмәте бардыр Алмагач чишмәсенең. Зөлфәтнең кайтканын күз кырые беләнме, кояшка сикергән тамчысы беләнме күреп алган да сәлам бирә. Юк, ул моннан күренми икән, инеш ярына оялаган карлыгачлары житкергәндер.

«Сәлам, Алмагач чишмәсе! Дөньялыкта белепме-белмиме кылган гөнаһларымны кичер, аның җәзасын булачак балаларыма, оныкларыма калдырма, Аллам», — дип битен сыпырды Зөлфәт.

Казыган таудан йөгереп төште егет, Сәләхи тавына йөгереп менде. Сәләхи кабере бу тауны мәңге саклаячак. Ул кеше Мамадыш базарында күмер саткан, кесәсендә дулаган сыер кебек шашынган акчасына аракы алып чыккан. Әз эчкәнме, әллә күбрәк кителгәнме, әллә Казыган таудан төшкәндә аты чыгымчылаганмы, Сәләхине инешкә капланган килеш тапканнар. Дин кочле, шәригатькә таянган сүз закон булган, аны зиратка күмдермәгәннәр. Тауга җирләгәннәр. Бер уйласаң, гаепләнгән, башкаларга гыйбрәт өчен кылган гамәл. Икенчедән, зурлаганнар булып чыга түгелме?! Ул елларда күмелгән кешеләрдән хәзер кемнең генә кабере билгеле?! Ә Сәләхи каберен бар да белә, хәтта ул күмелгән тауга да аның исеме бирелгән.

Хәзер инде аның эчеп, инешкә капланып үлгәнен дә белүче аз, кызыксынучы да юк. Җир-Анага без барыбыз да баладыр, дип авыр сулады Зөлфәт. Әллә таудан ашкынып менү сулышына капты, әллә авылдашы Сәләхинең фаҗигасе җанына тидеме? Ул үлгән, ләкин аның кайтуын зарыгып көтүче әнисе, хатыны, балалары калгандыр...

Менә, ниһаять, Зәңгәр Күз белән дөньяны тыңлап, чишмәләрнең җырын җанга җыеп атлаган дымлы сукмак...

***

Сөенече эченә сыймаган әнисеннән бераз эләкте Зөлфәткә, бүген икеле алсам, кайтып китәм, икенче имтиханнан соң озаталар, дип уйлап хат язуны искә дә алмаган шул. Әй, сөенде инде энесе Илсур. Ул да Мамадыш урта мәктәбенен тугызынчы сыйныфын тәмамлады. Инженер-физик булам, ди. Университетка керәм, ди.

Рәхәт бит ул туган авылыңда! Сөйләшәм дисәң, сүзе аякка уралып йөри, күрешәм дисәң, әллә ничә кул сузыла, үбешәм дисәң... Анысы да табылыр иде, кызлар бөгә бөгәрлек, дип әйтергә ярата авыл егетләре.

***

...Беренче сентябрьнең кыңгырау бәйрәме күнелләрне җилкетте дә, яна уку елына алып та кереп китте. Аның сыйныфындагы малайлар-кызлар сизелерек калыккан, кояшта каралган һәм тәртипләре дә җәйгечә, күбәләкчә иде. Тик шулай да тормыш җайлы бара, инде бер ел буе дус-тату яшәделәр. Житмәсә, быел алар бергәләп колхоз басуына бәрәңге чүпләргә дә чыгасы.

Юк, абыйлары алар белән бәрәңге чүпләргә чыга алмады. Аны Казанга чакырып алдылар, университетка кабул ителгән егет һәм кызларга иң беренче вәгазьләрне житкерергә, уку, эшләү тәртибен аңлату өчен җыйдылар. Бик бәхетле чагы иде Зөлфәтнең. Авылда күпме гайбәт йөрде бит аның укырга керү-кермәве турында.

Егетләр күп түгел. Балык Бистәсеннән Раиф, Балтачтан Рәфыйк, Арчадан Радик, Төмәннән Илдус, Чүпрәледән Рәшит һәм Харис. Кызлар күп инде, анысы. Гадилә генә күренми. Ике атна буе университетта укыдылар. Кышкы сессиядә имтихан, зачет бирәсе фәннәрдән лекция тыңладылар. Мөхәммәт Мәһдиев тә үз фәненнән сораулар бирде, фольклор буенча кыш көне зачетмы шунда... Сораулар бирде дә икенче көнне лекциягә керде:

— Кемнәрдә мин биргән әйберләр буенча сорау бар? — диде.

Авыл оялчанлыгы баскан малайлар-кызлар бу чибәр кеше алдында тагын да бөкрәйде, үзләре дә сорау билгесенә әйләнде. Аудитория озак кына тик торды.

— Сау булыгыз!

Мөхәммәт Мәһдиев портфелен күтәреп чыгып та китте. Ул каядыр ашыккандыр... Ә алар... авыз ачып калдылар. Бу — чираттагы сабак иде. Сораганны-төпченгәнне, димәк, үз фәне белән кызыксынганны яраталар икән монда, нәкъ авыл мәктәбендәге кебек.

Өченче тапкыр да керде Мөхәммәт абыйлары. Фольклордан лекция укыды. Лекция башыннан мәзәк сөйләп, жыр такмаклап, бәет көйләп кереп китте. Соңгы мәзәген сөйләп ишектән чыгып киткәч тә әле алар көлә, шаркылдый иделәр. Бар икән кешеләр! Бай икән ул безнең халыкның фольклоры!

Рәшит белән боткалары пешә Зөлфәтнең. Аның Нагорный бистәсендәге милиционер абыйсына кунакка бардылар, су коендылар, көймәдә йөрделәр, фотога төштеләр.

Зөлфәтнең Равил абыйсы фатирына да бергәләп бардылар. Кешеләрне үзенә җәлеп итү, житезлек омтылышы бар иде бу егеттә. Аннан ул Зөлфәткә Чүпрәледән, Балтачтан, Арчадан хат та язачак әле.

Яшьлек! Ленин укыган университетны айкап йөрисең син! Горурлык та, нишләп без дә укымаска тиеш әле туган жирдәге бу мәртәбәле ак бинада, дип тә уйлатасың.

Алар инде профессорлар Диләрә Тумашева, Хатип Госман, Мөхәммәт Гайнуллинны да белә.

Алга таба искиткеч белемле, күренекле тәнкыйтьче, сугыш инвалиды Ибраһим ага Нуруллин, доцент Нил Юзиев, Зәет Мәжитов, Флера Сафиуллина да лекция укыр. Аларны иярчен жөмләләр, туры һәм кыек сөйләм белән җәфаларлар. Ләкин туган тел, әдәбият серләренә ишек ачылыр.

Рәшит белән университет китапханәсенә дә еш керерләр. Ленин исемен йөрткән, мәгарәле үзәк китапханәгә дә. Нәрсәдәндер тыела алмыйча көлә башлагач, әле аларны уку залыннан куып та чыгарырлар, чарасызлыктан үзләре чыгып йөгерер.

Китте шуннан имтиханнарга әзерләнү өчен китаплар алу, ташу. Китапханәара абонемент аша Нурфига апага кайтартып, имтихан, зачетларга әзерләнү, әдәбияты гына да ничә төрле икән бит. Беренчедән борынгы заман, урта гасырлар, дипме китә шунда. Хәтта бер гасырны эченә алганнары да бар. Мәсәлән, унтугызынчы гасыр әдәбияты. Татар әдәбияты, рус әдәбияты, совет әдәбияты, СССР халыклары әдәбияты, көнбатыш, көнчыгыш, Америка һәм дә Латин Америкасы, Азия-Африка халыклары әдәбияты. Проза, поэзия, драматургия, тәнкыйть, халык-авыз ижаты һәм башкалар. Бу әле бер әдәбият кына. Язмасы бар әдәбиятның, телдән-телгә йөргәне бар икән. Башта барысы да бик куркытты. Рәшит кенә беркайчан да төшенкелеккә бирелмәде:

—Кимерәбез аны! — диде.

Һәм ул әйткәнчә булды да.

Бер чемодан китап алып кайтты Зөлфәт.

Кышкы сессия буласы гыйнвар ае хәзер килеп житә ул. Ике контроль эш жибәрәсе, имтиханнар, зачетка әзерләнәсе бар. Контроль эшләрнең жибәрү вакыты билгеле, китапханәче Нурфыйга апасы белән, исемлекләрне барлап, Казанга кирәкле китапларга сорау да жибәрделәр. Өч ай эчендә кайчан аласың, укыйсың, кайчан кире жибәрәсең әле. Китаплары әллә киләләр, әллә юк. Зөлфәт көндәлек яшәү тәртибе кертте. Элеккедән дә кырысланды, хәзер инде шимбә көнне генә клубка чыга, кичке уен булганда гына. Киногa да менми. Көнгә өч тапкыр йөгерүен ташламады, анысы мәжбүри.

Китте шуннан. Аны, югары уку йортында укучы дип, кайбер

вазифалардан азат иттеләр. Һай ул мәктәпнең бетмәс-төкәнмәс эшләре! Чаңгы командасын шөгыльләндерүләр. Ярый әле җинел гәүдәле, очып кына йөри, вакытны дөрес бүлә. Өйдә дә берүзе бит, әнисе юлда йөри. Житмәсә, энесе Мамадышта укый.

Зәңгәр Күздән хатлар агыла гына, сагынуы ташып тора. Япон җырын җырлап бәйгедә дә җиңгән. Япон җырын җырлап йөрсә, Япониягә дә алып китерләр әле. Бигрәкләр дә чибәр инде ул кызыкай! Аны күрмәгәнгә дә ел ярым вакыт узган...

***

Укырга чакыру килде. Арыган иде инде аны көтеп студент. Исемлектәге бер китапны калдырмады, укыды. Сорап язган китаплары да килде, Нурфига апасына рәхмәт. Ике контроль эш тә вакытында җибәрелде. Яңа ел бәйрәмен яхшылап үткәрделәр дә Казанга китеп барды.

Биштәрендәге ит, май, каймак та кеше күтәрә алмаслык иде. Шуның өстенә күпме китап, дәфтәр, кием һәм дә яшәр өчен кирәкле вак-төяк.

Сагынышканнар бер-берсен беренче курслар. Егетләр гел бергә. Түбәннән, аксап-туксап булса да, Илдус абыйсы килеп җиткән. Бик тә староста булырга омтылучы Харис та күренә. Мишәр малае, кыю, үзе белмәгәнне дә авыз тутырып сөйләшә, очлап чыга алмыйча буталып кала. Без — милләтнең каймагы, дип тә җибәргәли.

Фонетика буенча беренче имтиханнан ук, авазларны дөрес әйтмәгәнгә, Харисны куып та чыгардылар. Юашланды малаең. Зөлфәт белән Рәшит янында сырпаланып йөри хәзер. Бигрәк тә Зөлфәткә сылана, чөнки ул барсын да укыган, бөтен билетка да җавабы әзер. Лекция вакытында укытучылар куйган сораулар да аны куркытмый. Кызлар, нәрсә булса да, аннан килеп сорыйлар.

Зөлфәтне гаҗәпләндергәне шул: контроль эшләрне җибәрсә дә, әдәбияттан хәзерлексез иде Рәшит. Үзе: «Район гәҗитендә эшләвем сәбәпле, бер дә укып булмый, гел юлда», — дип зарлана.

Раифны имтиханга кертмәделәр, чөнки ул контроль эшен тапшырмаган. Хәйләсен тапты тагын. Зөлфәт белән икесенең дә фамилияләре бер. Иң башта мин керим әле, малай, дип сорый да кереп имтихан биреп чыга, берзаман Зөлфәт керә.

— Сезне имтиханга кертмим, — ди укытучы, — сезнең контроль эшегез тапшырылмаган.

— Тапшырылган, менә рецензиясе, — дип Зөлфәт зачеткасы эчендәге кәгазьне алып күрсәтә.

Ә Раифнын инде зачеткасына да, ведомостька да билге куелган. Эш хутта, койрык сыртта дигәндәй.

Хәзерләнеп баргач бик җиңел була икән ул сессия. Укытучылар бик белемле һәм шуңа күрә таләпчән дә. Сессияне бик яхшы тапшырып, җәйгесенә сораулар, контроль эшләр алды, элеккесеннән дә күбрәк китап төяде, күпмесендер почта аша үз исеменә посылка итеп салды. Мамадышка самолетта очарга исәбе.

***

Тагын атнаның биш көнендә дәресләр, класстан тыш эшләр башланды. Зөлфәт арыган, ләкин укучыларын бик сагынган икән. Беренче сессияне түгәрәкләп кайту аңа көч биргәндер.

Яшь чак, ул ару-талуны белми, күктән йолдыз чүпләгән мизгел.

Җыр укыта бит әле. Дөньяны начар якка ияртеп китмәслек кенә җырлый да. Ләкин гармун уйнавы ташка үлчим. Кирәк булгач шыңгырдата

инде. Дәресләр ярыйсы гына бара. Уйный да, жырлап та күрсәтә. Бер көнне дәрескә завуч керде. Кермәсә дә ярар иде дә. Белә бит инде белгеч түгеллеген.

Укучылар жырның сүзләрен дә ятлаган, чартлатып сөйләп тә бирделәр, бергәләп жырлап та алдылар. Әйбәт чыга. Зөлфәтнен кәефе күтәрелеп китте. Ләкин завучның дәрестә утыруы үтерә иде.

Яна жырның сүзләрен язып өйрәтә башлагач, каушау үзенекен итте. Үзе жырлап күрсәтте, булдыра. Менә ул уйнау өчен кулына гармун алды. Каешын киде дә беренче телне таба алмыйча интекте. Уйнаганда гармун телләрен бутап бетерде. Завуч кычкырып көлеп жибәрде. Ана укучылар кушылды.

Үтерде бу дәрес Зөлфәтне.

Мәктәпкә яна укытучы килде. Институт бетермәгән, беркайда да укымаган, әле армиядән генә кайткан егет. Солдат киеменнән йөри һәм мәктәптә армия тәртипләре кертә башлады, чөнки әле ул муштрадан айнымаган иде. Малайлар тәртипле, ләкин Гәлләм абыйлары бик таләпчән иде шул, хәтта арттырып та жибәрә.

Тәртип бозган малайларга, бигрәк тә ис кереп, кызлар итәгенә күз төшеп чәч үстерүчеләргә авыр көннәр килде. Математик, әз генә гаебе булса да, егет кисәген эләктереп ала да, чәченә маңгайдан баш түбәсенә кадәр машинка белән юл ясый. Бу бер ел шома гына барды. Укытучыларның кайберсе Гәлләмнең мондый кыланышларын яклый, кайсы көлә генә. Ә Зөлфәт каршы чыкты, Гәлләмнең үзенә дә әйтте. Идән юдырырга дәрестән соң алып калсын, ди инде, ә һәрдаим чәче белән горурланып йөрүче үсмерне ни өчен шулай хур итәргә? Матур булырга тырышу начармыни?! Кызларга игътибар итә башлаган егетләр әйбәт укый, тәртипле була. Бар яктан да матуррак күренергә тырыша.

Беренче бәрелеш Зөлфәт классында булды. Беркөнне укытучылар бүлмәсен шакыдылар. Ишеккә барса – Нурулла:

– Абый! Класска керегез әле, анда Гәлләм абый белән Миннәхмәт сугыша... – ди.

Йөгерделәр коридор буйлап. Класста ике-өч кенә малай калган. Кызлар кая киткәндер? Гәлләмнең бер кулында чәч алу машинкасы, икенче кулы белән Миннәхмәтне буып тоткан. Ничек тә булса малайның башына машинка белән пеләш ясамакчы, ләкин Миннәхмәт бик каты каршылык күрсәтә, математик берни дә майтара алмый.

Зөлфәт йөгереп килеп Миннәхмәтне туктатырга, тәртипкә китерергә маташса да, үзе кебек ятим үскән, гаделлекне яратучы бу малайның хаклы икәнен тоя. Житмәсә, укытучы яклы да булырга кирәк бит әле. Ким куеп, ничек аерасы боларны?! Парталар кыегаеп, бүлмә уртасында мәйдан ясалган.

– Миннәхмәт, бу нишләвең? Туктыйсыңмы, юкмы?! – дип кычкырган класс житәкчесенә малай:

– Абый, бөтен сүзегезне тыңлыйм, ачуланмагыз, ләкин хәзер тыңламыйм! – дип кычкырды.

Аның зәңгәр күзендәге нәфрәтне күреп, Зөлфәт шаккатты.

Аерып булмый, Гәлләм белән Миннәхмәт идәндә тәгәриләр. Кинәт Миннәхмәт Гәлләм кулыннан чәч алу машинкасын суырып алды, математикның үзен читкә быргыды да машинканы стенага шундый көч белән бәрде, машинка бүрәнәдән атылып класс тактасын тиште дә шунда эләгеп калды. Ә Миннәхмәт чыгып йөгерде.

Алла саклады инде. Кешегә эләксә, үтерә иде, дип уйлады Зөлфәт. Шушы вакыйгадан соң мәктәптә маңгайга пеләш ясау туктады.

***

Читтән торып укуны «бетле тун» — дип дөрес әйтәләр икән. Янадан контроль эшләр эшлисе, Казаннан китаплар кайтарасы, аларны укыйсы, истә калсын өчен дәфтәргә эчтәлекләрен язасы бар. Бу кирәкле, ләкин газаплы эш. Дөнья әдәбияты океанына керә бара Зөлфәт. Әйбәт язучылар бар, әле бит ул аларны русча укый, тәрҗемәдә. Үз телләрендә укыса, гел икенче булыр иде.

Менә энесе дә мәктәп бетерә, аның укырга керәсе бар. Шәп укый, керер, Алла боерса. Абыйсының бурычы инде аны укыту.

Тагын сессия якынлаша. Килсен, әйдә. Ул атнага ике көн ял итә. Бер көн ял аңа укыган өчен бирелә, әзерләнеп бетә, җитешә. Шимбә көнне генә клубка чыга. Үзен бик кырыс шартларда яшәтә Зөлфәт. Укыйсы, кеше буласы бар, нихәл итәсең.

Эштә тәртип, чаңгы командасы өч тапкыр район ярышына барды, өчесендә дә җиңде. Нурулла ике километрлы дистанциядә чемпион булды. Шунысы гына да ни тора! Үзе фанатикларча шөгыльләнгәч, җаны-тәне белән спортны тойгач, чаңгычыларны ничек әзерлисен белә.

Әле көмешчишмәлеләр белән ярышырлык мәктәп командасы юк районда, шәһәр мәктәпләре дә, хәтта, спортчыларны сайлап алу мөмкинлекләре бик зур булса да, даими җиңеләләр. Күрсәткечләре түбән.

***

Май бәйрәмнәре якынлаша. Әй, Зөлфәтләр укыганда кызык уза иде ул бәйрәмнәр: алар мәктәп янында дүрт кешелек колоннага тезеләләр, байраклар, кәгазьгә, ситсыга язылган чакырулар күтәргәннәр. Шарлар тотып авыл урамын әйләнәләр. Колонна башында бер кулына кызыл папка тоткан Салих абыйлары. Үзе озын, үзе таза!

Бәйрәм тантанасыннан дәртләнгән директор эре атлый, вакыт-вакыт, укучыларны артта калдыра. Кинәт дәһшәтле тавыш белән кычкырып җибәрә:

— Яшәсен Беренче май — Бөтендөнья хезмәт ияләренең бердәмлеге көне! Ура-а!

Укучылар:

— Ур-ра! Ур-ра! Ур-ра! — диләр дәррәү.

Арттан баручы башлангычлар тыр-тыр йөгерсә дә, җитешә алмый. Ә директор шулкадәр дәртле, ул бернәрсәне дә абайламый. Авылны ду китереп, бәйрәм тантанасына күмеп, урамнарны шаулатып әйләнеп кайталар.

Һавада чыр-чу, шатлык бәргәләнә. Мәктәпнең тынчу һавасында гомерләрен уздыручы укытучылар да рәхәткә чыккан. Монда инде түштәге берәр сәдәфне дә ычкындырып җибәрергә була. Сүз дә юк. Директор, завуч ишетә күрмәсен, дип тә куркасы юк.

***

Зөлфәткә университеттан түләүле чакыру килде. Димәк, контроль эшләр уңай бәяләнгән. Ул инде, нигездә, матур әдәбият китапларын, дәреслекләрне укыды. Берничә махсус басманы Ленин китапханәсеннән алып карыйсы бар. Анысы инде сессия барышында.

Ял акчалары алып, өйдәге эшләрне караштырып китәргә исәбе. Быел энекәше дә урта мәктәпне бетерә. Алтын медаль алыр микән, әллә көмешнеме?

— Кайгырма! — диде ул энесенә. — Сау бул да, бар бул!

Быел Зәңгәр Күз дә урта мәктәпне бетерә, кая укырга керим икән дип баш вата. Зөлфәт кебек бер ел ял итәм, әбиләргә кайтам, дигән хаты килгән иде. Нәкъ Зөлфәт сессиясен бетереп Казаннан кайткан чорга, печән өстенә туры килмәгәе.

***

Ә бүген Көмеш Чишмәдә яулык жыялар. Авыл тулы кунак. Ул кызларның кара чәчлесе дә, сары чәчлесе дә житәрлек. Шәһәр кызлары бит алар, зәвыклы. Бар кимчелеген яшерә белә, затлырак киенә. Авылга күзгә-башка чалынмаган киемнәр киеп кайта. Авыр эштән изелмәгән, биленең нечкәлеген, кашының кыйгачлыгын көнәнә кырык тапкыр көзгедән тикшереп торучы чибәркәйләр.

Авылның Түбән очында да, Югары очында да тальян тавышы янгырый.

Сукыр урамда, капка төбендәге утыргычка чүмәшкән дә, Куян Хөсәене тальянны ялкау гына тарта, ләкин көе ургылып чыга, жырлап та жибәрә:

Зәңгәр күлмәкләрнең иң зәңгәрен
Жилләр ала, жилләр тарата,
Яшьлек бит ул, дустым, шуны онытмагыз,
Ул саф йөрәкләрне ярата.

Куяннарның нәсел ишле, баласы-чагасы, кодасы-кодагые, дисеңме. Хатынының абыйсы Гыйлажетдин дә шунда. Үзе бер Сабан туе. Аннан ике өйне генә узасың.

Болыннан яна чабып алып кайтылган печән ишегалдына кочак-кочак итеп таратып куелган. Анда тукранбаш, чыпчык башы кадәр жир жиләге. Печәнле арбага кожаның жәеп куйган да, Масупа Ибрае да тальян сыздыра. Моңлана:

Абыкаем, син икәнсең
Күрмәдем килгәнеңне,
Кара төннәргә охшатам
Аерылган көннәремне.
Без андый малай түгел,
Без мондый малай түгел,
Кая барсак та ярыйбыз
Күгәргән калай түгел.

Шулай кая барса да яраган, фашистларны жинеп кайткан фронтовик жиффәрә, хирурглар пычак белән тураклап бетергән эченен кай төшедер чәнчүенә дә карамый, көне шундый!

Ибраһим абыйдан бер бакча кинлеге атла да, тыкрыктан Кулаклар урамына мен.

Әнисләр, бөтнекләр үскән ишегалдында 17 яшеннән сугышка киткән, пулемет күтәреп йөргән Барый абый моңлана. Үзе өчен генә булса да, ул да жырлый:

Әй кара каш, кара күз.
Әйтмим, жаныем, авыр сүз.

Барый абыйның орынып торган күршесе Миргазиз абый хромкала сиптерә. Кызган.

Уфа юллары пыяла,
Таш булса, таймас иде,
Яна минем йөрәккәем,
Син булсаң, янмас иде.

Ул да фронтовик. Бүген ачылмалы тәрәзәсен үтеп барган һәр кеше саен ача, бер-ике сүз әйтүгә яба, аннан тагын шулай.

Кулаклар урамынын Норма авылы очында Минегаяз абый, аны авыл халкы Мыягаз дип йөртә, озын көйләрне сыздыра, гел зиратка карап уйный. Хәле авыр, каты яраланып кайткан кеше. Ә зират күзенә кереп, чекерәеп тора.

Аннан ике генә өй өскә менсәң, Куян Сәхие малае Миннәхмәт баян сыздыра, монысы инде уйный да, менә дигән итеп җырлый да! Моңлы егет, бәхете булыр микән?!

Аю Гаяннары урамында тумыштан сукыр егет, авылның искиткеч талантлы гармунчысы Зөфәр абый Закиров репетиция ясый. Кулына баянын ала да җырлап җибәрә:

Без үзебез таз идек,
Әстерханга баш идек,
Алты хатын, җиде кызның
Күз өстендә каш идек.

Яке урамында Хәсбәтулла абый уйный, Сәлах Миннулласы бии. Аннан Яхин Рәхимулла гармун сыздырып җибәрә. Күршеләре, клуб мөдире Хәсәнов Вәккәс абый баянын алып килгән, алдына сала торган бәрхет җәймәсен дә калдырмаган. Ул инде кыяфәтенә китереп:

Кая гына китеп кайларга бармадым,

Сагынып кайттым Иделем таңнарын... — дип сыза. Үзе чибәр, үзе сөйкемле, чын сәнгать кешесе инде. Хәтер генә чамалы. Мамадышка барасы булса, бармакларына гел җеп бәйли хатыны Нурфига апа. Бүтәнчә оныта Вәккәскәе.

Бераз өскәрәк менсәң, юкә төбендә Әскәров Нурислам уйный, ул җырламый, ләкин көйнең коесына төшә инде.

Менә Аю Мөгътәсе дә гармунчы булган. Сугышта кулын калдырып кайткан, әле шул килеш тә, йөрәген басу өчен, көрәшкә чыгып газаплый. Элек көрәшче булгач, нишләсен?!

Бакчабаштан бер бакча аста гына Әбрар абый ике рәтле гармунда сыздыра. Әллә аның гармун тавышын ишетепме, Әхәт абыйлар урамының чирәмле юлыннан Рифкать абый атлый. Кулында хромка. Ай-яй сыздыра Үрнәк авылыннан Көмеш Чишмәгә укытырга килгән егет!

Ә Югары очка борылсаң, Шәһәр Рәфәгате үзе уйный, үзе җырлый. Үзәкләрне өзәр өчен туган бу Городской!

Көрәшче Рәхмәтулла абыйга да кирәк микәнни соң ул тальян тарту?! Аның бармагы берьюлы ике-өч телгә басмый микәнни?

Югары оч урамының иң соңгы өендә Хәсән абый тальян елата.

Умарталар, куәсләр, май язу машиналары, гөбеләр, тагын әллә нәрсәләр эшләүче Аксак Хәсән абый да моңлана. Аның да күпне күргән йөрәген Сабан туе җебеткән. Ул капка төбендәге утыргычка кунаклаган. Малае Габделхәй исә тальян гармун алып чыгып биргән.

Урам тулып яулык җыючылар килә. Чиләкләр йомырка белән тула да, авыл Советы бинасына озатыла. Егетләрнең муенына яшь киленнәр чиккән чәчәкле-чуклы сөлгеләр, затлы озын буйлы ситсылар уралган. Бу озын ситсылар — читтән кайткан затлы кунакларның затлы бүләге. Кульяулыклар дистәләгән, йөзләгән! Күп шул Көмеш Чишмәдә кызлар. Сабан туена кульяулык чигеп бирмәгән кыз кешемени соң ул?! Әле кызлар исемлегенә эләкмәгән чебеш кенә. Моны кызлар үзләре дә, егетләр дә белә. Менә нәрсә өчен сөлгеләргә, ат дилбегәсе озынлыгындагы ситсыларга «урра!» кычкыручы егетләр һәр кульяулык өчен дә шул ук йоланы үти.

Һәр кызның Сабан туена бүләк иткән аллы-гөлле кульяулыгына рәхмәт әйтеп, «ур-ра-а-а!» кычкыралар. Шул минуттан кульяулык чигеп бүләк иткән кыз кеше рәтенә керә.

Авыл олы шул. Көне буе жыялар яулыкны. Кайсы кеше өендә туры килми. Икенче көнне тагын ярты көн, көндезгә кадәр жыялар. Көндездән соң авылда Сабан туе башлана. Иртәгә тагын көне буе бара.

Кемне генә күрмисең дә, нәрсә генә эшләп йөрмисен ул Бакырчы чишмәсе янындагы болында. Танышулар, табышулар, кавышуларны шушы бәйрәм хәл итә дә инде. Әллә кайчангы вакыйгаларны искә алып, шау-гөр киләләр.

Багана өстендә капчык сугышы бара. Авылда иң әкрен кеше саналган Куян Хөсәенен менгән берсен бәреп төшереп кенә тора. Колхоз эшенә генә әкрен ул. Чалбар сәдәпләре чишелеп беткән, аннан ак ыштан күренә. Берзаман ак ыштаннан «нәрсәдер» чыгып атына башлады. Куян Хөсәенен бер селтәүдә бәреп очырасы баһадир егет ак ыштаннан чыккан нәрсәне абайлап шаркылдап көлә башлады. Шул аның «язмышын» хәл итте дә! Куян Хөсәененең саллы капчыгы жиргә мәтәлдерде. Капчык сугышын караучы бар кеше сыгыла-бөгелә көлә, кемдер, яңа кием кигәнен дә онытып, чирәмгә егылды...

Куян Хөсәененә дә аның жиңүен алкышлаган халыкның сәерлеге барып житте бугай. Ул ак ыштаннан чыккан нәрсәсен күреп алды да:

— Монысы да чыгып тора тагын, әһе-әһе, — дип Сабан туен күрергә чыккан нәрсәсен ак ыштанына шудырды.

Йөгерештә беренче килеп, кайсыдыр киленнең чәчәкле-чуклы сөлгесен эләктерде Зөлфәт. Шиповка кигән, старт алырга торган Зөлфәт янына колхоз рәисе Зәкәрия абыйсы килеп бер салды ботинкасын, бер киде.

— Әйдә, барыбер йөрәгең яңа бит инде, марафон йөгергән кеше бит син, — дип кыстаса да, өченче тапкыр ботинкасын кигән Зәкәр абыйсы:

— Сине жинмәсемне беләм, кәкә, йөгерешчене адымыннан, бөгелгән аягы хасил иткән почмагыннан таныйм. Менә шул почмак адым саен берничә сантиметрны өстәп барса, кешене куып житә алмыйсың. Ярар, көч биреп торырмын, минем өчен дә йөгер, наным, — дип озатып калган иде.

Килүгә жилкәдән кагып:

— Ярый әле бармадым, артта калып, Бакырчыга турыга гына төшкән булыр идем, — дип янган йөрәген көйләп тә китте Зәкәрия абыйсы. — Рәхмәт, энем, матур, жиңел йөгердең.

Икенче көнне Зөлфәт Казанга китеп барды.

***

Китапханә залында укылмаган китапларны яшен тизлегендә карады, һәр көнне өчәр-дүртәр пар лекция тыңлыйсы, имтихан-зачетлар...

Лекция укырга профессор Хатип Госман керә. Үзенен татар шигырен тикшергән китапларын таратып сала. Татар шигырендә кайда ачык ижек, кайда ябык ижек. Вертикаль киселешләр, рифма, кабатлаулар урманына алып кереп адаштыра. Урман булгач, кайчан чәчәге күренә башлый соң моның? — дип көткән кызлар, рефренга тап булып, буксовать итә башлыйлар.

Хатип Госман үзе ырып-ерып чыгар ул, шуна да фән докторы, профессор, ә менә кызлар шул урманда кала. Берничәсе имтихан вакытында да адаша, ә бу ярамый, кышка түләүсез чакыру килә. Укыткан мәктәбендә педсоветта, менә Фәләнова сессиясен тапшырып кайтмаган, диләр. Хатип агага кышкы сессиягә кадәр имтиханынны бирмәсән, шул түләүсез чакыру аласың, жәйге ял хисабына укып йөрисең. Әле Казанга барып-кайтып йөрергә күпме вакыт, чыгым, түземлек кирәк.

Йөрер иде заочник иркенәеп, кышкы сессиягә ике-өч контроль эш

башкарасы, йөзләгән китап укыйсы, өч имтиханга, ике зачетка әзерләнәсе булмаса. Бар шул менә. Ни Хатип Госманнан котыла алмассың, ни кышкы сессиягә тиешенчә әзерләнә алмассың.

Рәшит Балтачына комсомолда эшләргә күчкән. Күчүен күчкән, ләкин барыбер юньләп әзерләнә алмаган.

— Әйдә, сөйлә әле, — дип Зөлфәтне сава гына.

Лекцияләр бара.

Гомерен Ватан сугышы чоры шигъриятенә багышлаган, Фатих Кәрим иҗатын тирәнтен өйрәнгән Зәет Мәҗитовның тавышы җанга ятышлы. Җылы тавыш белән шигырьләр укый. Һәр студентка, беләме, әллә белгәнен әйтергә авырыксынамы, яки бөтенләй белмиме — кеше итеп карый Зәет абыйлары.

XX йөз башы татар әдәбияты курсын алып баручы Ибраһим ага Нуруллин — сугыш инвалиды. Таяк белән йөри. Ләкин аның эрудициясе таяксыз. Ул белмәгән әйбер юктыр. Тукайны сүтә-җыя, тыңлаучыны Тукай заманына алып китә, Тукай рухы белән яшәтә. Әдәбият теориясен бирү буенча аңа тиңнәр юк. Бу кырыс кеше сине үзенең белеме белән сискәндерә, бер артык сүз кулланмый. Тыңлаучы дәрәҗәсенә төшеп очсызланмый. Киресенчә, яканнан, җаныңнан эләктереп, сине күккә күтәрә, ияртеп алып китә. Лекциянең бер минутын да әрәм итми, башкалар кебек аңа лекция кәгазьләре актару, портфелен барлаштыру кирәк түгел. Алары да бар Ибраһим аганың һәм тиештер дә, ләкин ул моңа мохтаҗ түгел. Ул бер ноктага төбәлә дә, сөйли, әйтерсең лә, Тукай белән янәшә атлый.

Рәшит тә:

— Да, малай, кешенең менә мондые да була икән! — дип куйды.

Сессия беткәч, Рәшит туган авылы Борбашка кайтырга димләп аптыратты.

— Кыз кайта укуын бетереп, ачуланма, малай. Киләсе җәйне сездә, аннан бездә каршылыйбыз, — дип көчкә ризалатты.

Рәхәт инде җәй көне, автобуска утырасың да, кайттың-киттең Мамадышка. Юл уртасында котлет кыздырып Теләче көтеп тора. Аңа кадәр өч сәгать селкенәсең дә, Казанда ашаган ризыгың коелып бетә. Теләче котлетлары бик ярап куя.

Мишә елгасын кичкәндә Сабага кул болгап аласың, кемдер Әбде урманының гүзәл юкәләрен күрергә ашкына. Күрерсең, бер сәгать иләнгәч, сәгатенә егерме чакрым тизлек белән тибрәнгәч.

Әнә, Никифорово да артка таба йөгерә, Сәртек шәйләнә, Ишкинең ашханәсенә кереп чыгар мизгелләр якынлаша. Сулда Тау Иле, бераз баргач Әҗмәк күренә. Икесе дә кечекирмәнлеләр нигезләгән авыллар. Юл үргә таба менә, инде Кече Кирмәннән егерменче елларда аерылып чыккан Хәсәнша, Өләүкә авыллары каршыга йөгерә. Алпавыт Алкин кызына бүләк иткән Кыз урманы унда кала, хуҗасы исемен йөртүче Алкин урамына килеп керәләр.

Зиратлар авыллар белән мәңгегә янәшә. Ак Чишмә, Иске Завод авыллары күренә. Тиздән аның төшәр вакыты та житә. Әби патша юлының Комазан урманчылыгы турына төшә дә авылга юл тота. Аны ай буе көтеп зарыккан туган җирнең кайнар сулышы монда да сизелә.

Юлда йөкне җилкәгә биштәрләп йөрергә өйрәнде. Ике кулны селтәп йөрү зур бәхет ул. Кесәсендә беренче курсны бетергәнлеккә белешмә. Такташ әйтмешли: эшлисе эш инде эшләнгән.

***

Быел да алар гаиләсенә бәхет ишелеп килде. Сипләгән өйдә яшәсәләр дә—үз өйләре. Сыерлары исән-сау бозаулады, майлы, катыклы итте. Печән өстенә әнисенең кыяры өлгергән. Сарыктыр, тавыктыр, каздыр үрчегән.

Энесе Ленин укыган университетның физика факультетына укырга керде, инженер булачак. Менә Зөлфәт беренче курсны бетерде. Алла боерса, энесе белән бер елны КДУны тәмамларга исәпләре. Читтән торып алты ел укыйсы шул анда. Әйдә, ул эшләр, энесенә ярдәм итәр. Укысын гына!

Бәрәнге күмелгән. Әнисе каралты-кура тирәсендәге карт кычытканны урып сәндерә түбенә җәйгән. Тычкан йөрмәсен өчен шулай эшләнә ул. Хәзер менә печәнне чабасы, киптереп алып төшәсе. Анысына Хәбыйк Мулласы булыша инде. Һәр елны шулай бит. Ул бөек атчы. Андый ат җигүче юк.

Әле урманчы печәнен чабып бетермәгән икән. Кулга ике чалгы тотып, әниләре төйнәп биргән ризыкны эләктереп, елгага киттеләр. Саурыш елгасыннан, Хәсән чүннигеннән печән кырдылар.

Иртүк чыгып киткән егетләр дөнья кадәр печән әзерләде, әле тараттылар да. Печәннәре икенче көнне кичкә кипте, шыгырдап торган бер йөк печәнне сәндерәгә алып кайтып өйделәр. Гел юктан кергән байлык булды бу. Өйдә эшләр менә шулай, туктале, йөрәк эшләре дә бар бит. Кайткан көнне болай булды. Күчтәнәчләр белән алма бакчасында чәй эчтеләр. Чәйгә күрше Мәтә Гарәфе белән Нурида апаны да чакыргач, дөнья тагын да ямьләнеп китте.

— Рәхмәт, бала, — диде Гарәфетдин абый. Аек баштан атналар буе ике сүз дә сөйләшми торган кешедән моны ишетү Зөлфәтнең күңелен аеруча күтәрде. Табадан беренче коймакны, мичтән беренче ипине, орлык бөккәнен киндергә төреп йөгереп керә торган Нурида апалар белән яшәү үзе зур бәхет!

Күршеләрдән бәхете бар аларның. Бер якта әнә Тәхиятулла абыйлар. Икенче якта Мәтә Гарәфе белән Нурида апа. Сала Гарәфетдин абый. Исергәч, хатын белән исәп-хисап эшенә керешә. Нурида апаны зәһәр сүгенеп куа башлый. Төптән юанрак, түгәрәк Нурида апа аксак иреннән курыкмый, ләкин аннан арыну өчен шактый башлы булырга кирәк. Беркайчан да Мәтә Гарәфнең хатынын тота алганы юк, куа, анысы. «Каһиренне» дә калмый, монысы Нуридә апаның беренче иренең исеме, «бөгелеп,» «сыгылып» дигәненә дә өсти. Эчкән әйберсе исерткәч, дәртләнүенең соңгы дәрәҗәсенә житкәч кенә Каһиргә барып житә Мәтә Гарәфе.

«Эләктенме, Әтәкә»... — дип (бу хатынының кушаматы), ишеккә килеп баса Гарәфетдин. Инде мона кадәр куышып өйдәге олы мичне биш-алты әйләнгән булалар. Кая барсын мескен хатын, тәрәзәдән сыймый, юан. Тәрәзәдән сыйсын да, ди, вакыт әрәм була, яшен тизлегендә килеп житә дә Мәтә йә өйгә кире суырып ала, йә ега.

Таранга бара Нурида апа. Хатынның барыр юлы калмауга шатланып тантана итүче, шуңа бераз уяулыгын жуйган Мәтә Гарәфенә таба томырыла да күкрәгенә ике кулы белән төртеп жиффәрә. Ире очып китеп кечкенә якның идәненә дөбердәп барып төшә. Үлде, дип уйлыйсызмы? Булмаганны! Ишегалдына чыга торган ишектән Нурида апаның күренүе була, Мәтә Гарәфенең дәһшәтле тавышы инде урамга ишетелә.

Алма бакчасы капкасыннан кереп югалган Нурида апа өчен хәзер инде ире чүп тә түгел. Мәтәсе сугышта һәлак булган беренче иренең исеме белән генә аны бәреп ега алмый, чөнки куып житә алмый. Икенче көнне ир белән хатын сөйләшеп туймый. Тавыкларга кычытканны шундый вак итеп турый Гарәфетдин абый, әйтерсең лә, кичә бернинди «Каһиренне!» дә булмаган.

Бакчадагы өстәлдә алмалы чәй эчәләр. Кем әйтә ала бу ир белән хатынны бәхетсез дип, хәтта без дә әйтә алмыйбыз.

Шәригатьчә яши Мәтә Гәрәфе, көн дә хатынның чәч арасыннан шайтанын куа.

***

Йөрәк эшләре дигәннән. Укуын бетереп кайткан көнне, алма бакчасында күршеләр белән чөкердәшеп чәй эчкәннән соң, Казанның бер айлык борчуын жаннан һәм тәннән югач, бәрәңге бакчасы аша гына йөрәк дәшкән сукмактан китте Зөлфәт.

Их, син яшьлекнең шул кызлар янына баргандагы ашкынулы сукмаклары! Кем генә очмады микән сездән жанны тирбәтеп! Менә Чегән тавы да ашкындырып инеш буена төшерде, инде Бакырчы чишмәсенең жыры ишетелә. Кая, хәлең белим әле! — Көмеш агымга кулын тыкты егет, су аның каләм тотып, ай буе язып сөялләнеп беткән бармакларын иркәли иде. Бер сүз эндәшмәде Зөлфәт. Чишмә челтерәгәч нәрсә кирәк тагын. Бөтнекләрне сыйпап кына калмады, берничәне өзеп Зәңгәр Күзгә дә алып китте. Чирәм каплаган су буе сукмагы аякны этеп жибәрә, чөнки чирәм астында торф. Менә ул туганнары Миннегөл Гаяны яшәгән бакчаның куш талы турысына килеп житте. Бу тал исән әле, инде су буендагы баһадир талларның күбесе китеп барган, язгы ташуларга аккан, жиргә туфрак булып яткан.

Трайт чишмәсе һаман жырлый. Әле аның агымына кулын куйгач көлеп тә жибәрде. Сагынган аны бу чишмә, таный, учка елыша, бармак араларын иркәләп ага. Зәңгәр Күзнең өенә бармады, күренәсе итмәде Зөлфәт. Инде күптән ишеткәндер. Авыл бит бу, аның күңеле һәрвакыт ачык. Кайтканны да, киткәнне дә күрә, кемлеген белеп тора.

Имәнгә барып сөялде Зөлфәт. Агачлар кешенең тискәре энергиясен ала, үзләреннән шифа бирә, дип укыганы бар. Имән ала микән, бирә микән?

Чишмә янында Корбанбикә апалар яшәде.

Аның медер-медер генә укыган догалары, ишегалдында утырган малайларның кулларын догага күтәреп тын калуы, бу халәтнең серлелеге шулкадәр хәтергә уелып калган. Зөлфәт тә ирексездән кулын догага күтәрде. Ходаем...

Шул вакытта ак күлмәкле фәрештә очып та килде, таудан төшеп егетнең кочагына да чумды. Бер сүз әйтмәде. Үзе дер-дер килә. Зөлфәтнең муенын чылатып елый да башлады. Кайнар яшь тамгач, Зөлфәт тә калтырый. Икесе дә дер-дер киләләр, нишләргә белмиләр. Их, бу саф мәхәббәтнең тетрәнүләре! Ике ел буе хат язышып кына яшәү газаплары! Их, бу әйтәсе сүзнең күплеге һәм очрашкач бер сүзнең дә кирәк булмавы!

Океан төбендә аткан вулканнан туган дәһшәтле дулкын меңнәрчә чакрымны үтә, хәтта, дөньяны әйләнеп чыга, берзаман дулкыннары тәбәнәкләнә, көчсезләнә, юашлана. Ләкин моның өчен күп вакытлар кирәк. Имәнгә сөялгән егет белән кыз да шактый тетрәттеләр имәнне. Берзаман кыз сулкылдауга гына күчте, инде күз яшьләре дә Зөлфәтнең муенына тамудан туктады. Сонга таба ул хәтта суламый да кебек. Бер тавыш та чыкмый. Йоклады дисәң, күкрәгендәге ике калкулык вакыт-вакыт жанга чаң суга.

Икесенең дә кыл кыймылдатырлык хәле юк, чөнки ике ел буе күрешмәү газабы инде жаннан дерелдәп чыккан, очрашу бәхетенә исә күңел ышанмый, сулкылдый иде.

Зәңгәр Күз тагын да чибәрләнгән, күзләре очкынланып тора. Күкрәкләре түгәрәкләнгән, биле тагын да нечкәргән. Аның атлаулары тау битенә әллә нинди чигешләр ясый. Житез хәрәкәтле, жинел гәүдәле кызыкай омтылышлы күкрәкләре белән авылның сихри кичендә очып йөри. Юктан да кызык таба, чөнки Зөлфәт белән күрешүгә чиксез шат!

Алар узмаган сукмак калмады. Кая ашкыналар, үзләре дә белмиләр.

Матур, эчкерсез авыл кичләре тымызык яңгырлары, йомшак жилләре, ә кайчагында коры эсселеге белән дә ямьле. Июль ае да үтеп китте, сөелеп, сөеп. Август та шулай башланды.

Зәңгәр Күз иртәгә китәсе көнне кичен аларга төште Зөлфәт. Өйгә кермәде. Кыз сөйләшенгән вакытка чыкты да, кич салкынча бит дип, кием алырга кереп китте. Ишектән апасы күренде. «Зөлфәт, берүк кызга кагыла күрмә, юньле гаиләдән икәненне беләм», — дип өйгә кереп югалды.

Алар ул кичне Зөлфия белән алма бакчасындагы мунча өялдында гына утырдылар. Кыз өрфия күлмәктән, тәненен кайнарлыгы кулны пешерә. Аны берөзлексез кочаклап үбәсе килә.

— Нишләп монда утырабыз сон? Су буена чыкмыйбыз, — ди Зөлфия.

— Ярар инде, апаң шунда гына утырыгыз, ди. Аны рәнҗетәсе килми.

— Зөлфәт, син безнен шәһәргә килсән, физкультура укытыр иден. Мин дә эшләр идем. Бүген әти-әнидән хат килде. Апаны бик кисәткәннәр, кызга ул-бу булмасын. Без аны кияүгә бирәбез, дигәннәр... — Зөлфия елап җибәрде. — Каршы торып булмас, кил инде Зөлфәт безнен шәһәрдә торырга. Югалмабыз!

Нәрсә әйтер микән инде ана Зөлфәт?! Күренеп тора: кызыкай авылда яшәрлек фәрештә түгел. Авыл тормышы, анын авырлыгы, гарык итә торган мәшәкате канатларын сындырачак. Авылга кайту уенда да юк. Ә Зөлфәт туган җирен, әнисен ташлап, әле генә университетка кергән энесен язмыш кочагына ыргытып авылдан китә аламы? Әйтегез әле шуны? Аннан сон шәһәр мохите аңа бөтенләй ят, андагы чират торулар, ыгы-зыгы, ызгыш-талаш, авылнын тымызык тормышында яшәгән егетнең җанын имгәтәчәк. Кем аңа фатир әзерләп куйган? Ул анда кызнын өендә яшәргә тиеш булачак. Ә авылда нәрсә диләр: йортка кергән — б...ка кергән. Андый кешене авылда кешегә дә санамыйлар, чөнки ана, йортка кергән кешегә, өрергә генә торалар. Ахыргы исәптә, ул кеше үзен дә кешегә санамый.

Зәңгәр Күз кич буе елады.

— Мәңгегә аерылабыз, белеп торам, — диде. Зөлфәт тә кистереп әйтә алмады. Икесе дә сабыйлар иде шул. Берсенә унсигез, икенчесенә егерме яшь...

— Иртәгә Хәсән абый Югары Ушмыга ат белән чыгара. Кайтып җиткәч, хат язармын. Минем сине ничек яратканны белмисең әле син, — дип тагын елый башлады Зәңгәр Күз.

— Беләм, мин дә сине шулай.

— Дөресме? — дип йомшап төште кыз. Апасынын «кһым-кһым!» — дип бакчага керүе бик урынлы булгандыр, алар саубуллаштылар.

Капкадан чыгуга, ярсып китеп, костюмын бөтереп җилкәсенә салган иде, юлга чыңлап тимер акчалар сибелде. Зөлфәт аларнын тавышын ишетте, ләкин кая аларны җыю! Анын күнелен аерылу ачысы талый, җанын кая куярга белми.

Хәзер иртәнге алтыга да ике-өч сәгать кенә калгандыр. Су буйлатып, җанын таунын әле бер ягына, әле икенче ягына бәреп кайтып бара менә. Мәңгелеккә китте кызыкай. Ничә ел буе сагындырып яшәгән, йөрәктә сулкылдаган сандугачны шәһәрләрендәге бер козгынга бирәләр. Яратмыйм мин аны, дип ачыктан-ачык әйтте кыз. Әни белән әти көчләп кияүгә биреп мине бәхетле итмәкче була. Мин синнән башка гомергә бәхетсез буласымны беләм, ди. Кайтып баш төрткән иде Зөлфәт. Уянып китсә, сәгать җиденче ярты. Кая анда ашау! Киемнәрен әләктерде дә чыгып йөгерде. Кызыкай өзгәләнәдер, олы юлга чыгып озатып каласы иде. Бер сәгатьтә ат олы юлга чыгып та җиткәндер инде, дип йөгерде генә. Каршы тау һәм Казыган тау бер сулышта йөгереп менелде. Саурыш елгасы, Рәхимулла чүнниге, агач маш та артта калды. Менә Мамадыш — Казан юлы. Зөлфия! — дип кычкырды Зөлфәт.

Кыз сискәнеп китте. Ышанмады. Чөнки алар кичә саубуллаштылар бит инде.

Ачыклыкка чыгып кул изәде. Зөлфия аяк киемен салып атты да Зөлфәткә томырылды, килеп тә житте, муенына да асылынды.

— Ничек киләсе иттең? Улям! Нинди бүләк ясадың! — дип шашына: бер көлә, бер елый. Кочаклашып бер генә мизгел торырга насыйп булды аларга. Автобус килеп тә туктады, комсыз ишекләр ачылып та китте, Зөлфия тәрәзә кырыендагы утыргычка кереп тә утырды.

Үзе елый, үзе кул болгый, нишләргә белмичә еракка, мәңгелеккә китеп барган сөйгән ярны озату авыр, бик авыр икән.

Атка да утырмады Зөлфәт. Ниндидер юлдан урманга кереп китте, дымлы урман эчләрендә янган йөрәген басар өчен салкын ешлыклар эзләгәндер.

Өйгә кайткач күрде, әле генә Казаннан алып кайткан чех ботинкаларының табаннары купкан иде. Менә ничек йөгергән бит ул!

***

Зәңгәр Күзнең хаты озак көттермәде. Исән-сау кайтып житкән. Зөлфәтнең аны урман буена чыгып озатуына күңеле тулып, Уралга барып житкәнче елап кайтуын язган. Хаты да яшькә манчылган. «Ачуланма, хатны күчерә алмыйм, кул бармый, шул яшькә буялганын салам инде, дигән. Әти-әни кодалыйлар теге егеткә. Ул миннән күпкә олы, жан тартмый, кан тартмый. Бүлмәмә кереп бикләнәм дә, ул егет өйгә килүгә, елый да алмыйм. Акылдан шашмасам ярар иде», — дигән.

Ике арада хатлар йөреп торды. Зәңгәр Күзне кияүгә биреп әти-әнисе янында калдыру өчен бөтен нәселе тырышты. Хәтта, авылдагы абыйсы, Уралга хат язганда, Зөлфәт башка кызлар белән йөри дип, ялганлаган. Зөлфия моны хатта да язды. Син нәрсә, мине белмисең мәллә, шулай рәнжетәсең, дип үпкәләде Зөлфәт.

Декабрьдә сөйгәненең соңгы хаты килде. Конвертка фоторәсем тыгылган. Ә аннан сөйкемлелеген сурәтләргә сүзләрнең көче житмәслек чибәр кыз елмая. Фотога: «Мәңгегә сине сөйдем, нәрсә булса да, синеке булып калам!» — дип язылган иде.

Елмаюында моңсулык.

Бу Зәңгәр Күзнең Зөлфәт белән саубуллашу хаты иде. Кулыннан эш төште Зөлфәтнең. Моны өйдәгеләр, хәтта укучылары да сизде.

Барысы да аерылуның рәхимсез җәза икәнен аңламады. Күкрәгендә йөрәк урынында салкын таш тоеп, Зөлфәт кышкы сессиягә китте. Су буенда Трайт чишмәсе челтерәп ага. Мәгърур имән, кышкы бураннар гына килеп сарылганга исе китмичә, офыкка карап калды.

Аны яз көне, Зөлфәтнең туган көнендә, яшен сукты, көйгән-янган бер жире дә юк, ләкин кәүсәсе очыннан төбенә кадәр ярылган һәм ике ярка ике якка аерып атылган иде...

***

Без Зөлфәт белән бераз яшәп алдык. Аның күңел тәрәзәләренә күз салдык. Кеше күңеле — иксез-чиксез дәрья. Аның тәрәзәләре дә хисапсыз. Яшьлек тәрәзәләре бигрәкләр дә якты, нурлы!

Алга таба Зөлфәт ничек яшәр? Аны нинди сынаулар көтә? Тәрәзәләр күрсәтер...

*Беренче кисәк тәмам.*

# ТУКАЙЧА ТАТАР КОДЕКСЫ

*Каләм әһелләре әледән-әле искәрткәнчә, һәрбер әдип насыйп гомере дәвамында үзенең бердәнбер зур китабын яза. Табигый ки, олуг талант ияләре тарафыннан иҗат ителгән мондый фолиант ил-көн өчен бәһаләп бетергесез рухи кыйммәтләрне гәүдәләндерергә мөмкин. Әгәр шулай икән, без бөек шагыйребез Габдулла Тукайның бөтен язганнарын халкыбызга мирас кылынган яшәеш дәреслегенә тиңли алабыз. Чыннан да, аның даһилык белән тудырылган иҗаты биниһая тәгълим мөмкинлекләренә юл ача. Бары тик аннан зирәкләрчә файдалана белергә генә кирәк. Мондый затның классик әсәрләрендәге барлык сүзе генә түгел, хәтта һәрбер ым-ишарәсе газиз милләтенә хезмәт итәргә тиеш.*



Рәссам Эрот Зарипов эше

*Нәкъ менә шушы куллану осталыгы җәһәтеннән без үз вазифабызны тулы күләмдә үтәүгә ирешәбезме соң? Раслап әйтү кыен. Әнә, Габдулла Тукайның җәрәхәтле бәгыреннән савылган әлеге «бердәнбер китабы» эченнән «Татар кодексы»н үтәли күреп, аны халкыбыз дикъкатенә юнәлтер өчен дә безләргә бер гасырдан артык вакыт кирәк булды. Аһ, аянычлы кыска гомер шәме ике яктан янып килмәсә, яки кемдер тарафыннан җаваплы йөкләмә куелса, шагыйрь аны үзе дә кәгазьгә төшереп калдырыр иде. Берничә нашир тәрҗемәи хәлен язып бирүен үтенгәч, «Исемдә калганнар» рисаләсенә тотынырга кулы җиткән ләбаса. Җәмәгатьчелек вәкилләре сорагач, «Шәрекъ клубы»нда халык әдәбияты турында лекция әзерләп укырга да, «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» дигән дәреслек-хрестоматиясен төзергә дә өлгергән.*

*Ә татар халкын озын-озак гасырлар дәвамында тәрбияли алырлык ошбу кодекска килгәндә, сүз дә юк, Габдулла Тукай аны үзенең язганнарында ярылып яткан тәҗрибә нигезендә әзерләр иде. Нишлисең, әлеге эшне тиешенчә ахырына җиткерү бөтен җаваплылыгы белән безгә тапшырылган. Шик-шөбһә тумасын, сезнең игътибарга кануни шәкелдәрәк тәкъдим ителгән бу җыелма төп-төгәл шагыйрь каләме теркәп калдырган сүзләрдән генә тора. Хәрефкә хәреф туры килә, дип, нәкъ шундый очракта әйтеләдер. Хәтта бүлекләрнең исеме дә аның әсәрләре тукымасыннан алынды. Кодекстан файдалану барышын җиңеләйтү максатыннан, нибары*

*тәртип саннары гына өстәлде. Алары да шагыйрь өслүбе өчен ят түгел. Габдулла Тукай бүлем рәкымнәрен шактый еш кулланган.*

*Инде шундый искәрмә дә биреп үтәргә кирәк: кодекс калыбындагы әлеге уй-фикерләр ниндидер депутатлар төркеме тарафыннан түгел, ә аерым шагыйрь исеменнән юридик таләпләрне күздә тотмыйча язылган. Монда шәхси башлангычның өстенлек итүе табигый. Шул ук вакытта көрәшче әдипнең фикри сөземтәләре дәүләти югарылыктагы иҗтимагый гомумиләштерүләрдән дә мәхрүм түгел. Кыскасы, боларның һәммәсен дә белеп тору лаземдер.*

*Тукайлы язмышыбызга рәхмәтләр белдерик. Пәйгамбәргә торырлык шагыйребезнең еллар аша безгә җиткерелгән әлеге мөкатдәс бүләге, иҗтиһатка өндәүче әманәт буларак, татар халкының алгарышына янә бер ныклы нигез ташы рәвешендә салынсын. Аллаһ теләктәшлек кылсын.*

---

# Биисми Габдулла бине Мөхәммәдгариф ТУКАЕВ*

### I. Керешү сүзе. Алла гыйшкы хакына

1. Бисмиллаһ иррәхманир рәхим...

Без дә бер кешедәй дус булыйк Алла гыйшкы хакына;
Эрелек, төче теллелекне ташлыйк Алла гыйшкы хакына.

Милләтнең күнеле Ана юнәлсен Алла гыйшкы хакына;
Иске чир, түбәнлек юк булсын Алла гыйшкы хакына.

Шул юлга омтылыйк, и диндәшләр, Алла гыйшкы хакына;
Мондый омтылыш, тырышлыклар керсен гадәткә Алла гыйшкы хакына...

Гыйлемгә кирелек пәрдә булмасын Алла гыйшкы хакына;
Жанланыйк, кузгалыйк һәр җирдә Алла гыйшкы хакына.

Дуслык булмау сәбәпле, милләт шушы хәлгә килде, -
Гыйбрәт ал, и Мөхәммәд өммәте! Алла гыйшкы хакына.

Без дә кеше ич, итик гайрәт Алла гыйшкы хакына;
Бу дөньяны хәйран калдырыйк Алла гыйшкы хакына...

Бар һөнәребезгә канәгать булмыйк Алла гыйшкы хакына;
Тәнре мәрхәмәтенә каршы килмик Алла гыйшкы хакына.

2. Күп сөекледер бөтеннән – Тәңрегә сынган күңел... Һәрвакыт Аллаһы Тәгалә хәзрәте күңеленезгә тәүфикъ нуры кертеп изгелек кыйлмак... Тәкъдир сезгә теләктәшлек белән елмая: мондый зур бүләкнең кирәк кадерен белергә...

Җиһанда барча эшләр, барча хәлләр Тәңредән... Барчагыз Алла җебенә ныклап тотыныгыз. Алла җебе дигәнем үзара якынаю, дуслашудыр, димәк, үзара каршылыктан, ызгыштан сакланудыр...

Ярдәмендә һәр заманда Алла бар; ал җәсарәт[1], алга омтыл, һич ялыкмый алга бар!.. И Алла! Алга китүебезгә, югары күтәрелүебезгә булышлык итүчеләргә ярдәм бир...

Һәр ничек хәер-фатихада булышаек... Эшләрегездә парлак сурәттә муаффәкъ булуыгызны[2] телим... Алла сезне һәр ике йортта (дөньяда да, ахирәттә дә) бәхетле итсен... Алла риза булсын, гомерегез озын булып, байлыгыгыз һәм бәхетегез көннән-көн артып торсын... Милләтнең киләчәге айлы кичтән дә яктырак булсын.

## II. Баланың язмышы ата–анасына тапшырыла

1. Көлле мәүлүдин юләде галя фитърәтел-ислами, фәминә әбәваһе йөһәввиданиһи вә йөнәссыйраниһи вә йөмәҗҗисанаһи...

Хәдис шәрифнең мәгънәсе заһир[3]: һәр тугъмыш бала ислам, ягъни тәслим фитърәтендә[4] туа.

Баланың язмышы, ул тугачук, аның ата-анасына тапшырыла, тәслим ителә... Аның атасы яһүди булса, бала киләчәктә яһүд милләтенә хезмәт итәрлек рәвештә тәрбия ителә. Атасы нәсрани[5] булса, янә, нәсрани милләтенчә тәрбия кыйлынып, киләчәктә үз милләтенә файдалы бала булуы күзгә алына... Менә без, татар балалары да, татар милләтенчә тәрбия кыйлынганбыз... Татар диненчә тәрбия алганбыз...

Вәләкин... Тәрбиямез... коры, рухсыз, мәгънәсез, һич файдасыз рәвештә «дини» генә булмыйча, дини вә милли тәрбия булсын. Мөселман булганымыз вакыт татар икәнемезне дә онытмыйк.

2. Балалар – безнең шатлыкымыз... Балалар – безнең бәхетемез вә сәгадәтемез... Балалар безнең гомер нигеземезне тазарталар, балалар хезмәт өчен безнең көчемезне арттыралар.

Бу сүзләр һәрбер атаның да, һәрбер ананың да йөрәгеннән ләззәтле-ләззәтле генә өзелеп чыккан сүзләрдер.

3. Балалар якты дөньяга килгәндә, гадәтән, бер бәхетлелек дингезе булып киләләр. Ләкин әнә шул балаларны туган минутыннан алып балигъ булганга кадәр, ата-ана үзләренә бәхет вә башка инсаннарга да шатлык булырлык итеп тәрбия кыйлуы бик читен, ай-һай, бик читен!..

Бала, ир бала, әйбәт кенә тәрбия ителсә, ата-ана өчен, гомернең куркынычлы һөҗүмнәре вакытында шул бала шул ата-анасын сакларга күкрәп, нәгъэрә орып чыккан бер арыслан буладыр.

Кыз бала, бик матур гына тәрбия ителсә, бөтен дөнья байлыкларына сатылмаслык егетләрне, картларны, хәтта хатыннар вә карчыкларны үзенә таба тартып тора торган... бер фәрештә буладыр. Аның бер сүзен ишетер өчен, бер генә йөзен күрер өчен меңнәрчә җаннар атылып кына торадыр. Ул үзе шикелле тагы әллә ничә фәрештә кызлар вә әллә ничә арыслан йөрәкле, гайрәтле егетләр тәрбия итә аладыр.

## III. Укымак – үз халкыбызга хезмәт итмәк

1. Очып төш тә балалык бишегеннән, ябыш – аерылма мәктәп ишегеннән... Синең бу барган юлың – галимнәр юлы: бу юл белән барлык олы кешеләр җитешкән. Бу дөнья, бел... Максаты – иксез-чиксез бәхет; соңы – үсү, бөеклеккә күтәрелү... Көне килер: синең дә урының бөек булыр; ихтимал, исемең алтын белән язылыр.

Атагыз, анагызның шатлыгы сез, ике дөньяда йөз аклыгы сез. Барлык мөселманнарның урталыгы сез, безнең саф динебезнең пакьлеге сез. Гыйлем йозагының ачкычы сез, тәрәккый күкләрнең баскычы сез.

Мәгариф бакчасында очып йөр... Һәр чәчәк — сеңлең, апаң; абзаң — үсеп торган агач...

Мәгариф — хәяттыр. Һәр бәхетне, һәр сәгадәтне, һәр нәҗатны[6]... голүм[7] вә мәгърифәттән генә көтмәк кирәктер... Укып, балалар алга баралар...

Каз канатлары ак булыр,
Ир канатлары ат булыр.
Сабыйларның канатланыр вакъты
Мәктәпләрдә укыр чак булыр.

2. Яз, газиз угълым: кара тактаны сыз акбур белән! Һәм кара күңелеңне ялт иттер, сызып ак нур белән! Өч наданга алмашынмас — бер язу белгән кеше; мәгърифәт эстәр, иренмәс һич — кеше булган кеше...

Тынма, эшлә, и сабый!.. Тырыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул; картаеп каткач буыннар, эш белү уңайсыз ул!.. Тәңредән эшләргә — көн, эшләп аргачтын, бирелгәндер тыныч йоклар төн. Иртә торгач та язарга, дәресең укырга тотын; тынма, эшлә, торма тик... Гомер итмәк — тырышмактыр ялыкмый, ... гаталәт[8] хурлыгын асла[9] үзенә ихтыяр итми. Мәгърифәт эзлә, бар әле...

Адаштым дип егълый күрмә: гыйлем чын эз табар әле... Булганы белән канәгатьләнмә, тәрәккый ит, алга бас; гыйлем диңгезләренең иң тирәне сиңа кояр... Бит шуңа бәйле бәхет—рәхәт.

3. Бәхетле шул баладыр, кайсы дәресенә күңел бирсә, мөгаллимне олуг күрсә, белергә кушканны белсә. Сабакка калмаса сонга, борылмый барса уңсулга, уенга салмаса ихлас — менә бәхете аның шунда. Кечеләргә итеп шәфкать, үзеннән зурга юл бирсә, бәхетсезләрне кимсетми, егылганнарга кул бирсә!..

Төшсен ләкин исегезгә кайсы вакыт: һәркемгә дә бирелмәгән мондый бәхет; ятим калган сабыйлар бар, бәхетсезләр, ата-анасы вафат, җирсез һәм йортсызлар... Очрый калса сезгә шушындый ярлылар, яшьле күзле, моңланганнар вә зарлылар — яшь балалар! Аларны сез яратыгыз, җылы сүзләр әйтеп, сөеп юатыгыз!

4. Син әле үс һәм укы күп, шунда аңларсың барын; мәгърифәт нуры ачар күп нәрсәләрнең ялганын...

Укымак — дөрестнең ялганны, яктының карангыны, турының кәкрене, сафлыкның бозыклыкны җиңүләренә иң үткен, иң кирәкле коралдыр. Укымак — фикерләрне җирдән күккә җибәрмәк. Укымак — үз янында булып торган нәрсәләрдән бигрәк, фикерләрне булачакларга сузмак. Укымак — үткәннәрдән кичеп, киләчәкләр... тугърысында пәйгамбәрлек итмәк. Укымак — хәзерге көннәрне киләсе көннәр өчен, бу көнге мәсьәләләрне киләчәктәге мәсьәләләрне чишү юлына ташламак димәктер. Укымак — үзеңне һәрнәрсәне белергә вә һәр максудка ирешергә вә бөтен дөньяга солтан булырга лаек дип танымактыр. Укымак — ... гакыл пычагын гыйлем вә мәгърифәт кайрагына чынлап кайрамак дигән сүздер... «Укымак» ләфзы[10] астында монының кеби хисапсыз мәгънәләр чыкса да, барчасы үз халкымызга хезмәт итмәк дигән сүзгә кайтадыр.

5. Беләм инде, сабыйлар, сезгә мәктәптә күңелсездер, аның тоткынлыгыннан сез бигүк разый түгелсездер. Сабый чакта күңелсезләнгәнем бар мин дә... Заман үтте. Азат булдым... Күңелдән сагынам «тоткын»лыгымны, мәктәбемне мин...

Яшьләргә... уку кирәк. Бу аларның иң мөкатдәс, иң беренче вазифаларыдыр. Бу — безнең һәртөрле... бюрократия золымыннан, башка милләтләр илә берлектә, безнең дә котылуымызга иң беренче вә иң тугъры юлдыр... Сүз башында әйткәнемезчә... Аллаһы Тәгалә файдалы гыйлем бирсен.

6. Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң Аның, һәрдәм таян син Аллага!

Йа Ходай, күрсәт, диген, ушбу җиһанда якты юл;
Ул — рәхимле; әткән-әнкәннән дә күп шәфкатьле Ул!

Саф әле күңлең синең, һичбер бозык уй кермәгән,
Пакь телең дә һич яраусыз сүзләр әйтеп күрмәгән.

Пакь җаның һәм пакь тәнең – барлык вөҗүдең пакь синең;
Син фәрештә валчыгысың, йөзләрең ап-ак синең!

Кыйл дога, ихлас белән тезлән дә кыйбла каршына;
Бел аны: керсез күңелләрдән тугъры юл бар гаршенә!

Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң Аның, һәрдәм таян син Аллага!

7. Милләт образауный кешеләргә һәм халык файдасын һәртөрле үзенең шәхси мәнафигыннан[11] вә корсак файдаларыннан өстә тота торган, милләт файдасын күз өстендәге кашы дәрәҗәсендә газиз тота торган милләт арысланнарына мохтаҗ. Милләт аталарга, аналарга, мөгаллимнәргә, мөгаллимәләргә, мөрәббиләргә вә мөрәббияләргә[12], чын мөхәррирлек табигатьләренә вә сәляхиятләренә[13] мохтаҗ... Безнең милләт тә Пушкиннарга, граф Лев Толстойларга, Лермонтовларга мохтаҗ. Кыскасы гына, безнең милләт тә башка милләтләрнең тәрәккыйләренә сәбәп булган чын мөхәррирләргә, рәссамнарга, ... яңа-яңа милли шигырьләргә, музыкаларга вә гайреләргә, вә гайреләргә мохтаҗ.

Бу әйтелгәннәр булмаганда, безнең тормышымыз күңелсез, үлек чыккан өй төсле моңлы, тынсыз-тавышсыз, рәхәтсез булачактыр. Болардан башка безнең гомеремез бер дә бәйрәмсез, гомерлек мәшгулият яки бер дә җәйге кояшсыз мәңгелек көз көне төсле үтәчәктер.

8. Әүвәл милләт укысын, белсен... Мәгариф тарату булсын бездә гадәт... Ходай орган җәһаләт[14] бит ниләр кыйлдырмый, нишләтми?!.

Мәктәпләр – безнең арсенал, татар. Надан булу – гарь, татар, ангар дөнья тар, татар; алсаң өлеш һәр фәннән, бәхетең булыр яр, татар... Өмет анчак[15] мәктәпләрдә генә!..

Бармак берлән каткан җирне казып булмый, әлифбасыз (алфавитсыз) язып булмый; шуның төслүк, мәктәпләрне төзәтмичә, «Тәрәккый!» – дип кычкырырга базып булмый. Ислах дәрьясында йөзсен безнең кораб, китсен тугъры... Тик шундин соң – шундый гайрәт аркасында мәктәпләр дә әкрен-әкрен алга китәр.

9. Мөгаллимнәр!.. Һәр нәрсәнең гүзәлең яратабыз бит... Гыйлемнәр бакчасында күңел ачып йөрик... Балаларымызның күзе гүзәл нәрсәләр күрергә вә борыннары да хуш вә татлы исләр иснәргә иялəшсен. Кечкенәдән гүзәл нәрсәләр укыган балаларның күңелләре дә назик вә ләтыйф[16] булып, анчак гүзәл вә мөкатдәс нәрсәләрне генә сөючән буладыр. Моның киресенчә: кечкенәдән тупас вә ямьсез нәрсәләр күреп үскән балаларның язгы ачык күк кеби саф күңелләре томанланып, рухлары яхшыны вә начарны аермый, һәрнәрсәгә бертигез карарчы буладыр.

10. Киләчәктә... ямьсез исемнәр дә татар балаларына кушылмасын... Аллаһы Тәгалә исемемезне, җисемемезне вә рухымызны ислах әйләйә[17]!..

Без дә адәм угълы – адәмчә тормыш итик дөньяда. Гыйлем белән дөньяны кулда тотты япон, немец, француз... Без – бу мәгърифәт гасыры сараеның иеләре һәм балалары... Мәгариф мәйданында без, татарлар, ат уйнатыйк!

## IV. Татар яшьләре

1. Шөкер булсын, гасырыбызның яшьләре уянып тордылар... Дикъкатә лаек хәзерге көн татарның яшьләре: аңламак, белмәк, тәрәккый, мәгърифәт, хикмәт белән әйләнеп һәм нурланып тормакта һәрдәм башлары...

Сөям сезне, сез – чын яшь егетләр; өмет бар сездә, сез – интеллигентлар.

Телем, күнелем — бөтен барлыгым сездән риза; үткән чорда сезнең ишеләр булмаган. Сез — яна пешкән, житешкән баһадир; хәзер яшь баһадир — бәя биргесез. Без сезне гасырлар буе көтеп алдык; килерсез, дип һәрвакыт күз тегеп тордык. Сәламәт килдегезме — рәхим итегез!

Сез — күнел шатлыгы, тан жиле сез. Черек милләт өчен сынмас терәк сез; тугыз корбан суеп алган теләк сез...

Әгәр пәйгамбәр терелсә, ... сезне ул, һичшиксез, тәбрикләр иде, сезне өнләр һәм димләр иде; дияр иде: каһарманнар, гайрәт итегез; гайрәт итеп, дөньяны хәйран итегез! Бу — нәфислек һәм матурлыкны арттыру; түгелдер бу — ахмаклык һәм бозыклык.

2. Беләсезме, бу дөнья нинди дөнья? Бу дөнья — һәр ике дөньяда бәхетнең башы. Бу юлны, зинһар, мәнге ташламагыз, чөнки бу — милләтне алга илтүче юл... Бу юлда, шөбһә юк, без жан бирербез; ниһаять, милләткә дан һәм шан бирербез... Күк булып күкрәр һавада хөр яшәү даулашлары, ялтырар изге көрәшнең хәнжәре, алмаслары.

Йөрмәсен бәгъре өзек милләт киеп кашсыз йөзек — без аның бик зур фәхерле[18], чын бриллиант кашлары!

3. Бу тормыш кем белән туктар талаштан? Сугыш син һич тә армас-туктамастан. Синең төсле берәү ул: бергә-бер сез, көрәшкәнне жиңә алмый ул каберсез...

Авырлык төшсә түз, сер бирми-нитми... Жиһанда үлми һәрбер ыңгырашкан, вә юлны тапмый калмый һәр адашкан...

Якын дустым! Сиңа миннән киңәш шул... Эчендә нәрсә янганын үзең бел, үзең кайгыр, үзең егъла, үзең көл. Ачып яшерен хәзинәңне йөрәктән, сөйләшмә бер дә артык сүз кирәктән... Кача күр, кош кеби, мактауларыннан, хәбәрдар бул ки шунда ау барыннан. Әгәр басса сине бер-бер заманны егъламый йомшамас хәсрәт вә кайгы, утыр аулакка, кайда һич кеше юк, сабыйдай, тәмле-тәмле күз яше түк. Килеп керсә берәү нәкъ шул чагында, сиңа мин бер киңәш әйтим тагын да — диген син: «Күзләрем никтер авырта, өзелми яшь ага кич һәм дә иртә!.. »

Сәгадәт талына менсәң — үзең мен; ни ярдәм килсә дә килсен үзеңдин... Тартыш кирәк, кирәк тартыш!..

Берәүнең уйларын икенче берәү бикләп куя алмас; теләгендә нык торучыны беркем өметсез итә алмас. Тәңребезнең безгә кушуы: «Өметсезләнмәгез!..» Кояшың яктырсын... Курыкма, синең йолдызыңны Тәңре бәхетсез итмәс... Тырышмалы!..

Ир кеше теләкләрен күнелендә яшереп тотмас; үзен бер генә урынга агач кебек беркетеп куймас...

Саклан, күнелендә урын бирмә таләптән башкага; хаклык теләүче үз максатыннан бүтәнгә күз салмас. Хаклык үзенә иярүчене һәр хәлдә кире какмас; ялганны ялганга чыгарыр... Милләт иблис күләгәсен Тәнре күләгәсе ясамас. Хаклык зәгыйфь дип куркып, юлыгыздан чыктыгызмы? Тоткан юлны ташлау сезне, әлбәттә, бәхетле итмәс...

Ләззәт вә тәм нәрсәдә?.. Тик фәкать милләткә хезмәткә мәхәббәт... Бунда ямь дә бар, ләззәт тә бардыр, тәм дә бар!

4. Эшнең дөрестен сөйләргә кирәк... Без беләбез ки, татар шәкертен кеше ясар өчен, ин элек, аның «вәкар»ен бозарга кирәк. Бу — өй салганда ин элек нигездән башлау, сүткәндә түбәдән тотыну кебек кагыйдә инде... Бар егетләр: бик тәкәбберләрчә тоткан позасын... Андый «вәкарь» яшьлектә жимерелмәсә, ... неграмотный үләчәк «зате галиләрдә»[19] дә кала. Мисал эзләсәнез, күктән йолдыз эзләгән кеби генә булып, аны табуда зәхмәт чикмәссез... Инсаф кирәк... Тәкәллеф ише кимчелекләрне ташлыйк!..

Кызыкма һичвакыт шөһрәткә син; бик төренмә, иртәгүк артык булыр чүпрәккә син. Тапмасам шөһрәт, сизә алмаслар, димә күнелемдәген, зур тәрәзә бар дип анла дөньяга күкрәктә син...

Гафу итәсез... Шулай тәфсилләмәсән, татар анламый... Моны яздым, кинәш бирдем, юаттым һәм тыйдым, куштым; шулай булмыйча хәл юк, инде калган мин генә дустың!

5. Яхшы булыр тапшырсак без дөньяларны образауный егетләргә... Барып керик хөрриятнең кочагына, тәрәккыйнең күкләренә очмагына; бу егетләр безне дөнья оҗмахына кулдан тотып житәклиләр...

Измәсен яшьләрне дә күптән яше үткән кеше!

6. Татар яшьләре... Аналары тәрбиясе алар өстенә фарыздыр... Аналарын карасыннар, тәрбия итсеннәр, чөнки оҗмах аналар аяк астында табыла.

7. Сез — интеллигентлар... Татар халкы арасында хисапсыз күп зыялылар... Зыялыларымызга һәр ничек, жәсарәтле пожарныйлар кеби, жәһаләт ялкыны эчендә дөрләп янган милләтне, тизрәк утка атылып, коткарырга тырышу фарыздыр. Пожарны читтән тамаша кыйлып кына көлеп тормак — ирлек түгелдер.

8. Яшәсен гайрәтле милләт арысланнары!.. Яшәсен яна, яшь милләт каһарманнары!..

Татар яшьләре!.. Һайдәнез... Милләткә... тәкрар әйтәмез...

Бар уем кичен—көндезен сезнең хакта, милләтем; саулыгың — минем саулык, авыруың — минем авыруым.

Син каршымда бар нәрсәдән дә изге һәм хөрмәтле; дөнья бирсәләр дә сатмам ... миллиятемне...

Һичшиксез, һәр хыялдан татлыдыр милләт хыялы... Үтәргә иде юлда... түләү белән бурычны Тәнремә һәм халкыма... Шушы юлдан ризамын, башка төрле юл да тотмыймын...

Күнел берлән сөям бәхетен татарның, күрергә жанлылык вакытын татарның. Татар бәхете өчен мин жан атармын: татар бит мин, үзем дә чын татармын.

Хисапсыз күп минем милләткә вәгъдәм... Минем тырышлыгым һәм эшләрем бушка китмәсен.

## V. Нигә тарихтан гыйбрәт алмыйсыз?

1. Артка карасак борылып... Ачыла алдында тарихтан театр пәрдәсе: «Ah!» дисен, без ник болай соң? Без дә Хакның бәндәсе... Түбәннәр югары ашкан, бөекләр түбән төшкән...

Әйтсәгез, сездән сорыйм мин: бездә нәрсә юк иде?!.

Мәгъмур[20] Болгар шәһәрләре, Болгар авыллары, бер дә булмаган төсле, кырылдылар да беттеләр... Китте Касим, китте Казан. Бетте татар, кырылды хан... Жылый-жылый бирделәр жан: Сөембикә дә Чыңгыз хан; нә дәүләт калды да, нә шан!..

Күпме михнәт чиккән безнең халык, күпме күз яшьләре түгелгән... Аh, ник соң без булдык вәйран? Бөтен дөнья калды хәйран...

Нигә тарихтан гыйбрәт алмыйсыз?

2. Юк шул безләрдә берләшмәк; юк бергә-бергә гөрләшмәк, бер жан, бер тән булып, һәр нечкә серне бергә серләшмәк... Фида булган мөрәүвәтле[21] бер жан кирәк.

3. Вакытында жирне селкеттек... Инде эш үтте, булачаклар булды!.. Кемгә ләгънәт әйтәсе һәм каргасы?.. Шулай булган. Заман кичкән. Сулар аккан... Каршылык юктыр Ходайның иркенә.

4. И Жир, синдә — синен куенында ничә төрле кавемнәр бардыр?.. Бу, корткырмыскалар кеби, дөньяны каплаган адәмнәр эчендә Әмерләренә буйсынып, максудка житкәннәрне бик аз таптым.

5. Дөньяда һәр нәрсә дә үз асылына бер әйләнә... Эшкә ябышыр чак житеп, ямьсез озын төн үткәнен күз ачып белдек без, үлчәп күктәге Чулпан белән.

Булса да ул чакта бездә керсез иман, саф күңел, күз һаман булды эренле, йөз дә саф һәм пакь түгел. Шул сәбәпле дустны, дошманны дөрест фәркъ итмичә[22], күп саташтырдык ... шайтанны чын инсан белән. Аңгы-миңге баш белән дә эшләдек — булсын кабул.

6. Без һаман сабыр итәмез... Бу тормышка кальбән[23] разый булган кеше мөселман да түгел, мөэмин дә түгел, инсан да түгел диясем килә.

7. Хикмәти Хода, кая карасаң, анда без фәкыйрь милләтнең бер җире житмәгәнлеге заһир була!..

Үтте инде, дустларым, ул үткән эш, ни булса ул; инде эшлик саф, ачык күзләр белән... Фәиннә мәгаль госри йөсра**.

## VI. Вөҗданың белән килеш

1. «Аh!» дисен, без ник болай соң?..

Сүзне ничек башларга кирәк? Хәер, болай башласам да ярый бит... Туры әйтергә ярага̀нда, кинаяләргә сыгыну нәрсәгә?.. Китмәсен хак сүзгә һич кәефең синең... Тыңламасаң бу нәсыйхәтне, язу бушка фәкать...

Бик югартын күз салырга башладык әхлакка без, кер күңелдә күплегеннән бармыйбыз ак якка без... Әхлак, вөҗдан, инсафларны сөреп чыгардык истән дә; бозылдык шулкадәр начар, уздырдык без иблистән дә... Мәлганәт[24], пычрак вә ялган берлә тулган безнең эч; бар начарлыктан, бозыклыктан гыйбрәт безнең эш... Көнчелек, үчлек белән тулган татарлык, төяп илтеп Мәкәрҗәдә сатарлык.

2. Шаккатабыз тышкы зиннәтләр, киемнәргә карап... Өстеңдә әйбәт кием булгач, синең бәрәңге генә ашаганыңны кем белә?.. Жан сатабыз әллә нинди вак «тиен»нәргә карап... Йөз сумны урлап килгүче угры кеби, күз салабыз чын сүз әйтердән элек як-якка без. Бер сүз әйтергә сараңлансак гакыллы ярлыга, гөл кеби сүзләр чәчәбез акчалы ахмакка без... Акча барда бар да дуст шул, бар да яр; акча исе чыкмый торса, бар да яныңнан таяр!..

Кешеләр үзләрен анчак сөяләр, бәхетсезләрнең өстеннән көләрләр...

Туктале, бер көн килер дә өйрәтер, әлбәт, ләхет, миллионың ул тар ләхеттә файда бирмәс... Анда хакимнәр дә алтыннарга һич алданмыйлар; анда адвокат та юктыр — акчага ялланмыйлар.

3. Күрмәгез бер яклы дип сез бу вафасыз дөньяны; ул ике яклы: аның бардыр иләк һәм күн ягы. Әйләнә, көпчәк кеби, байлык вә шөһрәт, мәртәбә: син бүген бай, бәлки, шайтаннан да ярлы иртәгә!..

Килсә теләнче капкана, каты сүзләр берлә инсаниятен син таптама... Булса — бир, булмас исә, жайлап сөйлә булмаслыгын, сизми калма ак сакаллы картның Хозыр Ильяслыгын!

4. Дөресне сөйлә, ... беркемнән дә курыкма; сабыр бул, чөнки сиңа эшнең жинеле йөкләнмәгән...

Дөнья яратылганнан бирле ялганнар кубесенчә тотылмый калган... Һәр аллауга ышанмаска кирәк, алданмаңыз, карендәшләр, гафил улмаңыз... Алданмаңыз, болар сезнең дошманнарыңыздыр, болар тик үз файдалары өчен генә тырышып, сезне әсирлектән чыкмасын дип тырышучылардыр...

Дустлар, тугъры юлдан китик... Барыбер без алданмыйбыз дигәч алданмыйбыз!

5. Усаллык хәзинәсе бик зур, ул — күпме алсаң да бетми...

Өметсезлек, усаллык, вәсвәсәләр зәгыйфь жанны теләләр һәм кисәләр... Син үзеңчә изге эш эшлим дигәндә халкына, әллә нинди былчырак баулар салалар гакълына: «Бу заман шундый заман, — дип, — бу вакыт мондый вакыт, син үзеңне дөньяда безнеңчә йөрт, безнеңчә тот...»

Дөрест, һәрбер халыкта бар дорыр мондый кара йөзләр... Алар ерткыч, алардан читтә бул син, алар барда бүрең бер якта булсын...

Житәр, инсаф кирәк, инсаф кирәк... Ярлыкау эстә, шөкер ит, тәүбә кыйл...

Файдаланыйк кинлектән, ваз кичик мин-минлектән... Бүлик без бер алманы биш кисәккә... Жыйналып мәжлес ясыйк... Тәнемез аерым булса да, бер жан булыйк.

6. Эчә халык суык дип тә, бәйрәм дип тә, эчә халык хәләл дип тә, хәрәм дип тә; «Кытайский әфлисуннар яшьнектә», — дип, «Эчми үткән яшьлек гомере әрәм», — дип тә...

Жөмләдән берсе... Мәктәпләрдә укыр чак... Мин... үземне һәрвакыт мулла баласыча тотарга вә укыган китапларым илә гамәл итәргә тырыша идем. Мәсәлән, бер заман... минем илә күрешергә... авылымызнын шактый могтәбәр кешесе килде, үзе исерек иде. Мина килеп сәлам бирде — сәламен кайтармадым, кулын сузды — кулын алмадым. Сәбәбен сорадылар. Мин шул вакыт «Бәдәвам»нын:

Исереккә сәлам бирмә,
Ул бирсә һәм син алма... —

дигән бәетен ярдым да салдым...

Дөнья булгач кеше төрле хәлгә килә шул... Әхлаксызлык... Электән белгәнем хәлдә кешенен тышы яхшы, бозыклыгын эченен..., хөкем итмим, Ходай кыйлыр үзе судын...

Безнен гомер уен түгел, бәйрәм түгел, һич кайгысыз кеше булса — алэм түгел! Бераз вакыт шатлык таба исерек кенә, үз-үзенә ачы агу эчереп кенә... Эчә дустлар чәкәшеп, күзне-күзгә текәшеп; эчкән була карчык та — үзе беткән бетәшеп...

Әгәр күрсәң кызарган йөз аларда, бер дә алданма: «Оялгандыр», димә янлыш, «Жибәргәндер», дисән — әүлә[23]!

7. «Шайтан аздырган», имеш! «Юлдан яздырган», имеш! Кире татар, ин элек вөжданың берлән килеш!.. Сезгә һәм безгә ни житмәгән?..

Без ул милләткә... үз сурәтен үзенә күрсәтик... Күзгә каршысына китерик... Милләт күрсен... Ләкин авызы кыйшык кешенең авызын туры күрсәтмәгән өчен көзгене атып бәрмәсен...

Жинел уй, йөз кызарткыч төрле хисләр, сезгә мен ләгънәт! Яшә, тугъры караш, төпле гакыл, меңнәр яшә, хезмәт!

## VII. Исламның миллиятне сакларга кушуы табигый

1. Безләрне туры юлга күндергән Коръән икәндер... Анлангачтын Коръәндәге бик күп серләр, үз-үзеннән агаралар дини керләр...

Ислам бит хак дин, ә хаклык, һичшиксез, гел өстен булыр.

2. Исламнын миллиятне сакларга кушуы табигый... Билгеле ки, дин кешеләрдән аерым түгел.

3. Наданлык таптамасын — яньчелербез, каләмгә каршы бармыйк — чәнчелербез. Каләм — хөкем йөртүче Жир йөзендә, анын белән ант ителгән «Нүн» сүрәсендә...

Болар бит исламга терәк, безгә боларга таянырга кирәк... Көчсезләргә иптәш, көчлеләргә житәкче, болар — бөтен ислам инануларын ачыктан-ачык күрсәтүче...

Каләм — бөек, каләм — дәрәжәле; Ходайнын теленда ант урынында ул. Каләм — данлы, каләм — шанлы; каләм ул — чиргә дәва, кайгыны юар сабындыр...

Дин димәк — бетмәс-төкәнмәс бер хәзинә ул.

4. Шәригатемез — Коръәне хәдистер, Коръәне хәдис тә кыямәт барачак, анда бер дә шик-шөбһә юктыр...

Һәр кешенен үз хезмәте вә хәләл кәсебе илә тапкан бер телем икмәге юк

шәригатьләр чыгарып, фәлән кеше — кяфер, фәлән — фасикъ[26], син генә яхшы дип мактап яхшы булудан артыктыр.

5. Динле булып күренү — бик яхшы бер кәсеп ул... Бер кешене кяфер дип йөрү бик зур кабахәтлектер. Газиз иман капкасының ачкычы сезнең кулынызга бирелмәмештер. Сез үзенез теләгән кешеләрне иман капкасыннан кертеп, теләмәгәнне — чыгарып җибәрүгә нинди права таптыныз? Юк, сездә бернинди дә права юк.

6. Наданлык сәбәпле көфергә төшү җинел инде... Бер дә исенез китмәсен: Мәккәи мөкәррәмәдәге кәгъбә янында гөнаһ кыйлу мөмкин булган шикелле, Киевтәге монастырь янында саваплы эш кыйлу мөмкиндер...

Хак Тәнренен каршысында килешмидер тәһарәтсез намаз илә корбансыз хаж!..

Килешмидер Коръән уку, тәсбих әйтү фәхеш-вәхшәт берлән тулган бер ханәдә... Фахиш тавыш, фахиш рух, фахиш көй! Фахиш мәгънә! Менә шулар безнен фәхшиятсез, пакь мөселман түрләренә кереп утыралар...

Әйдә, дустлар, бер тибрәник, акны Тәнре яклар бит... Караны бер көн каралтып, акны бер көн аклар бит.

7. Мөхәммәд динен яклаучы!.. Бу эшләрдә зәхмәтләмик муллаларны, дин эшендә башчы иттек без аларны... Җитәр дин исеменнән кеше талау, җитәр шәригать исеменнән халыкны каралту, җитәр болганчык суда балык тоту! Батсын фанатиклар!

8. Җитми мыр-мыр хәтем — чын, саф Коръән кирәк... Телсез муллалар бер нәрсә әйтмәкче булалар, ләкин, аһ, наданлык, иреннәрен селкетәләр дә, бер нәрсә дә фәһемләнми.

9. Ялганчылар, гамәл сатып ашаучылар, ... үзләре яхшы аңлап җитмәгән нәрсәне балаларга укытып, ислам балаларының гомерен ашаган хәлфәләр, ... барлык һиммәтләрен[27], һәммә гайрәтләрен трахтирларда, мәйханәләрдә генә күрсәткән байлар... И явызлар!.. Динне хурладыныз, мөселманлыктан көлденез! Галимнәрне танымадыныз. Тугъры сөйләгәннәрне кыстыныз, изденез... Җавап биренез!..

10. Җәза бирми халык һич тә гөнаһ эш, яшерен эшләргә... Җәзалау камчысын биргән гөнаһлы ул халыкка кем? Түгел, юк. Бирмәгән һичкем; Ходай — гадил[28], Ходай — хаким!

11. Ашау-эчү өчен күнелен борчылмасын. Үзенне «байлардан ярлы» дип санама; тыр-тыр итеп бәлешләргә йөгермә... Бәлеш белән гыйлем бергә җыелмас, комсыз кеше үлгәнче тыелмас... Комсызлык — түбән, бик түбән сыйфат ул... Азыгынны Алладан өмет ит...

Хәзрәтләр, хәттин узмагыз!

12. Мөэмин булсан, чын мөэмин бул — намазынны калдырма...

Бездә җомга көннәргә дә бер дә игътибар юк: ул көннен бәйрәмлеге бер дә күнелдән хис ителми; халкымыз, бүген җомга, бүген бәйрәм, дип, яна киемнәр киеп, руслар якшәмбене олуглаган кеби олугламыйлар.

13. Мулла ахрысы фәрештә түгел, анын да остабикәсе бар, бала-чагасы бар, фатир түлисе бар — ни эшләсен, ачка үлсенме?..

Ну, болай булгач, мулла гаепleme? Әллә безнен милләт гаепләме? Әлбәттә, милләт гаепледер...

Бер мулла биш вакыт намазда, җомгаларда, гаетләрдә имам тора, никах, талак эшләрен карый, казыйлык итә, туганнарны, үлгәннәрне, никахланганнарны яза. Шул арада ук мәдрәсәгә кереп мөдәррис тә була... Зиратка да бара. Җә, бер кешегә бу кадәр хезмәт бирелсен дә, ул кешегә ни өчен жалование алу дөрест булмасын?!

Әүвәл бер кешегә шулкадәр эш бирү дөрест түгел, инде бирелгәч, анар жалование бирмичә, теләндереп йөртү дөрест түгел. Бер култыкка ике үгез башы

сыймавы, бер көймәче ике көймәнең койрыгын тота алмаганы һәркемгә мәгълүм була торып, бер муллага әллә тагы 20 төрле эш биргәннәр. Шулай булгач, ул мулладан нинди укыту, нинди иҗтиһат, нинди хәер күтәргә кирәк?

Минем уемча, муллаларны жалованиеле ясарга кирәк — бер; һәм аның өстендәге йөкләрнең һәрберсен аерып, үзенең иярәренә тапшырырга, йөкләтергә кирәк — ике... һәм боларның һәрберсенә аерым-аерым жалованиеләр бирелсен...

Муллаларның берсе бигрәк тук, икенчесе бигрәк ач булуының һәм дөрес укыта алмауларының... һәммәсенә сәбәп жалованиесезлектер. Шуның өчен мин үз тарафымнан, муллалар жалованиесез хезмәткә көчләнмәсеннәр, дип әйтергә батырчылык итәмен.

14. Үзенә башка хатиб, вагыйзьләр дигәнемез дә, безнең хәзергә чаклы булган муллаларымыз төсле, мөнбәргә менеп, баласын тирбәтеп жоклатучы хатын шикелле, халык анламаган тел илә көйләп, жырлап, халыкны гыр-гыр жоклатмасыннар, тик өч мәртәбә «әлхәмделиллаһ»ны гарәпчә әйтсәләр житәр. Вагыйзьләр безнең үземезнең ана телемез илә безгә, динемезгә, дөньямызга кирәкле вәгазьләр сөйләсеннәр. Халыкның тамырлары буенча каннарын йөгертеп, күз яшьләрен чыгарып, әллә кай жирләрен чеметтереп-чеметтереп алсыннар. Мөнбәргә менгәч, фәлән мәкам берлә жырлау, төгән көй илә көйләү бик зур оятлыр. Иске муллаларга алай гавам халкын көйләп тирбәтеп жоклатканчы, бер дә кешесез сахрага чыгып, гарәп шигырьләре көйләсәләр, артыграк булыр иде...

Хатибның сүзләре дару хөкемендәдер. Даруны, шифа биргәч, ачы булса да эчәләр бит.

15. Халыкның жыелган жире мәҗлестә, милләт исемене бер-ике калимә булса да, халыкны гыйлемгә, сәнгатькә өндәсәләр, нинди яхшы булыр иде... Мөмкин кадәр дөнья, ахирәт өчен файдалы мәгърифәт хасил кыйлмак кирәк...

Кыскасы гына, милләтнең тәрәккыйсенә вә башка милләтләрнең аяклары астында тапталмавына кирәкле нәрсәнең һәммәсе дә саваплы вә хәерле бер эштер... Һайдәнез, борадәрләр[29]!.. Галәме исламга нур сачик, нурланыйк, тырышыйк!.. Без... халыкны караңгыда калдырып алаштырырга кулымызда аз гына бер икътидар[30], тәнемездә жан бар вакытта аслан разый булмаячакбыз.

## VIII. Гаилә өчен иң кирәге — тигезлек

1. Өч кешедән дөньяда качып котылып булмый: берсе — кендек әбиседер ки, ул сине теләсәң дә, теләмәсәң дә дөньяга тартып чыгарыр. Икенчесе — жаучы карчыктыр. Ул сине, аласы кызынны күрсәң дә, күрмәсәң дә, алырга теләсәң дә, теләмәсән дә — өйләндерер. Өченчесе — мәзиндер. Ул сине теләсәң дә, теләмәсәң дә — жуар да күмәр.

2. ... теләмәсән дә — өйләндерер... Юк, ул алай булмый шул... Файдасыз бер ит кисәгеннән гыйбарәттер йөрәк, парә-парә кисмәсә гыйшык-мәхәббәт кайчысы...

Әгәр булса «сөю»... кочаклау куллар арганчы, үбү булса әгәр чут-чут, ирен һәм бит кабарганчы — гомер дә сөйгәнем юк һәм «сөям», дип әйтмәмен һич тә; сөюнең мәгънәсе, минчә, бигүк гали, бигүк нечкә.

3. Үзенә нәрсә лаек икәнен һәркем үзе белә... Мәхәббәт төрлечә... Мин, ахрысы, сөюдә дә милләтче... Мин татар кызының телен, сөйләшү рәвешен яратам.

4. Өйләнү — түгел сөйләнү... Гаилә хакында минем фикерем коры гына: ... син аны, ул сине якыннан белеп яратышсаң, шуның өстенә... килерен булса, һәркемгә өйләнү тиеш. Югыйсә, эченә сәнәк белән төрткәндә, бер тамчы кан чыкмаслык булса, ике күнеллә чын мәгънәсе белән булган мәхәббәт уты янмаса,

гаилә өчен әллә нинди түбән кешеләргә мөрәҗәгать йә тәлинкә тотарга булса — Алла сакласын!

5. Тигез-тинлеккә юл куймау бездә гадәт. Ярың тин-пар булмаса, әлбәттә, һәлакәт, пар булу шарт, пар булу шарт, пар булу... Бирмәде Ләйлә кеби мәхбүбәгә[31] дөнья бәһа; ул болай бер кыз гына — каршында Мәҗнүн булмаса... Өйләнештә иң кирәге — тигезлек.

6. Күңелсез сүз сөйли бәгъзе гакыллылар хатын-кызга: фәкать бер ел күңелле, дип, календарь һәм хатын безгә... Хатын өстенә хатын алсаң... Житмәгәнме бер хатын, өч-дүрт хатын асрау нигә?..

Хәзерге өйләнүчеләр... Күңелләр саф чагында шәп, матур кыз сайлыйлар анлар: «Булыр безнең хатын булса йөзе айдай», — диләр анлар. Әгәр басса дөнья һәм муеннарда бурыч тулса, убырлы карчыгыңны да алырлар, акчасы булса.

7. Алашкан кыз... Төшкән ул сатлык кызлар рәтенә... Суына төшкән кочагы. Шулай да ул типтерә, бетәсен сизеп тора; җылыйсы күз яшьләрен күз эчендә киптерә...

Уйнаш кыйлуы бик уңгай да, бала табуы бик читен, диләр... «Уйнаш»тагы*** яман күздән Ходай үзе сакласын.

8. Аерылу һәрвакыт начарлыкка илтәдер. Аерылмаңыз!.. Хөррият, ирек — барча кешеләргәдер; бай, фәкыйрь, галим, җаһил, ир вә хатын һәм милләт аерылмаенча, һәркемгә бертигездер.

## IX. Туган тел. Дөньяга фикеребез юл алсын

1. Мин Казанны тәхте пай[32] һәм Казан арты татарларын шушы көнгә кадәр милләтен югалтмаган вә киләчәктә дә югалтмаячак төп халык дип саныйм. Милли әдәбиятымыз фәкать шулар телендә, шулар рухында гына булуын телим.

2. Үз араларында төрекчә сөйләшеп маймылланучы шәкертләр, башларына фәс киеп, «Госманлыез, әфәндем», дип йөрүче хиффәтләребез[33] дә аз булмады. Ләкин мондый комедияләр вакытында булды да, узды да китте... Без татарлар һаман да татарлар булып калдык. Төрекләр — Истанбулда, без — монда.

3. Язучы... Каләме — милләткә файда, язганы — Хак көзгесе... Безнең милләткә кирәк... Каләм иясе булып чыгучыларымыз күбәйсен, солдатның өстенә дә шинель, астына да шинель, баш астына да шинель дигән шикелле, алай тартсак та, шул бер-ике мөхәррир, болай сузсак та, бер-ике язучыбыз гына булмасын. Мөхәррирләр гаскәрләр кебидер: сугышка чыкканда, запас гаскәрләребез булмаса, әсир булырмыз, хур булырмыз...

Боларның кемлеген яхшы белик без, боларның артуын Ходайдан телик без...

Әлхәмделиллаһ... Милләтнең яшь каһарманнары каләмгә сарылды... Каләм кулда була торып, ... мәгълүмдер ки, курку берлән өркү хәрәм... Ничаклы изсә дөнья, ирке бар — куркытмыйдыр безне...

Илаһым, рәхмәтең белән шагыйрьнең бәйле телен чиш; дуслар һәм дошманнар хәленнән ул бераз хәбәр бирсен.

4. И каләм! Китсен газап, ит син безне шат; без дә синең арканда туры юлга басыйк аяк... Милләткә мәрхәмәт ит... Европаны күтәреп син югары күкләргә кадәр, ник төшерден безне — җиде кат җир астына кадәр? Милләтнең бу хәле хикмәт китабына теркәлгәнме?.. Чакырып яз укырга, уку кыйммәтен тәкъдир ит...

Яз караны «кара» дип һәм акны «ак», җөпне «җөп» дип һәм шулай ук такны «так». Һәр кеше күңелен генә күрмә, милләт авыруына бак!.. И каләм, безгә һәрдаим ярдәм һәм мәрхәмәт ит.

5. Кеше ата берлек белән туган түгел, бәлки фикер һәм тоткан юлы белән кардәш була... Максуд житәр: бара торгач — юл кыскарыр... Алгарыш һәм күтәрелеш юлларына атлап үтик... Алга адым сал, татар... Бари Тәгалә сезләрне... сәламәт кыйлсын... Тән урнашмагач, җан урнашмый. Җан урнашмагач, фикер урнашмый...

Фикерегезне язгыгыз да фикергә фикер ялгагыз... Тик якты булсын фикерегез; фикерегездер — фикеребез һәм фикеребездер — фикерегез... Олы фикерләр кузгалсын... Дөньяга фикеребез юл алсын. Чөнки фикерләр кайнаса, эшләр дә алга китәр, — бу мәгълүм булсын һәркемгә, — шушындый безнен фикер.

Борынгыдан бирле безнен фикеребез тоткын иде. Кем соң безне мескен итеп тоткында тоткан иде? Килде форсат кысан читлекләрне итәргә тар-мар, килде, иркен сулыш алып, вакытыбыз канат кагар.

Фикеребез торсын янарып гел... Искермәсен, үзара җәнҗал-ызгыштан кыл каләр ис кермәсен! Фикеребез халыкны таркаткыч җилләр истермәсен, истереп, милләтнен берләшү юлын кистермәсен!

6. Яшәсен әрбабе каләм[34]!.. Яшәсен туган тел!

И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнен теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем
Син туган тел аркылы.

Ин элек бу тел белән
Әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе
Әбкәм хикәят сөйләгән.

И туган тел! Һәрвакытта
Ярдәмең берлән синен,
Кечкенәдән аңлашылган
Шатлыгым, кайгым минем.

И туган тел! Синдә булган
Ин элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм
Әткәм-әнкәмне, Ходам!

## X. Үзегез милләткә нәрсә эшләдегез?

1. Дөрестен әйткәндә, халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул. Ул әле, әллә нинди кара көчләр басканга күрә генә, бу күренештә йөри. Ләкин бу хәл вакытлы гына килгән бер авыру кеби...

Без ул милләткә әдәбият гөл-сулары сибик... Җан рәхәте булган музыкалар илә дәртләндерик, хәтта рәсемнәр илә милләтнен үз сурәтен үзенә күрсәтик; тәмам күзе ачылсын, дүрт ягына карансын, гакылын җыйсын.

2. Карендәшләр! Уйганаек, заман уйганмак заманыдыр... Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен... Як-ягымызны карап, дөньяның барышыннан хәбәрдар булалым. Башка милләт халкының барышыннан гыйбрәт алып, безләр дә алга таба аякларымызны атлап, һәр сәгать алга йөрмәгә иҗтиһат итик... Элек йоклап үткәргәнебезне уйлыйк та үкеник... Кыю һәм батыр рәвештә алга хәрәкәт итик...

Бушка узмасын һич безнең һәр ай, һәр ел, тәрәккый итеп тотыйк алга юл... Тырышыйк... Һәр көн үзгәрә заман... Тырышырга кирәк, карендәшләр! Уяныгыз да тартышыңыз. Тартышуда гына табарсыз сез үз хакыңызны!.. Изге эштер тартышмаклык хокук өчен... Тартыш, зинһар, тартыш, тартыш!.. Теләсәк яшәргә, дәгъвабызны исбат итик, дәлилләр китереп... Киләчәктә бәхетләр көтә безне...

Элеккечә кайгы-хәсрәт, ачынуларга хәзер урын бармы?.. Җанлансын халык, бар моңын, барлык зарын өстән салып... Тор! Тартыш! Тиз бар, татар... Тор! Селкен! Кузгал, татар!..

Житәр инде, житәр инде, давайте, сызганыйк жинне; ... һич өмет юк жинне сызганмай... Ачыйк иттифакъка[35] юл: ушбудыр ин тугъры юл; сынар жиннән ике кул чыгарыйк без...

Тотып милләт ливасын[36], юлга чыктык: «Бу куллар мәнге, дип, жиргә салынмас».

3. Бер теләктәге кешеләр, бер сүздә булып, мәйданга чыгып... Тырышып, күп акчалар тотып һәм төрле-төрле чаралар күреп, ниләр эшләмәс бу милләт, әгәр керешсә!..

Татарда акча юк, байлык та юк, дип, юкны сөйлиләр... Татар акча тапмый түгел, таба... Тау кисәр эшлекле ул — тотынса, дөнья төзәтер... Алла мондыйларнын санын арттырсын.

4. Тәрәккый дә итәмез, һәр нәрсәне күтәрәмез дә...

Безнен татарларда, ин әүвәл мәртәбә әйткәндә, һәрбер нәрсәгә каршы тору ата-бабадан калган бер гадәттер. Алар, иң әүвәл чыкканда, ысулы җәдит берлә укуга да каршы тордылар. Кара тактанын эченнән «тавык аягы» да эзләп маташтылар. Бара торгач, белделәр ки, кара тактаның эчендә «тавык аягы» түгел, «чебеш аягы» да юк, имеш!..

Өч яшьлек балага да үзенең сәламәтләнүе өчен дару эчерсәң яки: тышка яланаяк, яланбаш чыкма, дисән, билгеле, каршы торадыр. Шунын шикелле, татарларга да: болай итсәнез, сәламәт булырсыз, тегеләй итсәнез, үзенез өчен яхшы булыр, дисән: «Э... э... кирәкми, э... э...», — дип киреләнәләр...

Дөрест... «Яңа» дип һәр нәрсәгә мөкиббән кителмәскә... кирәк... Вәләкин... Нигә кирәк искелек, кирелек?.. Кирелек, наданлык гаскәрен жинеп, сындырып ташлыйк... Якты көннәр алда... Хужа Насретдин шикелле, атнын артына карап атланмыйк.

5. Бу заманда гафилләргә дөнья тардыр... И кардәшләр, кул тотышып, алга барыйк, башка милләтләрнен хәлен карап карыйк; мәдәният мәйданында урын алыйк, егъла-тора, алга таба атлыйк!..

Кем жигә безгә тәдәнни[37] арбасы?.. Безгә аяк чалырга маташсалар, янә безне алар белән кычкырышу кебек түбәнлеккә сөйрәсәләр, без аларны бергәләшеп юлдан алып ташлап, яки «Безнен юл беләнме, әллә түгелме?» дигән сорау куеп, ничек тә аларны ераклаштырыйк...

Без мөһажим улмай, анчак мөдафигъ улдыкымыз җәһәттән хәкыйкан бәхтиярез.****

6. Рус жирендә без әсәрле, эзле без, тарихында бер дә тапсыз күзге без. Рус белән тормыш кичердек сайрашып, тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып. Бергә тормыш, бергәлек чиктән ашып, без шаярыштык, вакытлар алмашып. Һич бетәрме тарихи бу бергәлек? Без туган бер жепкә бергә теркәлеп.

Без сугышта юлбарыстан көчлебез, без тынычта аттан артык эшлибез. Шул халыкнынмы хокукка хаккы юк? Хакъкыбыз уртак ватанда шактый ук!

7. Без — руслар белән татарлар — һәр вакыттагы кеби, тату гына, честный гына алыш-биреш итеп тора алабыз... Бик яхшы бит!.. Дуслыкта берлек, тигезлек, тинлек кирәклеген әйтмәсәм дә беләсез инде.

8. Һәр милләтләр максудларын хасил итә... Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнен әҗәл; бәйләмеш бу жиргә безне Тәнребез (Гыйззе вә Җәл). Ин бөек максат безем: хөр мәмләкәт, хөр Русия!

9. Әйдә халыкка хезмәткә, хезмәт эчендә йөзмәккә; бу юлда һәртөрле хурлыкка, зорлыкларга[38] түзмәккә!..

Һәр заман хакны сөючеләр сездәй каһәрләнгән булыр... Бармыни бездә, гомумән, чын кеше кадерен белү?! Без аны кайдан белик, мескин үлеп анлатмагач?!. Мәмнүн булсын рухлары...

Күрсәтә һәрбер жаһил милләткә золым вә жәбрене, таптыйлар пычрак аяклар берлә милләт садрене[39]... Искеләр белми һәнүз милләт дигән сүз

кадрене... Милләтемез дингезенен энжеләре төптә ятып, «ул-бу»лары гына өсткә калка шул... «Алла бирмәгәнне мулла бирмәс» мәкале бик тугъры сүзлер...

Сезнең болай каршы торуыңызны бик зур гөнаһ дип беләмез. Бу эшләренезне ташлап, тәүбә кыйлмак, кайтмак кирәк... Сезнен урыныңызга үзенез бар заманда һичкем күз җибәрми. Без исәк, һәр каюмыз, Аллага шөкер, төрле-төрле кәсепләр илә шөгыльләнеп йөримез...

Кайчанга чаклы татар... бер-берсенә ук атар?

10. Бар мөселман булалса иде бер гәүдә...

Бездә күзе ачык кешеләр дә бардыр... Бер-беребездән качмыйк... Барчабыз бер юлдан тырышып атлыйк... Гыйлем белмәс хайваннарга без охшамыйк, тырышмактан, тырмашмактан һич бушамыйк... Килер бер көн: милләтен сина шәфкатен күрсәтер... Фәкать сабыр кирәк.

## XI. Аерылышу соңында

1. Берегез укыгыз да, берегез тыңлагыз... Кап-кара кол белми хөррият дигән сүз кадрене... Сөальләр җавапсыз калмасын... Сез үзегез милләткә нәрсә эшләдегез?.. Әйдә, дустлар... Тәкрар әйтәмез... Җиһанда калдырып китсәм икән, йа Раб, гүзәл эзне!

2. Эшем һәм ниятем изге иде, ләкин максудыма җиттеме — анысы минем эш түгел... Актык сүз буларак шуны әйтәм... Татарларның бөеклеге, даны сигез кат күкләргә китсен; мәңге, һәрвакыт бу милләтне Ходаем бәхетле итсен!.. Алла ни бирер... Мин догада...

Яшәсен милләт!

Зиннур **МАНСУРОВ** *әзерләде*

## СҮЗЛЕКЧӘ

* Габдулла Мөхәммәтгариф улы Тукаев исеме белән.

** Авырлык соңында җиңеллек тә була.

*** Г.Камалның «Уйнаш» комедиясенә ишарә.

**** Без һөҗүм итүче (сугышны башлаучы) булмыйча, тик каршы торып, аны кире кагучы булуыбыз белән чын бәхетлебез.

Җәсарәт[1] — батырлык, кыюлык; парлак сурәттә муаффәкъ булу[2] — якты зур уңышка ирешү; заһир[3] — ачык; тәслим фитъратендә[4] — кемгә дә булса тапшырылырга тиешле хәлдә; нәсрани[5] — христиан динендәге кеше; нәҗат[6] — котылу; голүм[7] — гыйлемнәр; гатәләт[8] — ялкаулык; асла[9] — һич тә; ләфзы[10] — сүзе; мәнафигъ[11] — мәнфәгать, интерес; мөрәбби, мөрәббия[12] — тәрбияче ир-ат, тәрбияче хатын-кыз; сәляхият[13] — сәләтлелек, талант, булдыклылык; җәһаләт[14] — наданлык; анчак[15] — бары тик; назик вә ләтыйф[16] — нечкә һәм гүзәл; ислах әйләйә[17] — төзәтсен дигән мәгънәдә; фәхерле[18] — мактанычлы; зате гали[19] — бөек зат; мәгъмур[20] — төзек; мөрәүвәтле[21] — үз-үзен кызганмаучы; фәркъ итмичә[22] — аермыйча; кальбән[23] — күңелennән; мәлганәт[24] — түбәнлек, явызлык; әүля[25] — дөресрәк; фасикъ[26] — бозык; һиммәт[27] — юмартлык; гадил[28] — турылыклы; бораләр[29] — туган; икътидар[30] — сәләт, көч-куәт; мәхбүбә[31] — сөелгән хатын-кыз; тәхте пай[32] — башкала; хиффәт[33] — тиле, юләр; әрбабе каләм[34] — каләм ияләре; иттифакъ[35] — берләшү; лива[36] — байрак; тәдәнни[37] — артка өстерәү; зорлык[38] — авырлык; садр (садыр)[39] — күкрәк.

# «ЙӨРӘК КАНЫМ АГА ГҮЯ ТӘНЕМ БУЙЛАП...»

САЛИСӘ ГӘРӘЕВА ИҖАТЫНА БЕР КАРАШ

Татарстан Язучылар берлегенең әдәби ел йомгакларына багышлап үткәрелгән җыелышында бер халык язучыбыз мине тәнкыйтьләп чыкты. Аның актан киенергә һәм уратып-уратып сөйләргә яратканын белгән каләмдәшләрем ул әйтергә теләгән нәрсәләрнең барысын да аңлап бетердеме, анысын ачык әйтә алмыйм, ә менә тел төбеннән үземә тиешен төшендем: Айдар Хәлим, имеш, шагыйрьләребез иҗаты турында күп яза һәм шундый яхшы яза, аны укыганнан соң, ул шагыйрьләрнең бөек булуларына чынлап та ышанасың ки, хәтта Айдар Хәлимнең үзенә шигырь язарга кирәк микән дип уйлый башлыйсың... Чыгышны көнчел кинәяләр чытырманлыгыннан азат иткәннән соң хасыйл булган беренче фикер: әгәр шагыйрьләр шулай мин язганнан соң гына «яхшыра төшә» икән, димәк, алар – уртакул шагыйрьләр; икенче фикер: Айдар Хәлим йомшак шагыйрьләрне мактап язгач, аның үзенә шигырь язып маташырга да кирәкми.

Минем шагыйрьлегем-түгеллегемне, шигырь язарга хокукым булуы-булмавын бу актан киенергә яраткан халык язучыбыз түгел, ә моннан илле елга якын элек әдәби тәнкыйтебез, классикларыбыз һәм СССР Язучылар берлегенең абруйлы комиссиясе хәл иткән иде. Инде андый рөхсәтне беркемнән сорап тормам кебек. Нинди генә каралар ничек кенә актан киенсәләр дә. Мондый очракта шаяны-чыны белән Владимир Маяковскийны кабатларга туры килә. «Йөз елдан соң минем янымa килегез, – дигән ул. – Хуп күрсәм, бәлки сезләргә кулымны да бирермен әле». Ә «уртакуллар» мәсьәләсенә килгәндә, нindирәк уртакуллар турында яздым һәм язам соң мин? Мостай Кәрим һәм Сибгат Хәким, Хәким Гыйләҗев һәм Гамил Афзал, Равил Фәйзуллин һәм Роберт Әхмәтҗанов, Рөстәм Мингалим һәм Ренат Харис, Рифкать Закиров һәм Клара Булатова, Разим Вәлиуллин һәм Фәрит Габдерәхим, Әдхәт Синугыл һәм Мөдәррис Әгъләмов, Рим Идиятуллин һәм Кави Латыйп. Яшьрәкләрдән Булат Сөләйманов һәм Равил Рахмани, Айрат Суфиянов һәм Сирень Якупова, Рөстәм Зарипов һәм Ленар Шәех, Луиза Янсуар һәм Әлфия Ситдыйкова... Буыннары, иҗат-язмышлары төрле булган, кайберләре әле иҗат юлын башлаган гына, әмма ышанычлы башлаган һәм милләтләре-иманнары өчен утка керергә әзер торган бу яшьләрнең кайсысын «сәләтсез, уртакул» дип тамгалап булыр иде? Кешегә канат куйыйк!.. Әгәр иренмичә эзләгән булса, минем моннан берничә ел элек чыккан һәм бары тик тәнкыйть мәкаләләреннән торган «Талант. Шәхес. Язмыш» дигән икетомлыгымнан да таба алмаган булыр иде ул бер генә «уртакул»ны да.

Сорау туа: нигә күрми ул бу хезмәтне? Нәкъ урыны шул – җыелыш тәнкыйтьнең торышына багышланган бит! Нигә моннан ун ел чамасы элек чыккан һәм кайберәүләр әле булса айный алмый торган «Сез беләмсез кая барганны?» дигән мәкаләмә һәм «Татар балалар шигърияте һәм орчык-малай «Биктырыш» дигән китабымны искә алмый унай күренеш итеп? Әдәбиятыбызда чәчкә аткан уртакуллыкка мин шул әсәрләремдә җаным әрнеп каршы чыкмадыммы? Шул гаярьлегем өчен әле булса «репрессия» кичерәм түгелме сон инде мин? Халык язучысы боларның берсен дә күрми. Бу аның идеологиясенә туры килми. Чөнки ул үзе бердәнбер бөек һәм бөеклек өчен башкаларга урын калдырмаган шагыйрь, мине, аның фикеренчә, «шагыйрь булмаган» гавам баласын, аның үзеннән башка шагыйрьләр турында язуымны ошатмый һәм әдәби тәнкыйтькә багышланган җыелышта нәкъ менә шул

әдәби тәнкыйть таләпләренә җавап биргән хезмәтләрне күрәсе, аларга бәя бирәсе урында мина шигырь язмаска куша...

Яшермим, кайчандыр минем тирәмдә чәбәләнеп йөргән бу чибәр энекәшемне кызгандым мин. Шулай эреләнү, чамасыз зур күтәрү, биектән кузгалу өчен күпме акыл һәм талант кирәк икән? Шуна күрә бу, әле башланмаган, чираттагы «башкаларны күрә торган» мәкаләмне менә шулай тәкатьсезрәк башларга туры килгәне өчен мин укучымнан гафу үтенәм.

***

Өстәлемдә чираттагы шигырь җыентыгы – Салисә Гәрәеванын «Йолдыз янгырлары» (Казан, 2006). Җиде ел үтүенә карамастан, һаман да бәясен алмаган. Оясына якын җибәрелмәгән ятим аккош кебек кәтә ул мөлаем карашны. Их, бу юлсызлыкка тин тәнкыйть юклыклар! Шигърият ачылмаган:

*Тимер елый.*
*Минем үзәк өзгеч*
*Шул тавыштан йөрәк сызлана.*
*Телем-телем тиресе салдырылган*
*Тимерне мин өзелеп кызганам...*
*Авыртуны тимер кисәге дә*
*Белә кебек.*
*Бәлки беләдер?!*
*...Корал булып кеше үтергәнче*
*Тимер әллә ничә үләдер...*

Тимер дә елый һәм үлә икән. Нигә моны ачмаганнар? Бер китап кына түгел, барлык гомерен шигъриятькә багышлап, яшәвенен, кем әйтмешли, классик түбәсенә килеп житкән шагыйрәнен иҗаты тулаем үз бәясен алмаган. Анлыйм, киләчәктә ана биреләчәк бөтенхалык бәясенен мин биргән бәягә тин яки югарырак та булуы мөмкин, әмма һич түбән булмас һәм ул бәя бирер көн барыбер киләчәк. Шулай булсын. Әнә бит, автор үзе дә «Бер кайтырмын. Ачкыч янда йөри» дип белдерә. Нигә аны бүген үк эшләмәскә? Кемнән, нәрсә көтәбез? Татар бит күнел киңлегеннән түгел, тарлыгыннан йә битарафлыгыннан харап була. Гүя битарафлык белән тарлык рифма гына түгел, ә хакыйкать. Шуна күрә, көнчеллек-битарафлык ярыгыннан гына карап тору белән чикләнмичә, башка каләмдәшләрнен иҗаты белән чагыштырмыйча, үзем тойган, үзем сизгән бәямне бирергә тиешмен. Монын өчен әсәрләрне укырга кирәк. Мин укыдым. Шагыйрәнен 400 шигырен укыдым. Бушкамы? Бер тиенсезме? – дип сорады бер замандашым. Әйе, бу мәкаләне язар өчен генә укыдым. Нәрсә, вакытын артып барамы? Язарга үз әсәрләрен юкмы? – диде замандашым. Бездә мөхәрриргә, шоферга, идән юучыга, урам себерүчегә аз булса да түлиләр, ә менә сезгә, язучыларга, юкмы? Юк. Бу шундый ил. Шагыйрә әйтмешли, «200-ле йөк», шомлы табутлар иле. / «Русиядә сугыш тынганы юк: / Гел кан ага, гомер киселә...» Ләкин мин әдибә хакында сүземне әйтергә тиешмен, черт побери!.. Әлбәттә, дүрт йөз шигырьлек китап дүрт йөз энҗедән тормый. Тора да алмый. Гомердан Сәлисә Гәрәевага кадәр. Алай була да алмый. Меннәрчә шигырь язып, бер шигырь белән тарихта калучы классиклар бар.

Әйе, дүрт йөз шигырьне көннәр буе укып, мин биредә табылган дистәләрчә энҗеләргә куандым. Башкалар өчен куану – минем байлыгым. Еладым, нәфрәтләндем, ватансыз изелгән язмышыбыз өчен үкендем, буш кәрәштә түгелгән көчләребез өчен гарьләндем, үзебездә таш астыннан да тишеп чыгарлык көч тапканыбыз өчен горурландым.

*Кара да соклан кукләргә:*
*Зәңгәр биеклек тирән!*
*Хисләрең тирәнлегенә*
*Биек күкләрдән өйрән!*

*Кара миңа: күз төпләрем*
*Кара кайгыдан көйгән.*
*Кайгыда да нык булырга*
*Син миннән, миннән өйрән!..*

Нәрсә, моннан нәкь житмеш биш ел элек Минзәләнең шагыйранә Тулбай авылының эре йолдызлары өермәсендә туган татар кызы, Алабуга китапханәчеләр техникумын тәмамлаганнан соң, кияүгә чыгып, туган жиренә таш булып төшеп, тыныч байбикә, абыстай, остазбикә, бәлки, насыйп итсә, ат һәм мал өерләре, ялчылары, ярдәмчеләре хуҗабикәсе булып, туган илләрендә куанып гомер кичерә, бер көтү балалар үстерә, шул ук вакытта милләтенең бәһасез шагыйрәсе булып житешә алмас идеме?! Житешә алыр иде, әгәр дә... әгәр дә... әгәр дә милләтебез язмышы сынмаган-ватылмаган булса!..

*Кара башлы яшел камыш.*
*Үрдәк кычкырган тавыш.*
*Моңнардан ташый күңелем,*
*Кагыла күрмә ялгыш!*
*Исмә җил! Очма, сагыш!..*

Ник, ни сәбәпле инде үз язмышын тагын да чатнатып, чыгып ычкынырга мәҗбүр бу кызкай моңа кадәр күзе күрмәгән, колагы ишетмәгән Урал — Чиләбенең чаңлы «тракторстрой» тарафларына? Ни эзләп, ник таптый ул бер телем икмәк, җылы почмак дип җыелган чит-ят халык, борынгылар әйтмешли, урыс-улак арасында салкын гомумтораклар, вокзал-разъездлар, прокат станнары, мартен цехлары арасындагы түн сукмакларны болай тетрәнеп һәм кыйналып?!

*Идел илендә тудым мин,*
*Ык суында коендым.*
*Шулпасын эчтем Уралда*
*Тормыш диган кыенның!*
*Идел илендә тудым мин,*
*Сөрмәт тавында йөрдем.*
*Уралга килеп, язмышның*
*Мартен миченә кердем!..*

Нигә ул, туган Ватанында ипи миченә керергә тиешле кызкай, читләргә китеп, жиде ят мартен мичләренә кергән? Жир йөзенең иң гигант танк заводларының радиорубкаларына микрофон тотып күтәрелеп, шул ук төн микрофоннан чит телдә «партия кушканча яхшы эшләргә» ник чакыра?! Ни житмәгән, аның эшеме?! Нинди Ватан эзли ул читтә, Ватанында үз Ватаны була торып? Ул буыныбызны «коллар һәм тоткыннар» — сугыштан ятим калган боек күзлеләр буыны дип атый. «Оят качкан, жинаятьчел катлам / Сугыш ачкан заман колы без; / «Азатлык!» дип куллар йодрыкланган, / Империя аша юлыбыз...» Аһ, Ватанында үз Ватанын таба алмаганга чыгып киткән ул Минзәлә баласы!.. Миллионлаган татарлар!.. Шулай итеп, үзенең бай, сыгылмалы, моң белән сытылып торган теленнән төшкән менә мондый гажәеп табигый шигъри тукымалар яңгырый:

*Сандугачлар, күке, сарытүшләр,*
*Сыерчыклар шашты таллыкта!*
*Акчарлаклар әче чыелдашып,*
*Кинәнделәр күлдә балыкка...*
*Кояш нуры кылдай тартылды да,*
*Су төбенең тотты ташларын;*
*Һәм җылытты буйга җиткән кызның*
*Яр читендә калган башмагын... —*

Шушы телне ватып-бозып, шигъри көчәнешне түбәнәйтә торган антипоэтик трансформатор куярга мәҗбүр, аңа трактор заводларының «гравитация кырлары», «мембрана», «космологик кинлек», геннары, биоток, расточниклары, прессланган вакыт-пролетлары, сталевар-сварщиклары һәм тагын да әллә кем, әллә нәрсәләре килеп керә... Язмышмы? Язмыш!..Моны һәркем кичергәнме? Кичермәгән! Татар әдәби тәнкыйте бу фаҗигане ачарга тиешме? Тиеш! КПСС Үзәк Комитеты бездән шундый шагыйрьләр тәрбияләргә тырышканы өчен җимерелеп төшкәнен онытмыйк. Бу «модадан» заман темасының яшен суга торган кап уртасында торган Салисә дә читтә калалмады. Һәм ул, утыз ел Чиләбенең металл тузаның үзенең публицистик теле белән ялап яшәргә мәҗбүр булган, Горбачев демократиясе килгәч, «Үлән Әбисе» — Татарстанда түгел, анардан читтә, цехлардан цехларга чабып, татар милли мәнфәгатьләре өчен көрәшчеләр, татар милли әдәбияты өчен каләмдәшләр эзләп тапкан милли шагыйрә, безнең күпләребез кичермәгән газаплар кичереп,Чиләбе татар-башкорт милли хәрәкәтен һәм татар-башкорт милли әдәби тормышын — әдәби, сәнгать түгәрәкләрен, мәктәп-китапханәләрен оештырырга тотына... Шул заманнарда мина язган бер хатында ул менә нәрсә ди: «Их, Айдар, без кичергәннәрне тиешенчә аңлап, безнең бүгенге чәбәләнүләребезгә хак бәя бирүчеләр табылырмы?!» Әлегә табылмады, әмма киләчәктә табылыр, Салисә. Без исән бит әле. Татар халык җыры исән. Менә сине дә коткарды бит ул бөек татар халык авыз иҗаты, татар халык җыры, татар халык теле. Бу мәсләктән без синең белән, Салисә, охшаш идек. Минем өчен Түбән Кама төзелешләре сынау мәйданы булган булса, синең талантына Чиләбе, Урал чынбарлыгы илаһи сабырлык куйды. Син Казанга Татарстаннан китеп, Уралдан килсәң, мин Казанга Түбән Кама, Уфалар аша килдем. Теге режимның муенны буа, тынны кыса торган «гравитация кырлары»ннан син бит башың-күзең аларып, сөремле мунчадан чыккандай, чабып килеп чыктың. Синең яшәүгә ышаныч тулы нечкә лирикаң тун тимерне мартеннардан да сыйфатлырак итеп эретсә дә, тун йөрәкләрне һәрдаим эретә алмады. Әмма «аерылуны раслап яшь тамган соңгы хат» кулларда ничек кенә тетрәнсә дә, бу халәт сөю бөеклеген раслап, синең иҗатында хыянәткә каршы гаепләү акты булып яңгырады:

*Нинди кояш яна күкрәгемдә!*
*Өмет бугай якты исеме.*
*Ят ярларга бирмим кулларымны,*
*Ятка ачмыйм йөрәк хисемне!*
*Ак шәлемне салып иңнәремә,*
*Каршы барыр идем – хатың юк.*
*...Гомер буе көткән сөйгәнемә*
*Хыянәткә бармыйм – хакым юк!..*

Салисәнең шигырьләрен укыганда хистән хискә күчеп күңел ял итә. Аларда һәр авылның Үлән Әбисе киптергән дару үләннәренең хуш исе. Дөрес, иҗатының беренче чорында язылганнарында соклану, матурлыкка «таң калу» күбрәк һәм кайбер фикерләр кабатлана да кебек. Бу безгә Әхмәт Ерикәй, Мөхәммәт Садриләрдән килгән. Кабатлану — мәхәббәттән. Аны әйтеп бетерергә тырышкан саен әйтеп бетереп булмый. Соклану шигърияттнең состав өлеше булса да, төп элементы түгел. Чын шигърият соклану белән башланып, язмыш белән бетә. Нәрсә ул язмыш? Бу хакта Лев Толстой бик яхшы әйткән: «Мин итекче идем, солдат булдым, дизертир идем, фабрикант булдым, укытучы идем, хәзер нуль». Сокланып, язмыш ясап булмый. Соклану, еш кына, бигрәк тә хатын-кызларыбыз иҗатында шуның белән чикләнү — татар шигъриятенең иң йомшак өлеше. Ул шигырьне язмышка җиткермичә оета. Салисә бу камалыштан чагыштырмача имгәнмичә һәм ирләрчә сабырлык белән чыкты. Әмма мина, бәяче буларак, мондый эволюциянең барышын күрсәтү ифрат та читен, чөнки җыентыкта әсәрләрнең язылган еллары күрсәтелмәгән. Мөхәррирләргә — шелтә. Кайчан язылган ул — 1976 дамы, әллә 2000 дәме? Шагыйрәнең Урал тарафларына китүе аның соклануддан язмышка күчүе иде. «Яңгыр ява. / Зәңгәр җепкә / Саплаган энә кебек. / Шаян яңгыр куыклары / шунардан сүнә кебек». Бу

«Зәңгәр агым аша» дигән шигырьнең башы. Соклянудан язмышка күчә башлау халәте. Куыклар сүнә. Ә шигырь ничек тәмамлана? Тетрәткеч язмыш белән:

*Җилләр яңгыр болытларын*
*Этәрделәр, иштеләр.*
*...Өздереп җанны, кемнеңдер*
*Үксүе ишетелә...*

Монда Блоклар, Анна Ахматовалар, Пастернаклар чалымы бар. Шундый ук чалым «Разъездлар»шигырендә аеруча ачык сурәтләнә.Биредә язмыш детальләрдә күренә:

*Ике өй дә... киң каралты-кура,*
*Разъезд кала поезд юлында.*
*Кое тирәсендә яшь бер хатын*
*Һәм ыштансыз бала кулында.*
*Бәрәңгеләр инде шау чәчәктә,*
*Бозау йөри тартып арканын.*
*Күренеп калды печән чүмәләсе*
*Һәм берәүнең печән чапканы...*

Татар күңеленә нинди якын күренешләр, гүя печән өстендә Минзәләсеннән юлга чыккан авыл абзыйсы-апасы кайдадыр Уралның Миәс, Сим тирәләреннән поездда үтеп бара... Уралга килгәндә, ул Салисә Гәрәеваның тәрҗемәи хәлендә икенче җөмлә булып килә. Әгәр ул адәмзат булып үз Тулбаенда туса, иҗатчы, гражданин һәм көрәшче булып ул үз Уралында туа. «И Туган ил! Татарстан! Әти-әни!.. / Тоталармы илдә мине исләрендә?!» ди ул Прагада җирләнгән татар кызы Сания Фәхретдинова авызыннан. Үзе әйтмешли, сүзендә Урал кырыслыгы, эшендә Урал һәвәслеге аның. Караса, онытылмаслык итеп карый, тараса, таралмаслык итеп тарый. «Яшь кулларым белән корыч койдым. / Ә язылган җырым азмы сон?! / ...Урал — минем җырлы тормышым ул, / Урал — минем кырыс язмышым!» Урал шагыйрә өчен язмыш тизләткече һәм тәмләткече. Ул тәмләткечтән яратылган яралар милләт өчен горурлыкка, милли горурлык һәм аның алдындагы мөкатдәс бурычка барып бәйләнә:

*Европаның кырчын ташларыннан*
*Азиягә атлап үтәм мин.*
*Тамырларда*
*Ике континентка*
*Хуҗа халык канын йөртәм мин!..*

Менә бу инде безнең бу җыентыктан ала алган иң кадерле тойгыбыздыр кебек. Безгә менә шундый хуҗаларга хас горурлык җитми дә инде. Язучыларга килсәк, язучыларыбыз, тарихчыларга килсәк, тарихчыларыбыз, тотабыз да үзебезне, имеш, без бу тарафларга фәлән-фәлән елда килгәнбез, без килгәнче бу җирдә марилар, чуашлар, башкортлар яшәгән дип, үзебезнең тарихыбызны XYII-XYIII гасыр белән чикләп, биредә төп халык икәнлегебезне онытып, үзебезне үзебез тарихсыз һәм җирсез итәбез дә куябыз. Тарихчыларыбызда милли идеология булмагач, безнең халыкның җире кайда икән сон ул? — дигән сорау да туып куя.

Шушы кадерле «хуҗа булу» дигән тарихи тойгы җыентыкның башыннан азагына кадәр мәхәббәт белән сугарылган. Әлбәттә, бу мәхәббәт, гадәттәгечә, женси мөнәсәбәтләрнең гармониясеннән яратылган. «Яратмаган кешем янда йөри, / Юлларыма чыкмый яраткан», дип уфтана ул хатын-кызларга хас хиссият белән. Әмма Салисә Гәрәеваның мәхәббәте субъектларның җаваплы-җавапсыз мавыгу статусыннан арынып, милләтне яшәтү-яшәртү субтропигы дәрәҗәсенә күтәрелә. Мәхәббәт — милләт сихәте. Аның өчен татар халкының дәүләтчелеген аякка бастыру гасырлар буе тартып алына барган мәхәббәтне — яшел яфрактай хлорофиллны кире кайтару өчен көрәш ул. «Аерылышты юллар. / Сине уйлап / Сызып йөрим

һаман. / Синсез тунам: кар өстенә кунган / Яшел яфрак сыман». Башка шагыйрә-шагыйрьләрдән аермалы буларак, аның мәхәббәте кайвакыт натуралистик дәрәҗәдә ачык һәм биологик яктан параграф кебек шәрәләндерелә:

*Араларга уйда кылыч куйдым:*
*Чикләр бикле, чикне үтмәсен!*
*Тән шашына, эзли иреннәрен,*
*Акыл әйтә: Тыел! Үпмәсен!..*
*Үбешәсе килә!.. Кулларына*
*Тапшырыл, ди күңел – боера!*
*Эчтә көрәш бара. Әнкәй дулый,*
*Кырыс әткәй кашын җыера...*

Татар шигъриятендә әлеге нечкә хисне мондый халыкчан юмор, сихри калкыну белән сурәтләгән әсәр юк иде шикелле әле. Монда безне тирән һәм тормышчан чынбарлык та каравыллый. «Ике күкрәк ике якка караган, / Саф тамчылар ага ике арадан! / Ике йомры ярымшарлар ут йота – / Күргән кеше бар дөньясын оныта!..» Бу унайдан Ромен Ролланның хатын-кыздагы мондый халәт турында «Әгәр гыйшык хисе хатын-кызны биләп алган икән, бирелә гыйффәтлек турында сүзнең булуы да мөмкин түгел» дип мыек астыннан шаярткан хәтергә килә...

Безнең шигърияттә ел фасылларын Салисә Гәрәева кебек тәфсилләп һәм яратып язган тагын да берәр шагыйрь бар микән? Яз, җәй, көз, кышка багышланган йөзгә якын шигырен укыдым мин аның. Бик күп язучы-шагыйрьләр ел фасылларына еш кына очраклы гына кайтып киләләр. Салисә гүя аларны көтеп ала һәм озатып куя. «Өшеткеч һәм елак көз зарына / Ачылганнар басу капкалары!» «Эссе җәйнең соңгы атналары. / Үләннәрдә соңгы аккордлар... / Озакламый болын өсләрендә / Оча башлар салкын, ак кортлар!..»

Мин шагыйрә тудырган бу ел фасыллары шигъриятенә аерым бер мәгънә бирәм. Искиткеч бай тел, камил сөйләмдә, берсен берсе «җигеп», җырлап торган рифмалар белән (югарыдагы «аккорд-ак корт»ны гына алыгыз) язылган бу әсәрләр Петр Ильич Чайковскийның «Ел фасыллары» циклын хәтерләтә. Әгәр шундый могҗиза булып, Татарстанның симфоник оркестры берәр сүз остасы башкаруында Салисә Гәрәеваның шушы шигырьләренә аккомпаниатор булса, Чайковскийның урыс композиторы, Салисә Гәрәеваның татар шагыйрәсе икәнен онытыр иде. Менә түбәндәге юлларга кемнәрнеңдер бушка көчәнеп куерткан «милли мөнәсәбәтләрнең» ни катнашы бар?

*Сөям кышның озын ялы бураннарын,*
*Көртләр күмгән, үргә менгән урамнарын;*
*Тәрәзләрдә ут уйнаткан клубын да,*
*Әткәемнең иске авыр толыбын да.*
*Туган җирнең ак карлары – киткән юлым.*
*Сабан туен бәйрәм иткән яшел болын –*
*Бары да истә... Зәңгәр Ыгым ага уйнап,*
*Йөрәк каным ага гүя тәнем буйлап...*

Менә шундый-шундый хәлләр Салисә Гәрәеваның шигърият илендә. Кайсыбер укучыда «Бу Салисәбезнең бер җитешсезлеге дә юк микәнни?» – дигән сорау туу мөмкин. Бар. Нигә булмасын! Аларның беренчесе – бәйләнеп булмас дәрәҗәдә камиллеккә омтылган шомалык. Икенчесе – күзгә кереп барган матурлык. Өченчесе – гел юксыну, гел сагыну. Шигырь шомалыгында да, матурлыгы-купшылыгында да, сагындыруында да авырттырып сыналырга тиеш. Соңгы чорларда татар шигъриятендә, аеруча хатын-кыз шигъриятендә, менә шундый авырттырып сына торган шигырьләр күренми башлады. Ул әхлакның әдәптән аерылуына бәйле бугай.

Безгә сынып сыналырга һәм шулай сакланырга кирәк.

**Айдар ХӘЛИМ**

# ХАК СҮЗ ӨЧЕН КАБАТ КАЙТКАНДЫР

## ФАКИЛ САФИН ИҖАТЫНА БЕР КАРАШ

Факил Сафинның «Галәм күзе» исемле китабыннан (Казан, 2011) «Агымсу» шигырен ничәнче кат укыймдыр инде, әмма андагы сагышлы сурәтләрдән алган тәэсирләр һич кимеми һәм алар күз алдыннан да китми. Шигырьнең, дөресрәге, аны язучының һәм укучының рухи халәте үзара тәңгәл килгәндә шулай буладыр, мөгаен. Күп дистә еллар элек кайсыдыр журналдан очраклы укылган бер шигырьнең шундый жете сурәтенә исем китеп йөргәнем хәтердә. Әле ныклап танылырга да өлгермәгән, безнең яклар өчен ятрак та булган Зөлфәт исемле (Зөлфәт таныла барган саен андый исемнәр бездә дә күбәйде) шагыйрьнең «Айлы соната» дигән шигыре иде ул. Соңрак автор аны «Ай сонатасы» дип үзгәртте, чөнки «Айлы соната» рус телендәге «Лунная соната»дан кемнеңдер уңышсыз тәрҗемәсе иде. Менә шагыйрь «теплоходның ак салонында» Бетховенның «Ай сонатасы»н тыңлап бара. Гаҗәеп музыка аңа кадәр тып-тын аккан Иделне дә, андагы бар тере табигатьне дә әллә нишләтә: «Актарыла, күбекләнә Идел, / Акчарлакның сына канаты... / Чәрдәкләнгән ай чайкала суда».

*Яр өстеннән, яшен суккан микән,*
*Чәрдәкләнеп ауган бер имән,*
*Чәрдәкләнгән кулын алга сузып*
*Ул мәрхәмәт сорый Иделдән.*

Яшь шагыйрьнең (бу шигырен язганда Зөлфәткә нибары унсигез яшь әле) сүз белән тудырган жете сурәтләренә сокланып йөргән, чәрдәкләнеп Идел өстенә сузылган имәнне әлегәчә күз алдында йөрткән безнең буын укучылары (андыйлар күп түгелдер, билгеле) ул чакта Зөлфәтнең Факил Сафин атлы тагын бер шагыйрь якташы булачагын белми иде әле, әлбәттә. Ә ул булды, бар һәм Зөлфәтнең, Харрасның, Наиснең, Шәмсиянең... жинел кулы белән шәп шагыйрьләр төбәгенә әверелгән Мөслим данын ихласлык белән дәвам иттерә. Аның «Агымсу» шигыре исә, бер яктан, яшь Зөлфәтнең образлы сурәтләүләрен хәтерләтсә, икенче яктан, җитлеккән шагыйрь Харрас Әюп моңсулыгын искә төшерә һәм дәвам иттерә. Биредәге «офыкны кискән томанлы таулар» сурәте яисә тугарылган атны хәтерләтүче табигать күренеше генә түгел, шигырьнең үзенчәлекле көе, аһәне дә, «урманның тын сулышы» һәм урман өсләтеп искән көзге җил дә укучы күңелен үзенә тартып тора, җибәрми:

*...Табигать гүя тугарып атын,*
*Озатып кала көзнең бер көнен.*
*Моңсудан моңсу уйлар уйлатып*
*Җыелып оча кошлар төркеме,*
*Табигать гүя тугарган атын...*

*Күзәтә шуны тын гына сулап.*
*Томанлы таулар офыкны кисә.*
*Ага да ага бу көзге сулар,*
*Урман өсләтеп көзге җил исә,*
*Күзәтә урман тын гына сулап...*

«Галәм күзе»,

Шигырьләрен уку барышында без әле «Бөре күзләре яшькә тулышкан», «Хач кадалган күк күзе», «Мутант козгын тырнагына / Каты эләккән Казан», «Кыр уртасын кыл урталай бүлеп, / Аягүрә баскан каеннар», Мөдәррис Әгъләмнең тиктормас холкын ачып биргән «Портреты кысасында / Түзеп торадыр көчкә» кебек уңышлы сурәтләргә, «Чуен бәгырьлеләр кирәк, / Таш йөрәкле бу илгә», «Сон бу дәүләт оешканнан бирле, / Һәр көненә гафу сорарлык», «Намус ул — тумыштан бирелә, / Кайчандыр синдә дә булгандыр», «Каганатлы булган бабайларым, /

Яманатлы, әмма, булмаган» кебек хәтердә уелып калырлык тезмәләргә юлыгачакбыз һәм авторның шагыйрьлек талантына кат-кат inаначакбыз.

Факил Сафинның Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары булып сайланган һәм, әллә ниләр булдырыр сыман, дәртләнеп эшкә керешкән көннәре истә але. Аның иҗат тормышындагы бу күтәрелешне хуплаучылар, лаеклы санаучылар аз булмагандыр. Әмма мона көенүчеләр дә бар иде ахрысы, чөнки ана Берлек идарәсендәге эш бүлмәсен тиз арада калдырып китәргә туры килде. Моның житди сәбәбе булгандыр һәм ул сәбәпне, ихтимал, беренче чиратта, Факилнең тынгысызрак та, җайсызрак һәм килешмәүчәнрәк тә холкыннан, гел рухи хөрлеккә омтылуыннан эзләргә кирәктер. Теләгәнен, эшләргә уйлаганын эшли алмый икән, аны җитәкче кәнәфиендә дә озак утырту мөмкин түгел, минемчә (хәер, урынбасар урынын җитәкче кәнәфие дип тартып-сузып кына әйтергә мөмкиндер, чөнки урынбасарның эше күп, җаваплылыгы бар, түрәсе һәм түбәнгеләр каршында вазифасы чиксез; хокуклары, мөмкинлекләре исә байтак очракларда ноль аның). Факилнең эштән тиз китеп баруында ул вакыттагы Берлек рәисенен үзенчәлекле, хәтта үзсүзле һәм талантлы шагыйрь булуы да беркадәр тискәре роль уйнагандыр, бәлки, чөнки ике шагыйрь бер гаиләдә дә сирәк халләрдә генә тынышып яши. Берлек идарәсеннән киткәч, күпләребез аны чак кына элегрәк үзе оештырган һәм баш мөхәррире булган «Мәйдан» журналына кайтыр, дип уйлаган, шулай буласына ныклап ышанган идек. Әллә анда чакыручы, сәләтенә тиң вазифа тәкъдим итүче булмады, әллә үзе бер үтелгән юлына кире кайтырга теләмәде — Факил Сафин атлы Мөслим егете берара әдәби мохиттән бөтенләй югалып торгандай булды, хәтта берәр ел язучыларның еллык җыелышында да күренмәде, матбугатта исеме сирәкләнде. Нәкъ шул елларда филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә диссертация яклау мәшәкатьләре дә аны киң җәмәгатьчелек күзеннән яшеребрәк торгандыр. Әйе, чынында ул бу елларда бөтен көчен Кадыйр Сибгатуллинның иҗатын фәнни анализлауга багышлады. Заман шагыйрен олы иҗатчы буларак фәнгә кертте. Үзен галим итеп танытты. Ниһаять, «Галәм күзе» дигән күләмле китабы — шигырьләр, балладалар, поэмалар тупламасы басылып чыгу, әдипнең күләгәдән, аулак тормыштан шау-шулы, иҗади бәхәсле, кайчак сөенечле, кайвакыт көенечле әдәбият дөньясына, аның да шигърият атлы «әнкәсе»нә, укучылары каршына кабат кайтуы кебегрәк булды.

*Сынды, диеп уйлаучылар бардыр.*
*Гөр иттерел яшим җирдә мин.*
*Кешеләрдә тик яктылык күрәм,*
*Көн күзеннән төнне эзләмим!*

***

*Бакыр белән көмеш кенә түгел,*
*Кешеләрне аеру катмарлы.*
*Йолдызларны гизеп, хак сүз өчен,*
*Җаным җиргә кабат кайткандыр,–*

дип яза ул «Хак сүз өчен» шигырендә. Бу «катмарлы» дөньяда хакны ялганнан аеру да җиңелләрдән түгел, берүк, ялгыша күрмә, түрәләрдән күрмәкче, үз-үзенә артык ышанудан, үз хаклыгыңны гына хак санап абынулардан саклан, дип кинәш бирәсе килә ана. Ләкин кайсы шагыйрь кемнеңдер кинәшенә ияреп үз мәсләгеннән кайта ди але. Шулай да хак сүз өчен җиргә кабат кайткан җан андый сүзне әйтергә генә түгел, тыңларга да сәләтле булырга тиештер. Факил Сафин яңа чор татар әдәбиятында сирәк казанышларның берсе саналырлык «Саташып аткан таң» трилогиясе баш каһарманы Әхмәтсафа Дәүләтъяровның әтисе авызыннан «Таң саташмый, кешеләр саташа» дигән сүз әйттерә. Урынлы әйттерә, чөнки саташуларга, сөртенүләргә дә сәләтле без.

Авторның 2008 елгы «Үзгәртәсем килде...» шигыреннән менә бу строфа да югарыда сөйләнгән вакыйгалар кайтавазыдыр, бәлки:

*Диңгез эзләп киттем – чишмәм калды,*
*Таулар эзләп киттем үзәннән.*

*Кайттым – мине чишмәм танымады,*
*Үзәннәрдә киткән үләннәр.*

Шигырьләрендә әледән-әле күзгә күренмәгән, исеме аталмаган шәхси дошманнар белән көрәшүе Факил Сафинны беркадәр ваклый да кебек. «Күреп торам, тере килеш / Күммәкчеләр үземне», «Хәзер дә бит хөсет, шпана / Ябышалар яманрак эттән», «Әнчекләр, алабайлар / Өскә ташланыр жай көтеп, / Һәр яктан сагалыйлар» – бу тезмәләрнең өчесе өч шигырьдән алынды. Күбрәккә киткән түгелме? Аның шәүләләр белән алыштан туган аерым романы да («Шәүлә») бар әле. Мондыйларны бөек Тукай да языштыргалаган, ни хәл итәсең, бәреп әйтелгән хак сүз, «тугры Тукайлык» кайчакларда дошманнар да тудыра шул, дип йомгакласак кына инде. Бәлки Факилнең «Үземнеке!» шигыреннән ошбу юлларны «үзенә» бер укып багаргадыр?

*Көрәшәсең дию белән,*
*Булып чыга – күләгәң.*

Факил Сафин шагыйрь һәм шагыйрьлек хакында да күп яза, болар турында кат-кат уйланган, күрәсең. Әдәби ижатын шигырьдән башласа да, шактый сонарып, моннан егерме бер ел элек дөнья күргән беренче китабы повесть һәм хикәяләрдән тупланган була. Бәлки шушы хәлне ул шигърияткә хыянәте кебегрәк хис иткәндер һәм яна зур шигъри тупланмасы белән, үз «гаебен» юарга ниятләгәндер? Аны әдип буларак иң нык таныткан әсәрләре дә шигырь-поэмалар түгел, ә бәлки «Гөлжиһан» повесте, «Биек тауның башларында» романы, «Саташып аткан тан» роман-трилогиясе һәм берничә хикәясе бит әле. «Әдипләребез» исемле биобиблиографик белешмәлектә дә Факил Сафинны прозаик дип язганнар. Әйтәсе дә түгел, үзен шагыйрь санаучы каләм иясенә уйланырлык хәлләр бар монда. «Шигырь алдында жавапны / Тотам мин аягүрә!» диярлек шул.

*Бурычларым булса әгәр,*
*Шигырьләтә түлим.*
*Алар җирдә һәр нәрсәдән*
*Кыйммәт(е)рәк йөри.*

*Талчукта сатылмый алар,*
*Алар – күңел кошы.*
*Бу дөньяга килүемә*
*Түләү булыр шушы, –*

дип яза ул «Утка ташлый, суга сала» дип башланган шигырендә. Шагыйрьлекне, шигырь язуны үзенең яшәү мәгънәсе дип исәпләгән каләм иясеннән без тагын да югарырак ижат биекләкләре көтәргә хаклыбыздыр, мөгаен. Әйтик, бөек Тукайны, каһарман Жәлилне уйлап язылган «Сәер китә шагыйрь...» шигыре, Зөлфәт истәлегенә багышланган «Халык шагыйре» поэмасы, «Аталар каберe» балладасы кебекләрне, хәтта тагын да яхшыракларны, иншалла, күп ижат итәчәк әле ул. Бу әсәрләрдә милләтебезнең ике мәшһүр шагыйре һәм татар әнкә тудырган дөньякүләм зурлыктагы әдип Чыңгыз Айтматов язмышлары халкыбызның гыйбрәтле вә катлаулы язмышына тыгыз бәйләп бәян ителә. Чөнки «шигырьдән аерылып», «Саташып аткан тан»га материал туплау, аны ижат итү барышында Факил Сафин трилогия каһарманнары белән бергә үзе дә рухи яктан нык үсте, мәгълүматлылыгы артты, күнел офыклары киңәйде, ул зур шәхесләребезнең бәхетен дә, фажигасен дә ил һәм халык язмышы белән бәйләп карарга өйрәнде. Шул вакытта Жәлилнең яшь чагын, Такташның зур хәвеф көтүдән жаны тынгысызланган чорын «күрү», явызлыгы чиктән ашкан елларда Сталинны «тыңлау» да аннан эзсез узмагандыр. Элегрәк язылган «Биек тауның башларында» романы да авторны кыю, хөр фикерле, милли хисле каләм иясе итеп күрсәткән, аерым әдәби геройлар көрәше аша тулы бер милләтнең хөрлеккә, ирекка омтылышын чагылдырырлык әдип булуын раслаган иде. «Кыргызларга кайгы килде, / Бар дөньяда – траур» дип яза ул «Аталар каберe» балладасында. Татар әнкәдән туган Чыңгыз Айтматов – татар баласы да, ләбаса. Әдип үзе дә моны белә, таный иде. Бәла шунда гына, андыйларны улым дип дөньяга күрсәтү өчен татарның жегәре житми – аның мөстәкыйль дәүләте юк.

*Ике халыкның баласы,*
*Белеп яшәде, тоеп.*

*Әмма дәүләтсез халыкның*
*Улы аталу кыен, –*

диелә балладала. Бу урында талантлы шагыйрь һәм публицист Газинур Моратның бер мәкаләсендәге: «Шагыйрьне олылар өчен дә дәүләтең булу кирәк. Дәүләтсез халыкның шагыйре, хәтта ул даһи булса да, дөнья әдәбияты классиклары рәтендә йөри алмаячак» дигән сүзләре хәтергә килә. Шагыйранә нинди тәнгәллек! Менә халыкның үз дәүләтчелеген торгызу омтылышы кабат җимерелде. «Хәзергә җимерелде» диясе килә дә, тик бу «хәзергә»нең чикләре ерак офыкта да шәйләнми әле. Әйе, суверенлык декларациясе һәм референдум нәтиҗәсендә җитәкчеләребез үзләре теләгән кадәр мөстәкыйльлеккә ирештеләр дә кебек: теләсәләр, бәһасеннән тормыйча, шау-гөр китереп дөньякүләм спорт уеннары уздыралар, кирәксә, иллә, Европала бердәнбер дип мактанырлык төзелешләр башкарып чыгалар. Халыкара дәрәҗәле һәм бюджетлы спорт командаларыбыз да олы түрәләребезнең һәм зур байларыбызның һәркайсына берәрдән җитәрлек булды шикелле. Безнекеләр Россия сайлауларында үзләре якын күргән, ышанган, ин кулае дип тапкан кандидатларны «үткәрүдә» дә, Чечнядан гына калышып, иң яхшы күрсәткечләргә ирешә беләләр, Мәскәү законнары нигезендә халыктан салым, штраф җыюда да беренче урыннардан төшмиләр, бер елда Татарстанның дүрт еллык бюджеты кадәр акчаны «иректә тостә» Мәскәүгә озатканда да («Звезда Поволжья»да еш кабатлана торган мәгълүмат) артык сыкрану сиздермиләр. Мәскәү аларны тавыш бирүләрсез, ягъни, халык һәм бигрәк тә милли көчләр каршында бернинди җаваплылык, бурычлар алмыйча, вәгъдәләр бирмичә, инде хәтта сайлап алып чакырылган кешеләр белән дә очрашмыйча гына республика, район башлыгы булу мөмкинлеге белән дә бүләкләде. Татар гавәме бу хәлләргә куанып кына яшәргә тиештер, бәлки. Милли мәнфәгатьләрне гамәлгә ашырганда гына Мәскәү чикләүләрен сизәбез: иң күп диярлек тавыш белән үзебез сайлаган Дума депутатлары һәм Президент (рәхмәт йөзеннәндер!) халык теләгән, телебезгә ярашлы булган хәреф кулллануны тыеп (нинди хәтәр сәбәп табып бит әле, янәсе, татарга кулай хәреф Русия дәүләтен җимерергә мөмкин!), тиран Сталин көчләп таккан кириллицада калдырды, мәктәпләрдә русча укучылар алдагы тормышларында уңайлырак шартларга куела һәм башкалар, һәм башкалар. Әнә татар дәүләтчелегенең тарихи бер баскычы булган Болгар чоры истәлекләрен дөньяга күрсәтерлек итеп торгызу эше дә шушы халыкны мөстәкыйль ханлыксыз калдыруда, кыру-бетерүдә Явыз Иванның хәрби терәге булган утрау-шәһәрчекне өр-яңадан кору белән бергә генә алып барылырга тиеш булып чыкты. Әле җитмәсә, кайбер урыс тарихчылары һәм федераль мәгълүмат чаралары Болгар харәбәләре астыннан да борынгы славян истәлекләре «табып», бу җирдә руслар күптәннән яшәгән (ягъни, Явыз Иван Казан ханлыгын буйсындырудан шактый элек үк бу тирәләр Рус дәүләтенеке булган) дип расламакчылар икән. И дөньялар... Бирелә Фәкил Сафинның «Хәтер» шигырендәге менә бу строфаны ничек искә төшермисең ди инде:

*Тарихыңны шәйли алырсыңмы –*
*Кемнәр ниләр уйлап чыгара?*
*Кемнәр кайда хәтер күзен чокып,*
*Яңа тарих язып шомара?..*

Дөньякүләм бөек кардәшебез Чыңгыз Айтматовка багышланган баллада хакында сүз башлаган идек бит әле.

*Нәгыймә апаның рухын*
*Шатландырмак иде ул.*
*Әнисенең илен күреп,*
*Дога кылмак иде ул, –*

диелә балладала. Монда әдипнең соңгы көннәре, иң ахыргы изге нияте күз алдында тотыла. Балтачта да ничек көткәннәр иде аны! Нәгыймә апа Кукмара төбәгендә туса да, нәсел тамырлары Балтач районының Борбаш авылына ялгана. Алай гынамы, бу районны, гомумән, бөек әниләр төбәге дияргә мөмкиндер. Тарихчы Равил Әмирханов мәшһүр Фатих

Әмирханның әнисе Рабига абыстай Балтач төбәгеннән булырга тиеш дип язган, үзара сөйләшкәндә дә шул фикерен кабатлаган иде. Бөек Тукай әнисе дә соңгы сыену урынын шушы як туфрагында тапты. Үзләре чит җирләрдә тусалар да, академик-язучы Миркасыйм Госмановның, дәүләт эшлеклесе Камил Исхаковның, композитор-башкаручы Рәшит Абдуллинның, җырчылар Альберт Әсәдуллин белән Гөлзадә Сафиуллинаның, музыкант Рәшит Мостафинның, танылган әдип, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Ибраһим Саләховның, рәссам, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Фиринат Халиковның, режиссер, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Равил Тумашевның, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе режиссер Рәшит Заһидуллинның әниләре (арадан өчесенең әтиләре дә) — шушы район авылларыннан (Камил Исхаковның әнисе Илһамия туып-үскән Хәсәншәех та иң элек Балтач районныкы иде. Илһамия ханымның әнисе Нәкыя — Балтач районы Югары Кенә мулласы Борһанетдин хәзрәт кызы). Кызларыбызның болай чәчелеп тормыш итүләрендә дә бер сәбәп — дәүләтсез халык булуыбыздыр, мөгаен.

Факил Сафинның Хәсән Туфанга, Нурихан Фәттахка, Зөлфәткә, Мөдәррис Әгъләмгә, Фоат Садриевка (Тукай бүләге ияләре), шулай ук Гаяз Исхакыйга, Рафаил Хәкимгә, Наис Гамбәргә, Кадыйр Сибгатуллинга, Фәннур Сафинга... багышланган яисә аларны уйлап, алардан эпиграф алып язылган шигырьләрендә дә авторның рухи хөрлеккә, милли бәйсезлеккә, шигъри сүз биеклегенә юнәлгән кыйбласы ачык күзаллана. «Биеккә дәшү» шигырендә ул, эпиграф итеп, бер газетадан Мөдәррис Әгъләмнең «Җирдә йөреп шагыйрь булып булмый. Шагыйрьлекнең ике юлы бар — йә тарих төпкеленә төшәргә, йә йолдызларга менәргә тиеш ул» дигән сүзләрен китерә дә:

*Сискәндереп күктән, көтмәгәндә,*
*Аваз ярды: Монда – мин! –диеп.*
*Сүзең булса, илгә җиткерерлек,*
*Ишетерлек булсын, мен биек! –*

дип язып китә. Аның «Рәсеменә карыйм. / Сурәтеннән / Күреп калдым яшен тамганын» дигән шигырь юллары Фәннур Сафинның «Исемеңне синең телгә алгач, / Күзендә яшь күрдем гөлләрнең» дигән искиткеч матур шигъри тезмәсен хәтерләтә. Ике автор да шагыйрьлекнең бер үк яссылыгындадыр, бәлки. Үз сүзен халкына ишеттерерлек биеклеккә күтәрелү бик аз шагыйрьләргә генә насыйп була. Кызганыч, туксанынчы еллар кузгалышына халыкны әзерләшкән, күтәрешкән шагыйрьләр рәте, аларны тыңлаучылар, «ишетүчеләр» рәте кебек үк, сирәгәеп килә. Үз хокуклары, ирке өчен көрәштән башы чыкмаган татарда шагыйрьлекне дә үзенә бертөрле сугышчан дәрәҗә дияргә буладыр һәм шуна күрә алар арасыннан корбаннар, шәһитләр дә күптер, бәлки. Факил Сафин «Сәер китә шагыйрь...» шигырендәге «Яуга дисәң — иң беренче сафка / Шагыйрьләрен куя килде ил» тезмәсен язганда иң элек татар «иле»н күз алдында тота, әлбәттә. Революция, канлы ватандашлар алышы, Сталин һәм аның җәлладлары уйлап чыгарган зыялыларга каршы сугыш (шуннан бирле хәзергәчә ил чын зыялыларга мохтаҗлык кичерә һәм бу тормышның һәр өлкәсендә үзен сиздерә), фашизм белән канга-кан, үлемгә-үлем «уены» — һәммәсендә төркем-төркем татар шагыйрьләре һәлак булган. Туксанынчы еллар вакыйгаларыннан соң да күпме шагыйрь мәңгелеккә китеп барды.

Факил Сафинның лирик шигырьләре (алар яна тупланмасының зур өлешен алып тора), матур һәм мәгънәле сонетлары беренче карашка бер шагыйрь сүзләре генә кебек тоелсалар да, бер-бер артлы укый барган саен, алай түгеллегенә төшенәсең, чөнки шагыйрь җырлаган туган як хисләре, яшьлек серләре яки югалту сагышлары, гомер, яшәү хакында уйланулары, җанына уралып, шул арада синеке дә булып әверелә. Аның «Тын суларга карап» исемле сонетлар такыясыннан иң ахыргы алты юлны гына укысак та, менә инанырбыз:

*Тын суларда йөзә ак мамык.*
*Ярда булмас, булмас шул калып.*
*Кызылланып яна чаганнар.*

*Мин дөньяга карыйм сокланып,*
*Әйләнешне танып, таң калып –*
*Җилдә тирбәлешә таганнар...*

Күңел күзе белән табигатькә багып язылган шигырьләрен укыганда да үзеңне әле шул наратлыкта, әле кыр каеннары арасында яисә дала кылганнары каршында итеп хис итәсең, печән өстен сагынып уйланасың. Мөслимдәге Ык, Әмәкәйдәге Калмия сурәтләнгәндә үзеннән Шушманны, Ширәнне, бүтән исемдәге елга-инешләренне күз алдына китерәсең һәм алар тагын да кадерле, газиз булып әверелә. Фәкилнең бер шагыйрь зары кебегрәк башланган шигырьләре дә милләт өчен, аның югалган дәүләтчелеген, Татарстанда да дәүләтнеке була алмаган, шунлыктан куллану даирәсе һаман тарая барган телен, милли хисләрнең отыры сүрелүен, ә битарафлыкның тамыр җәюен, татар халкындагы тискәре сыйфатларны уйлап сыкрану-сызлану белән тәмамлана.

*Татардагы тарлык – гаҗәп,*
*Мең кавемгә җитәрлек.*
*Сата, сатыла – бирсәләр*
*Бераз чәйлек, шикәрлек, –*

ди ул бер шигырендә. Арттырасың, шагыйрь, Җәлилләр төркемен, роман-трилогияндә үзен үк язган ныклык, тугрылык үрнәкләрен оныттың мәллә, диясе бик килә дә бит, тик менә кулларыбызны күкрәккә куеп, референдум нәтиҗәләрен берниндн хакка да сатмадык бит дип, чын күңелдән кайсыбыз әйтә ала? «Базар хуҗалары»ның да андый сүз әйткәне юк кебек, беркем аңламаслык итеп сүз уйнатсалар гына инде. Шул ук вакытта, шундый-шундый чаралар белән Мәскәү безне чигенергә мәҗбүр итте, дип тә кистереп әйтмиләр.

Ләкин татар тарлыгын язу белән генә шагыйрьнең хак сүзе тәгалләнми, билгеле. Гамьле җаннарга татарның тар күңеллелегеннән тыш та гамьләнер сәбәпләр җитәрлек. Уйлап баксаң, тарлык үзе дә әнә шул сәбәпләрдән барлыкка килмәдеме икән әле?

*Хәбәрдарлык һәм чынбарлык,*
*Шаулаштык ул чагында.*
*Хәбәр – барда, чынлык – дарда,*
*Без – ятлар кочагында, –*

дип яза ул әлеге дә баягы туксанынчы елларны һәм аның «җимешләрен» уйлап (бу очракта җимешләрне куштырнаклар эченә алмыйк, чөнки бөтенләй үк юк түгел алар. Халыкның бердәм башлаган эше бер нәтиҗәсез кала алмый). Әмма Тукайлардан ук килгән, Мөдәррисләрдән калган шигъри биеклектәге шагыйрь-көрәшчеләр хөрлеккә омтылган халыкның гел «ятлар кочагында» гомер сөрүе белән килешә, иреккә өметен кисә алмыйдыр.

*Җиһангирлар аз булмаган,*
*Көрәшкәннәр, җиңелгәннәр...*
*Ирек өчен яу – аяусыз,*
*Мәңге булмас җиңелләрдән.*

*Җиңелүме?–*
*Алар даны*
*Гасыр-чорлар аша кичеп,*
*Сүндермичә саклап калган*
*Киләчәккә Ирек хисен, –*

дип яза Фәкил Сафин «Милләт бакчасыннан репортаж» исемле поэма-эсседа. Ирек, матурлык хисен җуймаганнар белән бер сафташ, фикердәш, уйдаш булу, аларны аңлау һәм алар өчен аңлаешлы булу шагыйрь өчен бәхеттер ул, мөгаен.

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ**

**Редакциядән.**

*Бу айда Фәкил Сафинга 60 яшь тула. Каләмдәшебезне юбилее белән котлыйбыз, сәламәтлек, иҗат уңышлары телибез.*

# «Казан утлары» архивыннан



Әдип-галим Нәкый Исәнбәтне 80 яшьлек юбилее белән тәбрикләү. Сулдан уңга – Нәкый Исәнбәт, Шәукәт Галиев, Шәхсәнәм Әсфәндиярова, Тавил Хаҗиәхмәтов, Гайнан Әмири (Уфа), Мирсәй Әмир, Нәби Дәүли. 1980 ел.



Шагыйрь, журналист Ямаш Игәнәй (Ананий Малов, 1938-1997).



Казанның ял паркында. Әхәт Гаффар йомры җир гөмбәсе тапкан. Уртада Әхсән Баян, янәшәсендә – Наис Гамбәр. 2007 ел.



*Татарстанда Кыргызстан әдәбияты көннәре. Кунаклар республиканың төзелеш объектларында. Уртада – Чыңгыз Айтматов. 1972 ел.*



*Шагыйрьләр Ренат Харис һәм Сафуан Әлибаев Төркиядә. Истанбул. 2000 ел.*



*Онытылмас яшьлек, студент еллары. Казан университеты тулай торагында бәйрәм. Сулдан уңга – Григорий Родионов (Гәрәй Рахим), Рөстәм Мингалимов һ.б. 1964 ел.*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Нарат–Елга

Татарстанда каен, имән, чыршы, нарат, карама, чия, тал, балан һәм башка агач исемнәренә мөнәсәбәтле авыл атамалары байтак. Шундыйларның берсе – Чистай районындагы Нарат-Елга авылы. Ул Чистай шәһәреннән 14 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыл зиратында Һ.В.Йосыпов XIII – XIV йөзләргә мөнәсәбәтле кабер ташы таба.

Д.А.Корсаков (XVIII йөз) җыентыгында Нарат-Елга авылы искә алына. Анда 60 йомышлы татар, 18 керәшен яшәгән. 1898 елда Нарат-Елга авылында татарлар яшәгән. К.П.Берстель хезмәтендә күрсәтелгәнчә, Нарат-Елга авылында барлыгы 925 кеше исәпләнгән, алар ислам динен тотканнар.

Авылның оешуы турында аксакаллар түбәндәгеләрне сөйли.

Нарат-Елгага башлап бер сунарчы килеп утырган. Чистайга бара торган юлның уң ягында тау башында куш нарат үскән. Куш нарат эченә сунарчы куыш ясаган да шунда яши башлаган. Сунарчы янына скрипкада уйнаучы бер кеше дә килеп куыш корган. Аннан соң башкалар да бер-бер артлы килеп гаилә белән торырлык куышлар корып, бергәләшеп көн күрә башлаганнар.

Авылның ни өчен Нарат-Елга дип аталуы сер түгел. Монда нарат агачлары күп үскән. Аларның тамырлары 1911 елда тау казыганда бик күп чыккан. Авыл эчендәге күл буенда үскән ике төп нарат турында әле дә сөйлиләр. Ул агачлар шулкадәр юан булган, мулла өенең иДәнен, түшәмен җәяргә дә җиткән. Кыскасы, заманында авылның исеме җисеменә бик туры килгән.

Казан ханлыгы тез чүктерелгәннән соң, бу авылга 20ләп рус гаиләсе килеп урнашкан. Тора-бара алар рус телен онытып, татарча сөйләшә башлаганнар. Хакимият әһелләре бу хәлдән куркып, Нарат-Елга русларын Каргалы янындагы Тукмаклы дигән рус авылына күчергән.

Авыл халкы хәтерендә «Әбүбәкер» исемле кеше турында риваять сакланып калган. Аны 1973 елда шушы авылдан Әминов Гаяз язып ала.

«Нарат-Елганың Мөслим ягындагы кыр капкасыннан алып Мөслим сыртына кадәрге җирләре сукаланмаган, халык аннан печән чабып ала торган булган. Бервакыт, җиләк пешеп өлгерә башлаган чакта, уникe яшьлек бер кыз бала хәзерге таш утыртылган зират турысында җиләк җыеп йөри икән. Якыннан гына рус туе үтеп бара, ди. Туйдагы кешеләр гармуннар уйнап, җырлап барганнар. Андагы

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

кешеләрнең күбесе исерек икән. Жиләк жыеп йөрүче кыз туйның янына ук килгән. Шулвакыт бер егет бу кызны арбага күтәреп салган. Кызны алып киткәннәр. Кыз кычкырган, елаган. Шул вакытны Нарат-Елга авылының Әбүбәкер исемле урта яшьләрдәге бер кешесе килеп чыккан. Әбүбәкер туйны туктаткан да, кызны бирүләрен сораган. Тегеләр бирмәгән. Әбүбәкернең кулында балтасы булган – урманнан кайтып килеше икән. Ул бик нык ачуланып, кызны жибәрүләрен таләп иткән. Тегеләр кызны арбадан төшерергә мәжбүр булганнар. Ләкин Әбүбәкерне жибәрмичә, Нарат-Елгага кайтып, старостага алып барганнар һәм исем-фамилиясен язып алганнар. «Менә бу кеше туебызны туктатып иконабызны хурлады» дип Әбүбәкерне судка биргәннәр. Суд аны үлем жәзасына хөкем иткән. Әгәр чукынса, үлем жәзасын алмаштырырга булалар. Ләкин Әбүбәкер моңа ризалашмый. Аны төрлечә жәзалыйлар. Соныннан мунча себеркесенә керосин сибеп, себеркене аркасына бәйләп, ут төртеп яндырганнар. Әбүбәкерне, васыяте буенча, туйны туктатып, кызны коткарган урынга кабер казып күмгәннәр. Таш утырткannар. Ташның язуы без яшь вакытта шактый таныла иде. Хәзер кителеп танымаслык хәлгә килгән инде...»

Патша хакимиятләренең чукындыру сәясәте халыкны урыннан кузгаткан. Халык, иманын жуюдан куркып, башка эшләр белән бәйләнешле сәясәтне дә чукындыру түгелме икән дип шикләнгән. 1973 елда шушы авылның Гаяз Әминов язган тарихының «Перепись вакытында» дигән бүлеген укыгач, шул чорларны ачык күз алдына китерәсең.

«...1897 елда Россиядә халык санын алу – перепись башлана. Халык арасында «патша хөкүмәте татарларны чукындырып бетерергә тели икән» дигән хәбәр тарала. Күп кенә татарлар күчеп китәргә әзерләнә. Байтагы күчеп тә китә. Кире борылып та кайта.

Шөбһәгә калган Нарат-Елга халкы да Төркиягә күчеп китәргә карар кыла. Коли (Рахманкол) улы Хәйбулла Севастопольгә барып житкәч, андагы жуликлар Төркиядәге «рәхәтне» сөйләп, аның барлык акчасын эләктерәләр. Хәйбулла башта Нарат-Елга халкына: «Әзерләнегез», – дигән хәбәр жибәргән була. Жуликларның алдауларын сизгәч: «Әзерләнмәгез», – дип хәбәр итә. Үзе көчкә Нарат-Елгага кайтып егыла.

Гыймалетдинов Фәсхетдин исемле карт: «Әзерләнегез, дигән хәбәрне алгач, Нарат-Елга халкы мал-туарын, әйберләрен юк бәягә сатып, әрәм-шәрәм итә башлаган», – дип сөйләде...».

Шул чордагы авыл тормышына кагылышлы риваятьләрнең берсе «Налог өчен сатылган кызлар» дип атала.

«XIX гасырның соңгы чирегендә берничә тапкыр ачлык килгән. Хөкүмәт салымнарын түләү бик авыр булган. Ул вакытта аны «казна салу» дип йөрткәннәр. Налогларын түләмәүчеләргә бик каты жәза биргәннәр, мал-туарын, кием-салымнарын һәм башка әйберләрен тартып алганнар. Авыл башлыклары гына жыеп бетерә алмагач, волость башлыклары, кораллы көчләр белән авылга килеп, налогы бетмәгән кешеләрне жыеп, налог таләп иткәннәр. «Түли алмыйм, бернәрсәм дә юк!» – дигән кешеләрне жыеп, идән астына ябып куя торган булганнар. Ябылучылар арасында гаиләсендә фәкать кызлар гына булган Гайнулла агай да була. Налогларын түләргә сүз бирүчеләрне идән астыннан чыгарып торганнар. Идән тактасы ачылгач, Гайнулла агай да башын тыгып:

– Ике житкән кызым бар, налогларымны түләгән кешеләргә кияүгә бирер идем, – дип, калтыраган тавыш белән өй эчендәгеләргә эндәшкән.

Шундагы Саттар белән Сәйфелмөлек агайлар кинәшәләр дә, кызларны үз улларына алырга булалар. Гайнулла агайга идән астыннан чыгарга кушалар.

Саттар агай үзенең Жиһанша исемле улына Гайнулла агайның кече кызы Минлесафаны, Сәйфелмөлек исә Баттал исемле улына олы кызы Фәхрижамалны хатынлыкка алырга булып, Гайнулла абыйның налогын түләгәннәр. Налог өчен сатылган бу кызларның балаларының балалары Нарат-Елгада әле дә бик күп».

## Нәдер

Нәдер авылы Әлмәт районында урнашкан. Ул — жирле үзидарә советы үзәге. Әлмәт шәһәреннән — 12 чакрым, Бөгелмәдән — 65, Чаллыдан 132 чакрымда утырган.

1864 елгы белешмәдә авыл Яна Нәдер дип бирелгән һәм андагы 132 хуҗалыкта 529 ир-ат һәм 560 хатын-кыз яшәве күрсәтелгән, авылда 1 мәчет эшләгән.

1878 елның 23 ноябрь көнне иртән Нәдер һәм Кәшер авылларының 500гә якын кешесе чуалышларда катнаша. Ачуы чыккан халык волость идарәсенә килеп, волость старшинасы Мөхетдиневне якасыннан эләктереп урамга алып чыга һәм татарларны чукындырырга дип язылган әмер кәгазен бирүен таләп итә.

Авыл олылары сөйләвенә караганда, Нәдернең баштагы урыны хәзерге Урсала урынында булган. Элекке Нәдер янына руслар килеп утыралар һәм татарларга зыян сала, аларны кысрыклый башлыйлар. Нәтиҗәдә, нәдерлеләр икенче жиргә, хәзерге урыннарына күчеп утырырга мәжбүр булалар. Яңа урынга күчеп утыргач, авылны халык Яна Нәдер дип йөртә башлый. Рәсми белешмәләрдә авыл хәзер Нәдер дип атала, ләкин русча тәрдәше Яңа Нәдер (Ново-Надырово). Ә менә Сугышлы авылы тарихи чыганакларда да һәм халык телендә дә Иске Нәдер дип йөртелә.

Нәдерша, Сөләйман, Әлмөхәммәт, Исмәгыйль исемле кешеләр бертуган булган дип искә алалар. Аларның һәрберсе авыл нигезләгән. Нәдерша — Нәдерне, Сөләйман — Сөләйне, Әлмөхәммәт — Әлмәтне, Исмәгыйль — Кама-Исмәгыйльне.

Кама — җәнлек исеме. Исмәгыйль шул су күсесен аулау белән шөгыльләнгән. Аның һөнәре исеме янында килеп, авыл атамасы составында ныгып калган.

Авылның яртысын типтәрләр дип йөртәләр. Аларны Каманың көнбатыш тирәләреннән килгән дип әйтәләр. Олылар сөйләгән бу сүзләрдә, һичшиксез, дөреслек бар. Татар шәжәрәләрен өйрәнүче Марсель Әхмәтҗанов мәгълүматларына караганда, Нәдер авылының оешу тарихы Тау ягы белән бәйләнешле икән. Галим үзенең «Татар шәжәрәләре» (Казан, 1991) дип аталган хезмәтендә «Надир шәжәрәсе» дип исемләнгән шәжәрәне китерә. Ул үз эченә 15 буынны ала. Хронологик рамкалары — XV –XIX йөзләр.

Яңа Нәдер авылында татарлар яши. Аларның телләре, гореф-гадәтләре, йола-кануннары — барысы да татарча. Шуның өстенә халык үзен татар дип исәпли. Авылның традициясе, гадәтләре, йола-кануннары системасы әйбәт сакланган.

Авыл урнашкан урын матур. Анда тау, чишмә-кизләү, инеш-сулар һ.б. җитәрлек. Авыл янындагы күренекле елга — Урсала. Ул Кама суына кушыла. Урсалага Бирге чишмә һәм Аргы чишмәләр коя. Сәвәләй чишмәсе Кама суына тоташа.

Авыл янында Капитан тавы, Морат тавы, Сәвәли тавы, Хантимер юлы тавы һ.б. таулар бар.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# Р

**РОМАНТИЗМ**, әдәби метод (юнәлеш, ысул), иҗат тибы. Ул 18-19 гасырлар чигендә барлыкка килеп, өр-яңа форма һәм эчтәлек тәкъдим итә, акылның хакимлек итүен кире кагып, кешедә аң төпкеле, күзаллау-хыял б-н бәйле яңа яклар ача, әдәбиятта тормышның чиксезлеген һәм кешенең эчке дөньясының байлыгын белдерүче геройлар тудыра дип санала. Р.ның аермалы сыйфаты — ике катлы дөнья сурәте, әдәбиятта яшәешнең реаль һәм идеаль модельләрен тудыру. Р. туура алшартлар булып 18 гасырның мистик-теософик тәгълиматлары, И.Гердерның тарихи-фәлсәфи концепциясе, алман классик фәлсәфәсе вәкилләре И.Кант, И.Фихте, Ф.Шеллинг, әдәбиятчылар Э.По, А.Мицкевич, Дж.Байрон, О.де Бальзак, В.Гюго, В.Скотт эзләнүләре хезмәт итә. Рус әдәбиятында Р. В.А.Жуковский һәм А.С.Пушкин исемнәре б-н бәйле.

Татар әдәбиятында Р. мөстәкыйль юнәлеш буларак 20 гасыр башында С.Рәмиев, Г.Тукай, Н.Думави, С.Сүнчәләй, Г.Ибраһимов («Яшь йөрәкләр» романы, «Дингездә», «Сөю-сәгадәт», «Карак мулла» хикәяләре), Ф.Әмирхан («Гарәфә көн төшемдә», «Кадерле минутлар» хикәяләре, «Урталыкта» романы), М.Фәйзи («Тәкъдирнең шаяруы», «Галиябану» пьесалары) һ.б. әсәрләрендә оеша. Р. чоры татар әдәбиятының төп темасы милләт язмышы була. Язучылар актив рәвештә тарихка (Г.Исхакый, «Зөләйха»), легендаларга (М.Гафури, «Хан кызы Алтынчәч», Н.Думави, «Болгар кызы Тойгы туташ», Ф.Әмирхан, «Халык кызлары», Ш.Әхмәдиев, «Хан кызы») мөрәҗәгать итәләр; төп тенденция булып үз чорының тулаем бер сурәтен тергезү санала. Романтик прозаның олы формалары (Г.Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр», «Безнең көннәр» романнары) драматик кичерешләр б-н сугарылган, психологик анализның тирәнлеге ягыннан аерылып тора. Г.Исхакыйның «Мулла бабай» романында, «Остазбикә» повестенда халык тормышын, ислам кануннарын, руханиларны идеаллаштыру, мәхәббәткә, гаилә бәхетенә дан җырлау идиллик күренеш хасил итә. Татар романтик әдәбиятының табигате — идеал, гүзәллек, гармония дөньясы (А.Тангатаров «Өмет», Гали Рәхим «Серле-серле әкият» хикәяләре). Романтиклардагы мәхәббәт кешеләрне берләштерә, явызлык һәм золымга каршы чыга (Н.Думави «Серле тамчылар»), камилләштерә һәм рухландыра (Ш.Камал «Ике яхшы», К.Тинчурин «Искәндәр») торган көч. Идеал һәм реаль тормыш арасындагы каршылык герой аңы һәм күнелендә икеләнү тудыра; аның ялгызлыктан интегүе һәм идеалга сусавы әдәбиятның эсхатологик юнәлешен көчәйтә (Дәрдемәнднең «Без», «Өмид», С.Рәмиевнең «Мин үләм» шигырьләре; Ф.Борнашның «Коркыт» поэмасы, М.Хәнәфинең «Тегеннән» хикәясе һ.б.), үлем фәлсәфәсенә кайтып кала. Дошмани чынбарлыктан котылу чарасы булып табигать кочагына (Г.Ибраһимов, «Табигать балалары»), экзотик урыннарга (Г.Ибраһимов, «Дингездә», «Табигать балалары»), балалык хатирәләренә (Дәрдемәнд, «Үткән көннәр»), хыялый дөньяга (С.Рәмиев, «Авыл»), күнел дөньясына (Г.Тукай, «Күнел»), мәхәббәт кочагына (Г.Ибраһимов, «Сөю-сәгадәт»), дингә (Г.Тукайның дини шигырьләре), үлемгә (М.Хәнәфи, «Тегеннән») качу санала.

Мәгърифәтчелек хәрәкәте милли әдәбиятта традицион булган символ һәм образларны, дини-суфичыл әсәрләргә хас композицион ысулларны үзгәртүгә этәргеч бирә, һәм алар үзгә контекстта кулланыла, нәтиҗәдә әсәрләрнең күпчелеге дини һәм дөньяви яссылыкларда кабул ителә башлый (Г.Тукайның «И, каләм!» шигыре).

Сүз сәнгатенең милли үзенчәлеген бозмыйча, 20 гасыр башы татар шагыйрьләре һәм язучылары татар әдәбиятын Европа һәм рус әдәбиятлары өлгесендә үзгәртергә омтылалар. Романтик әдәбиятның төп тенденциясе милләт-

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санында басылып килә.*

не саклау, үстерү һәм камилләштерү мәсьәләсе була. Шәрык әдәбияты контекстында таныла һәм укыла торган детальләр, мотивлар, образ һәм традицион структураларны файдалану үзенчәлек кебек кабул ителә. Яна эчтәлек янартылган форма таләп итә башлый, бу, үз чиратында, жанрлар арасында чикләр җуелуга (мәс., хикәяне лирика б-н якынайтучы нәсер жанры хасил була) китерә. Романтизмны нәзари яктан нигезләп, Г.Гобәйдуллин, Г.Ибраһимов, Ж.Вәлиди татар романтик әдәбиятынын шәрык әдәбияты б-н бәйләнешләрне сакларга омтылуын, монын, үз чиратында, әсәрләргә милли төсмер бирүен ассызыклап чыктылар.

1917 елдан сон романтик әдәбиятнын үзәгенә бәхет мәсьәләсе һәм кешеләрнен социаль тигезлеге куела (Ф.Бурнашнын «Таһир-Зөһрә», М.Фәйзинен «Асылъяр» пьесалары). Иҗтимагый-тарихи вакыйгаларны тасвирлаганда авторлар дини-мифологик һәм символик образларга мөрәҗәгать итәләр (Гали Рәхимнен «Идел» повесте; Һ.Такташнын «Жир уллары трагедиясе» һәм шигырьләре).

Р. традицияләре татар поэзиясендә 20 гасыр буе үзен сиздерә. Бу чор Р.ында шартлы рәвештә 2 капма-каршы агым бүлеп чыгаралар: оптимистик һәм пессимистик. Беренчесенә бөтен тереклек дөньясына мәхәббәт, якты киләчәккә өмет, яхшылыкнын җинәчәгенә ышаныч хас. Кеше һәм җәмгыятьне камилләштерү мөмкинлеге геройга үз эчке каршылыкларын җинәргә көч бирә. Ул үз чоры проблемаларын хәл итү өчен көрәшә, идеалын киләчәктә таба һәм шул якты киләчәкне якынайтырга тели. Мәс., Р.Гатауллин (Гаташ) иҗатындагы күпсанлы метафоралар һәм хисләрнен бер чиктән икенчесенә ташлануы иң югары кыйммәт итеп мәхәббәтне тануга хезмәт итә. Пессимистик Р. дөньяны үзгәртү мөмкин түгеллеген анлаган, реаль чынбарлыктан хыял-фантазия дөньясына китеп барган, идеалны үткәннәрдә генә күргән герой тудыра. И.Юзиевнен мифология б-н сугарылган иҗатында романтик геройнын катлаулы күнел кичерешләрен, бай һәм тирән рухи дөньясын бирүгә омтылыш яшәеш мәсьәләләренә җиһан масштабында мөрәҗәгать итүгә сәбәп булды.

20 гасыр ахырында Р. үз үсешенә сәнгати форманы янарту максаты хас булган неоромантизмда яна импульс ала. Җәмгыять кануннары буенча яшәргә сәләте булмаган романтик герой тудырыла (М.Вәлиевнен «Качу» повесте). Ике катламлы дөнья башкаларны яратуга сәләтле булу һәм үзенне яратү (эгоизм) каршылыгында хасил була (Ф.Садриевнын «Кыргый алма әчесе» повесте). Бу ике төрле тормыш моделе укучыны башкалар мәнфәгатен хөрмәт иткән кешеләр тирәлек һәм үз-үзләре б-н гармониядә яши дигән фикергә китерә. 20 гасырнын 2 нче яртысында Р. традицияләренә беренчеләрдән булып М.Галиев мөрәҗәгать итә: анын «Ак абагалар» һәм «Алтын тотка» повестьларына лириклык һәм тирән фәлсәфә хас. Мәхәббәт һәм иҗади илһам турында сөйләгәндә, автор тарихны — чынбарлыкка, рухи кыйммәтләрне матди кыйммәтләргә каршы куя.

20 гасыр ахырында реалистик һәм романтик агымнар кушылып китә. Мәсәлән, М.Кәбировнын «Мәхәббәттән җырлар кала» повесте укучы игътибарын урта гасыр шәрык әдәбияты өчен традицион сөю мотивына юнәлтә торган аллюзиягә әйләнә. Повесть бәхетсезлек белән тәмамлануга карамастан, фаҗигалелек өстенлек алмый, аны мәхәббәтнен чиксез көченә ышану б-н бәйле якты хис җинә.

20-21 нче гасырлар киселешендә гадәти булмаган мәхәббәт тарихы милләтара конфликтларнын, техноген катастрофаларнын, сугышларнын фаҗигале тарихы б-н үрелеп китә торган повестьлар языла (Ә.Сәлаховнын «Сонгы вальс», Р.Бәшәрнен «Адашкан кош тавышы», «Акбалык» повестьлары). Романтик повестьлар тукымасына бик табигый төстә тирәлекне сызланып (экзистенциаль) кабул итү принциплары урнаша һәм алар әсәрләрнен кыйммәти юнәлешен үзгәртә.

Әдәб.: Нигматуллина Ю.Г. Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. К., 1997; Теория литературы. Т.4. Литературный процесс. М., 2001; Зарипова-Четин Ч. Проблема демонизма в творчестве С.Рамиева в контексте восточно-европейской эстетики. К., 2003; Ганиева Р.К. Совет көнчыгыш әдәбиятларында иҗат методы мәсьәләләре. К., 1988; Заһидуллина Д. Дөнья сурәте үзгәрү. К., 2006.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

**РУМИ** Җәләлетдин (30.9.1207, Әфганстан, Бәлх ш. — 17.12.1273, Төркия, Көнья ш.), шагыйрь, суфи шәех, философ. Фарсы һәм төрки телләрендә язган. Атасы — күренекле дин галиме Баһаветдин Вәләд сәлҗүк солтаны Әләветдин Кәй-Кубад солтанга хезмәт итә. Вафатыннан сон (1231) Р. анын урынына кала. Ин

дәрәҗәле, иң абруйлы дин әһелләренә генә бирелә торган «Мәүләнә» (төрекчә), «Мәүләви» (фарсыча) хөрмәткә ия булган «хуҗабыз», «остазыбыз» дигән исем йөртә. Шул исемдәге Мәүләвия суфичылык тарикатен төзи. «Рум» ләкабе (псевдоним) исә Көнчыгыш Рим (Византия) империясенә кергән, Рум дип аталып йөртелгән Кече Азиягә нисбәттә кабул ителгән. Р. 15 ел дәвамында язылган, 6 томнан торган «Мәснәви-и мәснәви» («Мәгънәле мәснәвиләр-нәсыйхәтләр») дигән поэма авторы. Әсәр — фарсы халыкларының фольклоры үрнәкләрен — хикәятләрен, риваятьләрен туплаган, Коръән аятләре һәм хәдисләрнең мәгънәсен тәфсирле нәтиҗәләр б-н аңлаткан җыентык. Аларда шагыйрь Илаһи хакыйкатьне танып белү юллары, Галәм җаны, язмыш һәм кеше ихтыяры турында уйлана, кеше табигате өчен хас кимчелекләрне тәнкыйтьли, рухи камилләшүгә, төрле конфессия вәкилләрен һәм идарәчеләрне үзара тату яшәргә чакыра. «Көллияте Шәмс Тәбризи» исемле 60 мең шигъри юлны берләштергән газәлләр җыентыгы рухи остазы Шәмсетдин Мөхәммәткә багышланган. Аларның эчтәлеге — суфичылык тәгълиматындагыча кешене илаһилаштыру, галәмдәге һәрнәрсәне универсаль эчтәлекле Илаһият б-н кушылу дип пантеистларча аңлату. Җыентыктагы газәлләр суфичылык символларына корылганнар, искиткеч музыкаль һәм экстатик кичерешләр белән сугарылганнар. Р. фәлсәфи юнәлештәге чәчмә әсәрләр авторы да: «Фихи мә фихи» (Ибн Гарәби касыйдәсеннән алынган гыйбарә: «Аның эчендәгесе — эчендәдер»), «Мәвагыйз әл-мәҗалис әс-сәба» («Җиде мәҗлес вәгазьләре»), «Мәктүбат» («Хатлар»). Р. иҗаты татар шагыйрьләре Өмми Камал, Мөхәммәдьяр, Кол Шәриф, Һ.Салихов, Ә.Каргалый, Ш.Зәки, Г.Тукай һ.б.ның фәлсәфи-эстетик һәм этик карашларының формалашуына йогынты ясый. «Мәснәви-и мәгънәви» поэмасы Г.Утыз Имәни тарафыннан күчерелә һәм шәрехләнә, татар мәдрәсәләрендә фарсы теле һәм әдәбияты буенча дәреслек вазыйфасын үти. Р. мирасы Г.Таһирҗанов, Ш.Абилов, Ә.Шәрипов, Х.Миңнегулов һ.б. тарафыннан өйрәнелә.

Әдәб.: Фиш Р. Джалалиддин Руми. М., 1972; Акимушкин Ф.О. Вдохновенный из Рума: Поэма о скрытом смысле. М., 1986; Миннегулов Х. Целитель человеческих душ // Татарстан. 2007. №18; Хәкимҗан Ф. Мәүлана Мөхәммәт Җәлалетдин Руми (1207-1273) // Милли мәдәният. 2007. №13.

*Р.К.Ганиева.*

**РУС ӘДӘБИЯТЫН СӨЮЧЕЛӘР ҖӘМГЫЯТЕ** Казан Император университетында А.С.Пушкин истәлегенә Казанда 1899 елда А.С.Архангельский һәм Е.Ф.Будде тырышлыгы б-н төзелә. Җәмгыятьнең максаты — «рус һәм башка славян халыкларының тел тарихы, әдәбият һәм халык иҗаты мәсьәләләрен төрле яктан өйрәнү, ш.у. алда әйтелгән мәсьәләләр буенча мәгълүматларны рус җәмгыятендә тарату һәм шуңа карата кызыксыну уяту». Җәмгыять әгъзалары һәм иганәчеләр акчасы хисабына яши. Җәмгыять әгъзалары арасында — А.И.Александров, Е.А.Бобров, А.И.Смирнов, Н.П.Загоскин, И.Н.Смирнов, Н.Ф.Катанов, С.П. һәм Д.П.Шестаковлар, Д.И.Дубяго һ.б., шәрәфле әгъзалар В.Ф.Миллер, А.Н.Пыпин, П.Д.Боборыкин. 1907 елга кадәр җәмгыятьнең рәисе булып А.С.Архангельский тора. Ул С.-Петербургка киткәннән соң җәмгыять номиналь рәвештә яши. 1916 елда аның эшчәнлеге торгызыла һәм 1918 елга кадәр дәвам итә (рәис — Н.М.Петровский). 1921 елда «иске властьнең идеологик таянычы», «консерватизм таратучы» дип саналган ун-тның тарих-филология факультеты ябылуы уңаеннан җәмгыять эшчәнлеге туктатыла.

Әдәб.: Воронова Л.Я. Литературное общество при Казанском университете в конце XIX — начале XX в. / Лингвистические и эстетические аспекты анализа текста и речи: Сб. статей Всерос. науч. конф. Соликамск, 2002. Т.3.

*Л.Я.Воронова.*

**РУС ӘДӘБИЯТЫН СӨЮЧЕЛӘРНЕҢ КАЗАН ҖӘМГЫЯТЕ**, Казанның, Идел буе һәм Урал шәһәрләренең Россиядә рус язучыларын берләштергән җәмгыятьләренең берсе. Казанда 1806 елда Беренче ир балалар гимназиясе каршында оеша (соңыннан Казан. ун-ты каршында эшли). Җәмгыятьне төзүче һәм беренче җитәкчесе — Н.М.Ибраһимов. Җәмгыятьнең максаты — «язучыларның үзләрен әдәбиятта камилләштерү теләге», «ватан әдәбиятының уңышларын таратуга» ярдәм итү. 1806-14 елларда хакыйкый әгъза булып җәмгыятьтә П.С.Кондырев (алыштыргысыз сәркәтип), В.М.Перевощиков, К.Ф.Фукс, С.А.Москотильников, Г.И.Солнцев, В.И.Панаев, И.М.Симонов, Я.О.Ярцев, С.Т.Аксаков, Н.С.Арцыбашев, Ф.М.Рындовский, А.И.Тургенев, шәрәфле әгъзалар — К.Н.Батюшков, Г.Р.Державин, В.А.Жуковский, Н.М.Карамзин, В.В.Капнист һ.б. тора. Җәмгыятьнең Программасы һәм 1814 елда расланган Уставы була. 1818 елда җәмгыятьтә 100

кеше санала, ш.и. 25 читтә яшәүчеләр. Ачык җыелышлар уздырыла. Шуларның Г.Р.Державин истәлегенә багышланган берсендә (1816) Казанда шагыйрьгә һәйкәл булдыру тәкъдиме б-н чыгыш ясыйлар. 1817 елда «Рус әдәбиятын сөючеләрнең Казан җәмгыяте хезмәтләре»нең 1нче китабы басылып чыга. Казан укуукыту округы җитәкчесе М.Л.Магницкий эшләгән чорда (1819-26) җәмгыять эшчәнлеген туктата, янадан 1828 елда гына эшен дәвам иттерә. 1830 елдан соң җәмгыятьнең җыелышлары сирәгәя, соңыннан бөтенләй туктатыла. 1846 елда ул янә торгызыла, ләкин эшчәнлегенең эчтәлеге һәм характеры нык үзгәрә: утырышлар тематикасы әдәби юнәлешен югалта, алар төгәл фәннәргә һәм башка өлкәләргә багышланалар. Җәмгыятьнең составы күбрәк ун-т профессорлары — төрле фәнни юнәлеш вәкилләре хисабына тулылана. Соңгы утырыш 1853 елның 24 сентябрендә уза. Казан җәмгыяте регионның әдәби һәм рухи үсешендә сизелерлек роль уйный, рус зыялыларын агарту эшчәнлегенә тартуга сәбәп була, Петербург һәм Мәскәүдә таныла.

Әдәб.: Загоскин Н.П. История Императорского Казанского университета (1804-1904). К., 1903. Т.2; Литвина Ф.А. Литературно-общественная жизнь Казани в конце XVIII — первой половины XIX вв. // Страницы истории города Казани К., 1981; Аристов В.В. Первое литературное общество Поволжья. К., 1992.

*В.И.Шишкин.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире ияләренә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштәшкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

Клара
Булатова

## Таш тәтиләр турында баллада

*Р.Төхфәтуллинга багышлана*

I

**Снаряд кыйпылчыгы уң кулыннан
өч бармакны китте өздереп.
Авылда бер тракторчы иде
һәм гармунчы иде бу егет.**

**Ник ичмасам сулы эләкмәгән,
Кулсыз хәзер кая барырга?
Вещмешогын асып аркасына
Җәяү кайта егет авылга.**

**Госпитальдән өйгә җибәрделәр,
Алай язып хәбәр бирмәде,
Станцага төшкәч белешсә дә
Олау–мазар туры килмәде.**

**Арча якка үрдән борылуга
Тезелеп килгән кәрван күренде,
«Олаучылар. Атлы юлчылар» дип
Сөенеп куйды солдат күңеле.**

**Түгел икән. Тезелеп килгән олау
Атлы түгел, ябык хатыннар.
«Симәнәгә» дигән орлык салган
Чана сөйрәп җәяү атлыйлар.**

**Кул бармагы нәрсә, бу күренештән
Әрнеп–янып күңел сыктады.
Бу күренеш гомер буйларына
Солдат хәтереннән чыкмады.**

II

**Әнкәсе шат, юкса, кул юклыгын
Күреп алды капка ачканда.
– Исән кайтуларың кыйммәт, бала,
Кулсыз түгел, башсыз кайтсаң да...**

**Ярый әле анысы өзелмәгән
Үлем әлмәгеннән чыкканда.
...Эч пошудан сул кул әвәләгән
Таш тәтиләр тора кучкарда.**

Әнкәсе шат. Әнә, балакае
Хәвәс икән нинди һөнәргә.
Үз—үзен дә, аны да туйдырыр
Бу һөнәре килер көннәрдә.

III

Ә солдатның күңел экранында
Бер картина һаман тирбәлә.
Чана тарткан ябык солдаткалар
Заман йөген сөйрәп киләләр.

Киемнәре затлы булмаса да
Чырайлары якты, бил зифа.
Шулар арасында туып килгән
Повесть каһарманы — Гөлзифа.

Шул күренеш егет күңелендә
Үсмер чактан яткан хыялны,
Тергезә дә кабат әллә кая
Алып китә салмак уйларны.

Ә мәктәптә военруклар кирәк,
Тарихчы юк. Заман кушканга
Ияреп ул укытучы булды —
Таш тәтиләр калды кучкарда.

Үз яшенә якын үсмерләргә
Төхфәтуллин дәрес аңлата.
Чыш—пыш килә класс, шаян сүзләр
Бармагы юк кулга карата.

Укытучы гарип кулы белән
Минут саен чәчен сыдыра.
—Әй тарагы шәп соң абыйның, — дип
Арткы парта көлеп утыра.

Ә тешләре сынган... Тешсез тарак
Аерыла чәчтән, салына...
Төхфәтуллин бер тын сүзсез тора
Тынып калган класс алдында.

Сөйләргәме шаян малайларга
Бармакларның ничек сынганын?
Ул картага кабат йөзен бора
Яшерер өчен күңеле тулганын.

...Еллар үткәч шушы укучылар
Әсәрләрен алып укырлар
Һәм аңларлар тарих тудырганын
Тешсез тарак булган бу куллар.

Укыр алар «Авылдашым Нәби»,
«Йолдызым» һәм «Агымсу»ларны,
Тарих итеп халык кабул итәр
Төхфәтуллин язган юлларны.

...Гомерлеккә һөнәр булыр дигән
Таш тәтиләр калган кучкарда.
Сыйпап куя солдат (сул белән)
Туган йортка кайтып чыкканда.

Аманулла

# БУХГАЛТЕР ГЫЙШКЫ

**Сез, җәмәгать, аңламыйсыз икән һаман.
Дебет белән кредиттан тора заман.
Күпме керә, күпме чыга — гел исәптә.
Хәзер сезгә бер хәл сөйлим шушы хакта.**

**Беркөн эштә күз кыстым да бер чибәргә,
Бу шунда ук СМСкалар җибәрә:
Мин дә чибәр, син дә матур! Без пар килгән!
Соң, әйдә, дим, күрешә башлыйк иртәгедән.**

**— Мин риза, — ди. — Күптән көттем синдәй ярны.
Очрашырга берәр җайлы урының бармы?
Дача салкын хәзер, димен, анысы — җәйгә.
Элек башта син кунакка чакыр, әйдә.**

**— Ну, ярар, — ди. — Көтәм сине бүген кичкә.
Кич җиткәнен көтеп алдым көчкә-көчкә.
Машинага алты литр бензин салдым,
Туксан биш тәңкәлек чәчкә букет алдым.**

**Одеколон!.. Дезодорант «пышык!.. пышык!..
Һәм мәхәббәт канатында килдем очып!
Ишекне ачс-а-а... Атлас халат... маккияжы!..
Изүләре кендеккәчә ярым ачык.**

**Менә нинди бәхет басты мин абзаңны!
Ну, бозабыз инде хәзер уразаны!
Хуҗабикә миннән чәчәк кабул итә....
Шуның өчен мине хәзерниләр көтәәә?...
Дигән мәлдә күр инде бу телефонны —
Хуҗабикәне чакыра җырлы моңы!**

**«Хәзер киләм» ди, чибәрем, гөлдер-гөлдер.
Минем ише бухгалтер гына түгелдер.
Онытты бит үз өендә кунак барын!
Хурлыгымнан кая барыйм, йә үч алыйм?!.**

**Утыртты да мине өстәл кырыена,
Сыек сары чәе белән сыйлый гына!
Кәгазь калынлыгы сырын алга төртә,
Катып беткән сохариларын кимертә.**

Соң ул чәйне күпме тагын эчеп була?!
Буфетында бит 300 сумлык коньяк тора!
Наз-фәлән дә кирәк түгел, тик бер теләк:
Бензин, чәчәк хакын чыгарырга кирәк.

Җыеп бөтен ихтыярны, барлык көчне,
60-70 сумлык чәен барыбер эчтем.
Кисеп куйган бөтен сырын тешләп чыктым.
Юри төртеп, чәйнеген дә бәреп ектым.

Атлас халат ап-ак түгел, хәзер сары.
Бензин хакын кайтардым мин, анысы ярый.
Ну бит әле тагын теге... букет та бар.
Туксан биш сум акчамны бит апкалдылар.

Мин бит карбюраторга дигәнне бирдем.
Моңа ничек түзсен минем бу йөрәгем?!
«Чу-ты... әллә нәрсә булды» — дигән булып
Туалетка кереп киттем эчне уып.

Чәчәк бәясен дә кайтардым бераздан
Рулон ярым кәгазь китте унитазга.
Кулларымны сабынладым әллә ничә,
Шампунь белән носки юдым иренмичә.

Эмалләре юкарганчы теш чистарттым,
Бер тотынгач, мыекны да кырып аттым
Һәм, ниһаять, чәчәкнең дә хакын каплап,
Ванна бусагасын чыктым киң-киң атлап.

Уң кесәмдә ачылмаган исле сабын.
Сул кесәмдә ярты рулон кәгазь тагын.
Йөзем-битем алсуланган! Җиңү төсе!
Һәр җиремнән аңкып тора парфюм исе!

Ярар, дидем, күбәләгем, миңа вакыт.
Син борчылып йөрмә инде мине озатып.
Мин бүгенге очрашудан бик канәгать.
Бик ошады. Гел йөрермен мин кергәләп.

Рәхмәт әйтеп, кулын үбеп чыгып киттем.
Менә нинди итагатьле, менә мин кем!
Ул хисләнеп керфекләрен сөртеп калды.
Ә мин чыккач лампочкасын борып алдым.



*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнен сәхифә!

# ХИКӘЯ ЯЗА АЛАСЫЗМЫ?

*Былтыргы 11, 12нче саннарда, дәвам итеп язар өчен, башламнар бирелгән иде. Килгән хикәячекләрне баса башлыйбыз.*

## Ачкыч

**Бу кызны ул троллейбус тәрәзәсеннән күрде. Күрде дә, гашыйк булды!**

**Төшеп калып, бик озак эзләде ул аны. Таба алмады. Кайтып подъездан керсә...шул кыз...аларның ишеген... ачкыч белән ачып маташа иде!** Халик аптыравыннан телсез калды. Кызның кырында ике зур сумка тора. Егет, гаҗәпләнүеннән бигрәк кызның матурлыгына сокланып, җай гына баскычтан менә башлады. Тегесе, менеп килүен шәйләп, егеткә озын камыш керфекләр белән бизәлгән, зәп-зәңгәр диңгездәй күзләрен бер сирпеп алды да һаман ачкыч белән ишек йозагын боргалавын белде.

— Нәрсә, ачылмыймы әллә? Кая, үзем ачып бирим әле. — Егеткә бераз шикләнебрәк караса да, кыз, аның ихтыярына буйсынып, ачкычны егетнең учына салды. Егет иелеп йозак тишеген караган булды. Кызга:

— Сумкаларыгызны читкәрәк алып торыгыз әле, мишәйт итәләр, — диде.

Кыз сумкаларны читкә шудырган арада үзенең ачкычы белән йозакны ачып:

— Сим-сим, ишек ач! – диган булды. Әкияттәге кебек ишек җай гына ачылып китте.

Кызның нәрсәдер әйткәнен дә көтмичә, иелеп аның сумкаларын алды да эчкә үтте. Тегесе дә бертуктаусыз рәхмәтләр яудыра-яудыра аның артыннан ирде:

— Әл дә ярый сез туры килдегез. Югыйсә подъезд төбегездә кунарга туры килер иде. Рәхмәт инде сезгә. Зур рәхмәт. Чыгып китми торыгыз. Хәзер чәй куеп җибәрәм. Авыл күчтәнәчләре белән чәйләп алырбыз.

Егет, эшнең көтмәгәндә шушылай борылуына куанып, үзенең фатирында чит кеше, кунак ролен уйнарга тотынды. Ваннада кулын чайкап чыгуына кунак кызы кухняда чәй табыны әзерләп йөри иде. Сумкасындагы авыл күчтәнәчләрен өстәлгә тезгән. Халикның залга үткәнен күреп, болай диде:

— Мондагы тәртипсезлеккә бик аптырамагыз. Бу — Саимә апаның энесенең фатиры. Ул Себер якларында акча каера. Бүген генә авылдан килдем. Иртәгә миңа имтихан бирергә кирәк.

Кара-каршы утырып чәй дә эчтеләр әле. Кыз Фәһимә исемле икән. Егет тә үзе белән таныштырган булды. Тик күбесенчә кыздан сорашты. Кайсы институтка һәм кайсы факультетка укырга керәчәген белеште. Фәһимә авыл кызларына хас булганча бик ихлас. Чөкердәшеп озаклап чәй эчкәч, ул болай диде:

— Әнекәй генәм! Сәгать ничә булган! Сезгә дә чыгарга вакыт, миңа да иртәгә бәйрәм түгел.

Егет тә аптырап тормады:

— Сезнең теләк миңа — закон. Баш өсте, хәзер үк түтәләчәк, — диеп, урыныннан торды. Кыз табын җыештырган арада, зал ягына чыгып, сервант тартмасыннан өйнең икенче, каракөн ачкычын алып кесәсенә тыкты. Шулай да, кыздан аерыласы килмәүдән бигрәк нәрсә эшләргә инде дигән сорауга җавап таба алмыйча, болай диде:

— Хәзер бик соң инде. Сезнең колыгызга шушында баш төртергә җай табылмас микән? — Чибәр кыз исә, төпсез күзләрен аңа текәп.

— Юк, юк, абзый кеше. Бәй, сез күршедә тормыйсызмыни? – диде.

— Әй, юк ла, мин дустыма килгән идем, — диде дә, егет саубуллашып чыгып китте.

Ул төнне Халик машинасында йоклады. Йоклады дип әйтеп тә булмый инде. Төне буе Фәһимә турында уйланып, хыялланып чыкты.

Икенче көнне кыз имтихан бирәсе бүлмәгә барып керсә, егылыплар китә язды. Имтихан алучылар арасында... Хәким дә утыра иде! Ул әллә бирде имтиханны, әллә бирмәде. Сорауларга җавап итеп ни дип әйткәнен дә хәтерләмәде.

Инде кичләтеп кенә фатирына кайтса, ишек ачык! Өстәлдә төрле-төрле сый. Уртада бик матур гөлләмә. Һәм чәчкәләр янындагы кәгазьгә болай дип язылган: «МИН СИҢА ЙӨРӘГЕМНЕ БИРӘМ! СИНЕҢ КУЛЫҢНЫ СОРЫЙМ». Кыз тәмам аптырап калды. Шул вакыт кухня ишегеннән кояштай балкып Хәким килеп чыкты...

**Хисаметдин ИСМӘГЫЙЛЕВ,**
*Башкортстан*

---

## Сөйкемле кыш

**Төште гыйшкым минем кыш аена,**
**Гашыйк булдым яуган ак карга...**
**Кар көртләрен минем эзләр бизи,**
**Мин сукмаклар ярам яктыга!**
**Кичен ошый ишеп кар яуганы,**
**Иртәләрен − таңнар атуы,**
**Ә соңыннан мине әсир итә**
**Серле генә кояш батуы.**
**Бу күренеш кабатлана һәркөн,**
**Ләкин һәркөн үзгә, үзенчә:**
**Бүгенгесе булмый кичәгедәй,**
**Иртәгесе булмый бүгенчә...**
**Бүген дә мин йокыга китәрмен**
**Бураннарның әче көенә.**
**Алар моңсу, алар өзгәләнә,**
**Ә күңелем,тиле, сөенә...**

**Алсу СӘЛАХОВА,**
*Яңа Чишмә районы Чаллы Башы урта мәктәбенең 11 сыйныф укучысы.*

Факил
Сафин

# ТУЛГАН АЙ

БӘЯН

## IV

Җәй житте. Тулганайны дөньясында бер эт — сирәк һөнәр иясе итеп күрәсе килү теләге бик көчле иде. Үзе дә сынатмаска охшаган. Бакча тирәсендә төнге ябалакның һава кыйнап канат кагынганын ишетеп алса да, чылбырын ду китереп өстерәп, әрле–бирле чаба башлый. Көндезен дә берәрсе бакча коймасына якынлашса, колакларын үрә торгызып, ырылдап ала. «Белегез, минем төп эшем — бакча саклау!» — дигән кебек. Әткәй Тулганайны үз итте инде. Сизгер, кыю эт булып үсеп килә. Кәлимулла абзый да мактап кына тора:

— Тәки этка охшап килә бит, — ди. Тулганай аны күрүгә, арт аякларына утырып, уң тәпиен күрешергә суза. Кәлимулла абзыйның кәефе дәррәү күтәрелә инде. Минем дә баш күккә тия. Гади бер эт кенә түгел инде Тулганай, гаҗәп акыллы җан иясе. Яшермим, минем аны шундый итеп күрәсем килә. Кинода күрсәткән Мохтар кебек үк булмас инде булуын. Бердән, Мохтар — овчарка, икенчедән, ул — чик саклый. Тулганай бакча сакларга әзерләнә, буйга да кыскарак. Әмма безнең этебез акыл иясе булуы белән бөтен авыны гаҗәпләндерергә тиеш дигән уй һич кенә тынгылык бирми.

...Шулай беркөн Гыйлемҗаннарга кергән идем. Шаккатмалы хәл күрдем. Актырнак исемле этләре бар аларның. Бәйдә тоталар. Акыллы эт, мине әллә кайдан танып алуыннан чыгып әйтәм. Шаккатуым шуңа, Актырнак ал тәпиләренә башын куеп, кояшта йокымсырап ята, ә аяк арасына бер оя сап-сары чебиләр кереп тулган. «Чеп-чеп» киләләр, хәтта шундый кыюлары табылган — баш өстенә үк үрмәләп менеп, колак очларын чемчеләп маташалар. Актырнак күзен ачып-йомып, рәхәт чигә. Чебиләрнең аналары — тавыкбикә исә корт-корт килеп, бер читтә йөри. Тиктормас чебиләрнең әле берсе, әле икенчесе каядыр китмәк була, Актырнак андыйларны сак кына алгы тәпие белән куенына кертә, тегеләре карышмыйлар, саргылт томшыкларын Актырнакның түшенә төртеп, ял итеп, йокымсырап, хәл җыялар. Якынрак киләм. Тавыкбикәнең коты очты, чебиләремне алмакчы була — ди торгандыр инде, «корт-корт» килеп үзе дә Актырнак тирәсенә сырышты. Яклау, сыену эзли бу!

Телсез калдым. Гыйлемҗан исә, шаккатуымнан һуш җыя алмый торуыма күңеле булып:

— Безнең Актырнак бер генә җан иясенә дә тими, — диде һавалы тавыш белән. — Сыер, сарык кайтмаса, авыл буйлап эзләп алып кайта, чебеш, бәпкәләрне тилгәннән саклый, — ди. — Синең Тулганаең түгел инде... — Баскан урынымда бишкә ярылып үлә яздым. Күрә торып мыскыл итә. Әле Тулганай күрсәтәчәк осталыкларын, сабыр ит, Гыйлми тәре! Тулганайга бер яшь тә тулмаган бит. Актырнак инде әллә кайчангы, хан заманындагы карт эт. Койрыгын җирдән өстерәп йөри.

— Нәрсәсе бар аның? — дим эре генә. — Тулганайны да өйрәтеп була бәпкә сакларга.

Гыйлемҗан минем Камил абыем белән бер сыйныфта укый, алтынчыга

*Дәвамы. Башы узган санда*

күчкән. Камил абый быел колхозга эшкә чыкты, Гыйлемҗан үткән–сүткән бала–чаганы үртәп, көне буе капка төбен саклый.

— Тулганаеңны Кыркүлгә алып бар син, — диде Гыйлемҗан. Бик зур сер чишкән сыман, ялт–йолт тирә–якка каранып алды.

— Нигә? — дип сорау биргәнемне сизми дә калдым. Кызыксыну көчле, Актырнакның кыланмышы бөтен зиһенне алды да куйды.

— Тулганайның холкы да әйбәт. Озын йонлы, йомшак эт. Кыркүлдә кыр үрдәкләре бәпкә чыгарган. Кичә күреп кайттым, күл өсте тулы йөзеп йөриләр. Әллә аларны өшеми дип беләсеңме? Көне буе су өстендә йөзеп йөреп кара, ярты сәгатьтән «әп–те–чи» килә башлыйсың. Кич кырын Тулганаеңны Кыркүленә алып бар да талга бәйләп куй. Иртән баргач күрерсең, этеңә бер оя үрдәк бәпкәсе сырышып яткан булыр. Җылыга җылан ияләшә, мин әйтте диярсең, шулай була. Барган шәпкә ун-унбиш кыр үрдәге бәпкәсе тотып алып кайтасың инде. Син, ачык авыз, кәрҗин алып барырга онытма! Бу хакта үзең генә бел, сөйләнеп йөрмә, сизенсәләр дә мин әйкәнне әйтмә.

Анысын гына беләм инде. Өйгә чаптым.

Кичкырын кояш офыкка авыша башлагач алып киттем Тулганайны Кыркүлгә табан. Кырга чыккач этем ничек куанганны күрсәгез! Сикерә, күбәләк куа, аяк астыннан пырхылдап кош очып чыкса, куркып, минем аякка килеп сырыша, «Аңлат, ни булды бу?» — дигәндәй күзен түгәрәкләндереп миңа карап тора башлый. Шулай уйный, шаяра Кымызлык чокырын үттек, арыш басу эченнән сузылган тар юлдан Печмән инешенә төштек, Имәнлек урманына табан ярты чакрымлап баргач, тигез болынлыкка ташлап калдырган көзге сыман Кыркүле күренде. Барып җиткәч, бертын күл өстен күзәтәм. Тулганай телен салындырган, ни өчен монда килгәнен аңларга тырышып. Тирә–юньне күзәтә. Нидер бар монда. Әнә колакларын шомрайтып куе үләнгә сузылып ятты да, тын алганы да сизелми, аргы яктыгы камышлыкка карап катты. Гыйлемҗан дөрес әйткән, чыннан да күл читендәге камышлардан ара-тирә үрдәк бәпкәләре йөзеп чыга, камыш ышыгыннан бик ераклашсалар аналары тынгысызлана башлыйлар, «бак–бак» кычкырып, кире үз ояларына чакырып алалар. Камышлыкта шыштырдаулар көчәйгән кебек булды да, тирә-юнь тып-тын калды. Күл буена башка җан ияләре килгәнен сизенделәр бугай үрдәкләр. Күл өсте буп-буш, аксыл, соргылт мамыкларны җиңелчә искән җил ярга табан куалый. Алар борыннарын югары чөйгән кечкенә көймәләрне хәтерләтеп, әйләнә–тулгана җил уңаена йөзәләр.

Су керәсе килсә дә, түзәргә булдым. Кыр үрдәкләрен куркытуым бар. Инде эшкә керешик. Сынатма Тулганай, синең сәгать сукты. Чыннан да, Гыйлемҗан әйткәнчә, үз яныңа үрдәк бәпкәләрен сыендырып, җыеп тота алсаң, медаль бирәм мин сиңа! Малайларны — Әбүзәрне, Фәритне, Рәхимне күз алдына китерәм. Әгәр эш уйлаганча килеп чыкса, телдән калачаклар, бичаралар.

Тулганай ниятемне сизми, мин исә әлегә берни дәшмим. Бераз вакыт уңайлы урын эзләп үтте. Камышлыкка якын гына яр читенә үк терәлеп үскән таллык бар, яры да сөзәк. Минем ният буенча, Тулганайны яшереп кенә бәйләп куясы, үрдәк бәпкәләре йөзеп киләләр дә яр өстендәге чирәмлеккә менеп тә китәләр. Аннан инде Тулганайны күргәч, аның тирәсенә елышырга тиешләр. Эт әнә үзе үк, «шулай шул, дөрес уйлыйсың, Фирүз», дигәндәй, рәхәтләнеп тал төбенә сузылып ятты. Су өсте тынычланып калды, марҗа көянтәләренең пырлап очуын, сирәк кенә ишетелгән үрдәк тавышларын исәпкә алмаганда, бар табигать эсседән талчыгып, таралып ял иткән шикелле.

Тулганайны талга бәйләп куйдым. Бавы озынрак булсын, тамагы кипсә, күл читенә төшеп су да эчсен дип тырыштым. Шым гына камышлыкка карап утырам, менә яшел камыш төпләрен чемчекли–чемчекли үрдәк бәпкәләре йөзеп чыга башладылар. Кулым белән сак кына шул якка күрсәтеп, пышылдап кына Тулганайга аңлаткан булдым:

— Тулганай, акыллым, әнә теге йөзеп йөргән үрдәк бәпкәләрен күрәсеңме?

— Тулганай колакларын үрә чөеп, урыныннан сикереп торды. Мин иплән кенә «ятарга» дигән әмер бирдем. Этем теләмичә генә кире чүкте. Болай булгач — була! Мине аңларга тиеш ул. — Үрдәк бәпкәләре янына килсә, пырдымсызланып, куркытып, куып җибәрә күрмә! Тәпиләреңне менә шулай алга сузып ят. Тыныч кына бәпкәләрнең үз янына җыелганын көт. Алар, акыллары булса, синең куеныңа кереп кенә тулачаклар. Эчең пошмасын, мин иртүк килеп җитәм кәрҗин күтәреп. Менә сиңа ипи кисәкләре, тамагың ачса ашарсың, бер конфет та калдырам.

Тулганай мин сөйләп бетергәнне көтмәде, конфетны сузуга һап эләктереп, кәгазе-ние белән йотып та куйды.

— Булдырдың инде, — дидем, ачулана төшеп. — Сабыр ит, әле төн чыгасың бар.

Күп сүз — юк сүз, ди әткәй, кайту ягына кузгалдым. Тулганай шыңшып өрергә тотынды. Аңламаган бит бу! Башны яндырып шушы уй йөгереп үтте. Харап итте эшне, мондый елак эт янына бәпкә киләме инде?! Тик кире чигенү юк, күңелсезләнә төшеп, кайтып киттем. Колак төбендә — Тулганайның елак тавышы янгырап тора. Күңелдә шик камыры ташый башлады, шул кадәр аңлатып та, өч–дүрт бәпкә эләктерә алмасак...

...Көтүләр кайтты. Күңел урынында түгел, җан бәргәләнә. Арып-талып Камил абый кайтып керде. Ишек алды тып-тын. Башка көннәрдә аны күрүгә Тулганай койрыкларын болгый-болгый аяк астында урала, тезләренә сикерә иде, бүген андый хәл кабатланмады. Камил абый, нидер сизенгәндәй:

— Тулганай кайда? — дип сорады.

Боргалап торуның мәгънәсе юк. Чын дөресен сөйләргә кирәк.

— Моны әле әткәй белән әнкәй дә белмиләр. Үзеңә генә әйтәм, Тулганай — Кыркүлдә... — дидем, кыюсыз тавыш белән. Инде сизәм — Гыйлемҗан капкынына эләктем бугай. Этсез калсак, нишләрбез?.. Балыкка килгән берәр малай эләктереп китсә...

— Кыркүлдә? — диде Камил абый җилдә чатнап яргаланган иреннәрен бөрештерә төшеп. — Нишли ул анда?

Гыйлеҗаннан ишеткәннәрне түкми-чәчми сөйләп бирдем инде.

Камил абый башта ышанмыйчарак торды, аннан баскычка барып утырды да, кычкырып көлде.

— Сиңа акыл керәме, Фирүз, юкмы? — диде, бераз тынычлангач. — Кыр үрдәгә эт янына килә ди сиңа. Бәпкәләрен euткә тапшыра ди ул, тот капчыгыңны. Гыйлемҗанның тавыгы чебиләрен эт оясында чыгарды, аларны беренче көннән үк Актырнак саклап торды. Чебиләр аны әтиләре дип беләләр, җүләркәй! Алып кайт Тулганайны. Талга бәйләп куйдым дисең бит. Суга төшеп, буылып харап булмасын.

Көн яктысында Печмән буйларыннан эт белән бергәләп үтү бер нәрсә, ә хәзер шикләндерә. Кичке тыгыз һавада арыш басуын да кичеп чыгасы бар шул. Башак чыгарган арышлар миннән биегрәк тә әле. Тулганайны Кыркүл буенда калдырып кайткан чакта, бер кәрҗин бәпкәле булу хыялы белән янып, дәртләнеп бу араны йөгереп кенә үткән идем. Кичке эңгерне ярып бер ялгызың барулары үлеш инде анда. Ул яктан эт өргән тавыш та ишетелми, ичмаса. «Барып алып кайт!» — дип әйтүе генә җиңел. Күңелне корт кимерә.

Камил абый хәлемне сизептер инде, ахры, өйалдындагы чиләктән чүмеч белән су чумырып алып, бер тында эчеп куйды һәм иреннәрен кояшта уңа башлагач күлмәк җиңе белән сак кына сөртеп, миңа шелтәле караш ташлады:

— Җебеп торма, Тулганайны бергәләп алып кайтабыз. Моннан соң андый җүләр уйларыңны башыңнан чыгарып ташла. Үскән малай бит инде син, икенче сыйныфка барырга җыенасың, — диде. — Кем ни әйтсә, шуңа ышанасың.

Кыркүленә якынлашкач, өзгәләнеп өргән эт тавышы ишетелде. Эчкә җылы йөгерде. Тулганай тавышы! Исән, димәк, аның тавышын әллә каян таныйм.

Йөгерә-сикерә барып җиттек тал төбенә. Чыланып, пычранып беткән Тулганай миңа күтәрелеп тә карамады, елый-елый Камил абыйга тартылды. Тирә–якны болыт кебек чебен-черки сырып алган, күзе эренләнеп беткән, кашы җимерелгән, колаклары салынган. Гел уйнаклап торучы түгәрәк матур этебезне танып та булмый.

Тулганай үзен алырга килүләренә ышанмый иде бугай, «зинһар, коткар!» — дигән кебек, дүрт аягын як–якка җәеп, корсагы белән чирәмгә ауды да, Камил абыйга табан шуыша башлады. Шушы хәлдән соң Тулганай атна буе миңа күз дә салмады. Кәлимулла абзый: «Эт халкы бер үпкәләсә нык үпкәли» — дип әйтергә ярата. Дөрес икән.

## V

Ниһаять, алмалар кызарып пешеп киләләр. Әткәй төннәрен шылт иткән тавыш ишетсә дә, урыныннан сикереп тора, ян тәрәзә пәрдәсен күтәрә төшеп, игътибар белән бакчаны күзәтә башлый. Төн йокылары качты аның.

— Ник интегәсең инде? Ни үзең йокы күрмисең, безне дә йоклатмыйсың, — диде берсендә әнкәй ачулангандай итеп. — Әнә Тулганайны бәйдән чишеп җибәр бакчага. Чуртым да булмас, шуның өчен асрыйбыз бит. Хәтәр тернәкләнеп, эткә охшап бара. Үзенекен бирми, кешенекенә тими торган, акыллы эт булып үсә бу. — Ачуы тышка ук бәреп чыкты, сукранып дәвам итте. — Бу яшьләргә ни җитми инде, ә? Өсләре бөтен, тамаклары тук, кеше бакчасына угрылыкка кермәсәләр дим... Кичә Миргали бабайларга кереп, кыяр түтәлләрен харап итеп чыкканнар. Түтәлнең өстенә ятып ауныйлар икән, карангыда кармаланып йөриселәре килми, сыртларына кыяр тигәнен сизеп алгач, сабагы-ние белән йолкып аталар, имеш. Фәсхигә явиться иткәннәр икән, куып чыгарган сәвиттән. «Бер эшегез дә юк, саклап ятыгыз», — дип әйтә ди.

— Дөньясы урлашудан тора бит... Күзеңне ачып карасаң — барысы да кыек юлда. Ни-нәрсә җайсыз ята, нәрсәне кыстырып китеп була — барысын да әләктереп китеп кенә торалар. Хуҗа юк илдә. Талау-урлау белән көн күрә халык. Сорасаң — бирмиләр, урлап, әләкмәсәң — күрмиләр. Фәсхи гел әйтеп тора: «Закунны аны бозарга һич тә ярамый, әмма да ләкин урап үтәргә ярый», — ди.

— Үткән ел алмагачның зур бер ботагын сындырып чыкканнар иде, быел ни күрергә язгандыр. Әйбәтләп өзеп алсалар түзәр дә идең әле..., — диде әнкәй, рәнҗешен тышка чыгарып. — Намуссыз хәзерге яшьләр.

— Намус, нәфес... — диде, әткәй тәрәзәдән күзен алмыйча. — Намусы зур булганның нәфесе азгын булмый, намусы бәләкәйнең нәфесе зур була аның. Хәзер кешеләр нәфес колларына әйләнеп баралар. Илнең киләчәге шушы буын кулында — түрәләр булып үсеп җитәрләр, ил башына менеп утырырлар, халык белән идарә итә башларлар. Уйларында исә бер генә нәрсә — ничек тә урлашу, талау, байлык әләктерү җаен табу булыр. Имансыз, алласыз буыннан ни көтмәк кирәк. Әнә үткән атнада ураза гаетенә җыелган картларны куып тараттылар. Әхмәтзакир мулланы районга алып китеп, өч көн ябып тотканнар. Яклап сүз әйтүче юк. Нәфесне аны бер уч туфрак кына баса... Теге дөньяга бу дөньялыктан иң зур мәһәр шул була.

— Әйтеп кара, үзеңне алып китәрләр. Бүрәнә башы тишек дигән борынгылар. Тыңланып, күз–колак булып йөрүчеләр беткән ди. Инде барып кайттың бит. Мулла кызын алган дип ун елга ябып куйганнар иде.

— Сугыш коткарды. Себер урманында катып үлә идек. Нимес бәреп кергәч, безнең ишеләрне кулга мылтык та бирми ут эченә куып керттеләр, хөкем эше

шуның белән бетте. Сугыштан кайткач, кире җибәрергә укталып йөрүчеләр булды булуын.

Мин озак тыңлап ята алмадым, әвен базарына киткәнмен. Әткәй таң беленгәнче тәрәзә төбендә утыргач, угрылар бу вакытта йөрмәс дип йокларга яткан. Бәйдәге Тулганай берзаман шау килеп өргән, әмма өйдәгеләр игътибар итмәгәннәр, ахры. Иртән карасалар — бакчаны бутап чыкканнар икән.

Әткәйнең сабырлыгы төкәнде. Көн кичкә авышкач, Тулганайны бәйдән ычкындырып, бакчага җибәрмәкче булды. Нидер йомыш табып, Кәлимулла абзый да кергән иде. Тулганайны үзенчә сакта торырга өйрәтә, акыл бирә. Тулганай исә, күзләрен Кәлимулла абзыйга төбәп, һәр әйткән сүзен сеңдереп барган сыман.

— Эт иң ышанычлы җан иясе бит ул, — ди Кәлимулла агай, Тулганайның колак артын кашыгандай итеп. — Ил чиген юкка гына этләр белән саклап йөрмиләр. Кешегә калса — ышаныч бәләкәйрәк аңа. Солдаттан кайткан берәү әйткән, имеш: солдатка киткәнче йокының иң тәмлесен йокладым — чөнки илне саклап торганнарын белгән идем. Аннан соң йокы аз тиде — чөнки солдатка алынып, илне үзем сакладым. Солдаттан кайтканнан бирле йоклый алмыйм, чөнки ил сагында кемнәр торганын беләм инде, ди икән. — Кәлимулла абзый белән әткәй көлешеп алдылар.

— Тәртип юк шул илдә, тәртип юк.

Әле беркөнне колхоз рәисе Фатих абый Салихов каравылда торучы Хәләф абзыйның хәлләрен сораша. «Ничек, Хәләф агай, төннәр әйбәт кенә үтәме?" — дип сорый. Тегенең телен шайтан ялаган, күзен дә йоммый: "Бик әйбәт үтә, иптәш Салихов, башта, йоклап киткәнче генә кыенрак», - ди. Ни кырыс рәис Хәләф агайга нәрсә әйтергә белми кеткелдәп көлде дә, кулын селтәп китеп барды. Хәләф агай каравылда чакта күзен дә йоммый, монысын гына белә ул, илдә һәр урында шундый Хәләф агайлар булсын иде дә...

— Тәртип урнаштыру, бер уйласаң бер дә кыен эш түгел ул, — ди Кәлимулла абзый, тәмәке төпчеген мөштегеннән кагып төшереп, — дөньяда һәр нәрсәнең үз урыны булырга тиеш тә, һәр нәрсә үз урынында торырга тиеш, әйе бит, Тулганай? — Эт аңлагандай тыенкы гына өреп алды.

— Әйберләр генә түгел шул, Кәлимулла кордаш, кешеләрнең дә һәркайсы үз урынында утырырга тиеш. Кешесе дөрес утырмаганга әйбере дөрес куелмый аның...

Җиргә караңгылык иңгәч, әткәй Тулганайны алма сакларга, бакча эченә кертеп җибәрде. Эт иркенлеккә чыгуына мәтәлчек ата–ата уйнап алды да, төп эшен исенә төшергән сыман, урам якка иң якын алмагачның төбенә барып ятты. Мин исә чоландагы йомшак урыныма кереп ятуга, тансыклаган әвен базарына киткәнмен.

Тулганайның ачыргаланып өргән тавышына уянып киттем. Әткәй ишекләрне җилле ачып, сукранып чыгып бара әнә. Тулганай дулый–дулый абалап өрә. Кемнәрдер кычкырган сыман, бернәрсә аңламый ятам башта. Тулганайны бакчага ябып куйганны искә төшеп, мин дә тышка атылдым. Тәрәзәдән төшкән электр утында яхшы күренә, әткәй берәүне якасыннан эләктереп, ишек алдына өстерәп алып чыкты. Үзе Тулганайны тыярга маташа

— Булды, Тулганай, җитте, тимә кешегә, чәбә-чәбә, дим!

Эт ярсыган, һаман тынычлана алмый, теге бәндәгә очып-очып куна.

... Алма карагын эләктерү шатлыгы озакка бармады. Карак дигәнең — авыл советы рәисе Фәсхи абзыйның улы, колхозның комсомол оешмасы секретаре Фердинант булып чыкты.

— Районнан инструктор кыз килгән иде, кунакны тәмле алма белән сыйлыйм дигән идем, — дип акланган була. — Харап икән, берәүләрдә алма бар. Бакчага эт ябып куйган булып. Кулак сыңары... — Ул үзендә бөтенләй гаеп күрми,

төп гаепле итеп бакча хуҗасын саный иде. Тулганайга ачу белән карап тора, хәленнән килсә, ике уйламый өзгәләп ташлар иде. — Тибеп кенә очыраем мин аны, — диде ул гайрәтләнеп. Этне мин кочаклап алган идем инде, җибәрер чама гына юк. Җибәрсәң, тагын өскә ыргый. Адәм страмы ясаган булып... Район инструкторы алдында...

Фердинант тавышланып чыгып китте. Тавышка аптырап, әнкәй дә чыкты. Әткәй, озаклап вакыйганы аңлатып бирде.

Бакча эченә сикереп төшеп, алмагач ботагын дыр–дыр селкетеп, алма коя башлауга, моның өстенә кисәк кенә Тулганай ташланган. Нәкъ Кәлимулла абзый өйрәткәнчә, өрми-нитми угрының арт ягына төшкән дә, һап! Эләктереп тә алган егетне. Фердинант һушы китеп ауган. Эт тавышына исенә килеп, коймага сикереп менәм дигәндә, әткәй куйган капкын — элмәккә китереп баскан. Элмәк — бер башын кеше аягы сыярлык кына итеп, шудырма төенләп җиргә ташланган бау, икенче очы - койма баганасына бәйләп куелган. Фердинант коймага ыргылган да, аягы бумакка эләгеп, ярты гәүдәсе белән коймага асылынып калган. Урамга сикерер иде — аягын шытырдатып элмәк кыскан, бакчага кире төшәр иде — анда Тулганай хуҗа. Шулай беренче зур чыныгуын алды Тулганай.

Чыннан да төнге вакыйгада әткәйне гаепле иттеләр. Фәсхи абзый монда да әткәйне гаепләп, кәнсәгә чакыртты. «Этеңне бәйләп куймасаң, мылтык белән үзем атып чыгам, — ди икән. Штраф салулары, чалбар хакын түләтүләре генә җитмәгән, әткәйне сүгеп тә җибәргән. — Малайны адәм рисвайт иттең, чалбарын төбеннән умырып төшергән этең... Бәхетең, теге чак булса... Кулак син, алма сатып көн күрмәкче буласың», — дигән. Әткәй өйгә кайткач, шомга төшеп, сөйләп бирде.

— Куркытмасын! — диде әнкәй көтмәгәнчә усаллык күрсәтеп. — Ак эт бәласен кара эткә такмасын. Бер хәл булса: «элекке чак булса», — дип тотына ул Фәсхи. Аның элеккесе дә, хәзергесе дә бер — сәвит дигән булып, ыштан төбе туздырып йөрү. Малаен кайгыртсын, әллә кем булды, олыны олы, кечене кече дип белмидерие, әйбәт итте Тулганай. Йөрсен инде менә хәзер «алма буры» исеме күтәреп. Авылда халык үткен, кушаматны бер такса, юып та төшереп булмый.

Чыннан да Фердинант абыйга урларга маташкан алма исеме ябышты — аны «Антун» дип йөртә башладылар. Антоновка сортлы алма бар безнең. Хәер, кушамат күтәреп йөрүе озакка бармады, аны партия мәктәбенә — Ленинградка укырга җибәрделәр. «Өметле, кыйммәтле кадр» — дигәннәр районда. Монысын Фердинантның әнисе, көтү куганда, хатыннарга мактанып сөйләгән.

Этнең батырлыгын болай гына калдырып булмый, билгеле. Кинода күргән бар — шәп этләрнең муенына медаль тагалар. Кәнсир калаеннан медаль ясап, Тулганайның муенына өч медаль тагып куйдым. Берсе — Равилне адәм көлкесенә калдырганы өчен, икенчесе үз гаебемне йолу исәбеннән — Кыркүле вакыйгасы уңаеннан, өченчесе — алма саклаудагы кыюлыгы өчен. Ышансагыз, шушы медальләргә Тулганай чынлап сөенде. Ни дисәң дә, аларның берсе чын батырлык күрсәткәнгә бирелгән «медаль» иде бит.

*Ахыры киләсе санда*

# БАЛАЧАК–ҮСМЕРЧАК ВАКЫТЫНДА ЯЗЫЛГАН ХАТЛАР

(ОЛЫ МӘҢГӘР, ЯҢА КЕНӘР, 1939 - 1941 ЕЛЛАР)

**Мәхмүт Хөсәен хатыннан:**

Рафаил дус!

Архивтан Синең хатларыңны эзләп таптым - 6 хат. Хәрефен-хәрефкә күчереп үзеңә җибәрәм - укып рәхәтлән. Кечкенә генә рәсемең дә бар - бик тонык. Хатка салып җибәргән «Чәчкә» һәм «Беренче кар» исемле ике хикәяң дә саклана миндә. Алары үзеңдә дә бардыр, күчереп тормадым.

Нигә миңа бер дә хат язмыйсың? Алай ярамый. Минем «Сайланма» җыентык чыгып килә. Үземнең 2 кульязмам калды редакциялисе. Аннан 1973 елның планы тулысынча үтәлә. Аннан юбилей мәшәкате килеп җитәр.

Хатларыңны алуың турында обязательно хәбәр ит, югыйсә борчылып торам.

Егетләрчә сәлам.

Мәхмүт. 24.02.73 Казан

**Мәхмүт Хөсәенгә җибәрелгән хатлар:**

Кадерле Мәхмүт!

Бу хатны мин сиңа, Татарстан республикасы, Әтнә районы, Олы Мәңгәр авылыннан язам.

Мин әле генә «Яшь Ленинчы» газетасыннан синең Госманга язган хатыңны укыдым, һәм мине тирән уй чолгап алды: «Чыннан да - мин әйтәм - башка өлкәләрдәге укучылар һәм пионерлар белән элемтә тоту нинди яхшы эш ул».

Һәм мин сиңа хат язырга утырдым.

Бераз гына үзем хакымда сөйлим:

Шулай, югарыда әйткәнчә, мин, Олы-Мәңгәр Урта мәктәбенең 7 классында укыйм, 2-чирекне отлично билгеләренә генә тәмамладым. Мәктәптә отряд советы председателе булып эшлим. «Яшь Ленинчы» газетасына язышам. (Бәлки газета битләрендә күргәнсездәдер). Шулай ук әдәбият белән дә бик нык кызыксынам.

Мәхмүт!

Бу хатны алгач та миңа хат яз һәм без туктаусыз язышып торыйк. Бу сиңа да, миңа да бик тә күңелле булачак. Миңа үзеңнең фотокарточкаңны һәм Казахстан күренешләрен җибәр, һәм мин дә шулай эшләрмен.

Без аерылмас дуслар булыйк.

Аннан соң шуны да әйтим, күбрәк «Яшь Ленинчы» газетасы аша да язышыйк. Безнең дуслыкны бөтен ил белсен. Әйеме? Шулай ук миңа үзеңнең язган шигырьләреңне җибәр, ә мин сиңа үземнең хикәяләремне җибәрермен. Мин күбрәк хикәя язарга яратам, һәм без хат аша бер-беребезнең әсәрләребез хакында үз фикерләребезне әйтербез, эш тәҗрибәләребезне уртаклашырбыз, моның файдасы бик зур булачак.

Безнең Татарстанда хәзер елның иң матур вакытлары килеп җитте. Май ае ул безнең иң матур аебыз.

Кояш ягымлы гына көлә. Кошлар үзләренең берсеннән-берсе матуррак тавышлары белән язга мактау җырлары җырлыйлар. Яңа гына аткан матур шомырт чәчәкләре исе борынны кытыклый.

Табигать көннән-көн җанлана, матурлана. Язгы йомшак җил башлардан сыйпап иркәли.

Ә кичләрен авыл өстендә колхоз яшьләренең шатлыклы җырлары яңгырый. Искиткеч күңеллелек!

Мин иң матур айлы кичләрдә тышка чыгып утырырга яратам.

Ай акрын гына күктә күзләп йөри. Агачлар искән җил белән акрын гына шаулашалар, нәрсәдер сөйләшәләр. Бөтен нәрсә тын гына йокымсырый кебек. Тын. Яшьләрнең шат авазлары инде ишетелми. Алар киноларга һәм болыннарга китеп беткәннәр һәм менә шул вакыт инде мине уйлар томаны чолгап ала. Мин уйларым белән әллә кайларга барам, әллә кемнәр белән сөйләшәм.

Шулай, дустым, без туктусыз хат язышып торыйк.

Хатларны мөмкин кадәр ешрак язарга кара. Киләсе хатыңда ук миңа үзеңнең тулы адресыңны җибәр. Зарыгып хат көтеп калам. Хуш! Пионерларча сәлам белән: Рафаил Төхфәтуллин.

Май 1938 ел.

Мәхмүт дускай!

Күптән инде сиңа бер хат салган идем. Шулай ук синең үтенечең буенча 3 данә «Пионер каләме» дә җибәрдем. Ләкин шулай да әлегә кадәр җавап алганым юк. Сиңа моның өчен бик нык үпкәлим.

«Артек»та ял итеп кайттың, Кырымның искиткеч һавасын суладың, гүзәл Кара диңгезнең суларында коендың, никадәр күп нәрсәләр күреп кайттың, никадәр бәхет һәм шатлык сиңа! Ләкин нигә инде шуларны дустың белән уртаклашмаска! Мине бөтенләй оныттың. Үзеңнән түбәннәр белән язышасың килми ахры! Комсомолга бер дә килешми инде бу!

Үземә килсәк, хәзер минем адрес үзгәрде. Шушы елның сентябрендә Тат. рес. ның Кызыл-Юл районы, яңа Кенәр авылына күчеп килдек. Авыл яхшы гына. Кызыл-Юл районының үзәге. Үзендә урта мәктәп тә бар. Библиотекасында китап бик күп. Бусы минем өчен бик яхшы!

Авыл шактый матур урында урнашкан. Якында гына урман бар. (Яратам да соң урманны!)

Мин дә хәзер комсомолга кердем. Үзебезнең класс газетасының редакторы булып эшлим. 1- чиреклне уңышлы тәмамладым.

Бездә хәзер кыш.

Мин ак күбәләкләрдәй шаяра-шаяра төшәргә урын эзләгәндәй акрын гына очынгалып йөрүче кар бөртекләренә сәгатьләр буенча карап торырга риза! Яратам мин аларны. Алар миңа үзебезнең шат балачагыбызны хәтерләтәләр кебек!

Кыш!

Бөтен җир ап-ак! Ягымлы кояш салкынча гына елмая. Кышкы һава рәхәтләндерә. Күңелле!

Сиңа үземнең «Чәчкә» исемле лирик хикәямне җибәрәм. Хикәям турында үзеңнең тәнкыйди карашыңны язып җибәр. Обязательно җибәр. Онытма!

Ярый хуш!

Минем адрес: Тат. Республика Кзыл-Юлский р-н

дер. П/о Нов. -Кинер. Ср. школа.

Хат көтеп калам.

Сәлам белән: Рафаил Төхфәтуллин. 10.12.39 ел.

Мәхмүт иптәш!

Хатыңны алдым. Әйе, минем үпкәләвем урынсызрак булган икән шул, гафу ит инде.

Ул менә ничек булды: үземнең беренче хатыма җавап алгач та сиңа озын итеп хат яздым, шулай ук син сораган журналларны һәм бер карточкамны да җибәргән идем. Ләкин алар, күрәсең, тапшырылмаганнар. Ә мин бик озак җавап көттем, ниһаять чыдамадым, сиңа азрак үпкәләп хат салдым.

(Ләкин бу син уйлаганча ук бәла ягу түгел, ә болай гына, дусларча үпкәләү генә иде).

Я, әйдә ярар килешик, һәм бу аңлашылмауны тизрәк онытыйк.

Шулай, мин теге хатымда язганымча яңа урынга күчеп килдек. Хәзер инде яхшы гына ияләштем. Тыныч кына укып ятам. Комсомол сафына кердем. «Пионерская правда» ачкан «Разведчики» уенына катнашам.

Мәхмүт!

Мин сиңа берничә сорау бирәм /мин моны тапшырылмаган хатымда да язган идем/.

1 Синең Казахстанның халык акыны Җамбулны күргәнең бармы. Булса, очрашу истәлегеңне яз.

2. Син кайчан яза башладың, беренче шигырең басылдымы?

Хуш!

Ком. сәлам белән: Р.Төхфатуллин.

Син миңа һәрвакыт Сез дип мөрәҗәгать итәсең. Болай итмә, ә дусларча син дип кенә әйт. Якын дуслар һәрвакыт шулай итәләр бит.

Хат көтәм. 25.12-39 ел.

Мәхмүт дус!

Синең 25/11 дә язган хатыңны алдым. Минем «Артек» турындагы сорауларыма тулы җаваплар язгансың, рәхмәт!

Син «Пионер каләме»нең 12-номерын сорагансың икән. Ләкин моны таба алмадым. Чөнки үземә бу номер килмәде, подпискам тулган иде.

Мәхмүт! Миңа үзеңнең бер иң яхшы шигыреңне җибәр әле! Мин аны дуслыгыбызның истәлеге итеп күңелгә бикләрмен һәм үзебезнең мәктәптә үткәрелә торган әдәби кичәләрдә укырмын!

Аннан соң үзеңнең язылган, язылачак һәм языла торган әсәрләрең турында миңа яз!

Укуыңда һәм эшеңдә уңышлыклар теләп, сәлам белән:

Рафаил Төхфатуллин 6.03 - 40ел.

Кымбатты җолдасым, коч бол!

Мәхмүт дус!

Сиңа кайнар сәлам җибәрәм һәм күңелле ял теләп калам. Үзем 8-классны отлично һәм яхшы билгеләренә тәмамлап 9-класска күчтем. Хәзер яхшы гына ял итәм. Су коенам, физкультура белән шөгыльләнәм, кояш нурларыннан файдаланам. Кичләрен тәмле хыялларга бирелеп, ярыша-ярыша кычкырышкан бакалар тавышын тыңлый-тыңлый, үзендә яр буеның матур күренешләрен чагылдырган тыныч су өстенә карап, бик озак яр буенда утырам; офыкны алсуландырып баеп баручы кояш нурларын кул болгап озатып калам. Хуш исле чәчәкләр исен иснәп, җырчы кошларның шат җырларын тыңлап, акрын гына бакча буйлап атлыйм. Кешеләрнең эчке характерын, үзенчәлекләрен табарга тырышып аларның эчләренә кердәй булып карап узам. Аларның сөйләшүләренә колак салып базарларда тулганам. Үз яныма малайларны, иптәшләремне җыеп урманнарга, болыннарга чыгам. Әбиләрне-бабайларны әкият сөйләтеп алҗытып бетерәм. Менә боларның барысын да түкми-чәчми көндәлегемә яза барам. Фольклор материалларын аерым, ишеткән кызыклы фразаларны, сүзләрне, вакыйгаларны аерым дәфтәргә язам. Шулай итеп хикәяләрем килеп чыга. Шушы арада «Фәйзүк» /хикәя/, «Вәли белән Гали» /фельетон/ исемле нәрсәләрне яздым, һәм «Костер янындагы хикәяләр» исемле хикәяләр циклы өстендә эшли башладым. Моның инде «Васият», «Инженер хикәясе» исемле бүлекләре язылды да.

«Яшь Ленинчы»да минем «Әнәснең теше» һәм «Беренче көн» исемле әйберләрем басылып чыкты. Укыгансыңдыр.

Мин Ю.Твердин /Куйбышев/, Фатыйх Хөсни /Казан/, Н.Баязитов, М.Галеев /Олы-Мәңгәр/ләр белән язышам.

Миңа 16 яшь.

Хат көтеп: Рафаил Төхфәтуллин. 15.06 - 40ел.

Мәхмүт иптәш!

Син инде, әлбәттә, миңа бик каты ачуланасыңдыр. Гафу ит... синең үтенечеңне /П.К.№12/ үти алмавым оятыннан, буш вәгъдәләр белән генә хат язарга теләмичә мин язышуыбызны туктатып торган идем. «П.К.»не соратып барлык иптәшләремә хат яздым. Ләкин ... үч иткәндәй, барысы да төрле сәбәп табып, кире язалар. /Алар белән ачуланышып та беттем/. Шулай да Азнакай урта мәктәбе укучысы С.Фәйзиев шактый тырышып эзләп тә таба алмагач, «П.К.» редакциясенә хат язып, аннан синең шигыреңнең күчермәсен алып, миңа җибәрде. Бу күчермә, әлбәттә, сине канәгатьләндерә алмаса да, синең үтенечеңне ничек тә үтәргә тырышуымны күрсәтү өчен аны сиңа җибәрәм. Киләчәктә «П.К» журналының үзен дә ничек тә җибәрергә тырышырмын.

Үзем таза-сау. Хисләремдә давыл, уйларымда өермә, йөрәгемдә Идел ташкыны... Шулай да мин хәзерге тормышым белән һич, һич канәгать түгел. Күңелем нәрсәдер эзләнә... Күңелсез мәктәп тормышы /әйе, Яңа Кенәр мәктәбе минем өчен бик, бик күңелсез. Сәбәпләрен, теләсәң, киләсе хатымда язармын/, өемдәге эчпоштыргыч обстановка, эч серләреңне, киләчәк планнарыңны уртаклашырлык чын дустым /Рәфгать Бикчәнтәй/Казан/, аның турында да киләсе хатымда язармын/ янымда булмау - вакыты белән минем өермәле хисләремне җиңеп, күңел төшенкелегенә бирелергә мәҗбүр иткәлиләр. Ирексездән кешеләрдән читләшеп, ялгызым уйланып утырам... күңлем еракка, еракка китә. Уйларым ташкалага, Кремльгә барып тоташалар да тагын уйларымда давыл, йөрәгемдә көчле ташкын башлана... Бу кичерешләрне язып аңлату читен.

Бу арада әдәби иҗат белән шөгыльләнүне дә туктаттым. Социализм чорының социалистик реализм методы белән үлмәс әсәрләр тудыру дәрте аркасында туган башымдагы мең төрле тормыш сорауларыма җавап биреп бетерми торып мин яңадан әдәбият мәйданына килмәячәкмен. Ләкин мин бу сорауларга җавап табып, әдәбиятка үз сукмагымны салып, үз иҗат җимешләрем — йөрәкләрдә көрәш, оптимизм дәрте тудыра торган әсәр белән әдәбиятка килермен. Моның өчен бәлки ярты, бөтен гомерем дә китәр. Ләкин мин үз теләгемә ирешермен,ирешермен!

Быелгы җәйге каникул вакытымны авылда, табигать кочагында үткәрдем. Рәхәт урман һавасын суладым, кояшта кызындым. Әдәбият белән дә мавыктым. Кайбер әсәрләрем матбугатта да чыкты. Зурраклары: «Чәчкә», /«Яшь Ленинчы»/, «Наиль дус» /«Пионер каләме»/, «Шәриповның борылырга да вакыты юк» /фельетон, «Яшь сталинчы». Шулай ук республика күләмендәге үзешчәнлек олимпиадасына катнашып библиотека белән бүләкләндем. «Яшь Ленинчы», «Яшь сталинчы» газеталары шушы уңай белән үз битләрендә бу беренче тәҗрибәләрем турында язып та үттеләр.

Дускай! Минем берәр әсәремне газетада очратмадыңмы? Алар турында үз фикереңне яз! Чөнки мин яңа көч белән яңадан әдәбиятка кайтырга җиткән вакытта бу беренче шат балалыгым тәҗрибәләре турында үземнең һәм иптәшләремнең карашларын ныгытып калдырырга телим.

Үзеңдә ни хәлләр? Укуың ничек бара? Нинди яңа әсәрләр яздың? һ. б. Хуш!

Ком. Сәлам белән: Рафаил Төхфәтуллин.
Тат.АССР, Кзыл Юльский р-н
дер. Новый-Кинер, СШ.
Тухватуллину Рафаэлю.
2.04.-1941.

*Камилханә*

Гүзәл
Фарсыева
*Актаныш районы*

# «ӨЧЕНЧЕ КЛАССЛЫ» КИЯҮ

ХИКӘЯ

Кичә, озак кына икеләнеп йөргәннән соң, ниһаять тәвәккәлләдем — миңа һичшиксез өйләнергә кирәк! Ә нәрсә?! Мин быел инде 4 нче класска күчәм, баш та күпне күргән, шуңа да карамастан кәләшем юк. Оят. Иртәме-соңмы барыбер бер тәвәккәлләргә кирәк. Тагын бер-ике ел өйләнми йөрсәм... буйдак булып калуым бар! Ул чакта инде чиләгем дә, теләгем дә булыр... Әмма әбием әйтмешли, янгын беткәч, көлгә су сипмиләр... Ходай үзе сакласын! Әтием дә: «Синең яшьтә инде кайберәүләр герой булып, күкрәгенә орден тактаннар», — дип, еш кабатларга ярата. Гадәттә, аның бу сүзләре мин чалбарымны бот төбеннән ертып кайткач еш яңгырый. Койма башыннан йөрергә яратам мин. Әбием әйтмешли, «мәчтер». Сез тагын боларның капкалары юк, коймадан гына йөрешле икән дип уйлый күрмәгез. Бар ул койма... Тьфу, капка үз урынында. Аннан һәркем йөри ал.а. Ә менә коймадан миннән башка курыкмыйча кем йөрсен инде тагын! Анда бит мин яратмаган, әмма кызганычка каршы минем чалбар балагымны үлеп яраткан каһәр төшкән сары башлы тутык кадак бар...

Өйләнергә җыенуым хакында мин иң якын дустым Аязга сөйләдем. Без аның белән бакчадан ук дус. Башта «гәршүкләребез», соңрак парталарыбыз уртак булды. Безнең арадан бернинди җил дә үтми.

— Маладис!— диде Аяз, инсәмнән кагып. — Вакыт, дустым, вакыт! — Аяз орынган урында канатлар үсеп чыктымыни! Авызымда булыр-булмас тугыз пар тешем белән ягымлы итеп елмайдым. — Озын тәнәфестә, сиңа үзебезнең класстан кәләш сайларбыз, — диде Аяз, белдексез йөзенә белдекле кыяфәт чыгарып.

Кыңгырауның яшелле-күкле тавышы яңгырау белән, унынчылардан «Горилла» кушаматлы малай коридорның беренче башыннан икенчесенә уктай атылды һәм бөтен мәктәпне дер селкетте. Иптәшенә: «Борчааак, тәгәрә монда!» — дигән боерыгыннан соң, техничка Кәүсәрия апа сыңар пыялалы күзлеген төзәткәләп : «Исән калдык!» дип авыр көрсенеп куйды.

Коридордагы тавышлар бераз түбәнәя төшкәч, Аяз миңа текәлде:

— Сиңа Алия Бадамшинага өйләнергә кирәк!

— Нигә?

— Сон ул бит гел «5» кә генә укый. Кучерткән өчен «Сникерс» ташып акчаң бетте бит инде. Өйләнсәң акчаң да янга кала, гомер буе бушка да кучерәсең! Тик кара аны, мине онытма!

— Ю-у-ук,— дидем мин авызымны бөреп, — ул «ботан» мине китап

укырга мәҗбүр итәчәк. Нотыктан болай да туйган. Андый хатын, хатын түгел инде ул...

— Соң алайса, Зиләне сайла, «ботаник» кирәк булмагач...

— Син нәрсә?! Ул бит аңгыра булуы өстенә, бетле дә. Беркөнне дәрес буе партага бетләрен коеп утырды. «Кавык» дигән була, бетле карга... Үзем күрдем, парта буйлап бетләре укытучы өстәленә таба элдертте. Соңыннан линейкам белән туп-туч үлчәдем, төп-төгәл 27,83 см ара үткәннәр. Әле арып кына туктагандыр, мөгаен.

— Ә Җәмилә ничек? Аның әтисе,беләсең килсә, «Мерседес»ның соңгы моделендә җилдерә!

— Кит, Аяз, симез бит ул.

— Симез түгел, таза диген инде, та-за! Зато «Мерседес»ы бар. Аңа өч Җәмилә сыя әле, сыйдырсаң...

— Мышный ул. Лап-лоп атлый. Коридор уртасында туктап хәл җыя да, тагын атлый. Ашаганда Сәлимнең порциясен дә үзенекенә өсти. Тегесе ач калса да дәшми — курка. Аннары соң... Мин аннан үзем дә куркам.

— Сиңа, дустым, өйләнмәскә сәбәп кенә булсын. Агы — нык ак, карасы — кирәгеннән артык кара... Йөр инде шунда, берүзең...

— Ә беләсеңме, Аяз, миңа Рәйхан ошый.

— Кит, теге Харуновамы?

— Әйе, «Х!» Хайван дигәндәге... Ул миңа охшаган. Әнием әйтә: «Синең әтиең минем үземә охшаган — эшкә таләпчән, башкаларны хөрмәт итә, шуңа күрә без бер-беребезгә туры килгәнбез», — ди.

— Шуннан?

— Шуннан, шул. Рәйхан да миңа охшаган. Чәчләре чем-кара, ул аларны гел үреп йөри...

— Кит, син үзең кайчаннан бирле чәчеңне үреп йөри башладың соң, җүләр?

— Нәрсә беләсең соң син, өйләнү турында?! Без аның белән барыбер охшаганбыз... Мисалларым күп әле... Беләсең килсә...

— Эх, өйләнү сөйләнү генә түгел шууул... Өченче класста, бәлкем, соңдыр да... «Картлык — шатлык түгел», ди дәү әтием.

— Мммда-а-а-а... Өйләнү математикадан да авыррак икән, Аяз!..

Бу вакытта инде «Горилла» «Борчак»ка каршы стартка басты. Ә Кәүсәрия апа, бер кулы белән күзлегенең соңгы пыяласын кысып, икенчесе белән нәүмиз генә кыңгыравын алга сузды, берара кулын селкергә тәвәккәлли алмый торды...

Уку елының соңгы кыңгыравы иде бу...

— Быел тагын өйләнә алмадың, — диде Аяз. Ә үзе мине юатасы урында, никтер, Рәйханны куа китте.

---

## Гүзәллекнең чиге юк

*Матур әдәбиятнын кырыс бер кануны бар – көчәнеп кенә талантлы язучы була алмассын... Кат-кат кучереп язсан, кулдан-кулга йөртеп эшләттерсән, мөхәррирләрнен тенкәсенә тиеп тәкъдим итсәң – бәлки, әйбәт кенә бер хикәя, хәтта жыйнак кына повесть та әтмәлләп булыр.*

*Нәрсә сон ул талант, диярсез?..*

*Мина калса, талант ул башкалар өчен гап-гади генә тоелган вакыйганы да шагыйранә сурәтләп, үз кичерешләрең белән тулыландырып, хисләрен белән өретеп укучынын игътибарын яуларлык әсәр итеп житкеру... Нәкъ менә Гүзәл Фарсыеванын хикәясе кебек итеп...*

*Өченче класслы кияү...*

*Исеме үк үзенә җәлеп итә. Әйбәт исем табу – әсәрнең яртысы уңышы. Без бит әле яңа туган балага да исем кушулары шактый ук кыен булган заманда яшибез. Яңа исем якын-тирәдәгеләрне кабатламасын, сөйкемсезләргә адаш булмасын, күңеле китекләрне сискәндермәсен дибез.*

*Бала димәктән, Гүзәл үзе дә әле балалыгын сагынып яшидер. Ә сагыну-сөю ул – иҗатка рухландыручы иң зур көч. Күбрәк язсын иде ул мондый хикәяләрне.*

*Бер уйласаң, бөтен кешелекнең башыннан кичкән халәт бит бу: шул самими балачакта ук кайсы малай кино артистларының рәсемен кисәсендә йөртмәгән дә, кайсыбыз дәү апаларга, олы җиңгәйләргә өйләнү турында хыялланмаган?! Әниләр итәгеннән төшкәч, назга сусаган килеш әкренләп мөстәкыйльлеккә таба атлый башлаган чор бит ул. Һәм Гүзәл Фарсыева өйләнү турында хыялланган малайның психологиясен рәнҗетми-нитми, күңелен сындырмый гына сурәтли алган. Шушы була да инде талант дигән бөек һәм изге нәрсә.*

*«Өченче классыл кияү» үзенең кыскалыгы белән отышлы. Тәҗрибәсез автор аны ун биткә чаклы суза алган булыр иде. Ләкин «кыскалыкта осталык»ны һәммәбез белә. Гүзәл дә әлеге комик ситуацияне ике бит ярымлык хикәяләүгә сыйдырган.*

*Жанр турында сүз кузгалгач үзеннән-үзе сорау туа – хикәяме бу, әллә әдәби фельетонмы? Өченче сыйныфта укучы башка малайларның, шул исәптән якын дусты Аязның да өйләнергә теләге юк бугай? Димәк «Мин»нең кәләш эзләве типик күренеш түгел, ә очраклы уен гына булып кала. Шуңа күрә дә әсәр әдәби фельетонга туры килә кебек. Бүгенгеләребезнең бик күбесе, шул исәптән Батулла, Р.Зәйдулла, Л.Лерон, В.Нуриев, А.Гыймадиев, Р.Галиуллин һ.б. иҗат юлын әдәби фельетоннан башлап танылган язучы була алдылар.*

*Дөрес, малаебызның фикер йөртеше, сөйләнүе кайвакыт артык олыларча да... Нишлисең бит, малайлар өлкәннәр кулында үсә, алардан алган сүз запасы белән генә яши. Әле ул укый башлаган гына, алда аны уноч мең сүзе булган бай хәзинәле туган теле көтә!*

*Уңышлар телим сиңа, сеңлем.*

**Камил КӘРИМОВ**

**Редакциядән.**

*Хөрмәтле укучылар!*

*Каләм тибрәтүче яшь дуслар!*

*Сез дә төүге әсәрләрегез белән «Камилханә» сәхифәсендә катнашыгыз. Сезнең иҗатны да игътибардан читтә калдырмабыз. Кем әйтмешли, бергә-бергә язарга өйрәнербез. Остаханәдә ачык ишекләр елы.*

## Альберт Хәсәнов

# ТАБИГАТЬ ТУРЫНДА ПАРЧАЛАР

### Көзге урман аланында

Төбәгебезгә сап-сары, ал-кызыл яфраклары белән алтын көз килде. Елның һәр фасылы үзенчә матур. Ә көзләребез — аеруча. Кортларыбызны кышка инде күптән әзерләп куйсак та, өй ягына алып кайтырга ашыкмадык әле. Һаман да урман аланында тотабыз. Бирегә иртә яз башында чыгып утырган идек. Ни дисәң дә, урман һавасы урман һавасы инде: тын, ышык, тузан юк, тавыш юк. Аз гына кояш караса, алан шундук җылынып китә, кортлар оча башлый. Канатларын язып, һава сулап керәләр.

Умарталыкны чиратлашып саклыйбыз. Бүген — минем чират. Килү белән учак ягып җибәрдем, су салып казан астым, көлгә бәрәңгеләр тәгәрәттем. Кесәгә генә сыешлы радиоалгычны каршыдагы имән ботагына элеп куйдым. Аннан, күңелгә рәхәтлек өстәп, җиңел көй агыла.

Моңа тикле бер атна тоташ яңгыр койды. Көн бүген генә ачылып китте. Аланда җылы, ышык. Кичке дүртләр тирәсе булыр. Шулчак, ишетәм, күрше аланда поши мөгри. Бу урманда байтак алар. Моңа кадәр дә еш күренгәләп китәләр иде. Тавышы бик гайрәтле ишетелә. Барып карасам, мин сиңа әйтим, аланның нәкъ уртасына чыгып баскан. Тау артына күчәргә җыенган кояш нурларында аның сырты, кызгылт төскә чумып, елык-елык килә. Кызыл мәрмәрдән коеп куйган сын диярсең. Поши үгезе бу! Янәсе, бу урманга мин хуҗа! Мөгри, мин сиңа әйтим, үзенә бер гайрәт белән! «Кем дә кем минем белән килешми, бирегә, ошбу аланга, көч сынашырга чыксын! Ягез, кемнең йөрәге җитә?!» — ди төсле. Әйтәм ич, бөтен урманны тетрәтеп мөгри. Күзләрен тәмам кан баскан.

Миңа бик кызык булып китте. Үземә дә кирәк бит шундый малайлыкны эшләргә: поши егетен үртәмәкче булдым. Инде чәчем агарып бара, акыл керергә дә вакыт югыйсә, ә шуклыкларны эшләргә генә торам. Каеш белән тотып ярасы нәрсә, дип орыштым үземне соңыннан. Әйе, соңыннан. Ә хәзер исә үз аланыма кайттым да, ике кулымны авызыма куеп, пошича мөгри башладым. Бик килештереп мөгрәгәнмен, күрәсең. Әлеге пошием юлында очраган усак үсентеләрен, чикләвек куакларын шатыр-шотыр сындырып килеп чыкмасынмы каршыга?! Ажгырып минем өскә килә. Йөзендә миһербан әсәре күренми. Инде нишләргә? Ярый әле каршыда гына карт имән бар иде. Уйлап-нитеп торырлык ара юк, космик караб тизлеге белән шуның башына үрмәләдем.

Үртәвемне, үзенең алдануын поши шундук сизде. Әй ачуы чыкты да соң моның! Мине изеп ташларга әзер. Хурлыгыннан тагын да ярсый төште. Имән төбенә килеп басты. Селәгәен чәчә-чәчә уңга да сулга башын чайкый, усал пошкыра. Топ та топ тибенә. Имән нык, йөз еллык, юкса аны да сөзеп аударган булыр иде. «Төш монда, куркак җан! Күрсәтәм хәзер күрмәгәнеңне!» — ди бугай поши.

Әйтәм ич, әле ярый башына менеп кунаклаган имәнем нык. Нечкә генә

*Ахыры. Башы 11нче санда.*

усак янсә юкә булса, шундук сөзеп аударган булыр иде. Аудармас, бар! Җен көчләре бардыр үзендә.

Имән тирәсендә таптангалап берни майтара алмагач, пошием учакка таба юнәлде. Учак өстенә каккан казыкларны, аркылы агачларны сөзеп аударды. Болар гына аз тоелды, ахры, үзенә. Казыклар өстендә утырган умарталар арасына барып керде. Берәм-берәм аларны аударырга кереште. Агач башыннан гына: «Пиф-паф! Атам бит!» — дип әтәчләнгән булам. Колагына да элми, хулиган. Соңгы умартаны мәтәлдергәннән соң гына ачуы бераз басыла төште әзмәвернең. Радиоалгычта яңгыраган «Җиңүчеләр маршы» көенә аланны янәдән бер әйләнде дә каршы як чыршылыкка таба атлады.

Бераздан мин дә агач башыннан төштем. Сукрана-сукрана умарталарны янәдән казыкларга утыртып чыктым. Урынсыз шаяртуым өчен хәтта үземә дә оят булып китте. Колак очларыма кадәр кызарды. Аларны күрергә янымда иптәшем генә юк. Ә поши үгезенең гайрәтле мөгрәве урманның аргы башындагы аланлыкта ишетелә. Ул әле дә үзенең көндәшләрен — поши егетләрен — аның белән көч сынашып карарга чакыра. Аларның хәзер нәкъ менә көч сынаша, бил алыша торган вакытлары шул.

## Башкаларга кое казысаң...

Әле иртә кыш башында ук карт алма ботагына фанер кисәге элеп куйдым. Шунда һәр көн җим сибәм. Бер көтү чыпчык, сарытүш, карабүрек, соры песнәкләр шуннан җим чүпләп тукланалар. Шатлыклары түбәләреннән аша, бөтен ишегалдына чыр-чу килешәләр. Ә нигә шатланмаска, сөенмәскә. Җан биргәнгә җүн бирә тора. Тау артыннан февраль кояшы карый инде, җылы язлар җитәргә дә күп калмый. Әлегә исә җим тактасында җылы тары боткасы, ипи валчыклары. Ә җаны теләгәннәргә әнә ботакта бер кисәк дуңгыз мае да бар. Теләсәң, анысыннан авыз ит.

Беләм, бик аңлыйм мин аларның хәлләрен. Әгәр кышның шушы авыр чорында ярдәм кулыңны сузмасаң, эшләре мөшкел. Былтыр шулай үтә салкын төннәрдән соң, иртән эшкә барганда, туңып үлгән кошчыкларны юлда күп очраткаладым. Салкыннан түгел, ачлыктан үлгәннәр алар, бичаракайлар. Тамаклары тук булса, берни булмый, туннары калын, җылы. Ә менә кешеләр ярдәм итмәсә, кышын җимне каян табып бетерәсең? Кош-корт, бөҗәкләр кар астында. Шуңа күрә кышка керү белән үзебезнең кошчыкларны мин җимнән өзмим. «Үзебезнекеләр» дим шуның өчен. Чөнки алар чыннан да безнекеләр. Безнең өй, мунча, лапас шиферлары астында, гараж кәрнизләрендә бик күбәү яшиләр алар. Чыпчыкларның кайберләре, хуҗалары җылы якларга китү белән, кышкылыкка сыерчык ояларына да күчәләр. Чөнки анда җылырак, ышыграк.

Ә бер тапкырбаш чыпчык гаиләсен генә күр син. Искитмәле бит. Ике-өч ел саен череп-авып аптыраткан кайбер койма баганаларын тимер торбалар белән алыштырган идем. Әлеге чыпчык гаиләсе, мин сиңа әйтим, шул торба эченә оя корган. Башлары җиткән. Үзләренә аннан очып чыгу чүп кенә. Ә менә песи-разбойникка йә башка ерткычка анда якын килешле дә түгел. Әйтәм ич, профессор башы бар икән үзләрендә. Икенче елларын инде шунда кайгы-хәсрәт, хәвеф-хәтәрсез дөнья көтеп яталар.

Бүген исә җим сибүем генә булды, фанер такта өстен үзебезнең һәм күршетирә чыпчыклары, сарытүшләре, песнәкләре сырып алдылар. Ачыкканнар. Әмма әдәплеләр. Бер йотып куялар да, нәни томшыкларын югары күтәреп, җылы ботканы мактарга керешәләр. Миңа да рәхмәт әйтәләрдер инде. Елмаям үзләренә.

— Чәчмәгез, түкмәгез, сак кына ашагыз! — дип бармак яныйм.

Шулчак, каян килеп чыккандыр диген, каршыдагы агач ботагына карчыга-юлбасар килеп кунды. Кошчыклар сизгерләр, шундук як-якка сибелештеләр. Карчыга, качсагыз, исем китә бик, миңа сез генә кирәк инде, дип, ялкау гына очып узды да янәшәдәге миләш ботагына барып утырды. Дөресрәге, яшеренде, посты. Сизәм, изге уй-ният белән йөрүе түгел моның. Кышын, бигрәк тә шушы чорларда, бу бичаракайның да хәле мөшкел. Аның да тамагы гел ач. Каз ясә үрдәк бәбкәләре чәлдерергә бик мачтыр да бит, ләкин әле иртәрәк. Алары инде, боерган булса, яз җиткәч, болын тутырып бәбкәләр чыккач. Әлегә исә өзелеп ашыйсы килгәнне басарга шунда бирәр аңгырарак чыпчык яисә песнәк түшкәсе эләксә дә би-ик ярап куяр иде.

Ярар, карап карыйк, нинди хәйлә корыр икән бу юлбасар?

Карчыганы күздән җуйган, инде аның турында онытып өлгергән чыпчык-песнәк халкы янәдән җим тактасын сырып алды. Тактаны барабан урынына тукылдаталар. Авызыңны ачып торсаң, ботканың бетеп куюы да бар. Ач карын белән оянда дер калтырап куну язмасын инде.

Бу беркатлылар артыннан яшерен генә күзәткән карчыга: «Вакыт! Тәвәккәллим!» — дип хәл итте, күрәсең. Җәядән аткан ук тизлеге белән кошчыклар өстенә ташланды. Әмма тегеләр дә сизгер. Сакта торучылары да булган икән. Алар: «Караул! Юлбасар!» — диешкә, чыпчык-песнәкләр як-якка борчак булып сибелештеләр. Ә карчыга сунарчылар дәрте белән мавыкты, ахры. Атылып килә. Көчле канатларының аэродинамика куәтен тыя алыр микән ул? Бу бит коточкыч көч, һавага ничәмә тонналы самолетларны күтәрә. Икесенең берсе: йә хәзер ул җим тактасына бәрелеп коймак була, йә туптан аткан снаряд тизлеге белән тирән кар эченә чума. Бичара!

Әмма ул зур кыенлык белән булса да очу юнәлешен чүт кенә читкә юнәлтә алды. Ләкин бик аз. Тизлеген баса алмады, бар хутына очып, вак ботаклар баскан алмагач арасына килеп керде. Шарт-шорт итеп коры ботаклар сынды. Канатларын нык имгәтте, ахры, башын түбән игән хәлдә ботакта асылынып калды. Ул да булмады, шап иттереп кар өстенә килеп төште. Ята. Селкенми. Мин инде килмәкче, аны кардан күтәрмәкче, кулдан килгән ярдәмемне күрсәтмәкче идем. Әмма соңардым.

Шушыларның барысы артыннан тагын бер пар нәфселе күз бик игътибар белән күзәтеп торган икән. Монысы тәмлетамак ата песи — Наполеон. Мин ике адым ясаганчы, ул койма башыннан гына кар өстендә һушсыз яткан карчыга өстенә сикерде. «Прәс, шайтан!» — дип тә өлгерә алмадым. Карчыганы эләктереп, күршеләрнең утынлыгына сызды. Аннан аны, ачкүзне, кран белән дә өстерәп чыгара алмыйсың.

Ни генә әйтсәң дә, тере җан. Бик кызганыч булып китте миңа бу бичара карчыга. Мескенем. Ләкин бу очракта: «Башкаларга кое казыма, үзең чумып куймагаең», — дип әйтергә генә калды шул...

# ҖЫР ӨМӘСЕ ҮТКӘРИК ӘЛЕ!

2000 елдан башлап ел саен «Татар җыры» халыкара эстрада фестивале үткәрелә. Быел декабрьдә менә, шулай ук бик зурдан кубып, «Болгар» радиосы милли җыр бәйрәме үткәрде. Анда милли музыкаль премия лауреатлары сәхнә тотты.

Ләкин сокланып, чын-чыннан ләззәт кичереп ничә генә җыр тыңлый алабыз соң? Монда башкару, җырлау кимәле дә чагыла, әлбәттә. Ләкин төп сәбәп – җырларның сыйфаты. Җырчыларга һәм җырларны алар аша тамашачыга, тыңлаучыга сатучыларга шәп җырлар инде кирәкми дә башлады бугай.

Бу чир безгә мода рәвешендә Мәскәүдән йоккандыр. Ун еллап элек данлы Александра Пахмутованың радиодан әйткән сүзе хәтергә уелып калды. Болайрак диган иде ул: җырларны радио-телевидениегә, берәр музыкаль оешмага китерсәң, хәзер җавап гел бер була: бу безнең формат түгел.

Татар җыр сәнгате, борынгы заманнардан ук килгән милли үзенчәлеген онытып, башкаларның итәгенә (шул җөмләдән, пычрак итәккә дә) ябышып, ияреп кенә барырга, гел «хөршидә-мөршидәләнергә» тиеш микәнни соң инде?

Мина заманында Сара апа Садыйкова белән әңгәмә үткәрергә туры килде. Безгә хәзер аның шулчакта әйткән сүзләренә колак салу фарыздыр: «Теләсә нинди стильдә иҗат итсеннәр, әмма халык моныннан аерылмасыннар. Шунда гына җырың татлы була. Халык аһәңе көйгә ямь, төс бирә. «Кара урман», «Тәфтиләү», «Рәйхан»... – искитмәле көйләр. Без шул көйләрдән илһам алып, аларның баш хәрефләреннән башлап иҗат итәбез». Болай дип тә әйтте әле ул: «Соңгы вакытта һәрбер композитордан берәр кисәк ялгап көй язучылар бар. Болары инде – мир каракларь». «Композиторлар арасында тырышып көй ясап утыручылар да бар. Шуңа күрә көйләре күңелгә барып керә алмый. Гөл шыткан күк, көй күңелдә үзе шытып чыга ул.»

Бу сүзләрне Сара апа 35 ел алга карап та әйткән диярсең! Ләкин хәзер «бар» дигәнне «күп» дип яки «бик күп» дип укырга кирәктер инде.

Җырның сүз ягын тәэмин итүчене, шагыйрьне дә тыңлап карыйк әле. Гәптәшем – **Роберт Миңнуллин**. Аның сүзләренә язылган җырларны ярты гасыр тыңлыйбыз бугай инде.

— Йә, танылган «сүзче» ничек хис итә хәзер үзен, Роберт?

— Җыр сүзенең, җыр шигыренең тәме китте татар җырында. Җырларның бөтенесе дә сүзгә нигезләнә бит. Көй нинди генә моңлы, шәп булмасын, сүзләре пүчтәк икән, җыр барып чыкмый инде. Күп бит мондый җырлар. Шуңа күрә мин бик борчылып йөрим. Тагын бик тә борчылган нәрсә шул: җыр авторларына бернинди ихтирам юк. Хәзер «җыр хуҗасы» җырчы янындагы хезмәтче малай кебек кенә алар. Бусы – мораль ягы, матди яктан да шул ук хәл: «хезмәтче»гә тиеннәр генә тама инде.

Бер дә дәртләнеп, күңел үсеп кенә эшли торган түгел. Берзаман хәтта җыр авторларының исемнәрен әйтми башладылар: җырчыны игълан итәләр дә, бетте-китте. Аптырагач, бу эш өчен җаваплы кешеләргә болай дидем мин: «Алай җыр текстлары язучы кирәкмәгәч, җырчылар сүзсез генә җырласыннар инде. «Ләләлә, лә-лә-лә» дип кенә!..

Чыннан да гаҗәеп хәл бит бу. Космоска беренче кешене очырган чак искә төште. Юрий Гагарин әле дә ин данлы кешеләребезнең берсе. Батырлык бар монда, әлбәттә, әмма Гагарин урынында «Тагарин» да, «Шагарин» да – бик күпләр була ала иде бит. Ә менә космик караб конструкторының исем-фамилиясен (Сергей Королев) белүче юк диярлек.

Җырчылар, әлбәттә, «җыр карабында» утырып баручылар гына түгел. Алар – аны

халыкка житкерүчеләр. Ләкин булмаган җырны беркемгә дә тыңлата алмыйсың бит инде. Аннан, алар — бердәнберләр түгел. Татарның шәп җырларын гасырлар дәвамында кемнәр генә җырламаган әнә.

Роберт Миңнуллин белән мондый сүз башлавым тикмәгә түгел. Үземә бик-бик мөһим тоелган фикер килгән иде башыма: чын җыр бәйгесе үткәрергә кирәк. Әзер җырларны башкару түгел, аларны иҗат итү конкурсы. Көен дә, сүзен дә язып! Без хәзер суны тамырга сибәсе урында яфракка бөркибез ләбаса!

— Син дөрес уйлыйсың — диде Роберт. — Җыр конкурсы икән ул, иң алгы планда җыр булырга тиеш. Без исә җырчыларны пропагандалыйбыз, һәм — җырчы тирәсендә биеп йөргән шәрә ботлы кызларны. Шоу-бизнесның бик начар ягы шул: җыр өченче-дүртенче планда кала. «Татар җыры» да, милли музыкаль конкурс та — чиста корпоратив конкурслар алар. «Барс медиа» да, «Болгар радиосы» да үзләренең җырчыларын пропагандалады. Шул бер үк җырчылар диярлек бер конкурстан икенчесенә, икенчесеннән өченчесенә күчеп җырлый. Күпме еллар шулай инде. Монда җыр гаме юк. Минем сүзгә профессионал композиторлар язган җырлар күп менә. Резидә Ахиярова белән язганы гына да егермеләп. Тик беркемнең дә җырлыйсы килми. Чөнки аларны башкара белергә кирәк бит әле. Ә бу «тыр-тыр-тыр»ларны композиторлар яза алмый шул инде, мондыйларны еш кына җырчылар үзләре яки баянчылар яза. Сүзләрен дә шул сәхнә тирәсендә йөрүчеләр әтмәлли. Менә шундый хәзер безнең вәзгыять. Чыннан да, аны үзгәртергә кирәк. Җыр алга чыгарга тиеш.Чын җырлар күп иҗат ителергә тиеш. Һәм монда чыннан да җыр конкурсы ярдәм итә ала. Аны бик шәп итеп, зурлап үткәрергә кирәк...

Димәк, чын композиторларны, чын шагыйрьләрне хәзер җырдан читтә тоткан төп сәбәпләр ким дигәндә икәү булып чыга: Пахмутова әйткән «формат», ягъни «тыртыризм» модасы һәм — акча ягы. «Җырның кереме күпме?» дигән сорауга Р. Миңнуллинның җавабы тәп-төгәен булды: «Декларация тутырганда җырлардан килгән еллык гонорарымны ачыкладым мин — 3620сум 60 тиен. Радио-телевидениедән яңгырап торган, дискларга кергән, концертларда, фестивальләрдә җырланган ике йөзләп җырның әҗере шул инде!

— Мәскәүгә күпелы вагон билеты — бер билет алырга да җитми ләбаса бу!..

Димәк, ошбу иҗат бәйгесен җыр иҗатының абруен күтәрерлек әйбәт шау-шу куптарып һәм бик тә саллы призлар билгеләп үткәрергә кирәктер?

— Шулай, әйе.

Җыр конкурсы идеясен Татарстан Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе **Разил Вәлиев** тә күтәреп алды. Мәсьәләгә һич тә туры күзлегеннән генә карый торган кеше түгел бу: 1989 елда чыккан «Җырларыбыз» дигән җыентыкка ук шагыйрьнең 17 җыр тексты кергән инде.

— Чыннан да бик тә мөһим, бик тә кирәкле эш бу, — диде Разил. — Халкыбызга җырлау сәләте мул салынган, күрәсең. Җырчыларыбыз әллә кайлардан, һич көтмәгәндә пылт итеп килеп чыгалар. Бөтен Рәсәй халкын әсир иткән «Голос» телевизион конкурсында Татарстанда ук яшәп тә без бөтенләй белмәгән Динә Гарипова белән Эльмира Кәлимуллинаның җинеп чыгуын күр әнә! 12 ел элек Чаллыдан Будапештка китеп барган Регина Хөснуллина Венгрия күләмендәге җыр конкурсында уңыш казанды. Казан Мәдәният-сәнгать университеты студенты Лилиана Газизова «Гәрәбә йолдыз» дигән Латвия конкурсында һәм «Сәлам, Юрмала» дигән халыкара конкурста 2нче урыннарны алды... Әле янарак кына Татар Конгрессында Кытайда яшәгән Шәдия Шамил (Вәлиева) җырлаганны тыңлап ләззәт кичердем. Ул охшаш моннар — татар моңы белән Кытай моңын кушып гаҗәп матур итеп җырлый икән. Татар җырларын кытай телендә дә, уйгырча да, казакъ телендә дә башкара икән... Әйе, шәп тавышлы җырчыларыбыз бар безнең, яна шәп җырлар гына юк шул. Шуңа күрә мондый конкурс бик кирәк ул безгә.

Идеямне мәшһүр җырчыбыз **Салават** та хуплады.

— Бик ризамын мондый эшкә. Юкса бу өч ноталы җырлар белән тәмам тупикка кереп барабыз, — диде ул. — Ләкин ничек үткәрәсен ныгытып уйларга кирәк. Жюри бик шәп булырга тиеш.

Татарстан композиторлар берлеге рәисе **Рәшит Кәлимуллин** белән сүзне әнә шул «өч нота»дан башладым.

— Әйе, дөрес әйтә Салават, — диде Рәшит әфәнде. — Күп хәзер андый жырлар. Без яшь чакта эстрада жырлары юк диярлек иде. «Кайда эстрада? Даёшь эстраду!» дип шаулаулар истә әле. Эстрада бар ул хәзер, ләкин нинди генә жырлар чыкмый сәхнәгә!.. Нинди композиторларыбыз бар иде: Сәйдәшев, Мозаффаров, Яхин!..

Конкурс үткәрү әйбәт эш. Ләкин һәр әйбәт ниятне начарга әйләндереп була. Уйларга кирәк: конкурсны тулаем жыр буенча үткәрергәме, әллә аның бирәр төре буенчамы?! Үзешчәннәр дә катнашырга тиештер. «Мин яратам сине, Татарстан» жырын үзешчән композитор Роберт Андреев язган әнә, ләкин безгә хас жыр, матур татар жыры. Әнә шундый жырлар кирәк безгә... Мәкалә басылып чыккач, конкурс турында шәпләп бер фикер алышырга кирәк булыр әле.

**Илһам Шакиров** белән Камал театрында, «Татар моны»нын йомгаклау концерты башланыр алдыннан сөйләштем. Бер ун минутлар теге «мөхтәрәмнәр рәте»ндә анын күршесендә утырдым мин. Шундый-шундый эшкә фатихагызны бирәсезме, дип сорагач, бөек жырчыбыз: «Ул эшкә фатиха безгә тумыштан ук бирелгән, — диде. — Бу — бик олы эш, аны башкарып чыгуы да авыр булачак». Мин исә шул чакта Илһамыбызнын 34 яшьлек чагын күз алдыма китердем һәм... әкрен генә итеп жырлап жибәрдем:

*Шаулый диңгез, җил өрәдер...*

Мина акаеп карар инде дигән Илһам абый жырны үзе дәвам итте:

*Җилкәнен киргән караб.*
*Төн вә көндез ул йөрәдер,*
*Юл бара ят ил карап.*

1969 елны булды бу. Дөрестерме, юктырмы, мин, гади бер тамашачы, шулай дип хәтерләп калганмын: анарчы коцертларда жырчылар сәхнәдә гел бер-берсен алыштырып торса, Илһам Шакиров, татар жырчыларыннан беренче булып, үз концертын куйды. Һәм кайда диген әле: Казандагы Боз сараенда! Башыннан ахырынача сокланып, ләззәт кичереп тыңладым. Беренче тапкыр янгыраган өч жыр исә тетрәндерде дә. Бу — «Бик еракта идек без», «Әдрән дингез» һәм Дәрдемәнд шигыренә халык чыгарган(?) шул «Караб» иде... Залның котырыплар кул чабуын күрсәгез иде! Татар жыр сәнгатенен ин сөенечле сәгатьләре булмады микән бу!

Мин — үсмер чактан башлап армиягәчә, татар жырларына һич исем китмичә «Катюша»ларны дәртләнеп жырлап йөргән кеше. (Их, мәктәптә жыр дәресләрендә хәзер балалар күңеленә татар жырына мәхәббәт вә татар моны салынсын иде!) Шундый берәүнен ошбу татар концертына килүе ничек булды сон?

Армиядә башланды бу юл. Казармада радио бар иде. Шуннан агыла башлаган сүзсез музыка кинәт күнелне әллә нишләтепләр жибәрде. Сихерләнгән кебек акрын гына радиога таба атлыйм. Күнелем исә рәхәт бер елау белән елый. Соныннан аңладым: татар монын тоеп, күнелем түреннән үзем элек томалап яткырган татар рухы шулай бәреп чыккан инде ул!.. Ничәдер көннән, казарма янындарак жыелышып жырлап торган татар егетләрен күргәч, жырга мин дә килеп кушылдым. Шунда беренче кат тойдым: ай, рәхәт икән бит ул үз жырларыбызны жырлау!

Ошбу четерекле заманда татар халкына асыл жырлар сихәтле дару кебек кирәктер ул. Ә менә төрле шаукымнарга бирелеп язылган, миллилекнең әсәре дә булмаган шырдый-бырдый жырлар зәвыкны бозу гына түгел, татар кешесе күнелендәге милли иммунитетка да зыян саладыр әле. Ягъни агу кебегрәк тә буладыр. Жырдагы бу тугарылганлык әхлакый тугарылганлыкны да сендерә башлады бугай инде. «Акчарлак» гәжите «Бирмим мин сина» дип жырлаучы Аиша» белән әңгәмә бастырган әнә (2013, 6 июнь). Әңгәмәнен азагында бу жырчы «Кил, кил, ал мине» — дигән жыр әзерләп ятам», — дигән. Шундый жырлар тыңлап үскән яшь милләттәшләребездән киләчәктә ни көтмәк кирәк, йә!

Бер музыка әһеле мина болай дип әйтте: Менә син жырга кагылышлы

безобразиеләрне бетермәкче инде. Ул конкурсны үткәртерләр дисеңме?! Ә син нинди «гаскәр»гә каршы торганыңны беләсеңме соң? Аларга кесә тулы акча кирәк, синең яхшы җырларың түгел. Халыкның шул «музыкаль тәрбия»гә бирелеп хайванлаша баруы да шәп кенә аларга...

Бәлкем, бардыр андый «гаскәр». Ләкин мин күп көчлерәк «гаскәр» дә барын беләм. «Татар моңы» фестивален гамәлгә керткән, аны шәбәйткәннән шәбәйтә барган «гаскәр» бу. Татарстан хакимияте, «Татар конгрессы» һәм дә Салаватның актив катнашы белән үткәрелә торган әлеге халыкара телевизион фестиваль җыр сәнгатен нәкъ менә шул татар моңы, чын татар җыры ягына борып ята. Өстәвенә, яшьләрдән «җырчылар армиясе» дә үстерә әле.

Бу бик тә игелекле, гаҗәеп олы эш асылда күпләр инде «бүтән формат», искергән, үтми торган товар дип чүплеккә ташларга теләгән халык җырлары һәм җыр сәнгатебез көчле чагындагы җырлар белән гамәлгә ашырыла. Димәк, хәзинәдә бары белән. Уйланылган конкурс, ягъни яңа асыл җырлар иҗат итү, шушы олы эшнең дә кыйммәтле бер өлеше була алыр иде. Аннан, чын җыр иҗаты өзелеп калырга тиеш түгел бит инде!

Кая чәчелде-сибелде соң ул мондый җырларны яза алырлык композиторларыбыз, «сүзче»ләребез? Аларның һәркайсын кадерләп, игътибар түрендә йөртәсе иде кана!

Кайчан икәнен хәтерләмим дә инде, мине Наил Касыймов дигән егет эзләп тапты. Мин бөтенләй белмәгән кеше. Җыр сүзләре яза башламакчы икән. Бу хакта нигәдер нәкъ менә минем белән киңәшәсе иткән. Әлеге «лирик ният» турында кабинетта сөйләшмәдек инде, Казансу буенда, сандугачлар җырын тыңлый-тыңлый гәп кордык без. Без дип, ул гына сөйләде инде, бөтен хыялларын ачып салды миңа. Мин исә «Шәп!», «Шулай ит!», «Ныгытып тотын!» кебек сүзләр генә кыстыргалап бардым. Хәзер Наил Касыймов җырларын («Су буенда учак яна», «Туй күлмәге» һ.б.) белмәгән кеше аздыр. Ләкин ул да җырдан читләште менә...

Элекке кайбер «текстчылар» белән чагыштырсаң, Наил кебекләр кечерәебрәк кала. Әхмәт Ерикәй җырга инде 33 яшендә килгән, анарчы юньләп шигырь дә язмаган кеше. 300ләп сүзенә көй язылган, 1967 елны дөнья куйган Әхмәт агайның «Җәйнең аяз матур таңнарында», «Сиреньнәр хуш исләр тарата», «Әгәр син булмасаң янымда», «Эзләдем, бәгърем, сине» кебек 15-20ләп җыры бүген дә «сафта» әле...

Әтиле-кызлы композиторларыбыз (Әхмәт һәм Луиза Хәйретдиновлар), ирлехатынлы «җыр бригадабыз» (композитор Зиннур Гыйбадуллин һәм шагыйрә Гөлшат Зәйнашева) да бар иде әле безнең...

Мин бу мәкаләне фикер кузгатучы буларак кына язам. Белгечләр дә, җырчылар да, җыр сөючеләр дә үз фикерләрен, тәкъдимнәрен җибәрсеннәр иде безгә.

Мәдәният министрлыгына коры идея итеп кенә түгел, бу тәкъдимгә битараф калмаган кешеләрнең тәгаен пунктлардан торган күмәк план проекты рәвешендәрәк тапшырырга иде моны. Төрле якларын уйлап бетереп. Әйтик, исеме нинди булырга тиеш икән конкурсның? Бәлкем, «Асыл җыр» дип атарбыз? Сүз авторы белән көй авторларын ничек кавыштырырга? Җыр текстларын жюрига җибәреп, үтә алганнары Интернетта махсус сайтка куелып, көйчеләр шуннан сайлап алса? Күпме вакыт барырга тиеш ошбу конкурс? Менә шундый күп-күп сораулар туачак әле монда.

Үткәрик әле без татар җырына гына түгел, татарның үз язмышына да тәэсир итәчәк бу матур өмәне, җәмәгать!

**Рәфикъ ЮНЫС.**

**Редакциядән.**

*Олпат каләмдәшебезнең бу чакыруы аның җан авазына бәрабәр. Мәдәният елы шагыйрьләр һәм композиторларыбызны янә дә йокыдан уятып җибәрсен иде дә, чын милли журналыбызга җыр мәйданындагы сөенечле үзгәрешләр турында язарга насыйп булсын иде.*

***

Татарстан язучылар берлеге рәисенә
Фирдүс Нурислам улы Фәтхелисламовтан

Гариза

Мине Татарстан язучылар берлегенә кабул итүегезне сорыйм.

*02.02.2009 ел.*

«Татарстан язучылар берлегенә килгәндә, аны житди рәвештә телгә дә алып булмый...»

*Ф.Н.Фәтхелисламов (Россия стратегик тикшеренүләр институтының Идел буе үзәге житәкчесе). «Шәһри Казан». 6 декабрь, 2013 ел.*

***

С 2004 года Государственная премия Российский Федерации... стала в некоторой степени похожа на Нобелевскую премию. ...ведь эта высшая награда страны явилась в Татарстан только через 49 лет после Ленинской премии Мусы Джалиля.

*Ренат Харис*
*«Талант» (журнал) «Не верю в муки творчества... № 5, 2012 ел. 29 бит.*

***

Без бүген... Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Р.Төхфәтуллин (Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре – ред.) исемендәге премия лауреаты... Клара Булатова исемендәге премияне тапшыру тантанасына жыелдык.

*«Яңа жырлар шавы». (Коллектив жыентык). 3 бит. Казан. 2013 ел.*

***

«Мин чыксам (кияүгә – ред.) французга гына чыгачакмын. Татар егетләренә минем белән авыр булачак...»

*Йолдыз Миннуллина*
*«Минем шигърият мине «бесит». «Шәһри Казан». 10 сентябрь, 2011 ел.*

***

«Яшь чагымда мин болай ук матур түгел идем. Хәзер көзгегә карыйм да, карале, Венера, син матур икән бит, дим!».

*Венера Ганиева (жырчы). «Шәһри Казан». 12 июль, 2011 ел.*

## «ТАТМЕДИА»ДА КАДРЛАР ҮЗГӘРЕШЕ

«Татмедиа» ААҖдә, басма һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика Агентлыгы җитәкчесе Ирек Миннәхмәтов һәм «Татмедиа» ААҖнең генераль директоры Фәрит Шаһиәхмәтов катнашында, кадрлар үзгәрешенә багышланган киңәшмә булып узды.

Киңәшмәдә түбәндәге филиалларның директорларын — ММЧ баш мөхәррирләрен алыштыру турында игълан ителде:

«Казан утлары» журналына, Равил Фәйзуллин урынына — Илфак Ибраһимов; «Мәгариф» журналына, Габделхак Шәмсетдинов урынына — Илдар Миргалимов; Intertat.ru электрон газетасына, Булат Сруров урынына — Илназ Фазуллин; «Гаилә һәм мәктәп» журналына — Гөлүсә Закирова билгеләнде. «Чын Мирас» журналында Рамил Ханнанов мөхәррирлек вазифасын вакытлыча башкарып торачак.

Киңәшмә барышында билгеләп үтелгәнчә, Равил Фәйзуллин «Татмедиа» ААҖ генераль директорының киңәшчесе итеп билгеләнде.

«Татмедиа» ААҖнең республика районнарындагы филиаллары җитәкчеләре составында да үзгәрешләр булды. Аерым алганда, «Кайбыч таңнары» газетасына, Фәридә Нигъмәтҗанова урынына Луиза Сөнгатуллина; «Мөслим мәгълүмат-редакция үзәге»нә, Мөдамил Әхмәтов урынына — Рөстәм Зәкиев; «Әлмәт РТВ» телерадиокомпаниясенә, Гөлнара Миңнеханова урынына — Наилә Әл-Әйюби билгеләнгән.

## АВЫЛ ТОРМЫШЫ — ПРОЗАДА

Татарстан Язучылар берлегенең Тукай клубында авыл тормышын яктырткан проза әсәрләре конкурсын йомгаклау тантанасы булды. Бәйрәмдә Татарстан Премьер-министры урынбасары, ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов катнашты.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбан: «Моннан бер ел да ике ай элек Президентыбызның ярдәме белән без бу бинага күчкәч, иң беренче булып Марат Готыф улы белән очраштык. Марат әфәнде игенчеләрне генә түгел, язучыларны да эш белән тәэмин итәргә булды. Сөйләшү нәтиҗәсендә авыл тормышын яктырткан проза әсәрләренә конкурс игълан иттек», — диде.

Шушы вакыт аралыгында шактый күп әсәрләр иҗат ителде, шулардан сигез роман, егерме алты повесть, утыз дүрт хикәя конкурста катнашты. Кичәдә җиңүчеләр игълан ителде. Төрле номинацияләрдә түбәндәге язучылар җиңүче дип табылды: Зиннур Хөснияр, Нурислам Хәсәнов, Сәгыйдулла Хафизов, Вахит Имамов, Хәбир Ибраһимов, Айгөл Әхмәтгалиева, Габит Фәрхетдинов, Кәрим Кара, Рифә Рахман, Рәдиф Сәгъди. Марат Әхмәтов язучыларга үз куллары белән бүләкләр тапшырды: «Авылның нечкә каршылыклары белән тирән фәлсәфәсен ачар өчен, җаныгызны-тәнегезне биреп иҗат иткәнегез өчен рәхмәтлемен», — диде ул.

Кичә барышында һәр жанрда җиңүче әсәрләрдән өзекләрне Татарстанның халык артистлары Дания Нурлы һәм Әсхәт Хисмәт укыды. Татарстанның халык артистлары Мирсәет Сөнгатуллин, Асаф Вәлиев, Кирам Сатиев һ.б. халык җырларын башкардылар.

## ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАРЫ БӘЙРӘМЕ

20 ноябрьдә Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге оештырылуга 50 ел тулу республика күләмендә зур юбилей буларак билгеләп үтелде. Әлеге үзенчәлекле бәйрәмнең төбәктә күпләп нефть чыгара башлауның — 70, Әлмәт шәһәренең 60 еллыгына туры килүе тирән символик мәгънәгә ия.

Бәйрәм чараларында катнашу өчен Казаннан Татарстан Язучылар берлеге рәисе Р.Корбан, шулай ук танылган каләм әһелләре Р.Фәйзуллин, Г.Рәхим, М.Галиев, З.Мансуров, М.Мирза, Ә.Гаффар, Д.Салихов, Н.Ахунова, Г.Каюмов, Чаллыдан язучылар оешмасы җитәкчесе В.Имамов, Әлмәт бүлегенә караган төбәкләрдән Ф.Садриев, М.Әхмәтҗанов, Р.Хәбибуллина, Ә.Дусайлы (Мөслим), Р.Габделхакова, Т.Шәмсуаров (Лениногорски), Д.Гарифуллин (Сарман), И.Гыйләҗев, Ф.Исмәгыйлева, Р.Шәрипова, М.Гариф (Азнакай) һ.б. районнар вәкилләре килгән иде.

Әдәбият бәйрәмендә катнашучылар иң әүвәл Ленин урамындагы 24нче йорт алдында җыелды. Биредә Әлмәт язучылар оешмасын аякка бастыруда зур көч куйган ирле-хатынлы шагыйрьләр Ә.Маликов һәм

С.Сөләйманова, шулай ук язучы, «Татнефть» ААЖ генераль директоры урынбасары Ү.Саттаров яшәгән. Бу көнне алар турында мәгълүматлар язылган истәлек такталары ачылды.

Юбилейга багышланган төп тантана Әлмәт Татар дәүләт драма театры бинасында үткәрелде. ТР Язучылар берлеге рәисе Р.Корбан төбәктәге иҗат көчләрен ярты гасыр дәвамында бергә туплап яшәгән бүлекне Татарстан Дәүләт Советы, Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлеге исеменнән котлады, иң лаеклыларга Рәхмәт хатлары, истәлек билгеләре һәм бүләкләр тапшырды. Тәбрикләү сүзләрен шулай ук Әлмәт районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары В.Самойлов, «Татнефть» ААЖ профсоюз комитеты рәисе Г.Яруллин ирештерде. Бәйрәмгә алар да бүләксез килмәгән иде. Әлмәт язучылар оешмасын төрле елларда җитәкләгән Р.Фәйзуллин, Ә.Гаффар, Н.Әхмәдиев, Д.Салихов, З.Дәүләтовка һәм бүлекнең бүгенге җитәкчесе И.Нәбиуллинага Әлмәт шәһәренең 60 еллыгы уңаеннан эшләнгән медальләр тапшырылды. Юбилей кичәсендә күп еллар шушы калада иҗат итүче күренекле шагыйрә К.Булатова, өлкән язучы А.Хәсәновның да игелекле хезмәтләре зур хөрмәт белән бәяләп үтелде, шулай ук Ә.Сәлах, М.Әхмәтшина, Ә.Хәбибуллин, төрле районнарда яшәүче башка каләм әһелләренең эшчәнлекләре дә аерым билгеләүгә лаек булды.

Тантаналы кичәнең бер сәхифәсе хаклы рәвештә Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллинга багышланды. 1968-72 елларда ул язучыларның Әлмәт бүлеген җитәкләгән. Әлмәт районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары В.Самойлов аны хакимият башлыгы исеменнән 70 яшьлек юбилее уңаеннан ихлас тәбрик итте, истәлекле бүләкләр тапшырды.

## ГАЛИМНӘР ҺӘМ ШАГЫЙРЬЛӘР БЕРЛӘШТЕ

Татарстанда гадәти булмаган әдәби-математика форумы узды. Әлеге форум башкалада инде 3 нче тапкыр үткәрелде. Н.Лобачевский исемендәге III Халыкара поэзия фестивалендә 25ләп шагыйрь катнашты. Әлеге проектның оригинальлеге шунда — ул шагыйрьләр белән галимнәрне берләштерә. Конференция чараларында актив катнашучылар арасында Германиядән, Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан, Чаллы һәм Оренбург вәкилләре бар иде. «Влияние неевклидовой геометрии на художественное сознание» темасына багышланган конференциядә катнашучылар гадәти булмаган тема буенча фикер алыштылар.

## ЧҮПРӘЛЕДӘ ОЧРАШУЛАР

Татарстан Язучылар берлеге республикабыз төбәкләрендә даими рәвештә «Татар әдәбияты көннәре» үткәреп килә. Күптән түгел генә Арча, Әлки районнарында да шундый тантаналы чаралар булган иде. Узган атнада ТР Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбан җитәкчелегендәге бертөркем каләм әһелләре Чүпрәле районына сәфәр кылды.

Татарстанның көньяк-көнбатыш чигендә урнашкан районга әдипләр иртән үк барып җитте. Чүпрәле районы вәкилләре аларны ипи-тоз һәм чәкчәк белән каршы алды.

Казаннан килгән кунаклар дүрт төркемгә бүленеп, районның дүрт авылына таба юл тотты. Рафис Корбан белән Марат Әмирханов Кече Чынлы урта мәктәбендә очрашу үткәрде. Зиннур Мансуров, Рәмис Аймәт һәм Фәйрүзә Мөслимова Шланга мәдәният йортында җирле халыкка иҗат бәйрәме бүләк итте. Фоат Галимуллин белән Камил Сәгъдәтшин Иске Кәкерлегә китте. Марсель Галиев, Нәбирә Гыйматдинова һәм Рифат Сәлах Иске Шәйморза урта мәктәбендә укучылар белән очрашты.

## ИСКӘ АЛУ

Язучылар клубында Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Марс Шабаевның тууына 80 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә үтте. Кичәне Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбан ачты, М.Шабаевның шигъри иҗатына, тәрҗемәчелек хезмәтенә югары бәя бирде. Чыгыш ясаучылар — «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, Татарстан китап нәшрияты баш мөхәррире Ленар Шәех, халык язучысы Марсель Галиев, җырчы һәм композитор Мәсгут Имашев, хатыны Роза ханым Шабаева әдип турында истәлекләр сөйләделәр, шагыйрь һәм шәхес буларак хәтердә яңарттылар. Артистлар шагыйрьнең шигырьләрен укыдылар, аның сүзләренә язылган җырларны башкардылар.

Марс Шабаев озак еллар безнең «Казан утлары» журналында эшләде, яхшы редактор булды, язучыларның яшь буынын үстерүгә зур көч куйды. Юбилей уңаеннан Татарстан китап нәшрияты шагыйрьнең «Йөрәк хәтере» дип исемләнгән яңа китабын бастырып чыгарды.

## МИЛЛИ МУЗЕЙДА ШАГЫЙРӘНЕ ОЛЫЛАУ

Татарстан Милли музееның әдәби салонында танылган шагыйрә, Һ.Такташ исемендәге әдәби бүләк иясе Салисә Гәрәевага багышланган кичә уздырылды. Шагыйрәнең гомер бәйрәме уңаеннан үткән бу кичәгә аның якын дуслары, каләмдәшләре җыелган иде.

Әдәби салон кунаклары иң әүвәл Салисә Гәрәеваның иҗат һәм тормыш мизгелләрен чагылдырган фотолар һәм

газеталардан, китапларыннан төзелгән күргәзмә белән танышты. Чыгышларда исә юбилярның иҗаты, журналистлык һәм иҗтимагый эшчәнлеге турында җылы сүзләр әйтелде. Шагыйрәне ТР Язучылар берлеге исеменнән Рафис Корбан котлады. Шагыйрәләр Эльмира Шәрифуллина, Шәмсия Җиһангирова һәм Йолдыз Шәрәпова Салисә Гәрәеванын иҗаты, Чиләбе төбәгендәге журналистлык эшчәнлегенә, анда яшәгәндә милләттәшләребезне берләштерүдәге эшенә тукталса, шагыйрь Зиннур Мансуров «Мәдәни җомга» газетасына бергәләп нигез салып, шунда хезмәт куйган елларны искә алды.

Әлбәттә, шагыйрәнең иҗаты фәнни яктан өйрәнелергә дә бик лаек. Кичәдә күренекле галим Нурмөхәммәт Хисамов Салисә Гәрәеваның иҗатына тәфсилле анализ ясады, шигырьләренең үзенчәлеге турында сөйләде. Тарихчы галим Альберт Борһанов исә шагыйрәгә Чиләбе якташлар җәмгыяте котлавын алып килгән иде. Җырчылар Рөстәм Маликов, Искәндәр Биктаһиров, Флүрә Ялалова, виолончельдә уйнау остасы Лариса Маслова шагыйрәгә музыкаль бүләкләрен ирештерде.

### ДӨНЬЯДА УНЫНЧЫ БУЛУ ДА МӘРТӘБӘ

«Sportcal» порталы зур спортта абруйлы саналган илләр һәм шәһәрләр исемлеген игълан итте. Исемлектә Татарстан башкаласы 10нчы урынны алган. Россия — икенче баскычта, ә беренче урында — Кытай. Исемлек илдә яки шәһәрдә узган яки узачак зур спорт чаралары саны һәм аларның төбәк үсешенә нинди йогынты ясавына карап төзелгән. Казанның 10нчы урынны алуында узып киткән Универсиада һәм алдагы 4 елга планлаштырылган чаралар: бадминтон буенча Европа беренчелеге (2014), Фехтование буенча дөнья чемпионаты (2014), су спорты төрләре буенча дөнья чемпионаты (2015), футбол Конфедерациясе кубогы (2017) һәм футбол буенча дөнья чемпионаты матчлары (2018) хәлиткеч роль уйнаган.

### «ШУРА»НЫҢ ӨЧЕНЧЕ САНЫ ЧЫКТЫ

«Хузур» нәшрият йорты нәшер итә торган «Шура» журналының өченче саны дөнья күрде. Ул Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин мөхәррирлегендә Татарстан имамнары өчен кварталга бер тапкыр татар телендә чыгарыла.

Бу сан 248 битле, Мәүлид бәйрәменә багышланган. Басмада Мәүлид бәйрәменә, Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.)гә багышланган шактый язмалар бирелгән. Моннан тыш, динебезгә кагылышлы күп темаларны колачлаган басманың өченче санында да, алдагыларда гы кебек, имамнар өчен киләсе өч айда һәр җомгада сөйләр өчен вәгазьләр урнаштырылган.

«Хәнәфи мәзһәбенең дәлилләре», «Динебез — Ислам дине», «Дин гыйлеме», «Фән», «Әңгәмә», «Публицистика», «Сорау-җавап», «Мирасыбыз», «Догалар» дигән рубрикалардан тыш, яңа сәхифә — «Әдәбият» тәкъдим ителә. Мирасыбызның бер сәхифәсе буларак, «Шура»ның 1916 елгы 1 гыйнвар санында чыккан иске татар имлясындагы мәкалә белән дә танышырга мөмкин.

«Шура» 2000 данә тираж белән басылган.

### КАЛӘМДӘШЛӘРЕБЕЗНЕ КОТЛЫЙБЫЗ!

«Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыяте «Татарстан — Яңа Гасыр» каналы белән берлектә дүртенче ел рәттән, Татарстанның милли сәясәт программасын тормышка ашыру ниятеннән чыгып, татар телендә кыска метражлы телевизион фильмнар сценариесенә бәйге уздырып килә. 24 декабрьдә «Татмедиа»ның конференц залында 2013 елның җиңүчеләрен котлау тантанасы булып үтте. Республика матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр җитәкчесе урынбасары Нурия Беломоина җитәкчелегендәге жюри җиңүчеләргә премияләр тапшырды. Бәйге нәтиҗәләре буенча **Илгиз Зәйниев** һәм **Айгөл Әхмәтгалиева** — икенче урынга, **Рөстәм Галиуллин, Мансур Гыйләҗев** һәм **Лира Ибраһимова** — өченче урынга, **Фәйзелхак Вилданов** һәм **Сәмига Бәдретдинова** махсус призга лаек булдылар. Жюри әгъзалары сүзләренә караганда, бәйге алдагы елларда да уздырылачак.

### *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Кыш».

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрь **Равил Фәйзуллин** портреты. *Рәссам Э. Зарипов эше.*

## Яңа китаплар




Милләтләр язган китап. — Төзүчесе һәм кереш сүз авторы Айдар Хәлим. — Чаллы. «Диамант» нәшр., 2013. — 600 б. Тиражы 300 данә.

Китап А.Хәлим алган хатлар тупламыннан гыйбарәт. Бу хатларны язучылар арасында кемнәр генә юк. Мостай Кәрим (язылу вакыты буенча санала), Гәүһәр Камалова, Сибгат Хәким, Рафаэль Мостафин, Айрат Арсланов, Әбрар Кәримуллин, Мөхәммәт Мәһдиев, Әмирхан Еники, Нажар Нәжми, Фәнис Яруллин, Миргазиян Юныс, Минтимер Шәймиев...


Хат авторлары арасында инглизләр дә, американнар, молдованнар, якутлар, чеченнар, венгрлар да... — нинди генә милләт вәкилләре юк.

Бу «хатлы китап»та безнең заман, иҗат гаме, дөнья гаме, шул җөмләдән, татар гаме дә чагыла.




**Рәфикъ Юныс.** Татар гаме. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. — 496 б. Тиражы 2000 данә.

Кереш сүзне язган Разил Вәлиев болай дигән: «Бу китаптагы публицистик язмалар, әңгәмәләр белән шигъри әсәрләрнең аралашып баруы авторның фикерләү рәвешен тагын да ачыграк күзалларга ярдәм итә. Китапны тулысынча укып чыккач, ул аерым-аерым әсәрләрдән торган мәҗмуга түгел, ә бербөтен зур әсәр, заманыбызның шагыйрь йөрәге аша үткән елъязма-хроникасы булып күз алдына килә».



Равил Фәйзуллин

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)